# Казан утлары



8

АВГУСТ

1967

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК АЛТЫНЧЫ ЕЛ ЧЫГА

8

АВГУСТ
1967


## Бу санда:


ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯЛӘР, ШИГЫРЬЛӘР

Г. Минский. Мылтыклы кеше. Хикәя . . . . . 3
Ә. Еники. Мәчет җылый. Хикәя . . . . . . . 19
Х. Камалов. Күңелдәге язулар. Эскизлар . . . 28
Г. Бәширов. Туган ягым—яшел бишек. Повесть. 38
С. Сөләйманова. Балкыды да сүнде; Бу диңгезгә төшеп югалмыйсың; Таулар кичтем; Мәхәббәт фонтаны. Шигырьләр. . . . . . . 70

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Ф. Шәфигуллин. Эшче горурлыгы; Унҗидедә; Туып-үскән нигез ташларына; Сиксән яшьлек Тукай; Алтын эзләүчеләр. Шигырьләр. . . . 72

СССР ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ IV СЪЕЗДЫ

Делегатлар сөйли. . . . . . . . . . . . . 75

СОВЕТ ВЛАСТЕНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

Татар мәдәниятының көндәлек дәфтәреннән. . . 79
Х. Хәйруллин. Алмаз ихтыяр. Очерк. . . . . 84

ГАРИФ ГОБӘЙГӘ 60 ЯШЬ

Ф. Ибраһимова. Кайгыртучан дус. . . . . . 97

БЕЗНЕ ОКТЯБРЬ ҮСТЕРДЕ

Ю. Бейлькин. Скрипка моңнары. . . . . . . 102

ӘДӘБИЯТ ТЕОРИЯСЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Г. Халит. Романтизмны һәм реализмны яклап. . 105

ЯЗУЧЫНЫҢ ИҖАТ ПОРТРЕТЫ

С. Сафуанов. Бакчачы турында хикәя. . . . . 117

СӘНГАТЬ

Ф. Вәлиев. Чуптарлы һәм асалы тукымалар. . 127

ЯЗУЧЫ ТРИБУНАСЫ

Р. Батуллин. Бүген концерт була. . . . . . . 131



КПССның
ТАТАРСТАН ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ТӨРЛЕСЕННӘН

Г. Саттаров. Казан урамнарының исемнәре. . 138

ФИКЕР АЛЫШАБЫЗ, БӘХӘСЛӘШӘБЕЗ

М. Маликова. Кем ул Әнис Бадигин! . . . . 144

ЧИТ ИЛ ЯЗУЧЫЛАРЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТУРЫНДА

Ш. Вуап-Мокану. Җәлил Румыниядә . . . 147

САТИРА ҺӘМ ЮМОР

Ш. Галиев. Юаттылар...; Бари; Шигырьчегә; Дөнья — куласа...; Чамала; Чират күпере. Шигырьләр. . . . . . . . . . . . . . 148

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Х. Гобәйдуллин. Халык артисты. . . . . 149
Ф. Шәрәфиев. Сәнгатькә багышланган гомер. 150

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 152

Журналга язылыгыз. . . . . . . . . . . . 158

*Редакциягә килгән кулъязмалар кире кайтарылмый*

---

Редакциянең адресы. *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Габдрахман Минский

# МЫЛТЫКЛЫ КЕШЕ

*Хикәя*

Көн саен, бер үк вакытта — сәгать тугыз тулып, Мәскәү радиосы «Правда» газетасына күзәтү башлауга — профессор Хәмитев квартирасы ишегендәге ящикка почтальон газеталар төшереп китә. Кыштырдап газеталар төшүен башкалар ишетмәгәндә дә, Зариф тиз ишетә. Шулхәтле гадәтләнгән ул моңа, хәтта язу өстәле артында эшкә бирелеп утыруына да карамастан, минутында тотып ала бу кыштырдауны. Күңелле бер вакыйгага әйләнеп киткән почта килү сәгатен профессор түземсез кызыксыну белән каршылый.

Бүген исә Зариф почтаны аеруча сабырсызланып көтте. Тик ул үз хәлен Гөлсемгә сиздермәскә тырышты. Иртәнге чәйне дә көндәгечә абыл-кобыл эчеп өстәл яныннан торып китәргә ашыкмады, киресенчә, өченче стакан чәй ясаткач, эчмәсә дә, хатыны белән сөйләшеп утырган булды. Гөлсемгә дә бу иртәдә ирен тыңлап утыру кызык иде. Тыңлый торгач, елмаеп кына калмады ул, ә каршындагы төш сөйләүчедән көлгән төсле итеп болай диде:

— Сине тыңласаң, Зариф, көлмәс жиреннән көләрсең. Кара аны, «төшкә ышанучы профессор» дип фельетон язып куймасыннар үзең турында.

— Ышанам дигән кеше юк бит әле сиңа! — Хатынының кисәтүенә беркадәр хафалана төшеп әйтте моны Зариф.— Син, Гөлсем, бик тиз генә алай бәхәссез йомгак ясарга ашыкма! Төш күрү сере шушы заманга хәтле фән өчен ачылып житмәгән әле. Моны Павлов үзе дә инкарь итми.

Гөлсем кызыксынып сорады:

— Нәрсәгә юрадың төшеңне?

— Көтелмәгән хәбәр булырга тиеш.

— Ни өчен «көтелмәгән»?

— Үзе кызу җәй көне икән дә үзе ак кар ява икән.

— Ни өчен ак кар?..

— Син нәкъ бала төсле! «Ни өчен?» дә «Ни өчен?»

Әмма Зариф ни өчен икәнен аңлатырга өлгерә алмады. Пианино өстендәге сәгать, музыкаль тавышлар чыгарып, тугызны суга башлады. Зарифның сүзе бүленде, утырган жиреннән ничек торуын да белми калды, ишеккә барды, ачты һәм гомерендә беренче гаҗәпләнгән сыман кашларын күтәрде.

Почта ящигы буш иде.

Кухня ягыннан Гөлсем тавышы ишетелде:

— Я, нәрсә?! Бармы?

— Гаҗәп! — диде Зариф, әле дә булса мондый көтелмәгән хәл белән килешә алмыйча.— Юк, берни юк! Бөтенләй почтасы килмәгән.

— Төшең бик рас килгән икән алайса,— диде Гөлсем, көлгәндәй итеп.

Каян әйттем бу хатынга! Хәзер инде минә күзенне ачырмас. Зарифның борчулы уйларын телефон шалтыравы таратып җибәрде.

Телефонның аргы очында министр урынбасары Камил Мөбарәкев иде.

— Зарифулла, ишеттеңме, яңа хәбәр? — дип башлады ул сүзне.

— Яңа хәбәр?!

— Чү, син бик очып төшмә! — Зарифның бик кызыксынуын Камил аның тавышыннан ук шәйләде.— Бу хәбәр синең физикаңа бөтенләй кагылмый. Сәнгать турында бу, брат, сәнгать, театр сәнгате турында.

— Чыннан да, миңа ни катнашы бар соң аның?! — дип гаҗәпләнде Зариф.

— Бар шул! Артыгы белән! — диде Камил.

— Аңламыйм...

— Аңламыйсың шул. Радио тыңламадыңмыни?!

— Бүген тыңлый алмадым шул. Нинди хәбәр?

— Син Рәхимне онытмагансыңдыр бит? Кайсы дип, шул бер Рәхим инде. Унтугызынчы елларда безнең ячейкада бер «мылтыклы кеше» бар иде бит әле...

Ерактагы елларның онытыла язган кешесен хәтерләүгә, Зариф кычкырып җибәрде:

— А!.. Рәхим!.. «Инкыйлаб дулкыннары»ндагы явыз бай?!

— Менә шул «явыз баебыз» — бүген халык артисты!

Көтелмәгән бу хәбәрдән Зариф, берьюлы гына берни аңлый алмады. Камил, моны аның ык-мык итүеннән абайлап, тулырак аңлатты:

— Әле генә радиодан тапшырдылар. Татар артисты Рәхим Солтанморатовка Совет театрын төзүдә күрсәткән хезмәтләре өчен СССР халык артисты исемен бирү турында Указ чыгарылган.

Зариф, бердән кабынган куанычын баса алмыйча, кухня ягына кычкырды:

— Гөлсем, әйттем мин сиңа!

— Нәрсәне әйттең?! — дип сорады Камил.

— Юк, сиңа түгел. Гөлсем белән бәхәс булып алган иде.

— Бәхәс?!

— Әйе. Төшкә ышану-ышанмау турында.— Трубкада Камилнең көлүе ишетелде.

— Физик булсаң да, чудаграк шул син.

Мондый шатлыклы хәбәр уңаеннан ике дус якташлары Рәхим Солтанморатовка котлау телеграммасы сугарга булдылар. Ничек һәм кем язу турында ике арада «Син яз!» да «Мин яз!» дәгъвасы куба торгач, анысы да табылды. Бу шәһәрдә якташларның тагы берсе — язучы Усман Галиев яши иде. Аңа тапшырырга булдылар. Чөнки бу эш, Камил аңлатканча, язучы кеше кулыннан гына килерлек эш икән, мәсьәлә бер Рәхимдә генә түгел, ә аның кебек Октябрь таңында туып, бүген исә халыкның данлы уллары, кызлары булып үсүчеләр турында икән...

— Соң үзең уйлап кара,— диде Камил, әлеге фикерләрен куәтләп,— нинди авыр көннәрне, дошманын да, ачлыгын да, үлем куркынычын да җиңәргә туры килде бит безгә ул елларда...

* * *

Мен тугыз йөз унтугызынчы ел кышы бик авыр килде. Әле кичә генә аклар белән кызыллар сугышының ут-төтене эченнән чыккан җимерек шәһәр икмәксез, утынсыз калды. Шәһәр читендәге эшчеләр бистәсенең көннәре тагы да өметсезрәк иде. Бистә халкын ачлы-туклы булса да туендырып килгән такта яру, күн эшкәртү заводларының мичләре сүн-

гән, хуҗалары исә, ала алган кадәр алтын-көмешләрен алып, ала алмаганын җиргә күмеп, я Идел төбенә батырып, Мангышлак, Гурьев якларына сызган. Эшсез калган такта яручылар, күнчеләр, чарасыздан цехлардагы тимер-томырны ташып, зажигалкалар, «буржуйка»[1]лар ясарга керешкәннәр. Базарларда зажигалка, тишек солдат итекләреннән башка берни юк. Авыл җирләрендә хәлләр тагы да киеренкерәк. Кулак, мулла-мунтагай, поплар тарафыннан котыртылган аңсызларның, вак банда отрядларына оешып, тирә-як авыл активистларын асыпкисеп йөрүләре турында хәбәрләр көн саен арта бара.

Әнә шундый шомлы көннәрнең берсендә, бистәнең аптека чатындагы тукталышта трамвайдан бер кеше төшеп калды. Өстенә кыршылып беткән шинель, башына шлем кигән, аркасына каешланып беткән капчык аскан иде ул. Башта кая таба атларга белмичәрәк икеләнеп торды, аннары каршыдагы йорт капкасыннан атылып чыккан ялан аяклы малайны күргәч, үз янына чакырып алды.

— Яле, әйтеп карале, ячейканың кая икәнен беләсеңме?

— Белмичә! — Малайның йөзендә кызыксыну кабынды. Шул көннәр теленнән төшмәгән һәм ярыйсы ук даны таралып өлгергән «ячейка» сүзен ишеткәч, малай тегеңәр сөйләп торырга да бирмәде: — Әйдә, абый, үзем апбарам!

Шинельле кеше хәрби-революцион комитет вәкиле Камил Мөбарәкев иде. Аны бу бистә партячейкасына бер җитди йомыш белән җибәрделәр.

Шәһәр большевиклар комитетының бистә ячейкасы трамвай тукталышына каршы урамдагы Зыя байның асты таш, өсте агач, яшел буяулы яңа зур өенең икенче катына урнашып, аскы катында кыйраәтханә[2] ачылган иде. Бу уку өенә, Зыя бай каргышыннан, язык булудан куркып, кешеләр йөрмәсә дә, әмма ячейкага бистә коммунистларының дүртесе дә көн саен киләләр иде.

Ячейка секретаре канапатчы Зариф һәм калган өч коммунист — Мөслим, Хәсибулла, Рәхим — килүченең мандатын иҗекли-иҗекли җентекләп укыдылар, пичәтләренә кадәр карап чыктылар.

Мондый рәсми кәгазьләрне уку түгел, тотып та карамаган Зариф, сүзне каянрак башларга икән? дигән сыман бераз баш артын кашып торганнан соң, килүчегә күтәрелеп карады:

— Нинди ярдәм кирәк соң сезгә, иптәш? — дип сорады һәм, җавап та көтмәстән, әйтмәсәң дә беләбез дигәнне аңлатып, тагы сорады: — Азыкмы?

Камил аның сүзләрен раслап ым какты, аннары елмаеп куйды. Ник елмая ул?

— Әйе, азык! Тик карынга түгел, понимаете, җанга! — диде хәрби-революцион комитет вәкиле.

Тыңлап утырган дүрт коммунистның дүртесе дә бу сүзне берьюлы гына аңлый алмый тордылар. «Сәер сөйләшә бу иптәш, — дип уйлап алды Зариф.— Җанга. Ниткән җан азыгы ул?!»

Камил, шлемын салып, биш бармагы белән чәчен тарады, кесәсеннән шомарып беткән калай тартма һәм газета чыгарып, тәмәке төрергә тотынды. Моның белән ул, менә хәзер тәмәке кабызып капкач, төп мәсьәләгә күчәсен аңлатып, болай диде:

— Башта берәрне төрик әле, иптәшләр! Йомыш бик важный, понимаете, Ленин приказы!

Ленин исемен ишеткәч, дүрт коммунист, килүчене тизрәк тыңлау өчен, барысы бердән тәмәке төрә башладылар.

---

[1] Кулдан ясалган тимер мич.

[2] Уку өйләре ул елларда шулай гарәпчә аталып йөртеләләр иде.

Камил кесәсеннән снаряд башлы зажигалка чыгарды. Үз тәмәкесен кабызгач, калганнарның да кулларындагы «кәҗә сыйраклары»на ут элдерде. Барысы да авыз тутырып төтен йоткач, аеруча бер ләззәт белән төтенне борын тишекләреннән сузып кына кире чыгардылар. Камил сүзгә башлады:

— Мировой пролетариат юлбашчысы иптәш Ленин, революция хәвеф алдында, ди. Контра котыра! Безгә үз армиябезне төзергә кирәк, иптәшләр. Революцион комитет, понимаете, безгә әнә шундый бик зур эш тапшыра, кайсы ки революцияне саклау булырга тиеш. Без бу эшне фронтларда корал, ә тылда агитация белән, понимаете, башкарырга тиешбез. Менә шулай, иптәшләр! Аңлагансыздыр.

— Тагы бер аңлатыбрак әйтсәң икән,— диде Зариф.

— Нәрсәсен аңлатырга? — диде Камил.— Озын-озак аңлашып торыр вакыт бармыни? Бистәдә сүзгә, уенга, бию гә осталарның спискасын төзик тә эшкә башлыйк. Үзегез беләсез, иптәшләр, понимаете, революция көтеп тора алмый.

Күр син аны, ничек килештереп сөйли бу кеше! Кай арада болай яңача сөйләшергә өйрәнде икән? Курс дигән бер уку ачылган дип сөйлиләр, шул курста укыган, күрәсең. Зариф, шулай да, вәкилнең сүзләрен аңлый алмыйча торды.

— Яхшылап кына төшендерче. Бездәй рабочий кешегә яңа эшләр болар. Без нишләргә тиеш булабыз соң хәзергесе моментта?

Соңгы көннәрдә ишеткән «момент» сүзен кыстырып куюына Зарифның үзенең дә кәефе килде һәм ул хәрби-революцион комитет вәкиле алдында үзен бер баскычка үсеп киткән сыман сизде. Шул кыюландырды ячейка секретарен.

— Безгә, иптәшләр,— диде Камил,— ярлы пролетариат арасында аңлату эшен башлап җибәреп, Кызыл Армиягә доброволецлар чакыру йөкләнә. Сезгә — бистә коммунистларына, понимаете, һәм миңа! Нишләргә тиеш булабызмы? Хәзер әйтәм: без кем революциянең дусты, кем дошманы булуын ярлы пролетариатка фактически күрсәтеп бирергә тиешбез, понимаете. Аңлашылдымы?!

— «Фактически» дидеңме әле? Анысы нинди сүз була? — дип сорады Зариф.

— Ну... менә... әйтик...

«Ничегрәк әйтик икән соң?» дигән төсле, Камил, сүз таба алмыйча, тотлыгып торды.

— Сүздәмени эш?! — диде ул бердән.— Безгә хәзер эш турында сөйләшергә кирәк. Үзегез беләсез, иптәшләр, дошман революцияне буарга тели. Моның өчен ул «кара халык»ны алдау юлына баскан. Ә без аларның әнә шул явыз эшләрен фаш итәргә тиешбез. Хәрби-революцион комитетның тапшыруы шундый, понимаете. Инде дә аңлашылмадымы?

— Мин бу эшне болай аңлыйм, — диде баядан бирле сүзгә кушылу җаен көтеп утырган Рәхим.— Безгә революция театрын оештырырга кирәк.

Камил бердән җанланып китте:

— Менә... Менә... Революция театры! Аңладыгызмы, иптәшләр?!

— Театрдамыни эш?! — дип борчылды Зариф.— Икмәк, тоз кирәк хәзер безнең братка.

Камил катгый булып күренергә тырышты.

— Әнә шуны,— диде ул,— икмәкне ничек табу турында халыкка аңлатып бирергә кирәк, понимаете.

Исемлек башта зур гына булды, бергәләп тикшереп-сайлап иләктән үткәрә торгач, күп кенә исемнәр — кайсысы чит элемент, кайсысы мулла, я сәүдәгәр малае һәм башка шуның ише «сыйнфый чыгышлар» буенча — төшеп калды. Шулай итеп, ата-бабалары ягыннан революция

өчен хәвефсез табылган бистәнең җиде егете һәм бер кызы исемлектә калды. Сигезенчесе — Һаҗәр туташ — аптекчы кызы иде. Бу уңайдан аптека кибетме-түгелме дигән бәхәс тә кызып алды. Аптека халыкка кирәк ул, шуңа күрә аның хуҗасы сәүдәгәр була алмый дигән фикер җиңгәч, Һаҗәр исемлектә калды. Аннары моның тагы бер бик әһәмиятле ягы да бар икән: аптекчы Кәрим агай өендә революциягә кадәр үк «әдәби ахшам»нар булгалаган, хәтта спектакль да куелгалаган икән.

Шул ук көннең кичендә исемлектәгеләр ячейкага чакырылды. Бу йомышны үтәргә бик теләп теге ялан аяклы малай Вәли алынды. Бер күрүендә үк яратып өлгергән шинельле абыйсының тагы бер-бер эше төшмәсме дип, ячейка ишек алдыннан китмәгән бу ятим балага мондый йомыш бары аның бәхетенә эләккән мактаулы бер эш булып күренде. Ә инде шинельле абыйсы кесә төбеннән чыгарып кызыл йолдыз да бүләк иткәч, малайның куанычы эченә сыймады. Дөрес, кызыл йолдызның кадагычы сынган икән сынуын, әмма малай бер дә аптырап тормады, очларын без белән тиште дә бүрегенә тегеп тә куйды. Кыршылып беткән бүрек яңарып, ямьләнеп китте. Шул минуттан башлап ул үзен бердән үсеп, олыгаеп киткән сымак сизде.

Чакырылган сигезәүнең берсе дә килмәде. Нәрсә бу? Саботажмы? Ячейка чакыруын санга сукмаумы? Каршы килүме? Мондый баш тарту партячейка секретарен борчыса да, әмма ул тыныч күренергә теләде:

— Шулай буласын мин алдан сизгән идем.

Камил исә борчылудан битәр гарьләнде. Мандатны укыган теге дүрт коммунист мыек астыннан гына көләләр төсле күренде аңа. Шул гарьләндерде хәрби-революцион комитет вәкилен. Чигәсен боргычлап уй артыннан уй туды. Ярамый! Бу килеш калдырырга, килешергә һич кенә дә ярамый! Көчсезлегенне күрсәтү була. Тынгы бирмәгән шушы уен ячейка кешеләренә дә сөйләп белдерде ул:

— Болай ярамый, иптәшләр! Мондый саботаж белән килешеп булмый. Комитетның тапшыруы үтәлергә тиеш! Теләсә нинди юл белән, понимаете! — Бу соңгы сүзләрне басым ясап әйтеп кенә калмыйча, тагы бер кабатлады: — Теләсә нинди юл белән!..

— Бер юлы бар инде аның барын, тик мондый эшләрдә ярап җитәр микән?

Үз шигенә үзе дә җавап таба алмаган Зариф икеләнеп торды.

— Нинди юл? — дип сорады аңардан Камил.

Зариф кыяр-кыймас аңлатырга тотынды:

— Без ул юлны контрага карата гына кулланабыз. Контрибуциясен-фәләнен вакытында түләмәсә, я кушкан эшне эшләмәсә, мылтык тагып барабыз да, момент чыгарып бирә.

— Мылтык?!

Тыңлап утырган Рәхимнең йөзендә елмаю чагылды.

— Исеме генә мылтык ла аның. Бернигә ярамый. Затворсыз. Атмый.

Камилдә кызыксыну туды:

— Кая, күрсәтегез әле!

Көпшәсен тутык баскан, сабы ярык, затворсыз карабинны Камил кулында әйләндергәләп карагач, ихтыярсыздан елмайды:

— Әгәр дә бу мушкет революциягә шушы хәлендә дә файда китерә ала икән, әйдә китерсен! Безнең өчен моның зарарсыз ягы тагы шунда, мондый «корал» файдаланганга бирәү дә гаепли алмас. Тик менә кем тагып барыр моны?

— Рәхим аның остасы! — диде Зариф.

— Барам!

Мондый очрак чыгуына Рәхим бик риза иде.

— Шулай ит әле, Рәхим туган! Аңлатып кайт әле үзләренә безнең бурычны! — диде Камил.

Рәхимнең чыгып китуенә бер сәгать вакыт уздымы икән, чакырылган сигезәүнең сигезе дә килеп җитте. Эшнең бу хәтле уңышлы чыгуына барысы да — чакыручылар да, чакырылганнар да куанып бетерә алмадылар. Югыйсә, алар ячейкасына да, кыйраэтханәсенә дә бик теләп йөрерләр иде дә бит, я берсенең әтисе, я икенчесенең әнисе, өченчесенең әбисе ахрызаман килү, Дәҗҗал чыгу, Зыя бай бәддогасы төшү һәм башка шуның ише язык-мазыклар белән куркытып, якын да җибәрмиләр иде.

Ә хәзер менә алар Рәхимнең ничек итеп әти-әниләргә «аңлатканын» сөйләгәнен көлә-көлә тынлап утыралар.

Ә Рәхимгә сөйләргә генә булсын...

— Гарип мылтыкны иңбашка асып ячейкадан чыгып китүгә, тотындым план корырга. «Кемнән, кайдан башларга?» — дип сорыйм мин хәзергесе вакытта үземнән, үзем үк җавабын бирәм: «Башла син, Рәхим брат, Кәрим агайлардан. Нигә дисеңме? Ә шуңа, Рәхим брат, ничек кенә әйтмә, Кәрим агай грамотка оста кеше, гел дарулар арасында гына эш итә, нәрсәнең агу, нәрсәнең дару икәнен яхшы сукалый». Шул, килеп керәм Кәрим агайның аптигенә. Керәм дә «ыһһем» дигән булып тамак кырып куям, аннары иңсәдәге мылтыкны алып, дискет, теге җирен, бу җирен караштыргалаган булам. Готовыймы? Кәрим агаем ни әйтергә белмичәрәк карап тора. «Берәр зат-мат кирәкме әллә, Рәхим?» — дип сорый бу миннән. «Зат кирәкми, мин әйтәм, кызың Һаҗәр кирәк». Әйттем әйтүен, ну ошибка эшләп ташлавымны шунда ук абайлап өлгердем. Карыйм, агаем телсез калды. Значится, мин әйтәм эчемнән үз-үземә, төзәтергә кирәк бу ошибканы. «Кәрим агай, кызың безгә революция эшенә кирәк!» — мин әйтәм. Агаем баягыдан битәр аптырап төште. «Нинди революция эше?» — дип сорый бу хәзер миннән. «Нинди булсын, мин әйтәм, җир шарын капитализмнан коткару революциясе», мин әйтәм. «Минем кызым капитализмга каршы ни генә эшли алыр икән?» — ди бу миңа. Аңлатып бирәм мин моңа хәзер. «Әгәр син дә, дим, иптәш Кәрим агай, грамотный башың белән бу эшләрне аңламасаң, безнең кебек рабочий халыктан ни көтәргә кирәк?!» Агаем «шулай шул!» дигән кебек миңа карый. «Шулай шул! — мин әйтәм.— Ленин приказын ишеткәнсеңдер»,— мин әйтәм. Агаем бер генә сүз әйтә: «Барсын! Ячейка кешесе мылтык тагып үзе килгәч, Ленин приказы да булгач, ярамаган эш түгелдер але»,— ди. Ә менә бу егетләргә Һаҗәр сеңел белән икәү йөреп чыктык. Авызларын да ачтырмыйм. «Күрәсез бит, Кәрим агай кызын ышанганда, ә сез ык-мык итеп, мин әйтәм, оялмыйча яңа эшләргә каршы килер идегезме?» Шулай дим, ә үзем мылтыкны кулдан кулга күчергән булам. Готовыймы? Иң кызыгы канапатчы Рамазан агай булды: «Әнә, хатын бит, әнисе, «баламны юлдан яздырмасыннар» дип тузына», дигән генә иде, Сабираттәй элеп алып селкеп салмасынмы үзен: «Мине бинават ясар идеңме?! Үзең бит баланы тәмуг белән куркыттын! Барсын! Бик каныма тисәң, үзем дә барырмын ячейкаларына. Ленин мәңге кол булып яшәргә димәгән!» Шулай ди бит, әй, неграмотный хатын. «Рәхмәт яусын үзенә, Сабираттәй, мин әйтәм, мондый дөрес сүзләрең өчен, мин әйтәм, революцион комитет исеменнән рәхмәт!»

— Дөрес әйткәнсең! — диде кәефе килгән Камил.— Андый Сабира тәтәләрегезнең шундый сүз әйтүе өчен кулларын үбәргә дә ярый! «Мәңге кол булып яшәргә димәгән!» ди, ә?! Моны бит, туганнар, безнең татар хатыны әйткән. Менә без аңлатып та биргәч, күрерсез әле...

Шушы көннән алып һәр кич партячейка тәрәзәләрендә кичке тугызга-унга кадәр асылмалы лампа утының мул яктысы балкып торды. Фонарьлары яндырылмаган дөм-караңгы бистә урамы тәрәзәләрдән сирпелгән лампа яктысында бәйрәм кичләрендәгедәй җанланып, ямьләнеп китте. Бу яктылыкка башта бала-чага җыелды, капка аллары

балалар шау-шуы белән тулды, аннары, бер-ике көннән, яшьләр дә күренде. Алар «тиздән булачак театр» турында берсеннән-берсе мавыктыргыч имеш-мимешләр сөйләделәр. Ә кайбер кыюраклары, тәрәзәләргә үрелеп, репетиция барышын карадылар. Атна-ун көн уздымы икән, Зыя бай өенең тагы өч тәрәзәсендә кичләрен ут балкыды һәм ул утлар яшьләрне кыйраәтханәгә тартты. Улларының китап-журнал тирәсендә мәш килүен күргән кайбер әти-әниләр тынычлангандай булдылар.

Һәм менә бистәне шау китергән шундый бер көн дә килеп җитте: карты-яше, олысы-кечесе, хатын-кызы урам чатларында кулдан язып ябыштырылган,— шәмәхә дисәң, шәмәхә түгел, галәмәт кәгазьләрне күрделәр. Афиша дип исемләнгән бу кәгазьләрне укымаган кеше калмады. Тик мәчет картлары гына, «шайтан вәсвәсәсе» янына якын да бармыйча, бисмиллаларын әйтә-әйтә, урамның икенче ягыннан уздылар. Халык арасында мең төрле имеш-мимеш куерды...

Имеш, иблис ләгыйнь котыртуы белән хәзерләнгән театр уены кичендә клубны яшен сугачак. Имеш, театр уенын карауч ыларның күзләре чыгачак, уйнаучыларының аяклары сыначак. Берсеннән-берсе хәтәр уйдырма хәбәрләр таралган көннәрдә, чынлап та, көч куеп әзерләнгән спектакльне пыран-заран китереп ташлый язган бер хәбәр яшен тизлегендә бистәнең барлык мәхәлләләренә таралып өлгерде. «Инкыйлаб дулкыннары» исемле пьесада явыз бай ролен башкаручы Сибгатуллин фамилияле егет, төнлә репетициядән кайтканда, караңгы урамда кемдер казыган чокырга абынып аягын имгәткән. Бүген-иртәгә спектакль була дигәндә генә шундый хәл килеп чыксынчы! Моны ишеткән Камил: «Берни түгел. Сәхнәдә аксап йөри икән, әйдә, аксасын! Капитализм аксый, диярбез»,— дип эшне төзәтергә уйласа да, авыруның өенә барып хәлен күргәч, «капитализм аксый» гына түгел, түшәктә ята булып чыкты. Җитмәсә, фельдшер, бер атна кузгалмаска кушып, аягына чүлмәк хәтле гипс салып киткән.

Шул ук кичне репетиция ячейка җыелышына әйләнде.

— Әгәр дә, иптәшләр, театрыбыз куела алмыйча калса,— диде барысыннан да битәр борчылган Зариф,— эш харап! Барысы да...— ул кабат басым ясап әйтте,— беләсезме, барысы да бездән көләчәк...

— Көлеп кенә калсалар,— дип элеп алды Рәхим.— Мәчет картлары тараткан ялган хәбәрләргә ышаначаклар! Ул чагында берничек тә котыла алмассың.

— Әйе, әйе! — диде Зариф, бүленеп калган сүзен дәвам иттереп.— Ул чагында ячейканың да авторитеты очты дигән сүз. Давай, Камил иптәш, революцион комитет кешесе икәнсең, әйт безгә хәзер...

Камил Зарифка сүзен сөйләп бетерергә дә бирмәде.

— Әйтеп торасы да юк! Спектакль булачак! Шартласак та куябыз!! Аңлашыламы, понимаете?!

— Што ты бигүк аңлашылып җитми шул, брат! — диде Зариф.— Авырый бит кеше! Аягына баса алмый...

Кинәт Зарифның башында бер яңа уй туды булса кирәк, сүзеннән бүленде дә Камилгә сөзеп карады.— Әллә, Камил туган, мин әйтәм, ниме... нитәбезме, ә?!

— Нитәбезме?!

— Әллә, мин әйтәм, син әйтмешли, ниме... Сибгатуллинны караваты-ние белән сәхнәгә чыгарып куябызмы, ә? Капитализм үлем алдында, ә?! Сүзләрен төзәтәбез дә — эше дә бетә, ә?!

Камил, чынлап та шулай итеп булмыймы икән дигән төсле, беразуйланып торды:

— Булмый алай, булмый, Зариф иптәш! Сибгатуллин урынына башка кешене чыгарырга кирәк. Спектакльгә атнадан артык вакыт бар әле, төне-көне репетиция ясыйбыз да башка кешене чыгарабыз.

— Әйтүе ансат! — диде Рәхим.— Ә кемне?!

— Менә сине! — диде бердән Камил.

Моны ишеткән Рәхим, искәртмәстән бәреп миңгерәтелгән кешедәй, күзләрен мелт-мелт йомып карап торды, елмаерга теләде булса кирәк, елмаю урынына йөзе чалышайды. Ниһаять, ул телгә килде. Хәер, моны «телгә килү» дип әйтү иртәрәк иде әле, ул тамак төбе белән генә «һыы!»га охшаш бер мөңгерәү чыгарды.

— Ник аптырап калдың әле син?! — диде Камил.— Өйрәтәбез! Менә дигән явыз бай чыга синнән!

Рәхим бер агарды, бер кызарды. Күзләрендә берьюлы аңлавы кыен булган, ачуга да, гарьләнүгә дә, нәфрәтләнүгә дә охшаш очкын күренде.

— Мин рабочий! — диде ул, тешләрен кысып,— бай булырга теләмим!

Зариф егетнең бу хәтле киреләнүен күреп үзе дә аптырап калды:

— Театрда гына бит бу! Уенда гына!

Рәхим, ачу белән, аңа таба борылды.

— Бер җирдә дә булмыйм!

— Рәхим иптәш, киреләнмә әле! — диде Камил. Чынлап та кызып киткән Рәхимне тынычландырырга теләп,— бу уен гына бит, понимаете!

— Юк, не понимаем без мондый эшне! Бу уен түгел! — диде аның саен кыза барган Рәхим.

Зариф тагы аңлата башлады:

— Син бит бай булып кыланасың гына.

— Рабочий башым белән бай булып кылансам, кеше ни әйтер. Тотып кыйнатмакчы буласыңмы? Әнә ончы Гатауга әйтегез. Ул, кыланмаса да, он сатып капиталистка әйләнеп бара.

— Чынлап та, әй, яхшы фикер бу! — диде Зариф, шунда ук Рәхим белән килешеп.

— Ярамый! — дип кырт кисте Камил һәм ни өчен ярамавын аңлатты.— Чуждыйларны катнаштыра алмыйбыз...

— Чуждый булса?! Үзен уйный бит ул!

— Уйный алырмы соң? — дип сорады Камил.

— Нишләп уйный алмасын? Уйный алмыйча хәле юк! Налогны арттырабыз, дисәк, баеңны түгел, чортыңны уйнар! — диде Зариф.

Шул сәгатендә үк Рәхим, затворсыз мылтыкны тагып, Гатауны чакырырга китте.

Камил Рәхим артыннан тагы бер кычкырып калды:

— Ячейка чакыра, «немедленно!» диген.

* * *

Гатауны өйдә юк диделәр. Батыр атлап килеп кергән Рәхим аның кайдалыгын белергә теләсә дә, өйдәгеләре: «Белмибез!» — дип ялганладылар. Асылда исә, мылтыклы кеше килүен ян тәрәзәдән шәйләп өлгергән ончы, песи күргән тычкандай, мич арасына кереп качты.

Рәхим, өй эчен тентергәме-юкмы, дигән төсле беркадәр икеләнеп торды, аннары бу хакта ячейкада сүз дә булмагач, кисәтү белән генә канәгатьләнде:

— Кайткач ук бер минут тормастан ячейкага йөгерсен. Яхшы белсен — Советский власть ике әйткәнне яратмый, понимаете! — диде ул Камилчәрәк кискен булырга теләп һәм чыгып китте.

Мич артыннан чыккан Гатау, ачуына чыдый алмыйча, ераклашып барган Рәхимнең аркасын тәрәзәдән күзләре белән бораулап карап торды:

— Каян килгән «Советский власть». Өтек! Әнә анда, Башмаковка-

да синең ишеләрне чиркәү тәресенә асып куйганнар, ди. Гыйбрәткә. Ходай кушса, монда да килеп житәрләр әле ул азаматлар...
Гатауның «азаматлар» дигәне жирле карагруһ көчләрдән оешкан һәм Советларга каршы күтәрелгән банда отрядлары иде.
Гатау килмәде, ә икенче көнне бөтенләй юкка чыкты. Ячейканың мылтыклы кеше жибәреп чакыртуын ул үзенчә юрады һәм «көчләп Кызыл Армиягә язудан» шүрләп, тавыш-тын басылганчы бистәдән югалып торырга булды. Рәхим кереп чыккан көнне кич белән үк, караңгы төшүдән файдаланып, ашык-пошык жыенды да, юл капчыгына бер тезмә кипкән балык һәм бер түгәрәк кымырҗык әпәе салып, бистәнең бакалтай ягы белән чыгып ук китте.
Гатауның, ячейка чакыруына буйсынмыйча, бистәдән чыгып китүе коммунистларга түгел, башкаларның да күбесенә ошамады. Тик мәчет әһеле генә бу эшне хуплап телгә алды, аеруча Зыя бай хуплады. Ул моны ходай кушуы буенча эшләнгән эш дип, ярамаган эшләрдән качуны Гатауның күңеленә ходай үзе салган дип аңлатты. Бер хәбәр икенчесен, икенчесе өченчесен тудырды, байтак семьялар һәртөрле хәвеф килүеннән куркып яшәде. Нәкъ шундый киеренке көннәрдә Каспий диңгезендә инглиз сугыш көймәләренең күренүе, ә тагы да берничә көннән ул көймәләрнең Идел тамагына якынлашып килүләре, көньяктан исә Врангель гаскәрләренең һөҗүм башлаулары, шул уңайдан Идел буе авылларында яңа гына оешкан «Ярлылар комитеты» членнарын асу-кисүләр турында хәбәрләр таралды. Зыя бай өе тирәсендәге жанлылык та тынып калды. Кыйраәтханәнең тәрәзәләрендә ут тагы күренмәс булды. Тик икенче каттагы ячейка тәрәзәләре генә, төн карасын ерып, таңга кадәр яктырып тордылар. Ячейкада коммунистларның дежур чыгулары оештырылды. Спектакльнең өзелү куркынычы туды. «Явыз бай» ролен башкаручы булмавын сылтау итеп таралу турында сүз көчәйде. Мондый сүзләр бер Камилне генә түгел, ә барлык ячейка коммунистларын да, аеруча Рәхимне бер уттан икенче утка салды. Ничек инде?! Шулхәтле тырышып, көч куеп жыел да, спектакль әзерләнеп житте дигәндә генә, барысы да ишелеп төшсен, имеш. Кем генә рәхмәт әйтер икән моның өчен? Зыя баймы? Әнчы Гатаумы? Гатауны исенә төшерү белән, Рәхимнең каны кызды. Ул аны үз куллары белән буып ыргытырлык хәлгә житеп каһәрләнде. Егетнең мондый каһәрләнүе кискен бер карарга китерде үзен. Башындагы малахай бүреген салып өстәлгә шап итеп сукты да:
— Үзем уйныйм! — диде.
Репетицияләр башланып китте.

* * *

Аптекчы Кәрим ишек алдына аноним хат ташлап киттеләр. Хат иясләре әти кешене кызының язмышы белән кызыксынмауда гаепләгәннәр, дин тарафыннан тыелуга да карамастан, кызыңа ярамаган эшләр артыннан йөрергә ирек бирсәң, ахыры яхшы бетмәс дип тә кисәткәннәр иде.
Аптекчы бердән каушап китте. Хаттагы сүзләр зиһенен чуалтып, котын алдылар аның. Ата белән кыз арасында сүз купты.
Һажәр бистәдәге үз тиңнәре арасында тәрбия ягыннан да, белеме белән дә өстен торган ачык күзле кызлардан саналса да, әмма әти белән сүз көрәштерерлек дәрәҗәдә «бозылып» житмәгән иде. Киресенчә, моңарчы ул әтисен иң якын һәм туры киңәшчесе итеп карады. Әтисенең сүзен үзе өчен закон санады, хәтта хөрмәт йөзеннән әтисе алдында күп вакытта тел яшерде. Ә бүген...
Кызының бу тикле теле ачылуын күргән Кәрим агай чын-чыннан хафага төште.

— Акылыңдамы син?! Әле сине шулай атаңа каршы сүз әйтергә дә өйрәттеләрмени?! Менә сиңа ячейка! Дөрес язганнар шул әнә — «ахыры яхшы бетмәс» дип. Ишетсен колагың: ячейкаларына аяк та басмыйсың! Мондый эшләргә дин дә, мин дә баш-аягым белән каршы!

Һаҗәр нәрсә диярргә дә белмичәрәк сүзсез торды. Бу секундларда аңарда ике көч тартыша иде. Ул үзен кулга алды:

— Хәзер булмый инде, әти! Иртәгә спектакль...

Кәрим агай ачуланып кычкырды:

— Мин әйткәч, була! Синсез дә булдырырлар.

Әтисенең мондый кискен кирелеге Һаҗәрне чәнчеп, рәнҗетеп алды. Бу аның тавышында чагылды:

— Ул хатны дошман язган бит! Ә син шуңа нярәсең...

— Оятсыз! Белгән сүз — «дошман». Дошман кызымны тартып алырга тели минем!

Өй эчен авыр тынлык басты. Һаҗәр артык бер сүз дә әйтмәде. Кәрим агай да, кыз тынычлансын дип, өйнең аргы ягына — аптекага кереп китте.

Һаҗәр ялгыз калды. Бу ялгызлыкта, читлеккә ябылган кош кебек, үзенә урын таба алмыйча аһапланды. Башында мең төрле уй. Нишләргә?! Барыргамы? Әти кушмый бит. Ачулана. Ә тегендәгеләр?! Яшь кызның бер җилкенгән күңеле тиз генә басыла алмас төсле, гел аны ячейкага, шушы сәгатьтә репетициягә җыелучы яңа дуслары, танышлары янына, ничектер шунда якын да, ягымлы да күренгән ячейка кешеләре, теге, революцион комитет вәкиле янына тарта. Нишләргә? Бармаса? Була микән? Ничек итеп шундый күңелле эштән читтә калырга? Иптәшләре ни әйтер аннары? Ячейкадагылар ничек карар бу эшкә? Зариф абыйсы ни әйтер?

Һаҗәр чөйдән пальтосын ала. Кия. Кигән арада әтисе килеп керер дә тагы тузына башлар төсле тоела аңа. Шул борчый кызны. Я, тузыныр-тузыныр да туктар әле, үз әтисен яхшы белә бит ул, һәм кыз соңгы генераль репетициягә чыгып китә.

Спектакль киче килеп җитте.

Чат саен камырлап ябыштырылган афишаларны кәҗәләр кимереп бетерсә дә, партсекретарь Зариф: «Яхшыга түгел бу, егетләр, кеше килмәс»,— дип борчылса да, әмма хәл киресенчә булып чыкты. Спектакль башлануга ике-өч сәгать алдан ук театр буласы акбур сарае ишеге алдына бик күп кеше җыелды. Кызыксыну хәтсез көчле иде. «Спектакль» дигәннең нәрсә икәнен, нәрсә күрсәтеләсен ишетмәгән дә, күрмәгән дә кайберәүләр бердән беләмәннәргә әйләнеп киттеләр. Аларны тыңласаң, сугыш күрсәтәчәкләр икән, Зыя байны уйнаячаклар икән.

Элек акбур складь булып та, бу кичә өчен дип җыештырылган, метр биеклегендә сәкедәй итеп сәхнә урыны эшләнгән, ике-өч йөз кеше сыйдырышлы сарай иде бу. Пәрдәгә дип күрше-куләннән алып торылган төрле төстәге чуар чаршаулар корылып, сәхнә алдына ике яктан ике асылмалы лампа да эленгәч, сарай эче яктырып, ямьләнеп китте. Караңгы, кысан өйләрдә ут кабызмас өчен элек кичтән ятып йокларга күнеккән бистә ярлылары ялт иткән театр залын күреп хәйран калдылар. Барысы да тизрәк бу якты, иркен залга керергә, алгы урыннарны алып калырга ашыкты. Ишек алдында этешү-төртешү китте. Капкадай зур ишеккә куелган берсеннән-берсе таза абзыйлар халыкны тынычландырга чакырдылар:

— Ашыкмагыз, җәмәгать! Барыбер ястү бетмичә театр башланмый! — дигәч кенә, сабырсызлар беркадәр басыла төштеләр. Чөнки бу барысы өчен дә бәхәссез бер уртак дәлил иде. Болай эшләүнең, Зариф аңлатканча, дошман коткысына каршы хәлиткеч файдасы бар иде, югыйсә, мәчет картлары театр куюга «намаз вакытын бозу» дип кара-

макчы булганнар, ди. Шул уңайдан ячейка җыелышында спектакльне ястү намазыннан соң башларга дигән тәкъдим яхшы табылды. Шулай ук бу җыелышта артистларның кайда буяну-киенү мәсьәләсенә кадәр каралып, моның өчен иң җайлы урын ячейка дип табылды. Нишә әйтсәң дә, сарай сарай инде ул. Грим салу, киенү өчен сәхнә арты бүлмәләре түгел, залында бер рәт урындыгы булсын иде ичмасам! Гомер-гомергә сәкедә аяк бөкләп утырып, сәкедә ашап, сәкедә ятып яшәгән бистәдә ул хәтле кешегә каян табасың ул урындыкны. Шуңа күрә, такыр идәнгә иске капчыклар, киез, камыш палас кебекләрен җәяргә дә халыкны бик әйбәтләп шунда утыртырга. Алга — хатын-кыз, уртагарак — олы яшьтәге бала-чага, артта — ирләр. Ә уйнаучылар ячейка бүлмәсендә грим салып, киенеп әзер булуга, караңгы урам белән килеп сәхнәгә әрт яктан, махсус ясалган ишектән керәләр, уен барышында керергә тиеш булганнар, керер вакытны көтеп, урамда торалар.

Явыз бай ролен башкаручы Рәхимне, сәхнәгә икенче пәрдәдә чыгасы булгач, ашыкмыйча, бар җирен китереп әзерләделәр. Дөрес, башта кием табу ярыйсы ук кыен булды. Кыен дип, бай кеше мазутлы бишмәт киеп чыкмас бит инде, ә бистәдә мазутлы бишмәттән дә күп нәрсә юк. Шуннан соң бистәнең бай, хәллерәк кешеләреннән, мең михнәт белән, икенче көн иртәсендә үк кайтарырга ант эчеп — сүз биреп ала торгач, бер байны киендерерлек кием-салым җыелды. Бик затлы Европа модалы бер пальто кебегрәге дә табылса, нинди әйбәт булачак икән. Анысын да таптылар. Зарифның хатыны Зыя бай хатыны белән сөйләшеп, тегенең үзенә сиздермичә генә, бәрхет якалы кара пальтосын да алып кайттылар.

Көзгедәге кыяфәтен күрүдән Рәхим үзе дә шаккатты. «Вәт сиңа әкәмәт, ә!» — дип хәйран калды ул.— Өс-башың әйбәт булса, безнең брат та кеше кыяфәтенә керә икән, әй!»

— Син бу кыяфәтең белән хәзер Зыя абзаңның үзенә охшагансың,— диде Зариф.

— Коеп куйган Зыя бай! — дип кычкырды шатланган Камил.

— Чынлап та! Охшатыгыз әле Зыя байның үзенә. Сакал-мыекны аныкыча итеп ясагыз! — диде дәртләнгән Рәхим,— кыйланыемчы бер үзе булып!

Тынып калган кичке бистә урамнарын яңгыраткан көчле кыңгырау тавышы ишетелде. Кайберәүләр пожарный атлары чаптырып уздымы әллә дип капка төпләренә чыктылар.

— Егетләр, ишетәсезме?! — диде Камил ячейкачыларга.— Бу безнең театрыбызның беренче звоногы. Ястү беткән, күрәсең. Ашыгыгыз. Вакыт!

Спектакльдә катнашучылар әзер иделәр, урыннарыннан тордылар. Рәхимгә бер ярты сәгатькә соңгарак килергә кушып, «Инкыйлаб дулкыннары» геройлары театр сараена чыгып киттеләр.

Рәхим ялгызы калгач, тагы бер үзе генә иркенәеп ролен карапштыргалады. Зыя бай булып кыланды, аныңча атлады, сөйләшкән булды, тамак төбе белән хигылдап көлгәндәй итте. Чыга кебек. Шулхәтле тырышып та чыкмаса! Мондый җаваплы рольне ике-өч көндә үзләштерүен күреп, барысы да Рәхимне күккә чөеп мактады.

Караңгы бистәдән шундый булдыклы кеше чыгасын күреп, аеруча Зариф шатланды.

— Син, брат, әгәр белсәң, тумыштан артист булып тугансың!

— Юк инде, Зарифҗан дус, булмый торсын! Без нәсел-нәселдән рабочий, ә бай-капиталист түгел.

Тапкыр да, үткер дә булып яңгыраган мондый җаваптан Камил рәхәтләнеп шаркылдады.

— Ну, егет, син әле сүзгә дә оста гына икәнсең! Талант!

Баягыдай булып тагы кыңгырау яңгырады. Икенче звонок. Тегеләр барып җиттеләр, күрәсең. Хәзер, күп булса тагы бер биш-ун минуттан, пәрдә ачылыр, уен башланыр... Рәхимне җиңелчә эчке дулкынлану биләп алды.

* * *

— Сарайны яшен суга!
— Театрларын яшен атачак!
— Яшен сугачак!
— Яшен!!

Зариф караңгыда малайларның берсен эләктереп алды. Калганнары, карчыга күргән чыпчыклардай, сибелешеп юк булдылар.

— Ник кычкырасың син, ә, дуңгыз малай?!

Малай ычкынырга теләде.

— Җибәр!..
— Ник кычкырдыгыз, ә?!
— Җибәр!..

Камил килеп җитте.

— Җибәрермен менә мин сине! Казаматка илтеп япкач, күрерсең хәлеңне,— диде ул тегеләй дә коты алынган малайга.

Малай еламсырады:

— Мин үзем кычкырмадым бит... Куштылар.
— Кемнәр?!

Малай бөтенләй үк елап җибәрде:

— Әйтмәскә куштылар...
— Камил туган, син бар, халыкны тынычландыр! — диде Зариф.

Камил сәхнәгә ашыкты. Менә ул, чаршауларны каерып ачып, алга чыгып басты.

— Җәмәгать! Тыныч кына утырыгыз. Бала-чага, понимаете. Зариф берсен эләктереп тә алды. Котырткannар. Тыныч кына утырыгыз әле. Хәзер башлыйбыз. Бик кызыклы театр күрсәтеләчәк. Сез бу театрда революция дошманнарын, аларның безгә каршы эшләрен күрерсез, понимаете.

Аннары ул ишектәгеләргә ишарә итте:

— Өченче звонокны бирегез!

Зыңгылдап кыңгырау яңгырады. Ыгы-зыгы килә башлаган тамашачылар әкренләп басылдылар. Зал тына барды һәм, ниһаять, бөтенләй тынып калды. Камилнең эчке куанычы хәтсез зур иде. Нинди зур эшне өзелүдән саклап кала алдылар бит, ә?! Егеттә бердән дәрт кабынды һәм кабынган дәрт белән залга мөрәҗәгать итте:

— Иптәшләр, театр башлау алдыннан сезне агитацияләп алу өчен сүз миңа бирелде. Яхшы гына тыңлагыз.

Аерым бер күңел күтәренкелеге белән, Камил берничә көн алдан әзерләп һәм ятлап куйган «агитация»сен башлады:

— Иптәшләр, бөтен дөнья пролетариатының, ягъни безнеңчә әйтсәк, ярлыларның юлбашчысы иптәш Ленин әйткән, кайсы ки, Совет власте хәвеф алдында дип, понимаете. Мине сезгә хәрби, ягъни безнеңчә әйтсәк, военный-революцион комитет җибәрде. Коймаларга ябыштырылган возваниеләрне, ягъни безнеңчә әйтсәк, өндәмәләрне укыгансызлыр. Нобель заводы эшчеләре үзләре теләп Кызыл Армия сафына язылалар һәм башкаларны да чакыралар. Кызыл Армия безгә, иптәшләр, революцияне саклау өчен кирәк. Революция дошманнары безне тагы да изәргә, понимаете, кол ясарга телиләр. Бу турыда сезгә театрда уйнап күрсәтелер. Шуның өчен мин, иптәшләр, агитация сүземне бетерәм. Вопрослар булмаса, театрны башлыйбыз.

Арткы рәттән тавыш ишетелде:

— Бер вопрос бар иде.

— Бир вопросыңны!

— Кызыл Армиягә кайда, кемдә язылырга?

— Аңлашыла! — диде Камил.— Иртәгә партячейкага килегез. Списка шунда төзеләчәк.

Икенче тавыш кычкырды:

— Кавалериягә язылып буламы?

— Бик була! — диде Камил.— Рәхим итегез! Атын да бирәләр, иярен дә...

— Ә мылтык?

— Мылтыгын да, хәтта кылычын да бирәләр,— диде Камил.

Тагы бер сорау ишетелде:

— Шинель бирәләрме?

Бер-бер артлы туа башлаган «бирәләрме?» Камилгә бик үк ошап җитмәде. Ул моңа үзе дә ышанып бетми иде. Шуңа күрә ул бу сорауларга чик куярга теләде:

— Әйттем бит инде, иптәшләр, иртәгә партячейкага килегез дип, шунда барысын да ачыкларбыз...

— Тагы бер генә сорауга җавап бирә алмассыңмы? — дип кычкырды арттагы рәтләрдән бер олы яшьтәге абзый. Камил аны тиз генә күреп алды һәм аның бистәдәге хөрмәт ияләреннән берсе булуын да сиземләде, чөнки ул сорау бирүгә, зал бердән тынып калды.

— Ленин иптәшне татар икән дип сөйлиләр, шул дөресме икән?

Камилнең маңгаена салкын тир бәреп чыкты. Ул беркадәр аптырап калды һәм Ленинның кайсы милләттән булуы турында үзенең дә хәбәре юклыгын шушы аптырап калган минутларда абайлап алды. Уйламаган да иде бит ул бу турыда. Әмма озын-озак сүзсез басып тору ярамый иде:

— Ленин ул, иптәшләр, мировой пролетариат, ягъни безнеңчә әйтсәк, бөтен дөнья ярлыларының туганы. Ну, әйтергә кирәк, понимаете, безнең татарны да бик ярата, әйтәм ич... Ленин ул халык улы.

Кинәт Камил һич көтмәгән, хәтта уена да китермәгән бер хәл туды. Әлеге сорауны бирүче башлап җибәрдеме, кемдер кул чабарга тотынды, аңа тагы берничә кеше, аннары тагы берничәсе кушылды. Дулкынланган Камил, залга карап: «Яшәсен иптәш Ленин!» дип кычкырган иде, барлык халык гөрләп кул чаба башлады.

* * *

Рәхим, Зариф кушканча итеп, ячейка ишегенә чабата зурлыгы йозак элгәч, аягындагы яңа шиблетләрнең баскан саен шыгырдавына кәефе килеп, караңгы урам буйлап сарайга таба атлады.

Урамнар тып-тын. Бер караганда, җәйге челләдә күкрәп килгән давыл алды тынлыгын хәтерләтә. Тик, ара-тирә ерак күкрәүдәй булып, сарай яктан кубып-кубып алган көлүләр гөрелтесе ишетелеп уза.

Рәхим, чатка җитеп, зур урамга борылуга, каршысына тирги-тирги кызын алып кайтып баручы бер хатын килеп чыкты. Рәхим яхшы таный ул тынгысыз хатынны. Бу Сәрби тәтәй иде. Бистәдә аны солдатка Сәрби дип тә йөртәләр. Гаҗәп бәхетсез, ярлы хатын! Әйтерсең, тормыш бөтен авырлыгын шул бичара хатын җилкәсенә өйгән. Таң тишегеннән торыр да караңгы төшкәнгә кадәр, йорттан йортка йөреп, әле тегесенең керен юып, монысының суын китереп, җитенен тетешеп, шулай анысынмонысын алып кайтып тамагын туйдырыр, кызының мәктәпне ташламавы өчен тырышыр. Алыштырырга күлмәге булмас, җәен ялан аяк, кышын тишек киез катадан чыгар, әмма күңелендә саклаган бердәнбер өметеннән һич кенә дә ышанычын өзмәс. Өмете — кызы. Ундүрт яшен-

дәге Зөһрәсе бердәнбер карап үстергән шатлыгы да, кайгысы да аның. Ә кыз әкияттәге Зөһрә йолдыздай сылу һәм күркәм. Акылга да бик зирәк, кулы да хезмәт сөйгән, эштә уйнап кына тора. Ходай кушып, тагы бер өч-дүрт елдан үзедәй унган җан иясе алып куйса, бар кайгылары бетәр иде дә, аңардан да бәхетле кеше булмас иде бу дөньяда. Шуны өмет итеп яши, тырыша солдатка Сәрби. Шул көнне күрү өчен, кызын яман күздән, яман юлдан саклый. Шундый җиләктәй өлгереп килгән чагында, күрше кызына ияреп киткән дә барган бит, ә?! Кая диген?!. Яшен сугасы җиргә!.. Мине дә рисвай итүдән курыкмаган. Хәзрәт ишетсә ни дияр? Зыя бай бусагасыннан атлатмас...

— Акылсыз кыз! Сиңа ни калган анда?! Яшен сугудан да курыкмыйсыңмыни?!

Бу сүзләрне ишеткән Рәхимнең җен ачулары кузгалды. Каһәрләнеп чыгып басты ул Сәрбинең алдына.

— Нинди яшен ул?! Нигә куркытасың син баланы, ә?! Килешми бу эшләр сиңа, Сәрби!

Хатын аптырап калды. Теле тотлыкты. Сөбханалла!.. Караңгыда күренә генәме әллә? Юк, юк, күренми. Үзе, әйе, әйе, каршында Зыя бай үзе басып тора лабаса!

Рәхим ярсыганнан-ярсыды:

— Үзең дөнья рәхәтен күрмәгәч тә, инде шул кыз баланы мәхрүм итәр идеңмени?! Яхшы эшләр заманы килде хәзер. Тыйма син аны! Барсын!

— Барсын... Барсын...— диде коты алынган Сәрби. Аның өчен күктә алла булса, җирдә Зыя бай иде. Инде аның үз авызыннан да ишеткәч, Сәрби тәмам югалып калды.

— Барсын... Язгыннан курыккан идек, Зыя абзый. Сездән.

Рәхим айнып киткәндәй булды. «Зыя абзый!» — ди ич аңа бу хатын. Шуны абайлап алды бу секундта, югыйсә бөтенләй онытылган булган икән... Бердән аңарда үзенә дә бик үк аңлашып бетмәгән шундый бер әчке дәрт туды.

— Беркемнән дә курыкма! — диде ул, Зыя бай булып.— Барсын кызың! Үзең дә бар! Тинтәк хатын, ару гына буең-сының белән йөрисең үз кадереңне белмичә. Тәнеңдә җаның юкмы әллә? Барыгыз! Бик кызыклы булачак ди театрлары. Менә мин үзем дә барам...

Рәхим, кичегүдән куркып, кызу-кызу атлап китеп тә барды. Аның артыннан әнисе белән кыз да ияpде. Яшь йөрәк Зөһрәнең куанычы эченә сыймый иде.

Сарайга җитәрәк, Рәхим ашыгып килүче Камилгә очрады:

— Синең арттан бара идем,— диде тегесе.— Әйдә, тиздән сиңа чыгарга. Ник көләсең?!

— Сорама. Барыбер сөйләсәм ышанмассың. Шундый история булып алды хәзер... Үзе бер театр...

— Соңыннан, соңыннан,— диде Камил, Рәхимне ашыктырып,— әйдә, безне көтәләр. Чыгар вакытың җитә.

Алар, кызулатканнан-кызулатып атлый торгач, сарайга килеп тә җиттеләр. Артка, сәхнә ягына узганда, Рәхимнең колагы сарай ишеге төбендә барган бәхәсне һәм шулар арасында таныш Сәрби тавышын тотып алды. Җибәрмиләр тегене.

— Камил иптәш! — диде Рәхим, бик җитди йомыш тапшыргандай итеп,— бар, әйт әле, зинһар, егетләргә, кертсеннәр шул хатынны. Кызын да! Әбизәтелне кертсеннәр!

Камил, аларны Рәхимнең якыннары дип уйлап, ишеккә килде:

— Нәрсә бар?!

— Менә даулаша. Зыя бай үзе кушты дигән була бит... Ә безгә Зариф агай сүзе закон!

Камил берни аңлый алмады.

— Кем кушты дисең?

— Зыя агай,— диде Сәрби,— үзе дә монда китте... әле генә.

— Кертегез! — диде Камил ишектәгеләргә.

Әле генә Рәхимнең «үзе бер театр» дигәне шушы булдымы икәнни? Камил чак кына хахылдап җибәрмәде.

Тар гына итеп ачылган ишек арасыннан кысыла-кысыла, Зөһрәсен житәкләп, Сәрби тәтәй әчкә керде һәм бар нәрсәне дә онытып сәхнәгә карап оеп утыручылар янына күчте...

Спектакль зур уңыш казанды.

Икенче көнне барлык семьяларда сүз гел кичәге «кызыклы театр» турында барды. Сәрбинең ипи чиратында, суга торганда театрда күргәннәрен, ничек итеп Зыя бай белән очрашуын сөйләвен тыңлаучылар шундый кызыкны күрми калуларына үкенештеләр. Спектакльне беренче күргәнгә, тулысынча аңлап бетермәгәннәр дә күп булды. Алар, театрда Зыя бай үзе дә катнашты, дип сөйләделәр...

Бу сүзләр хәзрәткә дә ишетелгәч, ул моңа ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Нәрсә бу? Чынмы? Әгәр чын икән, Зыя байның мондый кыланышын ничек аңларга? Хәйлә! Мотлак хәйлә. Хәзрәт үз мәхәлләсенең терәк баганасы булып саналган, олысын-кечесен кулында тоткан Зыя байны, аның нинди эшләргә сәләтен, тапкырлыгын яхшы белә. «Әлбәттә,— дип уйлады хәзрәт,— шундый заманалар туганда, кеше үзенең тиресен саклап калу өчен ни генә эшләмәс тә, нинди генә кыяфәткә кермәс. Әгәр дә Зыя әфәнде дә шундый гамәл кылган икән...»

Әмма хәзрәт Зыя бай белән мәчеттә очрашып сөйләшкәндә эшнең асылын белгәч, үзе дә кайгыга төште.

— Кара син, йөзе караларны, ә?! Болай булса, һәркайсыбызның сурәтенә кереп халыкны котыртырлар болар...

— Менә шул турыда кайгыртырга кирәк безгә, хәзрәт,— диде Зыя бай,— имеш-мимешләр, «яшен сугулар» белән генә баса алмассың аларны. Ә басарга кирәк, өркетеп кенә калдырмаска. Башкача хәрәкәт заманы хәзер, башкача! Сүздән гамәлгә!..

Тагы бер атнадан урам чатларына яңа афишалар ябыштырылды. Афишаларда, шушындый-шушындый числода, акбур сараенда «Инкыйлаб дулкыннары»ның халык соравы буенча кабат куелачагы хәбәр ителгән иде.

Ләкин бу юлы спектакль була алмыйча калды.

Нәкъ шул көннәрдә шәһәрдәге контрреволюцион көчләр, яшь Совет хөкүмәтенең беренче көннәр кыенлыгыннан файдаланып, фетнә куптардылар. Шәһәр урамнарында тәртипсезлекләр, атыш-кисеш, талау-яндырулар көчәйде. Хәрби-революцион комитет вәкиле Камил белән партячейка секретаре Зариф бистә эшчеләреннән Кызыл Гвардиягә язылган унсигез кешене нарядтан шәһәр большевикларына ярдәмгә ашыктылар. Шундый җай чыгуын гына көткән бистә карагруһчылары, мәхәлләдәге томаналарны котыртып, партячейканы туздырттылар, ә ячейка члены Хасибулланы үтереп ташладылар. Таякның башы аптекчы Кәримгә дә төште. Аны, кызын яшерүдә гаеплап, «кызың, я үзең!» дигән булып, мәдрәсә подвалына ябып куйдылар.

Шулай да бу кан түгешле фетнә кыска гомерле булып чыкты. Бишун көн дигәндә заводлардан агылып торган эшче дружиналары зур бер көчкә әверелгәч, фетнәчеләр һәм аларның башлыклары ак офицерлар, байлар, руханилар — качканы качып котылды, кача алмаганы атылырга хөкем ителде.

Качып котылучылар арасында Зыя бай да бар иде.

* * *

Уй дингезе шундый икән ул!

Аның киңлегенә, тизлегенә тиңләшерлек икенче бер хикмәтле көч бармы икән бу дөньяда?!

Уйласаң, уйларың сине минут эчендә, хәтта секундның ниндидер бер өлешендә, әкият тизлегендә әллә кайларга, бала чагыңа, яшьлегеңә, яшьлегеңдәге вакыйгаларга очыртып илтә. Әйтерсең лә, син икенче кат үзеңнең яшьлегеңә кайтасың. Хәтереңнең күгендә онытылып беткән исемнәрне дә бердән кабындыра ул, хәтта син аларның тавышларына, сулыш алуларына кадәр ишетәсең, шул хәтле якынайта уйлар сине үзганга. Әйтерсең лә, барысы да, барысы да кичә генә, кичә генә булган...

Профессор Зариф Хәмитев белән дә әнә шулай булды. Камил белән телефонда сөйләшеп, трубканы урынына куйган арада, ул үзенең яшьлегенә кайтып килергә дә өлгерде.

Еракта, еракта калган өермәле яшьлеге, әйтерсең, яңадан кайтты. Шулай сиздe үзен Зариф. Бәлки, бу аның дулкынлануыннандыр? Бәлки. Онытылмаган. Бер нәрсә дә онытылмаган.

— Ах, кадерле дусларым, якташларым минем! — дип дәшкәндәй итә ул аларга.— Ничек сагындым мин сезне! Белсәгез иде, ничек сагындым!! Җыеласы иде, зур бәйрәмгә барыбыз да, беребез дә калмыйча — профессоры да, физигы да, химигы да, докторы да, композиторы да, артисты да, язучысы да — җыеласы иде дә төннәр буе, керфек какмыйча, узган героик көннәр легендасына биреләсе иде, ә аннары барыбызга да бергәләп, узган яшьлеккә кайтасы иде дә юлны яңадан башлыйсы иде...

*Март — апрель, 1957*

——□——

*Әмирхан Еники*

# МӘЧЕТ ҖЫЛЫЙ

*Хикәя*

Хәтер сандыгында бик күптән бер нәрсә саклана, — язмыйча котылып булмас, ахрысы, үзеннән... Әйе, кемнәр генә булмадык, ниләр генә күрмәдек без. Аянычын да, көлкесен дә. Сүз бирегә шундый көлкерәк бер әкәмәт вакыйга турында барачак.

1929—30 елның кышында мин өлкә газетасында штаттан тыш репортер булып эшләп йөрдем. Бик яшь идем әле мин ул чакта һәм «репортер» дигән исемне бик зурдан санап, шуның белән үземчә горурланып йөри идем. Асылда исә редакциядә минем урыным да, эшем дә бик кечкенә иде, даими хезмәт хакым да юк иде, редакция кушуы буенча төрле җирдән вак-төяк хәбәр ташып, шулардан килгән бәләкәй генә гонорарга яшәп маташа идем. Ләкин яшьлек дигән нәрсәне беләсез инде, барысына да түзә, барысын да күтәрә ул, ә житмәгәнен хыялы белән тутырырга ярата.

Заманның да бик кызыклы, бик киеренке чагы иде. Бөек борылыш елы!.. Илне индустрияләштерү, авылны колхозлаштыру, кулакларны бетерү — менә нинди зур вакыйгалар башланып китте ул елны... Сыйнфый көрәш гаять кискенләште, бу көрәш тормышның бөтен тармакларына үтеп керде, ни генә эшләнмәсен, барысы да шул көрәш хакына эшләнә торган булды. Мәчетләр мәсьәләсендә дә эш шундыйрак иде. Мәчет — сыйнфый дошман терәге, шуннан ул үзенең зарарлы коткысын таратып ята, бетәргә тиеш аның бу соңгы оясы!.. Әгәр мәчет агачтан икән, аның манарасын шунда ук кисеп төшерделәр. Янәсе, тормасын нечкә ае белән әллә кайлардан күренеп!

Без, газета кешеләре, бу эшне бик хуплап яза торган идек. Хезмәт иясенә мәчет кирәкми, мәчет — дин оясы, ә дин халык өчен әфиюн ул... Мәчетләрне япкач, дин дә бик тиз үзлегеннән бетәргә тиеш, янәсе... Гомумән, без ул чакларда күп нәрсәләр турында бик ансат кына уйлый идек. Теләк көчле, дәрт көчле, менә шуңлыктан бөтен нскене тиз генә аударып, өр-яңаны бастырып куярга без бик атлыгып тора идек.

Ләкин шул кышны Яңа Бистә татарлары арасында гаҗәп сәер бер хәбәр тарала башлый: күптән түгел ябылган шундагы бер мәчет җылап утыра, имеш. Дөресрәге, Ямашев урамы чатындагы таш мәчеттән һәркөнне, караңгы төшкәч, бала елавына охшаган тавыш ишетелә, имеш... Шуны үз колаклары белән ишетүчеләр дә бар икән... Билгеле инде, башта бу уйдырмага берәү дә чынлап ышанмады. Ләкин юньсез хәбәр бит ул яман ис кебек, бер чыкса, тарала да тарала; хәзер инде Яңа Бистәдә генә түгел, бөтен шәһәрдә диярлек шул хакта гына сөйлиләр: мәчет җылый!.. Бәгырьләргә төшәрлек бала тавышы белән мәчет җылап

утыра!.. Һәм тагын иң сәере шунда, бу «жылауны» үз колаклары белән ишетүчеләр көннән-көн күбәя бара. Менә хикмәт!

Ниһаять, бу хәбәр безнең редакциягә дә килеп керә. Күпләр моны, билгеле, көлеп кенә каршы алалар. Һәрнәрсәдән мәзәк табарга яратучылар исә үзләреннән жыен кызык өстәп тә сөйлиләр: янәсе, мәчетнең күз яшьләре яңгыр торбалары буйлап агып төшә, имеш; мәчет жылаганда аның ишек-тәрәзәләре шап та шоп ачыла да ябыла, имеш. Аннары хыялы йөгерек берәү, мәчет үзе жыламый, ә мәчетне япкан чакта чыга алмыйча калган карт мәзин жылап утыра дип тә безне көлдерә. Кыскасы, көлеп сөйләүләр күп була, әмма һәркем бу хәбәргә пустәк нәрсә дип кенә карый.

Ләкин редакциянең жаваплы секретаре Мөрти агай икенче төрлерәк уйлаган булса кирәк. Ничектер бу мине чакырып ала да әйтә:

— Менә нәрсә, егет, — ди, баскан килеш кенә. — Сиңа әйбәт кенә фельетон язарлык бер эш чыгып тора, шуны булдыра алырсыңмы?

— Нинди эш соң ул? — дим мин, гадәтемчә, каушабрак.

Биредә шуны әйтергә кирәк, Мөрти агай, күптәнге газетачы буларак, ара-тирә «Татарстан» битләренә сенсация кузгатырлык мажаралы, шаккатыргыч материаллар жибәргәләргә ярата иде. Миңа да күбрәк шундый материаллар табып китерергә куша иде.

— Ишеткәнсеңдер, — ди бу миңа, — әнә Яңа Бистә обывательләре мәчет жылый дип шау итәләр.

— Әйе, ишеткән идем.

— Менә шул провокацияне фаш итәргә кирәк.

— Ничек итеп?

— Ничек итеп, имеш!.. Их син!.. Репортер сорап торамыни, репортер үзе белергә тиеш.

Мин дәшмәдем, минем әле бөтенесеннән курка торган чагым иде. Ә Мөрти агай шактый коры кеше ул, һич юктан кыздырып, тиргәп ташларга да күп алмый иде. Ләкин шулай да ул мине, үземә сиздермичә, эченнән генә кызгана да шикелле... Еш кына тиргәп ташласа да, китергән хәбәрләремне үз кулы белән төзәтеп, озак яткызмыйча чыгаргалый тора иде... Редакторга да өстемнән зарланган чагы булмады. Үзе дә күреп, белеп тора инде минем хәлемне... Бу юлы да әнә шулай дорфа гына шелтәләп алды да кистереп кенә әйтте:

— Бүген кич шул мәчет янына бар да үз колагың белән тыңлап тор... Кайткач, бернинди мәчетнең жыламаганын, бары контр муллаМонтагайлар чыгарган бер провокацион уйдырма булуын әче генә итеп язып бирерсең. Аңладыңмы?

— Аңладым, — дидем мин, баскан урынымда таптанып.

— Бар, алайса.

Ләкин мин чыгып китәргә ашыкмадым. Куркып кына булса да, сорыйсым килде:

— Әгәр ишетелсә, нишләргә?

— Нәрсә ишетелсә? — диде Мөрти агай, кашларын жыерып.

— Мәчетнең... жылаганы.

Мөрти агай «Бу нинди миңрәү?» дигән төсле гажәпләнеп, азрак кызганып, күбрәк ачу белән миңа бераз карап торды.

— Син әллә шуңа ышанасыңмы, советский репортер?

— Ышанмыйм да бит, тик шулай да...

— Нәрсә шулай да?

Мин жавап бирә алмадым. Бу минутта Мөрти агай: «Булмас бу жебегәннән» дип уйлагандыр бәлки, ләкин ул артык сүз озайтырга теләмичә, боерык биргән сыман коры гына әйтте:

— Бар, кушканны эшлә. Бурычыңны яхшы бел: мәчет жыламый, безгә бу провокацияне фаш итәргә кирәк.

Мин сүзсез генә борылып чыгып киттем. Шулай да эчемнән генә,

нигә бу мине җибәрә инде дип, аңа рәнҗемичә булдыра алмадым. Син ышанмаган кебек, мин дә мәчетнең жылавына ышанмыйм, шулай булгач, нигә әллә кайдагы Яна Бистәләргә барып торырга? Бик кирәк икән, тотарга да шушында гына, Мөрти агай үзе әйткәнчә, контр муллаларны, фанатик карчыкларны, дин исламны — барсын берьюлы тетеп, фаш итеп ташларга! Андый нәрсәләр, редакциядән чыкмыйча гына, бездә аз языламыни?!. Юк, менә аның өчен җәһәннәм астына барырга, ниндидер ташландык, караңгы мәчетне күрергә, җитмәсә, шуның янында катып-туңып, тыңлап торырга кирәк. Әлбәттә, моның кебек мәгънәсез эшкә өлкән сотрудниклардан берәү дә бармаячак, ә минем шикелле малай-репортерны җибәрергә ярый инде...

Мин редакциядән чыкканда, кояшсыз салкын декабрь көне сүнеп тә бара иде инде. Искереп беткән пальтомның өтек якасын күтәреп, ашыга-ашыга Чернышевский буйлап (редакцияләр элек шушы урамда иде) Кольцога төшеп киттем. Күз бәйләнгәнче Яңа Бистәгә барып җитәргә кирәк, чөнки, кешеләрнең әйтүенә караганда, мәчет нәкъ менә караңгы төшкән чакта гына (ягъни икенде-ахшам арасында) жылап ала, имеш. Аннары төн буе көтеп торсаң да тавышын чыгармый, имеш.

Ул елларда Яңа Бистәгә трамвайлар йөрми иде әле. Ләкин бер шәп нәрсә — «барабызлар» күп иде. Үрәчәле чанага ялгыз ат җиккән «барабызлар» Свердлов урамының башында өелешеп торалар. Мин шул чаналарның берсенә килдем дә, сәлам тутырган чыпта капчык өстенә кырын ятып, барабызчы агайга: «Әйдә киттек», — дидем. Билен кызыл билбау белән әйбәтләп буып, тун өстеннән җилбәгәй генә соры чикмән кигән Әлдермеш татары, чанасына аягүрә басып, атын куа-куа мине алып та китте. «Кая барабыз?» дип сорады ул миннән... «Яңа Бистәгә, жылак мәчет янына» дидем мин, ваемсыз гына. Агай аны чыккан мәчетне белә иде, күрәсең, — «Була», — дип кенә куйды.

Бер егерме минуттан без барып та җиттек. Миңа кирәк ак мәчет Ямашев урамы белән бер кыска тыкрыкның чатында тора икән. Агайга унбиш тиенне бирдем дә төшеп калдым... Бу тирәләр миңа шактый таныш, — үткән ел гына мин мондагы мех фабрикасында берәз эшләп киткән идем. Ул фабрика мәчеттән ерак түгел, шул ук Ямашев урамында, татар зыяратына табарак урнашкан. Ә кыска тыкрыкта икенче мех фабрикасы, — ул элек кайсыдыр бер татар баенын сабын заводы булган диләр... Мәчет күршесендә генә, шул фабрика өчен булса кирәк, яңа бер бина салынып ята.

Караңгы тәмам төште диярлек. Инде нишлим, бу серле мәчетнең кайсы ягына чыгыйм дип торганда гына күреп алдым: тар тыкрык чатында, нәкъ мәчеткә каршы, кечкенә бер төркем халык басып тора. Болар анда белмичә тормыйлардыр дип, мин дә шуларга таба атладым һәм берсенә бер сүз катмыйча аз гына читтәрәк тукталдым. Алар минем килеп басканны сизмәделәр дә шикелле... Төркем дигәнем бернничә карт белән карчык һәм бер-ике-өч малай иде. Үзара һични сөйләшмичә тик кенә торалар. Нидер көтәләр. Тәрәзәләре караңгы ак мәчет тә тын гына, боек кына тора... Урам буш, үтеп-сүтеп йөрүчеләр бөтенләй юк диярлек. Тик әле бер яктан, әле икенче яктан бернничә агай һәм бернничә хатын-кыз төркемгә килеп кушылдылар. Исәнләшмәделәр, дәшмәделәр, килделәр дә бастылар. Сабырлыклары җитмәгән малайлар әкрен генә шаулаша башлаганнар иде, аларны шунда ук төрле яктан ысылдап кына тыйдылар... Шактый гына вакыт узды, минем юка оек белән кигән ботинкаларыма бик нык сиздереп суык үтә башлады. Инде тәмам күз дә бәйләнде, ә халык серле, караңгы, тып-тын мәчеткә карап, тавыш-өнсез тора да тора... Мин дә карап торам, бу салкын, таш мәчеттә нәрсә булырга мөмкин дип уйланам, һәм ихтыярсыздан малай чакта (моннан нибары 5—6 ел элек кенә) ишеткән төрле куркыныч әкиятләрне искә төшерәм: сөйлиләр иде, һәр

мәчетнең үз өрәге була, имеш. Өрәк кешегә бер дә күренми, яки бик сирәк кенә күренеп китә икән. Аның тавышы юк, йөргәне һич сизелми, үзе ул кәфенгә урангандай ап-ак, нечкә-озын була, имеш. Аннары тагын ул өрәк дигән нәрсәнең я бик шаяны, я бик явызы да булырга мөмкин, имеш. Шаян өрәк куркыныч түгел, кешегә тими, күбрәк ул кызык өчен, мәчеткә килгән картларның галош-календарларын буташтырып бетерә, мәзиннең манарага менгәндә чабуыннан тарта, хәзрәтнең мөнбәр таягын яшереп куя, имеш. Ә менә явыз өрәк бик хәтәр нәрсә ди, кешенең каршысына ул кинәт кенә килеп чыгып, аның котын алырга ярата ди. Кеше куркуыннан я телдән яза, я дивана булып кала ди. Хәтта үче бар кешене буып та үтергәли ди...

Мин хәзер бу әкиятләрнең берсенә дә ышанмыйм, билгеле, юк нәрсә дип кенә генә, батырайган булып, моның ише шик-куркуларны үземнән куам гына... Дөресрәге, куарга тырышам... Ә шулай да... ни пычагыма басып торам әле мин монда? Бу мәгънәсез көтүдән эчем дә поша башлады, катып-туңып йөрүемә ачуым да килеп китте... Ләкин нәкъ шул чакта төркемнән бер агай кинәт кенә «Чү!» дип куйды, аннары бик шомланып, коты алынган тавыш белән: «Әнә, әнә, ишетәсезме... башлады!» — дип пышылдады. Төркемдәге халык барысы да үлектәй катып, өнсез калдылар. Ә бераздан әле берсе, әле икенчесе: «Ие шул, ие шул, ишетелә, ходавәндә!» диделәр, аларга кушылып бүтәннәр дә: «Мин дә ишеттем, мин дә ишеттем!» дия башладылар. Бер карчык: «Мәчетебез җылый-й!» дип сузып кына шыңшып та җибәрде. Ә башкалар исә кызу-кызу гына пышылдап, белгән догаларын укырга тотындылар.. Ә мин берни дә ишетмим, күпме генә колагымны торгызсам да, юк, һичнәрсә ишетә алмыйм... Аптырагач, янымда басып торган бер агайга: «Чынлап әйтәсезме, мин нигәдер берни дә ишетмим»,— дидем. Агай миңа борылып карады да кырыс кына: «Ә син бүрегеңнең колагын күтәр», — диде. Мин тиз генә малахаемның колагын күтәрдем. Шул чакта тагын берәвесе ачулы гына «Чүгез!» диде, без барыбыз да шым булып тынып калдык. Һәм менә шушы тынлыкта, — кеше әйтеп кеше ышанмас, — минем колагыма да, ниһаять, нидер килеп ишетелде. Башта ышанмыйчарак тордым, ләкин... ишетәм бит, чәнчелеп китим, ишетәм! Чынлап та «и-и-и» дип бик нечкә генә сузып, әкрен генә җылаган тавыш!.. Бала җылавына охшаган, әмма сабый баланыкына караганда да нечкәрәк тавыш!.. Кайдан килә бу? Һичшиксез, мәчеттән, ләкин бинасы эченнән түгел, ә каяндыр югарыдан, түбә-кыек тирәсеннән килә, — шулай ишетелде миңа... Мин берьюлы аптырап та, шомланып та, куркып та калдым, әмма һич шик юк ки, җылаган тавыш бар, мин моны бер түгел, берничә тапкыр үземнең тырпайган колакларым белән ишеттем. Әллә галлюцинация микән бу? Алай дисәң, ишетүем бик ачык, кат-кат, галлюцинация шулай буламы икән соң? Аннары мондагы бөтен кешеләр дә ишетеп торалар ич, барыбызның да берьюлы алдануы мөмкин түгелдер бит инде!.. Димәк, тавыш бар, тавыш ишетелә һәм нәкъ менә җылаган тавыш!.. Ләкин ничек инде мәчетнең җылавына ышанырга мөмкин ди? Акылга сыймый ич бу... Алайса, мәчетнең эчендә нәрсәдер бар, нәрсәдер куйганнар анда...

Мәчетнең «җылавы», бүленгәләп, бер ун минут чамасы дәвам иткәндер, аннары ул тынды, ахрысы, бөтенләйгә тынды... Чөнки тавыш ишетелми башлагач та халык, сеанс тәмам дигәндәй, куркынып һәм укынып, тизрәк таралып та бетте. Ә мин баскан урынымда торып калдым. Кузгалырга көчем җитмичә, ихтыярсыздан торып калдым... Мин бик аптырауда идем, ни уйларга да, ни эшләргә дә белми идем. Әгәр кайтып, Мөрти агайга, үз колагым белән ишеттем дип әйтсәм, ул мине шул ук көнне редакциядән куачак, валлаһи, куачак. Конторлар провокациясенә бирелгәнсең, чыпык! — диячәк. Газетада эшләргә ярамыйсың, булмый, мәгънә чыкмый синнән, диячәк. Инде ышана кал-

са, нигә колагың белән ишеткәнне күзең белән күреп кайтмадың дип җаныма тиячәк. Бу очракта бигрәк тә — чөнки ул да мәчет эчендә нидер бар, нәрсәдер куелган дип уйлаячак. Аныңча бит, репортер дигән кемсә бөтен нәрсәнең төбенә үзе төшәргә, үзе күрергә, үзе белергә тиеш...

Нишләргә соң, ә?.. Вәт сиңа мәсьәлә, шайтан алгыры! Инде катыптуңып та беттем, дер-дер калтырый да башладым, ә торам, казыкка бәйләнгән тай шикелле селкенеп-таптанып торам да торам... Үзем мәчеткә карыйм, куркыныч ул миңа, үзенең серле тынлыгы, караңгы зурлыгы белән шомландыра, куркыта ул мине... Ә китеп булмый, китсәм, миңа тагы да начаррак булыр төсле. Ахырда чарасыздан бөтен шик-шөбһәләргә кул селтәп, мин катгый бер карарга килдем: керергә, бу серле-шомлы мәчетнең эчен бер әйләнеп, карап чыгарга кирәк. Ни булса ул! Әйе, ни булса ул!.. Ашамас әле таш мәчет, йотмас, әйләнеп чыгармын әле ничек тә, тик каушамаска, каушамаска гына кирәк. Егет кеше ләбаса мин!

Ләкин шулай батыраеп урынымнан кузгалуым булды, минем алга шунда ук беренче кыенлык та килеп басты: хәзер төн бит инде, мәчет эче дөм-караңгыдыр, утсыз-нисез нәрсә генә күрә алырмын мин?! Димәк, кермичә кайтып китәргә дә була, ут юк, вәссәлам!

Мөрти агай үзе дә дөм-караңгы мәчет эченә кереп тормас иде, билгеле... Әмма ни өчендер минем бу сылтаудан тизрәк файдаланасым килмәде, тәвәккәлләгән эштән ансат кына баш тарту ничектер уңайсыз булып тоелды.

Менә күзем мәчет күршесендә салынып яткан бинаның каравыл будкасына төште. Туктале, мин әйтәм, каравылчы янына кереп карыйм, аның фонаре булырга тиеш, биреп тормасмы... Булмаса инде, икенче мәсьәлә... Шулай уйлап, урам аша чыктым да такта будкага барып кердем. Каравылчы абзый бик әйбәт урнашкан икән, — будканың нәкъ уртасында, җир идәндә кечкенә чуен мич гүләп янып тора, ә абзый шуның каршында тун чабуларын кайтарып, аякларын аерып, ботларын ышкый-ышкый җылынып утыра.

— Исәнмесез, абзый, — мин әйтәм.

Абзый миңа кырын гына күз ташлап алды, көттереп һәм мыгырданып кына:

— Исән әле, чынлап сорасаң, — дип куйды.

— Җылы икән сезнең монда, — дидем мин, чакыруны да көтмичә тизрәк чуен мич янына узып; әх, үткән икән шул суык үзәккә...

Абзый дәшмәде, тик шактый гаҗәпләнеп һәм шикле сынап, миңа баштанаяк бер сөзеп кенә карап алды. Күрәм, минем вакытсыз килеп керүем абзыйга бер дә ошамады. Аның мине, бөтенләй ят кешене, хәзер үк будкасыннан җилтерәтеп куып да яки тревога күтәреп бирәр этлек эшләве дә мөмкин иде. Ләкин минем бик туңган булуым һәм балаларча әрсезлегем аны бераз аптырашта калдырды шикелле.

Шулай да мин абзый үзе телгә килгәнче йомышымны әйтергә ашыктым.

— Абзый кеше, тыңласагыз, минем сезгә бер йомышым бар иде.

— Нинди йомыш?

— Сезнең анә стенада «яркканат» фонаре эленеп тора. Шул фонарьны миңа биреп торсагыз иде... Әлбәттә, вакытлыча гына...

— Нигә ул сиңа?

Минем алдан әзерләп куйган бер хәйләм дә юк иде, шул сәбәпле дөресен генә әйтергә туры килде:

— Мин ни... менә мәчеткә кереп чыкмакчы идем.

— Мәчеткә? Нинди мәчеткә?

— Шушы сезнең күршедәге мәчеткә.

Абзый, тиз генә сүз таба алмагандай, күзләрен шарландырып, миңа

беравык тик кенә карап торды. Гаҗәпләнүе аның гүя чиктән ашкан иде.

— Син нәрсә, энекәш, — диде ул, ниһаять, әкрен-усал гына, — әллә бераз салып килдеңме?

— Юк, нишләп, салыйм, ап-айнык мин.

— Соң!.. Әллә башың икеме?

— Юк, башым да берәү генә, — дидем мин, елмаерга тырышып.

— Берәү генә булса, йөрмә монда... Үкчәңне күтәр. Син, ахрысы, ул мәчеттә нинди хикмәт барын ишетмәгәнсең әле.

— Ишеттем шул... Ә менә хәзер нәрсә барын кереп беләсем килә.

Абзый, кызып, кискен генә кулын селтәде:

— Әйдә, әйдә, йөрмә, кит моннан... Бетмәс монда сезнең эше суга... «батырлар».

Абзыйның бу хәтле сыртын кабартып, кире торуы мине чынлап борчый башлады. Ахрысы, мәсьәләне аңа ачыграк, житдирәк итеп төшендермичә булмас.

— Син, абзый, мине куарга ашыкма әле, башта әйбәт кенә тыңла, — дидем мин, ничек тә юмалап, иплэп кенә. — Мин редакциядән килгән кеше, миңа газета редакциясе сезнең мәчеттә нәрсә барын белеп кайтырга кушты. Ышанмасагыз, менә минем документым. Так што, сезгә куркып торырга урын юк, барысы өчен дә үзем җавап бирәм. Фонарегыз өчен дә курыкмагыз, киракса, менә акча калдырып торам... Ә газета заданиесен үтәргә кирәк, үтәмичә ярамый, белдегезме?

«Газета» дигән сүзнең тәэсире ул заманда мәчет җылавыннан бер дә ким түгел иде, — абзый шактый йомшарып киткәндәй булды. Шулай да ул тиз генә бирешергә теләмәде:

— Килгәнсең икән, бар кер, нигә мине борчып йөрисең, — диде бу, мыгырданып кына.

— Миңа фонарь кирәк, фонарьсыз мин анда нәрсә күрим? Син инде, агай-эне, мине заданиене үтәмичә кайтып китәргә мәҗбүр итмә... Каравылчы фонарен бирмәде дисәм, сиңа да рәхмәт әйтмәсләр.

— Их, парин! — диде абзый, чын-чыннан ачынып, — үз башыгызга бәла алу гына түгел, кешегә дә зыян-зәхмәт ясап йөрисез.

— Син, абзый, борчылма, бернинди зыян да, зәхмәт тә булмас сиңа... ун минуттан фонареңны исән-сау китереп бирермен.

— Бирерсең, башыңны алып чыксаң.

— Һи, чыгабыз аны, — дигән булдым мин, көлеп. — Нык утыра баш, тәгәрәп төшәрлек түгел... Әле без синең белән шушы мич алдында тәмләп кенә тәмәке көйрәтә-көйрәтә, мәчеттә күргәннәрне сөйләшеп утырырбыз.

Абзый авыр гына сулап, урыныннан кузгалды, ашыкмыйча гына фонарен чөйдән алып бирде. Бөтен хәрәкәте аның бу эшкә минем катнашым юк, бары мәҗбүр булганга күрә генә дип әйтеп тора иде кебек. Мин фонарьны урындыкка куеп яндырдым да, борылып чыга башладым. Шул чакта абзый түземдәе, кыюсыз гына минем арттан: «Денсез булсаң да, белгән догаларыңны укырга онытма!» — дип калды.

— Рәхмәт, абзый, онытмам, — дидем мин, ишекне ябып.

Урамда адәм заты түгел, эт тә юк иде. Аяк астымда чайкалган фонарь яктысына карап, мин ашыга-ашыга мәчеткә таба киттем. Мәчеткә керә торган ишек ихата эчендә икән. Ярый, капка ачык булып чыкты, ишек алдына уздым. Ләкин мәчетнең яшел тимер ишеге зур йозак белән бикле иде. Мин йозакны тотып та, яктыртып та караган булдым: димәк, мәчетнең үзенә керү мөмкин түгел... Гап-гади, әмма репортер башы уйлый белмәгән киртәләр чыга да тора. Нишләргә?.. Аптырап сулга борылган идем, тагын бер кечкенә яшел ишекне күреп алдым. Анысының йозагы юк иде. Бу манарага менә торган ишек булырга тиеш... Туктале, мин әйтәм, теге җылау тавышы

мәчетнең эченнән түгел, ә каяндыр югарыдан, чорма тирәсеннән ишетелгән иде бит... Мөгаен, бу манарага менә торган баскыч белән чормага да үтеп була торгандыр. Һич югы шунда менеп карыйм әле... Артык уйланып тормыйча кечкенә ишекне ачып җибәрүем булды — нәкъ каршымда бер озын ак нәрсә күренде: бу ни бу, өрәкме әллә?! Фу, нәләт, стенага сөяп куйган, мәет юа торган ак кабык икән лә!.. Йөрәк жу-у итеп китте. Яшен тизлеге белән хыялымнан бу кабыкта юылган мәетләр үтеп киткәндәй булды... Хәтта ул менә хәзер минем өстемә авар шикелле булып тоелды. Мин ихтыярсыздан бер адым артка чигендем, ләкин ишекне япмадым. Беренче курку шулай бөтен тәнем буйлап йөгереп узганнан соң, мин бераз исемә килдем. Тынычлана төштем. Аннары, нигә мин бу кабыктан шулхәтле шыр җибәрдем әле, җансыз нәрсә ич ул, әкәмәт! — дип үземне юатырга тырыштым һәм батыраеп янадан эчкәре атладым. Кабыкны читләтебрәк уздым да, борылмалы тимер баскычтан песи төсле тиз-тиз генә югары менеп киттем. Азрак менгәч тә уң кулда тагын бер тәбәнәк кенә такта ишек күренде. Бу, билгеле, чормага үтә торган ишек булырга тиеш иде... Мин шул ишекне әкрен генә ачып, алдан фонаремны сузып, кыек астына атладым. Һәм, кирәк бит, мәчетнең туфраклы түшәменә аяк басуым булды — минем фонарем кыек астында урап йөргән кискен җилдән бер-ике тапкыр гына пылт-пылт итте дә сүнде. Мин дөм-караңгыда калдым. Ашыгып, әле бер кесәмә, әле икенче кесәмә тыгылдым, ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, шырпымны каравылчы будкасында, фонарьны кабызган чакта онытып калдырганмын икән ләбаса! Инде нишләргә? Зиһенемне җыя алмыйча багана төсле катып торам, тизрәк, яхшы чакта кире борыласым килә, әмма аягымны кузгату түгел, аз гына селкенергә дә куркам, көчем җитми. Бу караңгыда ничек төшәрмен дә ничек итеп теге кабык яныннан узармын?! Ай-яй! Һәм, ышанасызмы, нәкъ менә шул чакта чорманың түр почмагыннан бик ачык булып әлеге бала жылаган сыман нечкә тавыш ишетелмәсенме: и-и-ии!.. Әтекәем, әнекәем, әбекәем!.. Чәч үрә тора дип ишеткәнем бар иде, белмим, үрә торгандырмы-юктырмы, әмма баш тиресе тартышып, чәч төпләрем сап-салкын булып китте... Тезләрем бөтенләй сыгыла башлады... Әгәр шуннан тагын ишетелә калса?! Чәчең генә түгел... алла сакласын!..

Ташка әйләнгәндәй торам, көтәм, ләкин юк, ишетелми, тып-тын, бары тик җил генә әйләнеп, выжлап йөри. Кайдан соң бу җиле тагын? Игътибар беләнрәк карасам, чорманың урам башында тонык кына бер яктылык күренә. Анда төнлек тәрәзәсе булса кирәк, ул, билгеле, ватыктыр инде... Әшәке җил әнә шуннан исә икән.

Теге жылау тавышы янадан ишетелмәгәч, минем котларым алынып куркуым әзрәк узгандай булды. Мин тынычланыбрак уйлый башладым: димәк, монда нидер бар. Шикләнергә урын калмады — бар, һичшиксез, бар! Әмма нәрсә икән соң ул? Үзлегеннән тавыш чыгара торган берәр механизм куйганнармы, әллә берәр җәнлек-мазар чыелдыймы? Җәнлек дисән, аның йөрү-хәрәкәте ничектер сизелергә тиеш иде. Ә бу бары «жылап кына» ала да тына, бүтән бер шылт иткән тавыш та чыгармый... Я, нәрсә булырга мөмкин? Ничек кенә белергә моны?.. Әллә шул тавыш килгән җиргә әкрен генә барып карыйсы микән? Чыннап та ни булыр икән, әгәр... шунда таба атласам? Әйе, ни булыр? Ә бәлки берни дә булмас, шайтан алгыры!.. Гаҗәп, адәм баласында кызыксыну дигән нәрсә куркудан да көчлерәк икән, — шул чакта моны мин бик ачык сиздем. Һәм шушы кызыксыну мине гүя аркан белән тарта башлады: үз-үземә хисап та биреп тормыйча, тәвәккәлләп мин әлеге шомлы почмакка таба атладым. Аягымны шудырып кына бер атладым, ике атладым, аннары кыюлана төшеп, аякны күтәребрәк тагын атлаган идем, кинәт ниндидер юан бер нәрсәгә абынып та киттем. Каһәр генә суксын, түшәмгә аркылы салынган өрлек

икән бу... Кулымнан шалтырап фонарем очты, үзем гөрс итеп йомшак туфракка капландым. Җан саклаган чакта гына була торган тизлек белән үз-үземне белештермичә сикереп торуым булды — каяндыр шунда кыек буеннан гына нәрсәдер фырылдап күтәрелде. Кош! Ходавәндә, кош ич бу, кош! Менә ул канатларын шап-шоп селкеп, пырылдап кыек астында бер-ике әйләнде дә, әлеге урамга караган ватык тәрәзәдән тышка очып чыгып та китте. Бу тамашадан күпме вакыт өнсез калып торуымны һич әйтә алмыйм, ләкин шуны ачык беләм, мин курку тоймадым, куркуны тоюдан узган идем. Барысы да шулхәтле кинәт булды ки, мин хәтта һичнәрсә уйларга да өлгермичә калдым. Тик бераздан исемә килгәч кенә мине курку-шомлану калтыратып җибәргәндәй итте, ләкин бу соңга калган курку иде инде — ул мине артык тетрәтмәде.

Тагын берәр нәрсә ишетелмәсме дип, мин күпмедер вакыт селкенмичә басып тордым. Тын, караңгы, җил өргәли, әмма бернинди тавыш та, өн дә юк. Алайса бөтен хикмәт шул кошта булса кирәк. Бик сәер, гаҗәп иде бу, ләкин башкача тагын нәрсә уйларга, нәрсә көтәргә мөмкин?!.

Ахырда мин кузгалырга булдым. Башта аягым белән капшанып, фонарьны табып алдым, аннары борылып, бик саклык белән чорма ишегенә таба киттем. Шушы минутта мине, артымда кемдер, нидер бар шикелле, тагын курку-шомлану биләп алды. Ирексездән ашыгып, ишеккә килдем, тизрәк баскычка чыктым һәм, даң-доң басып, түбән төштем. Әлеге зур кабык янынннан тын алырга да куркып, тиз генә уздым да кечкенә яшел ишекне шап иттереп яптым. Кар яктысына чыккач, башта өстемне каккаладым, шуннан соң каравылчы будкасына кереп, абзыйга фонарен бирдем:

— Менә, абзый, фонарең исән-сау, — дидем мин, үземә дә әллә ничек ят тоелган сәер тавыш белән.

Абзый миңа, өрәккә караган шикелле, телдән калып, күзләрен чекрәйтеп карап тора башлады. Аннары минем тирләп тунган ат шикелле калтыравуымны күреп, кашларын җыерыбрак җитди генә:

— Кил, утыр, җылын! — диде.

— Юк, мин өшемәдем, абзый, — дидем мин, бөрешкән авызымны ерырга тырышып. Чыннан да мин бу минутта өшү-туңуны һич сизми идем. Шуңа күрә абзыйга рәхмәтемне әйтеп, тизрәк чыгып китәргә ашыктым.

Яңа Бистәнең тын, буш урамнары буйлап атлаган чакта мин үземнең бик нык ачыккан һәм эттәй ватылган булуымны тойдым. Әзрәк кенә исерә төшкәндәй чалыш-чолыш атлабрак Пеләтән урамына чыктым, аннары Тукай урамына җитеп, тәрәзәләре агарып туңган трамвайга утырдым... Утыргач та ничектер йокы баса башлаган кебек булды...

Мәскәүский (хәзерге Киров урамы) чатына житкәч, мин трамвайдан төшеп калдым да «Сарай» номерларының ашханәсенә кердем. Монда торганы татар агай-энесе... Җылы пар, төтен, шау-шу эчендә утырып, шул агай-энегә: «Сез белмисез әле минем кайда булуымны, кәпәчләр!» — дигән төсле горур гына карап, бик әйбәтләп, сыралап, туйганчы пилмән ашадым. Аннары көчкә генә кузгалып, үземнең Суконныйдагы тар, ялгыз бүлмәмә кайтып киттем.

* * *

Икенче көнне мин редакциягә бернәрсә язмыйча буш кул белән генә бардым. Язарга вакытым да, хәлем дә булмады. Күрәсең, бик нык салкын үткәндер инде, төн буена калтырап, туңып, янып чыктым. Редакциягә килгәч тә туп-туры Мөрти агай янына кердем:

— Я, нәрсә китердең? — дип каршы алды ул мине.

Мин аңа түкми-чәчми бөтен күргәнемне сөйләп бирдем... Бу миңа ышанылгамы, юкмы дигәндәй бераз дәшми генә карап торды да, җилкәсен кашып алды, авыз эченнән генә нидер мыгырданып куйды, бары шуннан соң гына телефон трубкасына тотынды. Университетның зоология кабинетына шалтыратып, шундагы кем беләндер сөйләшә башлады. Мин шәкерт сыман тик кенә тыңлап утырдым.

Мөрти агай теге кешегә мәсьәләне кыскача гына аңлатып бирде дә: «Әйтегезче, шундый бала жылавына охшатыбрак кычкыра торган кош бармы, булса — нинди кош ул, безнең бу тирәдә очрыймы?» дип сорады. Зоология кабинетыннан болай дип җавап бирделәр: «Әйе, бала жылавына охшаганрак нечкә тавыш белән кычкыручы кош бар. Ул — филин, безнеңчә — төнге ябалак. Урманда яши торган кош, ләкин бик сирәк кенә авыл-шәһәр эчендәге кайбер ташландык биналарга да килеп оялый. Сезнең мәчеттәге кош әнә шул төнге ябалак булырга тиеш».

Мөрти агай рәхмәт әйтеп трубкасын куйды да миңа: «Кара син бу малайны», дигәндәй бераз сәерсенеп карап торды, аннары саран гына елмайды:

— Молодец, энекәш, заданиене әйбәт үтәгәнсең, — диде. — Ә хәзер бар, ике-өч битлек кенә фельетон язып китер... Тозлап-борычлап яз, мәчет жылый дип провокация таратучы обывательләрнең авызын томаларлык булсын.

Ләкин ни сәбәптәндер мин ул чакта фельетонны яза алмадым. Бик тырышып утырсам да, чыкмады миннән ул фельетон. Иң кирәге үтәлмичә өстемдә калды. Тик менә күпме еллар узгач кына минем аны, ниһаять, язып котыласым килде.

*1967 ел, май.*

*Хисам Камалов*

# КҮҢЕЛДӘГЕ ЯЗУЛАР

## *Эскизлар*

...Кеше бит ул һәрчак шулай инде,
Икмәк белән генә тук тормый;
Нидер җитми аңа, миллион теләк
Мәче кебек җанын гел тырный.
Яшәп булмый гамьсез, тыныч кына.
Алга бара тормыш, алышына.
Бәяләүләр еш үзгәреп тора:
Яңалыклар баса каршына.
Яңалыкны кайчак сизеп булмый,
Аның яшерен, эчке көчләрен.
Акылың белән болай аңлыйсың күк,
Консерватор була хисләрең.
Тәрле-төрле уйлар кылычы мине
Кисеп тора, җаным айкатып.
Капма-каршы фикер өермәсе
Белән тула башым кайвакыт.
Шул тартыштан арып, хәлдән тайгач,
Мин Ленинга барып сыенам.
Аның белән киңәшләшсәм генә,
Җанны телгән уйлар җуела!
Укыган саен аның китапларын
Фикер ирегем арта тагын да.
Мине изеп торган кара көчтән
Җаным минем тизрәк арына.
Үз-үземә ышанычым арта,
Офыкларым гүя киңәя.
Мин яңарып киткән кебек булам,
Өметләрем тагы күбәя.

1

Төн уртасы.
Эшләп утыра Ленин.
Зарур эшләр шулай нык тота,
Мең ихтыяҗ бугазларга ябыша,
Нервыларны тетеп, йончыта.
Дзержинскийны ал,
Нигә охшап калды ул хәзер?
Көрәшләргә үзен сарыф итеп,
Ябып бетә шәмдәй бермә-бер!
Әйдә, безгә булсын бар авырлык,
Бу тартышта калсак аумыйча,
Россияне — газиз туган илне
Төзәр идек бер дә армыйча.
Тик кытлыктан ничек чыгарга соң?
Төрле яктан изә, яралый,

Җинеп барган көчне ул хаостан
Ашатырга ләкин ярамый.
Соң нишләргә? Авыр хәзергесе!
Ә киләчәк түгел еракта.
Булса иде безнең тракторлар,
Эшләр идек менә шул чакта!
Елгаларга ГЭСлар салыргае,
Караңгылык бетсен, җиңелсен.
Эх!
Юк шул әле, юк шул, хәлләр мөшкел.
Их, Россия нинди кыен син!
Сарык өзгәләгән бүреләрдәй
Интервентлар илне өзгәли.
Тик Россия — мескен ана, түзә,
Берниндн ил моңа түзәлми.
Эх, Россия, авыр язмышлы ил:
Шуна авыр синең улларга.
Җанны учка шытырдатып кысып,
Тик чыдарга кирәк, чыдарга.

...Бер минутка күзне эштән алсаң,
Ник хыяллар уйны күмә соң?
Юк, юк! Монда бик кирәкле хат бар,
Укылмыйча кала күрмәсен,
Йокы кермәс. Әһә, Коллантайдан.
Авыр инде, авыр аңа да.
Ильич укый.
Бер егетнең хәлен
Кайгырткан ул шәфкать-анадай.
Ильичны да бөтереп ала шушы
Таныш түгел егет язмышы.
Бу мәхшәрдә аера белү — байлык
Дус, дошманны! Ә бу яшь кеше.
Һәм записка яза ВЧКага,
Төнге ике. Аттай арылган.
Кеше гомерен хәл иткәндә, Ленин
Җанын әзер меңгә ярырга.
«...Тотылган ул
Сугыш барган җиргә үткәндә,
Анда энисе бүленеп калган икән,
Юденичлар һөҗүм иткәндә.
Ә Коллантай аны яхшы белә,
Шуны әйтә аңа карата —
Бик тәэсирчән, сәясәтсез егет,
Һәм энисен үлеп ярата.
Бу тарихка килеп уралган ул
Акылсызлык белән. Шундый хәл.
Атарлар дип Коллантай бик курка,
Туктатырга юкмы бер әмәл?!..»

...Бүген күпме эш башкарган Ильич?!
Хәлдән таеп кайткан өенә.
Кешеләрне кайгыртудан ләкин
Тукталмаган арган көе дә.
Ил язмышы кыл өстендә тора,
Мең зарурлык суыра җилекне.
Ул шунда да кеше язмышына
Игътибарын һич тә киметми.

Берәү булса, монда күрер иде
Мәми авыз, иркә бер егет,
Яисә әйтер иде маскаланган
Ак шпион, шикле бу, диеп.
Ильич белә тормыштагы хәлләр
Күтелмәгән агыш алуын.
Котылмаслык хәлләрдә дә кешенең
Теләгән ул исән калуын.
Статистик берәмлек күк итеп
Карамаган Ильич кешегә.
Һәр җанлыга мәрхәмәтле хөрмәт
Саклаган ул — дәүгә, кечегә.
Юк, юк,
Түгел Ильич гуманлыгы барысын
Гафу итү! Ерак күргән ул!
Көрәшләрдә дусны дошманнардан
Даһиларча аера белгән ул.

2

Хөрмәтле Ильич,
Мин унсигез яшьтә
Зур сугышта йөрдем, гел утта.
Гомеремнең иң-иң матур чагы —
Үсмер чагым үтте окопта.
Ниләр генә анда күрмәдем мин?
Кан, яшь түктем, көйдем ачынып;
Кешеләрнең күрдем бөеклеген,
Түбәнлеген күрдем кайсының.
Сугышта бит кешенең яшерен эче,
Бөтен ягы бик тиз беленә.
Ул хәйләли алмый, карамыйлар
Кешенең мут, купшы теленә.
Тик эш белән генә күрсәтәлә
Туган илгә тугры булуын...
Кыен иде
Өйрәтелгән ерткыч —
Фашистларга каршы торуы.
Курку дигән нәрсә бар бит җанда.
Шул бетерә кешене... эх, шуны!
Сугышта бит иң бәхетле кеше —
Җиңә алган кеше куркуны!
Курку дигән шул «генерал», каһәр,
Чигендерә иартеп үзенә.
Син чын солдат — шуны җиңсәң генә
Ышанычлы.
Үлем күзенә
Туры карап, алга бараласың...
Бер кич шулай латыш җирендә,
Атакага
Дошман килгән чакта,
Яшьтәш куркып, артка чигенгән.
Ташлап качкан позициясен ул —
Бизгәк тотты гүя взводны.
Сугыш тынгач, бер штабист аның
Погоннарын умырып ыргытты.
Яшьтәш, мескен, нишләргә дә белми,
Әй, үкенә, ага күз яше...

Тик замполит аны йолып калды,
Жанны анлый торган үз кеше.
Ул өймәде бар гаепне аңа,
Үз өстенә алды күбесен.
Тиз туктатты, «трибуналга!» диеп
Хиреслэнгэн штаб кешесен:
— Мәктәпләрдә без тәрбия иттек
Кыен булмас диеп сугышта;
Киноларда дошман юк ителде
Бүрек белән генә сугып та.
Моны да без онытмыйк, дус кеше,
Ачыбрак карыйк күзләрне
Хакыйкатькә!
Шуны аңларга безгә
Ярдәм итә Ильич сүзләре:
...Бераүләрне сугыш чыныктыра,
Тойгыларын, аңын агарта;
Ә бер ишнең күнелен сындыра да
Түбән төшерә аны, каралта;
Һәрбер кризис кеше тормышында
Шулай итеп сыный кешене...
...Бу фикерләр аңга сеңеп калды,
Һәм соңыннан белдем, төшенеп
Сүзләренең аслын, зур чынлыгын...
Кич сугышта яраландым мин,
Авыр булды, газапларга баедым,
Шатлыкларга саранландым мин.
Зарланмадым, яшәү — уен түгел,
Ә яшәргә кирәк үлгәнче;
Көрәшергә — бар көченне жигеп,
Көрәшергә — гүргә кергәнче!

Ә замполит мәнге истә калды.
Әллә хаклык дәресе биргәнгә,
Авыр хәлгә калгач, мөшкеллектә,
Игелеген аның күргәнгә!
Ул алдауны, купшы сүзне сөйми,
Хаклык өчен көя иде гел.
Зур максатка төренсә дә ялган,
Бик зарарлы, дия иде гел.
Тыштан болай ягымлы да түгел,
Сөйләшкәндә йөзенә нур чыга.
Кыр сумкасы, хәрби киеме белән
Охшый иде ул бер кырчыга.
Ә эчендә — кешеләргә игелек
Катлам-катлам ята, файдалан!
(Гомерем белән мин дә бурычлы аңа!)
Кешелеген жуймас кайда да!
Кадерле Ильич, синең сыйфатларны
Күреп анда, ныграк ышандым.
Һәр нәрсәдән өмет өзгән чакта,
Шундыйларга карап көч алдым.
Ана тормыш жинел булмагандыр,
Кайда икән хәзер замполит?
Бер иптәшләр суды башындамы?
Житәклиме әллә сельсовет?

...Шундый ачы
Окоп хакыйкатен
Язган идем мин бу шигырьдә.
Күпме газап кичергәнне шунда...
Мин ялганлый белмим шул бер дә!
Тик кемгәдер шигырь ошамады.
Җыелышта мине теттеләр.
Бер якта мин, әллә дусларым да
Җил ягына авышып беттеләр?
— Булмаса да гаебең, таны, диеп,
Үз үгетен түрә үткәрә, —
Танысаң сиңа җиңел шелтә була,
Танымасаң үзеңә үпкәлә!
Ә мин дәшәлмадым... Дөреслектән
Кайталмый бит йөрәк барыбер... —
Мин үземне яклап чыгалмадым,
Шуңа җаным үзен каргый гел.
Әмма шунда
Ап-ак чәчле абый
Күтәрелде мине якларга.
Аралады эшне ваклыклардан,
Теләмәде беркем белән дә ул
Дуслык сакларга.
Хаклык өчен янып сөйләде ул,
Бу күренешкә ачуы тулганга...
Әй, сөендем шул чак,
Үзем өчен түгел,
Замполитлар исән булганга!

3

Ә Ленинга нинди кыен булган!
Белгертмәгән авыр хисен дә.
Кай дуслары эшне өзгән чакта,
Үчләнмәгән, авыр күрсенгән.
Нинди авыр — дусның аңламавы
Йөрәк өзгеч кирәк бер чакта;
Нинди авыр — юллар аерылуы
Икенә дә таныш бер чатта?!
Нинди авыр мин-минлеге өчен
Дусның сине тетеп салуы;
Дошманнарың шуны сиңа каршы
Сөенә-сөенә файдалануы?!
Эх!
...Йөз кешелек эшне, атом кебек,
Тик берүзе ничек башкарган?
Ай-ай, күпме туры килгән аңа
Борчылырга тинтәк башлардан?!
Сүнгән мотор кебек җаннар белән
Туры килгән күпме эшләргә?..
Ленин, рухи юмартлыгы белән,
Чаткы биреп торган кешеләргә!
Акылы күпнең кайгысы күп була,
Кайгысы күп булган Ленинның
Кайгыларны бетерү өчен көрәш —
Шатлыгы шул һәрбер кенеңең!

4

Кадерле Ильич, ниндирәк иде
Син хыялда йөрткән егетләр?
Килер көрәшләрдә җиңү өчен
Кирәк иде нинди беркетләр?
Нинди баһадирлар узды икән
Ул чагында синең уеңнан?
Мин аларны бик күп табам бүген,
Табам, Ильич, безнең буыннан.
Күкрәк белән ут дзотын капла! —
Дип беркем дә
Газинурга әмер бирмәгән.
Үзен саклап кала алыр иде,
Уена да ләкин кирмәгән!
Муса Җәлил дошман өнендә дә
Тиңсез көрәш юлын сайлаган.
Мөмкин булган аңа яшәп калу! —
Җан саклауны түбән санаган!
Күбәләкләр утка аңсыз керә,
Һәлак була шуның көлендә...
Ә Мусалар аңлап көрәшкәннәр,
Һәм барганнар аңлап үлемгә!
Бөек Париж коммунарларыдай
Сыйныф өчен һәлак булучы,
Туган җирнең изге азатлыгын
Бар нәрсәдән өстен куючы
Фидакарьләр иде алар!
Кешеләргә бәхет китерүче,
Шәхси яшәүләрне инкарь итеп,
Үлемнең дә йөзенә төкерүче
Каһарманнар иде алар!
Бирелмәде алар дошманга,
Кеше батыр була,
Мәҗбүр итеп түгел,
Ә намусы шулай кушканга!

... Без карында гына идек әле
Син Ватанны төзеп йөргәндә.
Ә Россия билен,
Кан төшкәндәй,
Көчкә яза иде ул көннәрдә.
Менә без дә бу дөньяга килдек!
Шатландырдык микән без илне?
Син күрергә теләп зарыгып торган
Кешеләрме без, әллә түгелме?
Теләгеннең тик бик әзен генә
Акладыкмы без бу заманда?
Синең киңәш безгә көн дә кирәк,
Тик алай да килә таманга.
Кеше аягы әле һич басмаган
Җирләрдән без алга барабыз;
Ялгышабыз, ялгышлардан һаман
Тик тәҗрибә, акыл алабыз.
Синең идеяләр кайнарлыгын
Сүрелдерми барып җаннарда, —
Хезмәт белән күбрәк кайнашабыз,
Тырышабыз әзрәк шауларга!

5

...Хөрмәтле Ильич, мәнә булган хәлне
Киңәш сорап сөйлим бу төштә.
Минем бер дус мине гаепли гел
Уңмавында үзенең һәр эштә.
Техникумны бергә бетердек без.
Ни булса да бергә яшәргә
Диган идек,
Ләкин ул авылга билгеләнде.
Ә мин — шәһәргә.
Ул кимсенде, шул этәрде бугай
Нәтиҗәне кискен ясарга:
— Аердылар, — диде, — ике якка:
Син — яхшыга, ә мин — начарга!
Көтелмәгән удар кебек шуны
Кабул итте, авыр кичерде.
Яшь чагында һәрбер юк-бар кайгы
Шулай кыен тоела ич инде!

...Биш ел элек моннан
Язган иде,
Бик ачынып, миңа төрттереп:
«Көне буе бүген хуҗалыктан
Бозау җыйдык, малай, эт булып.
Рухи арыдым. Тик син аңламассың!
Кичен лекция укыйм,
Иртән чыгам күкәй җыярга.

«Американы куып җитәбезме?» —
Ди, бер апа.
Белмим күзем кая куярга,
Гарьлегемнән бер сүз әйтә алмыйм,
Карыйм да аның оланнарына...
Авылны аны сагынып яшәү рәхәт
Якты шәһәр урамнарында!
Авылны аны мактап яшәү рәхәт
Газлы, сулы матур шәһәрдә,
Шул мактауны яисә сагынуны
Патриотлык дисәң әгәр дә!..»
Ә мин яздым:

«Мин авылда яшьләй эшләп үстем,
Сөрдем, чәчтем, урып-җыйдым мин.
Тик җиңеллек үземә эзләмәдем,
Түздем, ил белән бит, дидем мин.
Син рәхәттә иркә үскәнгәме,
Һәр кыенлык сиңа бик авыр.
Авыл хәле — мине дә әрнетә ул,
Олы юлга атлый тик авыл...»
...Ул югалтып түзем, чыдамлыгын
Күчеп килде ахыр калага.
Тик монда да юкка-барга көеп,
Күңеле аның ныграк талана.
Көяләк җан! Җанын бер төшкә дә
Беркетеп ул әллә торалмый...
Һәрнәрсәнең ике ягы була,
Шуны аңламый, фикер коралмый.
Әйбернең ул кимчелеген күрә,
Яхшы ягын күреп җиткерми.

Шунда, ахры, бәхетсезлеге аның!
Мин үзем дә белеп бетермим,
Шундый кеше.
Тагы авылга китте.
Күчену жене бардыр аңарда.
Ә авылны хәзер мактап яза,
Рәхмәт укый пленумнарга!
Үз эшенең тәмен тапкан икән,
Дип мин инде шундый сөендем!
Ләкин тагы үзенә кыенлыклар
Тудырган ул. Тагы көендем.
Тик ул гына, имеш, хаклы һәрчак!?
Тик аныңча эше бармаса,
Конфликтка керә.
Ул коллектив белән талаша.
Кичә минә үзе килеп чыкты.
Тагы бәхәс, мин дә кыдырач.
Хөрмәтле Ильич, синең бер хатынны
Укыдым мин аңа, бик кызгач.
Хатта язган:
...Тик үзеңчә, тик үзеңчә генә
Язмыш бирми сезгә эшләргә.
Мондый хәлне күрдем гомеремдә мин
Әллә күпме шундый кешеләрдә...
Нервыларың дәваларга кирәк!..
...Дустым минем җилдәй кузгалып,
Чыгып китте, сәер ым кагып...
Нәрсә алып,
Нәрсә югалтып,
Киткәндер ул, китте уйланып.

6

Дөнья үзенә игелек итүчене
Тоталмаган бер дә кадерләп:
Утларына салып яндырган, я
һәр төрлечә кылган җәберләп.
Аткан, аскан яки башын кискән,
Каторгага яисә озаткан.
Даһиларны ләкин ни җиңәлсын?!
Алар җиңә... ләкин азактан!

...Ленинны да хыянәтчел язмыш
Бәлаләре читләп үтмәгән.
Бер хаинның зәһәр пулялары
Чак дөньядан алып китмәгән.
Ята Ленин, гомере кыл өстендә,
Тик бирешми,
Сөенмәсеннәр!
Җимерелсен дошман планнары!
Җиңдек диеп тиенмәсеннәр!!
Дуслар кылган,
Бу фаҗига өчен
Зур гаепле санап үзләрен,
Кайгы туты баскан йөзләрен,
Эчтән сыза барысы, борчыла.

Сәламәтлек наркомы Семашко
Күзлек сөрткән булып,
Юеш күзен сөртә еш кына.
Бонч-Бруевич — теге чакта
Ленинның эш хакын арттыргач,
Шуның өчен хәтта
Ул Лениннан ала «строгач».
Утыра ул үзен-үзе тиргәп:
Ничек шуны әзрәк сизмәдек,
Ничек инде бердәнбер Ильичны
Бу хәвефтән йола белмәдек?!
Эх!!
...Ә Надежда ямый пальтодагы
Хыянәтчел пуля эзләрен,
Күз яшьләре аның яры кебек
Томалый да куя күзләрен.
Көчкә генә яшен тыеп тора,
Ә йөрәге өзелә аянып...
...Кризис үткәч, кәефе яхшырыпмы,
Ленин сорый гүя шаярып:
— Еладыңмы әллә син шуңа?
— Еладым, — ди Надя.
Ленин көлә-көлә:
— Революционерлар белән
Мондый хәлләр, — ди ул, — еш була! —
Һәм врачлар шуннан шәйли: хәле
Яхшыруга таба баруын.
Үзенә артык игътибардан куркып,
Яшерә Ленин булган авыруын.
Табигате аның шулай инде.
Ә бүтәнчә һич тә булалмый!
Аерым аны зурлауны ул сөйми,
Шәхес культын бер дә күрәлми.
... Шул, авырып яткан чакта, беркөн
Газеталарны укып, шакката:
Нишләп аны алла кебек итеп
Күтәрәләр? Нинди зур хата?!
Без геройлар турында бит инде
Мәсьәләне күптән хәл иттек!
Шәхес культы безгә чит, зарарлы!
Нигә тагы инде бу битлек?!
Ленин уйлый: «Архикуркыныч бу!
Табынырга да бик күп алмаслар!»
Шалтырата наркомнарга тизрәк:
— Бу эшкә, — дип, — салыгыз тормозлар!
Һәм наркомнар Ленин таләпләрен
Газет саен йөреп, үтәгән...
...Табигате аның шулай булган,
Ул ясалма була белмәгән!

Моңсуланган Ленин кайчак әзрәк,
Көрәшләрдән арып-талганда,
Әнкәсенең рәсеменә карап,
Тынган шулай ялгыз калганда.
Нәрсә булган аның уйларында?
Җанын гына өткән ни угы?

Ленин шундук үзен кулга алган,
Мона биргән тик бер минутын!
Яшь ватанның миллион кайгылары
Миллион тапкыр җанын әрнеткән.
Ул шунда да иске берәр дустын
Онытмаган, аны яд иткән.

7


Бервакытны Ленин янына килә,
Сэр Уэллс, фантаст-язучы,
Фантазиясен үзенең баетырга
Йөри әллә бөек багучы?
Аңа әйтәләр: Ленин ихтыярын,
Үз фикерен тагар ул сезгә!
Ә Ленинның үзен күргәч ләкин
Ялган булып чыга ул сүзләр.
Соңра яза Уэллс:
«Үз фикерен Ленин
Көчләп тагмый бер дә кешегә,
Ул дәлилле,
Дипломатлык итми,
Ышанасың аның эшенә!
Чын күңелдән, бик ягымлы сөйли,
Йомып калмый кыен якларны,
Англиянең эшчесеннән сорый
Советларны ныграк яклауны...»
Инглизчә бик шәп сөйли Ленин,
Фантаст аңа карап соклана,
Нык таушалган фантазиясенә
Ул яшәртә торган сок ала!
Ленин портретын болай яза:
«Киң җилкәле, атлет тулаем,
Киң маңгайлы һәм акыллы башлы,
Анда типик татар чырае».
Ленин сөйли аңа Советларның
Илне үзгәртеп кору планын...
Сизә Уэллс үзенең фантазиясе
Тоныкланып, уңып калганын.
Кремль хыялые, ди Ленинны,
Хыяллыны ул бик күп күргән!
Ленинның да, ахры, бу хыялы
Чынга ашмас диеп ук белгән.
Аңламаган азат хезмәт көчен.
Хәзер сана безнең ГЭСларны —
Братск, Идел...
Сүзсез ышандыра
Бик күп, бик күп Уэллсларны!

Һәркем белә, һәркем көн дә күрә:
Тормыш һаман бара гел алга.
Котылгысыз көчле агым булып,
Кешелек килә Ленинга таба!
Ул хәрәкәт туктатырлык түгел,
Планетаны ияртеп шул бара.
Бар хаклыктан аны өстен күреп,
Кешелек килә Ленинга таба!

1966

*Гомәр Бәширов*

# Туган ягым — яшел бишек



*Автобиографик повесть*[1]

### III

Авыл тегүчеләренең ул вакыттагы гадәтләре буенча, без өй борынча йөреп тегә идек. Бер йортта эшне бетерәбез дә икенчесенә күчәбез. Кайсында бер кич куныла, кайсында икене, өчне. Эшнең бетүенә карап.

Ул елларда Ямаширмә бүтән авылларга караганда бик зур да, баерак та иде. Анда калай түбәле таш кибетләр дә бар, тау башында Бәшир байның көне-төне пар белән эшли торган бик шәп тегермәне пүкелдәп утыра. Намаз вакыты җиттеме, мәзиннәр өч мәчетнең манарасыннан азан кычкыралар. Ирләре Казанда эшләп акча таба, кызлары, киленнәре кышларын байларга читек кайыйлар. Иш янына куш, дигәндәй, казгана торгач, чәй-шикәргә дә ярап куя, өс-башка әмәлләргә дә кала.

Ямаширмәнең хәллерәк кызлары белән яшьрәк киленнәре кием-салымның яхшысын, яңача теккәнен киделәр. Бишмәт булса, син аларга «бикламат» дип аталганын, озын итәклесен, нечкә биллесен тегеп бир. Аннан да бигрәк яшел, я зәңгәр плүштән жикит тектерергә бик һәвәс иделәр. Биле нечкә, җиң очлары тар булсын, иңбашлары бөрмәләнеп, күпереп торсын...

Сафа абый, килеп керүгә, эшне үлчәү алудан башлый. Мин машинаны майлап-җайлап куям, кирәк икән, үтүк кыздырып алам, шүре ясыйм. Әмма кулларым аз-маз гына эштән бушауга, минем янга яшьтәшләрем килеп җитә дә без алар белән тәрәзә төбендә бер-беребезгә я пәке, я карандашлар, каләмнәр күрсәтеп, әйбер алмаша, пышылдаша башлыйбыз. Тик мондый рәхәт бик кыска гомерле була иде. Тегүченең калын кашлары астындагы соргылт күзләре бөтенесен күреп торалар икән. Ул миңа шундук күзе белән генә урыныма килеп утырырга куша.

---

[1] Дәвамы. Башы 5, 6, 7 саннарда.

Тегүче буласың киләме синең, килмиме, анысын синнән сорамыйлар. Инде алып чыкканнар икән, рәхмәтеңне әйтеп, эшли бир. Әрәм тамак булып тик утырма, авызыңа чәйнәп салганны да көтмә! Тик шулай да бик ансат кына мин дә шундый шәп тегүче булып китәрмен дип нәфесеңне сузма. Тот капчыгыңны! Аңарчы әле синең бөкрең чыгар, тез башларың сөялләнеп катар, төннәрне йокысыз уздырып, күзләрең чепиләнер.

Иң кыены останың аз сүзлелеге иде. Көннәр буе авызыннан сүз чыкмый, көлми, елмаймый, күрсәтеп тә бирми. Үзең күр, үзең өйрән!

Кайвакыт шулай бик озак сүзсез утыра торгач, кечкенә яктан хуҗа хатын бик гаҗәпләнеп, башын сузып карый:

— Бәлеш, үлеп беттегезме әллә дисәм, юк икән! Кара, исән-сау икәнсез ләбаса!

Менә бер заман кичке чәйне дә эчәсең, авыл халкы акрынлап йокыга тала башлый. Иң элек синең ише үнбер-уникке яшьлек бала-чага күренмәс була. Бераздан су эчәргә дип кузгалганда, я кечкенә якка кереп үтүк кыздырганда аларның я мич башында, я кечкенә як сәкесендә борыннарын сызгыртып, йоклап ятуларын күрәсең. Алардан соң бérән-сәрән олылар да югала. Тора-бара бөтен өйдә без икәү генә калабыз.

Минем эшем күптән үк беткән. Йокыга түзә алмыйча, сыгылып-сыгылып төшә башлавым да әллә кайчан. Әмма барыбер ятарга ярамый.

Кайдадыр беренче әтәч тә кычкырды. Аңа кушылып Ямаширмәнең бүтән әтәчләре дә бер мәлне бөтен авылны шаулатып алдылар.

Без әле һаман утырабыз.

Лампаның керосины азаеп, уты да саргайды. Карт бабай, бер кат йокысын туйдырып, һавага да чыгып керде.

— Һи, әле һаман ятмыйсызмени? — диде бабай. — Ярты төн әллә кайчан узды бит инде.

Оста йокы баскан күзләре белән, берни аңламастан, бабайга карап кала. Аның юньләп тавышы да чыкмый, ул пышылдый гына:

— Аз гына, берәр җөй...

Әмма ул машинага килеп утыруга, башы, күтәрә алмаслык авыр әйбердәй, кинәт салынып төшә дә, маңгае кәтүк кадагына килеп бәрелә. Ләкин ул барыбер ятмый. Хәзер теккәннәрне иртәгә иртә белән сүтеп ташларга кирәк булачагын да белә. Шулай да һаман утыра.

Йокыдан тәмам исерешкән хәлдә шулай алмаш-тилмәш ава-түнә утырганда, кайбер кичләрне, кече яктан, чәчен тезәткәләп, мәрхәмәтле берәр карчык, я үзсүзле берәр җинги килеп чыкса:

— Әтекәй генәм! Карале боларны! — ди. — «Дөнья малы, дуңгыз каны» дигән олылар. Мал артыннан шулкадәр куармы кеше! Баланы азаплап! Ят, улым, менә синң урын!

Мин шуннан соң гына барып түнәм.

## IV

Беренче көннәр бик тә авыр узды. Эшнең җаен белмисең, куллар күнекмәгән, ялгыш чәнчеп җибәрәсең дә бармактан кан, күздән яшь чыга. Каеры тун янсә чикмән тегәргә туры килгәндә кичкә таба бармакларыңны кая куярга белмисең.

Төймә тагу нәрсә генә инде! Киемнең эше бетәр алдыннан, бик тырышып бишмәтнең төймәләрен тагасың. Инде югыйсә авызың да пешкәне бар. Акбур белән ясаган билгедән кәгазь калынлыгы гына да читкә тагылмады, җепләрең бөтенесе дә бер генә якка сузылып тора. Төеннәрең шайтан үзе таба алмаслык итеп эчкә яшерелгән. Шулай да бишмәтне остага сузганда өметеңне барыбер өзәсең. Ник дисәң, ул, юньләп карап та тормастан, биш төймәнең бишесен дә кисеп алдыра.

Синең бу хурлыгыңны хуҗалар да күреп торалар, аның балалары да Кызарасың. Кая керергә белмисең. Кулыңнан бернинди эш килми торган шундый уңмаган малай булып тууың өчен үләрдәй булып хурланасың. Әңгер-меңгер чагында капка төбенә чыгып үзебезнең авыл ягына күз салганда, башка төрле-төрле «батыр» уйлар да килеп куя:

— «Әгәр кайтып китсәм? Кайтасың да әйтәсең: «Булмый, кирәкми! Яратмыйм бу эшне, кулым бармый!» — дисең. «Урман кисәм, олауга йөрим, Корткачык ягына таш чыгарырга китәм, тик, зинһар, тегүче генә итмәгез, кирәкми!»

Әмма болар һәммәсе дә коры гайрәтләнү генә булып кала. Анысын үзем үк белеп торам. Урман кисәргә, я таш чыгарырга бот буе малайны кем алсын? Авыл читендәге пар тегермәне дә, күккә төтен алкалары чөеп: «Юк-юк, юк-юк!» — дип утыра.

Тагын әти күз алдыма килә. Авыру, йончыган...

Шулай бер атна да узды, ике атна да, өченчесе дә. Мин акрынлап бу хәлгә күнегә башладым. Ул арада ишеткән-белгән дә искә төшә: тегүчеләрнең бөтәннәре яңакка да салып җибәрә икән, ачуын китерсәң, куып та чыгара икән...

Күрәсең, малайлык горурлыгы да уянгандыр. Әнә синең яшьтәшләрең борыннарын мышкылдатып карап утырудан, теш казналарын уйнатудан башка пычагым да белмиләр. Ә син инде, кечкенә генә булса да, тегүче кисәге! Син хәзер энә тота беләсең, аяк машинасын келтерәткән буласың, эчлек сырасың, төймә тагасың. Кайчагында синең үзеңчә бик матурлаган булып, кыеклатып бишмәт эчен сыруыңны карап торучы берәр апай:

— Кара бу малайны! Тәки булдыра икән бит! — дип тә җибәрсә, тагын сиңа ни кирәк?!

Менә озакламый бер ае бетә дә инде, аннан соң өч ай гына кала. Сабан туена тәгаен кайтырбыз. Әти Сафа абыйдан беренче чәй янында ук сорар:

— Я, берәр эш киләме бу малайның кулыннан? Әллә килмиме? Бик җебегән нәрсә булып чыктымы?

Безнең әти телендә мондыйлар иң хурлыклы, үтергеч сүзләр булып ишетелә. Юк! Минем һич кенә дә җебегән, уңмаган малай буласым килми. Юк! Мин андыйны ишетмәм!

Аннары болай да була иде.

Эшеңне кире сүттергәнгә гарьләнеп борын тартып утыруыңны, яисә әңгер-меңгер вакытта, урамга чыгып, Яңа Сала ягына карап моңаеп торуыңны беркем дә күрмәде шикелле. Син кемгә кирәк?

Ләкин озак та үтми, хуҗа апаның үз анаң шикелле үк рәхимле һәм шәфкатьле кеше булуына игътибар итә башлыйсың. Ул сиңа табын янында ризыкның иң тәмлесен куя.

— Оялып утырма, улым, аша әле, аша! — ди.— Синең үсә торган чагың, күп итеп аша!

Ул сиңа урынны йомшак итеп җәя, юрганыңны япкан булып, үзенә дә артык сиздермичә, анаң кулы шикелле йомшак куллары белән арканны сыпырып уза.

Андый яхшы күңелле, бала җанлы апалар һәммәсе дә бер кыяфәттәрәк күренәләр иде. Йөзләре талчыккан, шулай да ягымлы, күзләре сине якын итеп, мәхәббәт белән, көлемсерәп карыйлар. Әйтерсең, синең күңелең булсын өчен, алар әлләниләр эшләргә дә әзер. Өс-башлары да бер чамалырак: гади генә ситсы күлмәк, алларында эре чәчәкле алъяпкыч, башларында артка чөеп бәйләгән гади генә яулык.

Тора-бара мин инде һәр яңа йортка күчкән саен, барып керүгә, иң әлек хуҗа хатынның йөзенә карый торган булдым. Шундыймы, түгелме?..

## V

Ул кешенең йорты Йомры атау ягында[1], мәчет тирәсендә иде. Капкасы кызыл белән зәңгәрне аралаштырып, ничектер бик сәер төскә буялган. Өйләре биек, кара-каршы итеп салганнар.

Чибәр киенгән яшь кенә бер апай безне ачык чырай белән каршы алып, туп-туры ак өенә алып керде.

— Шушында эшләрсез. Монда иркенрәк тә, яктырак та булыр. Үзе өйдә күп тормый, тавар артыннан йөри, — диде.

Мондый матур, мондый бай йортны моңарчы һич күргәнем юк иде. Тәрәзә өсләрендә утлы-яшелле көмеш шарлар асылынып тора. Мичләре нәкъ чынаяк төсле, зәңгәр чәчәкләр төшергән. Стеналарында бармак калынлыгы кыйммәтле көзгеләр, кара пыялага алтын белән искиткеч матур итеп язылган шәмаилләр, ефәккә чигелгән Мәккә-Мәдинә сурәте. Идәннәре сап-сары, аңа йомшак келәм җәелгән. Өстәл өстендә, зур торбасын сузып, граммофон утыра. Тагын әлләниләр!

Миңа болар һәммәсе дә бик ошап китте. Безнең авыл малайларыннан кем торып караган мондый бай өйдә? Зур үсеп, акчаны күп эшли башлагач, мин дә өемә нәкъ шундый матур әйберләр алырга булдым. Шулар турында хыялланып, күтәренке кәеф белән өйгә хат язарга утырдым. Хатның башын әллә кайчан ук уйлап куйган идем:

— «Сезки гыйззәтлү вә хөрмәтлү улып торгучы әти белән газиз әнигә безки Ямаширмә кариеләрендә сезне бер күрергә зар-интизар улып йөргүче угылыңыз Гомәр сезгә сагынып, саргаеп бик күп сәламнәремне ирсал вә тәблигъ әйләдем[2]...».

Тик шунда мин хат язып утырган өстәл астыннан кечкенә балалар тавышы белән көлеп җибәрделәр:

— Иһи-һи-һи!

Карасам, өстәл астындагы читлектән миңа тары ярмасы тикле күзләре белән текәлеп мысыр күгәрченнәре карап тора. Үзләре парлы икән. Төсләре ак та, сары да түгел, ниндидер аксыл коңгырт. Аннары алар, киштәләрендә утырган килеш, кызыл томшыклары белән каурыйларын тазартырга тотындылар. Ул да түгел, идәнгә очып төштеләр дә кызыл читекле аяклары белән, яшь киленнәр шикелле, купшы гына атлап, су эчәргә барган булдылар, «тек-тек» иттереп, текелдәтеп ярма чүпли башладылар.

Хуҗа хатын ишек янында туктап калды:

— Сиңа бик ошадылар, ахрысы, энем! Әллә үзегезнең дә күгәрченнәрегез бармы?

— Үзебездә юк юклыкка! Латифа түтиләрдә бар. Әни әйтә, безнең өйдә асрап булмый, ди. Безнең әти пыялачы бит, бик шакылдый.

Теге апай миңа нигәдер кызганыбрак караган кебек күренде.

— Алай атаң да акча эшләгәч, иген дә чәчкәч, ничек сине болай малайлыкка бирәсе иттеләр соң?

Аның белән сөйләшүе бик рәхәт иде. Шулай да, никадәр генә эчкерсез булырга теләсәм дә, мин ана тормышның авырлыгы турында берни дә әйтмәдем, эти белән әнине кимсетермен кебек тоелды.

— Шулай инде, — дидем. — Берәр эшкә өйрәнергә кирәк бит. Минем җирем юк бит. Соңрак туып, иманага керми калганмын. Әти әйтә, һөнәргә өйрәнмичә ярамый, ди.

— Синең яшеңдә мәдрәсәгә йөрергә кирәк иде дә бит...

— Мин укыдым инде, апай, бер кыш мәзиндә, өч кыш мәдрәсәдә. Хат та яза беләм, китап та укыйм. — Аннары бик тиз чыгып китмәгәе дип тагын сүз куштым. — Безнең Латифа түти әйтә, мысыр күгәрченнәрен сатарга ярамый, аны бүләк итеп кенә бирәләр, ди.

[1] Ямаширмәнең бер тирәсен шулай атыйлар.
[2] Ирсал вә тәблигъ әйләдем — җибәрдем, күндердем.

— Шулаймени? Кара син әй! Боларны да безгә Казандагы апабыз бүләк иткән иде.

Бу апайның минем белән ихлас күңелдән сөйләшүе мине бөтенләй эретеп җибәрде. Сизеп торам, аның әше дә күптер, шулай да чыгып китми. Әллә берәр җирдә, кайда да булса еракта, минем тиклерәк энесе бармы икән? Әллә бик бала җанлы кешеме? Әллә үз баласы булмаганга юксынып шулай сөйләшәсе киләме?

— Безнең Латифа түтинең күгәрченнәре чәч тараганны күрсәләр, кычкырып көләләр. Сезнең дә көләләрме?

Апаем, ялтырап торган кара чәчен уч кырые белән генә ике якка сыпырып, басынкы гына көлде.

— Кара, кызык нәрсәләр беләсең икән син! Безнекеләр дә көләләр... Күңелләре көр булса! Каяле!..

Ул күгәрченнәр каршысына чүгәләде дә яулыгын артка чөеп, чәчен тараган сыман юри генә ия-ия башын сыйпарга тотынды. Күгәрченнәр башта, бик гаҗәпкә калган сыман, алмаш-тилмәш муеннарын сузып, тары бөртеге хәтле генә кызыл мәрҗәннәре белән текәлеп тордылар. Ул да түгел, бу кәмиткә түзә алмыйча, кечкенә балалар тавышы белән көлеп тә җибәрделәр:

— Иһи-һи. Иһи-һи!

Читлектә күгәрченнәр көлә, алар каршысында, бик рәхәтләнеп, ихлас күңелдән, апай көлә, чырык-чырык мин көләм.

— Бик тә моңлы итеп гөрләшәләр алар. Бигрәк тә таң алдыннан... Менә шул чакларны йөрәкләрем өзелеп-өзелеп китә, күзләремә яшьләр килә. Беләсеңме...

Тик шунда хуҗа хатын, сүзен бүлдереп, кинәт сикереп торды да атылып-бәрелеп чыгып та китте. Ишек алдында чана табаннары чажылдаганы ишетелде. Озак та үтмәде, өйгә зур бүре толып кигән юан бер кеше кайтып керде. Хатынын почмак якка кертте дә каты пышылдап аның «арт сабагын» укытырга тотынды:

— Нишләп монда, ә?!. Кем рөхсәт итте? Кем? — дим мин сиңа!..

Тагын бераздан без аш өенә күчкән идек инде. Теге апай безгә таба карамаска тырыша башлады. Күгәрченнәр гөрләгәнне дә ишек ачканда, я өй алдына чykканда гына ишеткәләдек.

Кичке ашны ашап бетереп кенә торабыз. Хуҗабыз, күлмәк эченә мендәр кыстыргандай, шактый ук күперенке булып бүлтәеп чыккан йомры корсагын сыйпаштырып, уфылдап утыра. Авыз суларын китереп:

— Их, алма булса икән хәзер, алма! — ди.— Я әчерәк кенә җимеш суы. Тик алмага җитми инде. Их, алма!..

Үзе бу сүзләрне әйткән саен табын янына тегесен-монысын китереп йөрүче матур хатынына да елмаеп кына карап ала.

Бу кешенең кыш уртасында алма өмет итеп утыруына артык исем китмәде. Азмыни бер тамагын тыя алмыйча әллә нәрсәләргә нәфес салучы комсыз бәндәләр! Мине барыннан да бигрәк бу кешенең бите кып-кызыл, корсагы дәү булуы сәерсендерде. Безнең авылда йөкле хатыннардан башка юан корсаклы бер кеше дә күрә алмыйсың. Хәтта кибетче Чтапан да юан түгел. Күрәсең, безнең Яңа Саланың корсак симертерлек чамасы булмагандыр. Бу кибетчегә бирән зәхмәте эләкмәдеме икән?

Бераздан хатыны табынга алма китереп куймасынмы! Ниндиләр генә әле! Һәммәсе кызыллар, әле генә агачыннан өзеп алган шикелле ялтырап торалар.

— Үзебезнең кибеттә бар иде. Авыз итәрлек кенә калган икән әле,— ди.— Менә, аз булса да кабыгыз.

Хуҗа кулларын читкә сузып кына, янәсе, безгә күрсәтмичә генә, узып барышлый хатынының йомшак җиренә сугып алырга да өлгерде, күз дә кысты.

Хужа алмаларны буташтырды, маташтырды да берсен шартлатып ашый да башлады.

— Алыгыз, ал! Я, нигә кыстатырга! — ди торгач, Сафа абый да берсенә сузылды. Башын чайкый-чайкый бик озак әйләндергәләп торганнан соң, ул да житеште.

Үзем бер кечкенә китапчыкны актарган булам, әмма алмадан һич күзне алып булмый гына бит. Эшләр болайга таба борылгач, мин табыннан вакытыннан элек читкәрәк тайпылуыма үкенә башладым. Алмадан да авыз итәсе килә, яңадан табынга килеп утырырга да кыюлык житми. Безне бала чактан ук табынга рөхсәтсез тыгылмаска өйрәткәннәр иде. Андый ризыкларны безгә олылар үзләре алып бирә торганнар иде. Кибетче үзе бертуктаусыз сөйләнә, үзе авызын чәпелдәтеп һаман ашый, тастымалы белән авыз кырыйларын сөртеп ала. Шул арада Ямаширмә баеның аны Казандагы йортында кыш көне шәфталу дигән җимеш һәм Бохар кавыны белән сыйлавын сөйләргә кереште. Имештер, аларны байның Бохардагы хезмәтчеләре һәркайсын аерым-аерым ап-ак мамыкка төреп, шул хәтле җирдән кулларында гына тотып китергәннәр. Аннары ара-тирә минем якка күз салгалап, пышылдый төшеп, күп урыннарында серле генә ымлап, бер байның әллә ничәнче яшь хатыны турында сөйләп китте. Берсе дә калмады: килеп кергәч, читеген ничек салдыруы да, соңыннан ничек булуы да. Шулай кызып сөйләгән килешкә актык алманы да сузылып алды.

Ул кичне мин бик озак йоклый алмыйча яттым. Төн буе төшемдә алма белән саташып чыктым. Көз көне, имеш. Күрше Габдулла абзый авылларга чыгар алдыннан арбасына алма төяп маташа. Аның кабык әрҗәсендәге алмалар шундый матур булып тезелешеп яталар, безнең авызлардан су килә. Габдулла абзый безне әрҗә яныннан куып йөри:

— Күзегезне акайтып карамагыз, күз тидерерсез! — ди, имеш.— Патша хәзрәтләренең эче авыртыр. Аңа дигән алма бит ул! — Иегереп килә дә шап итеп әрҗәләрнең өстен үк ябып куя.— Исе дә әрәм булмасын, исе дә! Әнеч булыр бу, әнеч, белдегезме шуны!..

Иртә белән битемә салкынча бер нәрсә бәрелүгә уянып киттем. Капшап карасам, алма! Минем йодрыгымнан зуррак, исе дә төштәге алма исенә охшаган. Авыздан сулар килә башлады.

Ләкин... бит юганда мин аны ләгәнгә ташладым. Моны күреп хуҗа хатынының күзләре шакмак булды.

— Нәрсә кыланган буласың, малай актыгы! — дип пышылдады.

— Төшемне сызлатыр дип курыктым.

— Тәкәббер син, тискәре! Шундый кире малайны кызганган мин юләр!

Бу яхшы күңелле апайның кәефен бозуыма бик борчылдым. Алмадан баш тарту да бик авыр булды. Әмма соңыннан мин үземдә горурлык сиздем, үземне ныграк ярата башладым. Мин инде хәзер ул әшәке әйберләр лыкылдаучы юан корсакка, малай гына булсам да, өстәнрәк торып карарга хакым бар кебек хис итә идем.

Әмма аның хатынына, кире малай дип ачуланса да, соңыннан кырын карап йөрсә дә, бер генә дә үпкәли алмадым. Минемчә, бу кап корсакка ул бөтенләй пар түгел, ул аңа әрәм иде. Үзе яшь-яшь, үзе чибәр, үзе шундый ягымлы! Нигә шундый әшәке кеше белән тора икән ул? Бу минем һич башыма сыймый иде. Әле җитмәсә, тегесе узганбарганда төрткәләп, шапылдаткалап калса, шуңа һич ачуланмый, киресенчә, авызын гына ера. Мин бер жае килгәндә шушы уемны шыпырт кына аның үзенә дә сиздермәкче булып йөрдем. Әйе, шундый әйбәт башы белән нигә аннан мыскыл иттерә, кимсеттерә ул?

Ярый әле, жае чыкмады...

## VI

Менә тагын читекчеләр, безнең шикелле «энә белән кое казучылар».

Читекче кызлар булган йортка керүне мин зарыгып көтә идем. Бәлки, алар миңа апаемны хәтерләткәннәрдер? Бәлки, аларның шушы нечкә һәм пөхтә эшләре, шулай матур да, затлы да итеп чигә белүләре кызыктыргандыр?

Тәбәнәк кенә урындык белән тәрәзә каршысына килеп утыралар да, кечерәк кенә калыпларын тезләре өстенә яткызып, кайый бирәләр. Яннарындагы бәләкәй әрҗәләрендә — зәңгәр, яшел, кызыл, алсу, бишнн, миләүшә төсле нәни күн кисәкләре. Алар һәммәсе дә нинди дә булса яфракка, я чәчәкләргә охшаганнар. Әйтерсең, бу кызлар болыннардан, урманнардан яфрак белән чәчәкләрнең матурларын җыеп кайтканнар да хәзер менә шуны читек итеп кайыйлар. Җитез бармаклары бөгелеп тә сыгылып уйнаклап кына тора, көмеш балдаклары белән энәләре елтыр-елтыр килә. Бераз юаныбрак яңадан күз салсаң, әлеге шул төрле төстәге яфрак белән чәчәкләр я чигүле читек йөзе, я куныч кыяфәтенә кергән була.

Аулак өйләрдә кызлар бергә җыелып чигәләр. Олы-кары булмаганда, читекләрен кайый-кайый, йөрәкләрне уйдырырдай итеп җырлап җибәрәләр.

Шулардан берсе кара тут йөзле, яшьрәк кенә, чандыр гына Мазлума исемле кыз иде. Ул күрше Урмат авылында туып-үскән дә, атаанасы үлгәч, монда, җизнәсендә, яши икән. Анысын да беләм: кызыл сакаллы, теленә салынучан бер бәндә.

Мин Мазлуманың әйләнә-тирәсендә тегеләй-болай әйләнгәләп, узганда-барганда сүз әйткәләп йөрдем. Нигәдер ул бер генә дә башын күтәрми, бернигә дә исе китмәгән кебек иде. Нишләп алай икән? Ятимә булгангамы? Сафа абый озаккарак чыгып киткәндә, батырланып шуңа сүз куштым:

— Апай, бер җыру җырлачы, ә?

Ул миңа күзен генә сирпеп алды да бер сүз дә әйтмәстән чигә бирде. Мин яныннан китмичә, тегеләй-болай этенеп-төртенеп торгач, тагын күтәрелеп карады.

— Авылыңны сагындың мәллә?

— Юк та... Минем дә апаем бар бит.

— Ә...

— Бездә читек кайымыйлар, чигү чигәләр. Минем апай да чигү чигә.— Сөйләшергә бер кеше булуга, сүз дә ипле генә ялганып китүенә куанып, мин аңа апай бүләк иткән чигүле яулыкны да күрсәттем.— Менә шулай итеп...

Читекче кыз минем яулыкның почмакларындагы канәфер чәчәкләрен әйләндерә-әйләндерә бик җентекләп караганнан соң, аны сыйпап куйды.

— Апаең матур чигә икән. Үзе дә матурмы?

— Матур иде дә. Китте инде апай. Кияүгә бирдек бит инде.

— Үзе теләгән егетенәме?

Мин ничек булганны сөйләп биргәч, Мазлума калыбына кадәр иелеп:

— Шул инде бездә,— диде.

Шулай байтак кына сүзсез утырганнан соң, ул миңа тагын күтәрелеп карады:

— Безнең читекчеләр менә мондыйны җырлыйлар:

Палузур читекләр эчендә
Ефәк аяк чуы бар;

Ул әйттерде, мин йөрмәдем,
Миндә шул ачуы бар...

— Монысы болай, шаяртып кына.
Шулай да минем аның янынинан китәсем килми иде.
— Ниндиен җырлыйм икән соң?
— Үзең яратканны.
Читекче апай тамагын кырып алды. Менә өй эчендә аның басынкы моңы тибрәнә башлады.

Һай, кар ява, кар ява,
Бу йөрәгем ник яна?
Бу йөрәгем «сөй» дип яна,
Сөйгәнем ятка кала.

Бер үк вакытта ничектер бик рәхәт тә, монсу да булып китте. Җыр тынганнан соң да аның моңы өй эчендә һаман акрын гына тибрәнеп торадыр, читекче кыз аны үзе дә тыңлыйдыр кебек. Хәзер берәрсе килеп керсә, җыр моңы эленеп торган бу ягымлы, кадерле тынлык бозылып әрәм булыр иде шикелле тоелды.

Җырның сүзләре соңыннан гына искә төште. Бу апай да үзен бәхетсезгә саный микәнни? Кара кашлары, салават күпере шикелле, дугайланып менгән, калын чәч толымнары авыр булып идәнгә кадәр асылынып торалар. Шундый яшь, шундый матур... Менә дигән чибәр егеткә кияүгә чыга ала бит!.. Ул ничек бәхетсез булсын икән? Әллә югыйсә сөйгән егете ташлап китте микән? Әллә җизнәсе сөймәгән кешесенә көчләп кияүгә бирмәкче буламы?

Шуңа сәерсенеп утырганда, капкада бер карчык күренде. Мазлума эшеннән туктап сикереп торды.

— Әнә минем башымны ашарга йөрүче убырлы! Ходаем! Ичмасам, качып та өлгерә алмадым!

Ул арада карчык кереп тә житте. Авызын ачып беренче сүзен әйтүгә, мин иманеп киттем. Аның кап-карага буялган тешләре әллә ничек, караңгы төпсез чокырдай, бик ямьсез булып күңелгә шом салалар иде.

Карчыкның сүзләреннән шул аңлашылды: ул Мазлуманы Төркстан ягына китәргә димли икән. Юлына да, ашарына да андагы байлар алдан ук акча җибәргәннәр. Тик утырасы да китәсе. Барып житкәч, киемсалым, ашау-эчү — һәммәсе байдан. Курчак шикелле киенеп, монда булмаган җәннәт җимешләре генә ашап торачаклар...

Карчык, Мазлумага нелә төшеп, юмакай тавышы белән шуларны көйли иде.

— ...Иптәшләрең һәммәсе дә әзер инде, кызым. «Кайчан китәбез инде, әбекәй, кайчан мондагы җәһәннәмнән котылабыз, кайчан андагы баг-бостаннарга барып житәбез»,— диләр.

Читекче кыз, еларга житешеп, каршы әйтергә тотынды.

— Бармыйм мин анда, китмим әллә кайларга! Авылыма кайтам, туган авылыма!

— Җизнәң җибәрә бит, кызым, акчасын да алды...

Шунда Сафа абый кайтып керде дә мин бу сатулашуның ни белән бетүен белмичә калдым. Әмма Мазлуманың моңлы җыры белән: «Бармыйм, авылыма кайтам», дип инәлүе һаман колак төбендә яңгырап торды.

Биш йөзгә якын йорты булган мондый зур авылданиләр генә очратмассың! Әллә ниләр күрәсен, чәчләреңне үрә торгызырлык әллә нинди куркыныч хәлләр турында ишетәсең.

Андыйларны, гадәттә, безнең янга кич утырырга килүчеләр сөйли иде. Кайбер кичне андый «кунаклар» дүрт-бишкә үк тула. Аларның кайсы ян сәкегә утыра, урын җитмәгәннәре, аркаларын стенага терәп, идәнгә чүгәли. Без эшлибез, алар аю биеткәнне карагандай, кызыксынып, шуның өстенә бераз көлемсерәп, тын гына карап утыралар. Кәмит ич! Зуп-зур ир кеше түр башында, сакалын сәлпәйтеп, уймаклар киеп, инәләр саплап, хатын-кыз эше белән вакланып утыра.

Кайбер шаянрагы бу уңай белән теленә салынып та ала:

— Казыйсызмы коены?

Сафа абый озак еллар шулай йөри торгач, андыйларны күп ишеткән инде, күрәсең, һич исе китми. Башын күтәрмичә генә:

— Сезне кызганып килүем,— ди.— Мин булмасам, сез бичараларны кем киендерер? Сез бит төймәгез өзелсә, аны да тага белмисез.

Тора-бара ничектер үзеннән-үзе телләре ачылып китә дә төрле күргән-белгәнне, баштан узган хәлләрне, булырдай һәм булмастайларны сөйләп китәләр. Әмма сүз күбесенчә ничек баю тирәсендәрәк әйләнә иде. Казанның фәлән бае яшь чагында гидай хәерче булган. Шул ничек баеп киткән дисез? Юлда почтаның тулы ук итеп акча тутырган күн капчыгын тапкан. Фәлән бай караклар белән казна баскан да, аларның башларына җитеп, бөтен малны үзе йоткан.

Кич утырырга йөрүчеләр арасында түгәрәк сипкел битле, кызыл сакаллы Мазлума җизнәсе дә бар. Ул бер генә кичне дә килмичә калмый, иң алдан килеп, иң соңыннан китә, әле җитмәсә, көндезләрен дә яртышар көн утырып чыккалый торган иде. Мин бу кешене исемен ишетүгә үк яратмый башладым. Мазлуманы шул бәхетсез итмәкче була бит! Хуҗа хатыннарның аны ничә тапкыр әрләгәннәре бар:

— Чистый Хөрәсән ялкавы булдың инде син! Өеңдә бер эшең дә юкмыни соң? Әнә анда караптыларың ишелеп бара, балаларың ыштансыз да күлмәксез. Ни җаның белән көннәр буе ләчтит сатып утырасың?!

Шунда берәрсе:

— Ә балдыз нәрсәгә, балдыз? — дип төрттереп ала.

Әмма кызыл сакал йөзен чытып кулын гына селти, бөтенесен оныгырга ашыккандай, берәр кызык сөйләргә тотына.

Имештер, Чулпан авылына читтән бик оста бер алтынчы килгән. Көне-төне чүкелдәтә, ди бу. Йөзектәр, балдактыр, беләзектер — бөтенесен коеп кына куя, ди. Исемле кирәкме сиңа, исемсезме? Кашлымы, кашсызмы? Ниндине жаның тели.

Шулай бер көнне бу хуҗасына сүз салган:

— Байыйсың киләме? — дип.

— Һи, җүләр саткан нәрсә! — дигән хуҗа.— Кемнең байыйсы килмәсен? Минем башка тай типкәнме әллә! Пүчтәк сөйлисең!

— Алайса, парлап өч көнгә кунакка кит!

— Ни эшкә алай, зерәгә, тик торганда? Жыен түгел бит! — ди хуҗа.

Тегенең тагын җавап кыска:

— Байыйсың килсә, барасың...

Өч көн кунак булып кайтты, ди хуҗа. Тege әйтми, бу сорамый, яшиләр, ди, шулай.

Бер көнне ишек япканда хуҗа сәер бер тавыш ишеткән.

— Бу нинди тамаша?

Алтынчы дәшмәгән. Тагын сораган, тагын әйтмәгән. Өченчесендә моннан хатынга әйтмәм дип ант иттергән. Шуннан соң моны идән астына алып төшкән, ди, бу. Караса, ишекне ачып япкан саен өй астына «кыштырт» иттереп бер кәгазь акча килеп төшә, ди.

Тыңлаучылар, исләре китеп, «и-и-и!» дип суздылар.

— Әмма сүзендә тормаган, ди, теге тишек авыз, хатынына әйтмичә түзә алмаган. Әй, кызулый башлаган, ди, шуннан соң монын хатыны! Бер дә утырып тормый, ди, бу. Акча күбрәк сугылсын, дип, тыз-быз гел йөреп кенә тора, ди. Шуны сизгән дә бер төнне чыккан да тайган алтынчы.

Сафа абый, эшеннән туктап, тамагын кырып куйды:

— Акча суга торган машинасын да алып киткәнме?

— Һе, калдырыр сиңа, бар! Андый җебегәнгә бигрәк тә!..

Икенче бер кичне ат караклары турында ишеткәннәре башланып китә. Берсе сөйләп бетерми, аңа икенчесе кушыла, өченчесе нидер өстәп куя. Тәрәзәгә карый-карый шомланып, борчылып сөйлиләр. Әйтерсең, менә бүген төнлә аларның үз атларын урлаулары мөмкин. Кайбер караклар аранның арт стенасын сүтеп алып чыгалар, имеш. Алай гынамы әле! Түбәне тишеп, атны тактага салалар да өскә сөйрәп менгерәләр, шуннан бакча якка шудырып кына төшерәләр икән. Атың бүген төн генә абзарыңда булса, икенче көнне аны инде Бәрәңге базарында сатып та җибәрәләр.

— Ай-ай. Менә йөр син, авызыңны ачып! Бер төн эчендә кара җәяү калуың бар!

— Шулай! Аттан бер колак кактыңмы, бетте инде аннары, балачагаң белән өелешеп үләргә генә кала!..

— Алла язмасын бер үк!

Кызыл сакал тагын көлдерергә тырышып карый:

— Һе! Соң менә мине нишләп ат асрамый дип беләсез? Ә?! Төннәр буенча ат өчен дерелдәп татлы йокыларымны калдырасым бар икән!

Сафа абый, эшеннән туктап, беркавым уйланып утыра. Кем белә, бәлки ул бу вакытта күңеле белән Кибәхуҗасында булгандыр, үз атын күз алдына китергәндер?

— Йортта эт булса, мин әйтәм, нидер инде... шәт, алай ук базмыйлардыр?

— Һи, әйттең сүз! Эткә күпме генә кирәк? Сускә чорнап ит кисәге ташлый да... Кайчан актарып бетерә әле ул аны! Ә иткә агу кыстырган!

Кайсыдыр авыр сулый, кайсыдыр иреннәрен чапылдатып куя.

## VII

Шул кереп йөрүчеләр арасында бервакыт авыл агайларына охшамаган бер сәер абый күренә башлады. Бүтәннәрнең өстендә я каеры тун була, я бишмәт, башларында күбесенчә кырпулы бүрек. Бу абыйның башына кигән бүреге очлаеп менгән, әйтерсең, ул сөт чүлмәген аударып кигән. Өстенә кигәне дә кала пәлтәсе. Аның якасы зәңгәр хәтфәдән, тышлыгы, шәт, бармак калынлыгы булыр, шундый таза әйбер. Тик ул инде шактый ук искергәнгә охшый: җиң очлары, кесә капкачлары чачарып беткән, бер-ике урыннан мамыгы да күренеп тора. Менә аның җилкәләре дә бик киң сыман. Бу абыйның чырае көм-күк, яңаклары иңеп кергән, күз төпләре зәңгәрләнеп тора.

Авылдашлары аны үсмер чакта ук чыгып киткән дә шуннан бирле ярты дөньяны айкаган, диләр. Зимагур дип тә йөртәләр. Имеш, аннан берсе дә калмаган: чугунка да салган, алтын да казыган, бөтен Себерне кыдырганнан соң, хәтта Манҗурия дигән җир белән Кытайга тикле барып чыккан. Тик үзенә сукыр бер тиен дә няреп кайтмаган.

Кайтып керсә, егетнең өстендә гел урыс киеме. Шуннан киткән хәбәр:

— Ябалак Гыймае гүпчи урыс булып кайткан. Татарчасы ипилектозлык кына калган!

— Катыргадан качып кайткан ул, шуңар элеп киптергән шикелле икән!

Атасы, пыр тузынып, кибеттән бишмәтлек алган да бер мәлне Сафа абыйны чакырырга килде:

— Улымны мөселманча киендереп бирсәнә,— ди бу.— Болай йөрсә, йортымнан бәрәкәт качмагае дип куркам.

Тик нигәдер бишмәтлек һаман ята бирде, Зимагур Гыймае урыс пәлтәсен кия бирде.

Ул килеп керүгә, бүтәннәр кысылышып аңа урын бирәләр, сәкегә узарга әйтәләр. Әмма ул, очлы бүреген тез башына элеп, стена буена утыра да иң элек тәмәке соранырга тотына иде.

— Кая, көйрәтик әле берне!

Шунысы кызык: ул ни дә булса әйткәнче башын, гүя нык утырамы икән дигәндәй, ике-өч мәртәбә уңга-сулга каерып карый. Шуның өстенә, ул нигәдер Сафа абый белән генә сөйләшә, аңа гына дәшә иде.

— Күрәм, күрәм. Синең эшләр, кәнишне, симез түгел. Хотя, монда нәрсә? Халык бөлгән. Менә шахтада ул акча! Фарт килсәме? Фарт килсә, бер сәгать эчендә купис буласың. Без бер галах белән икәү бер казуда менә моның кадәр алтын каптырдык.— Зимагур йодрыгын йомарлап күрсәтте.

Телләрен чартлаткан, исләре киткән тавышлар ишетелде. Сафа абыйның хәтта йөзенә курку чыкты.

— Кит аннан! Шул тиклеме?! Икегезгә генәме?

— Нәкъ! Йодрык хәтле!

Кызыл сакал, күзләрен чекерәйтеп, зимагурның җиңенә ябышты:

— Сон, соң? Я, әйт тизрәк, нишләттегез, кая куйдыгыз?

Зимагур яңгыратып тамак астына чиертте.

— Эчеп бетердек!

Кызыл сакал ыңгырашып куйды.

— Их! Елап киткән мал! — Ул зимагурны селкетергә тотынды.— Соң, дивана, аның белән Ислам байныкы шикелле мөгәҗи ачарга була бит!

Гыймай кулларын җәеп иңбашларын гына җыерды.

— Чуртымамы?

— Нужэли аңламыйсың? Байыйсың бит, бай буласың, бай!

Зимагур көлде генә.

— Рәже ул көннәрдә мин бай булмадым? Беләсең килсә, мин байның үзен халуй итеп йөгерттем. Кереп утырдык та шулай, палавой бер чирек аракы китергән. Юк, мин әйтәм, безгә загранишний булсын! Китерә бу. Юан корсаклы, алтын пичәтле. Юк, мин әйтәм, хужа үзе китерсен, беләгенә салфетка салсын, өстәлне үзе сөртсен! Йөгереп кенә йөри, эттән туган! Ә мин аның йомшак җиренә тибәм, күлмәк эченә якасыннан тозлы кыяр суы агызам! Ха-ха-ха! Ә ул түзә, ул синең алдында кырыкка бөгелә, көчек баласы шикелле, койрыгын болгый! Ник дисәң, ул акчага чукынган, җанын саткан! Ә миңа кызык!

— Аның каравы, алтыныңны сыпырып калган! Акчаң беткәч, нибуч, бөгелеп-сыгылмагандыр әле, куып кына чыгаргандыр.

— Ә анысы икенче разговор. Бер намазга ике азан әйтелми, ди татар.

Кызыл сакал, үз малы җилгә очкандай, ачынып йөзен чытты.

— Соң инде, кулга төшкән бит, менә бит, менә, учында бит! Юк инде, юк! Алла-тәгалә әйткән, ди шул. «Малын биргәнгә акылын бирмәм»,— дип әйтеп әйткән, ди.

Зимагур аңа аркасын куеп утырды да тагын Сафа абый белән генә сөйләшергә тотынды.

— Ни җирләр йөреп, ни илләр гизеп, эшләп кенә баеган бер кешене дә очратмадым! Баер өчен я кеше үтерергә, я алдашырга кирәк!..

Кечкенә яктан хуҗа хатынның куркынган тавышы ишетелде.

— Китсәнә аннан, әстәгъфирулла-тәүбә! Сөйләмә минем өемдә андый көфер сүзләр!

— Менә сиңа иң чын, иң нык зимагур анты! Кешегә ялган, мина чын! — Зимагур, очлы бүреген тәрәзә төбенә ыргытып, аякларын идәнгә сузды.— Ярар. Шундый-шундый тамаша. Алтын чыккан якта булды бу, бик ерак, Себердә. Мин бер алтынчы байның хезмәтчесе булып йөргәндә...

Кече яктан, кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә, хуҗа хатын да чыгып басты. Сафа абый, эшеннән туктап, тынып калды. Барыбыз да тегенең авызына текәлдек.

— Я, я!

— Шуннан?

Зимагур юлбасарлар шайкасының караңгы төндә боларны таларга чыгуларын, алар белән төп буе сугышуын, ахыр чиктә кул-аякларын бәйләп ташлауларын шундый итеп сөйләде, мин аның өчен котым чыгып утырдым.

Зимагур чыгып киткәннән соң, бераз тын утырдылар.

— Булганны сөйли бит бу, шилма! — диде кызыл сакал.

— Аныкын аера алмассың: әллә чын, әллә ялган!

— Үзе күргән, үзе! Тик менә ярты малны кая куйган диген син? Бер нәрсә дә йогып кайтмаган бит!

— Төкерә ул синең малыңа! Аңа ике дөнья — бер тиен, ике чабата — бер кием. Сөйләгәне юкмыни? Нихәтле алтын табып, һәммәсен пыран-заран китергән!..

Хуҗа хатын кече якта беравык савыт-сабаларын чылтыратканнан соң, түзә алмыйча, яңадан аралыкка килеп чыкты.

— Юк, чын ул, билләһи, чын! Бары тик койрыгын гына тегеләйгә борып җибәрде.

Шулай ризасызлык тудырса да, зимагурның керүен без икенче көнне дә, өченче көнне дә түземсезлек белән көтеп алдык.

## VIII

Бер көнне без кием теккән йортка күршедән бер апай хат тотып керде.

— Тегүче малай язу белә икән, дигәч, керүем әле бу. Солдат улымның хатын укып бирмәссеңме икән, энем?

Кая инде ул укымаган! Бик рәхәтләнеп! Ичмасам, беразга гына булса да эшеңне куеп торасың. Шуның өстенә яхшылык эшлисең.

Башта өй эчендәгеләргә, аннан соң аз дигәндә ярты авылга һәркайсының исемен атап та, атамыйча да күндергән «күпдин-күп, чукдин-чук» сәламнәрне укып барганда эшләр ярыйсы гына иде. Солдат анасы, сәламнәрнең һәркайсын иясенә тапшырыр өчен, бер исем чыккан саен башын ия, бармагын бөгә барды. Әмма озак та үтмәде, апайның чырае бозылып, иреннәре дерелди башлады.

— ...Дәхи шул да мәгълүм булсын,— дип язган солдат,— куып китерә торгач, безне әллә тагын дөньяларның аргы якларына олактырдылар. Җир дисәң, җире юк, урман диерлеге дә юк, җилләре җил түгел, күз ачыргысыз ком бураны. Бер дә бүтән түгел, алла каргаган тау-таш арасы бу. Әти-әни! Безнең хәлләрне белэсегез килсә, бездә тәмуг газаплары. Әфисәрләрнең кансызлыгына бер дә түзәр әмәл юк. Көн дә кыен ашыйбыз. Бигрәк тә бәгырьләргә тигәне — слависный

дигәннәре. Урысча белмәгәнлек белән сүгелгән дә без, кыйналган да без. Патша хатынының исемен тотлыгыбрак әйттеңме, ява виличестваның кечтеки малае ни атлы икәнне оныттыңмы, фитфибель шундук «гаталубый!» дип муен тамырыңа утырта. Ата-ана белән сүгү дә калмады, яңаклау да, әчелек түктерү дә. Бер сүзне әйтә белмәгән өчен капчык белән ком күтәреп эссе кояш астына пад винтуфкы куялар. Бик үзәк-бәгырьләргә үткәндә: «Ник иჩмасам урыс булып кына тумадык икән?!» дигән чаклар да юк түгел. Әйтер сүзләремнең иң кирәге шул: энекәшләр урысча өйрәнсен! Хурланмасыннар, Чыпчык авылында дуңгыз көтсеннәр, алпавытка хезмәтче булып керсеннәр, тик урысча белеп үссеннәр. Безгә шунсыз көн булачак түгел.

Әти, әни, сезгә тагын гозерем бар: ул зобаныйларны майламасаң, моннан исән котылу юк. Зинһар өчен дип әйтәм, бер савыт кәрәзле бал белән өч тәңкә акча җибәрә күрегез. Исән йөреп, саулар кайтсам, газиз җаным тәндә чагында бу изгелегегезне онытмам...»

Хатны укып бетерү җиңел булмады. Әлеге апай битен каплап тыела алмыйча елый. Сафа абый башын иеп тынсыз калган. Зимагурның күзләре елтырап китте:

— Тормыш бит ул әкияттә генә шәп. Шуңа күрә без, аягүрә төш күреп, әкияткә алданып яшибез.

Апай кеше күзләрен сөртә-сөртә һаман сулкылдый иде.

— И бичаракаем, кешегә бармак белән генә дә чиерткән бала түгел бит ул. Кызлар шикелле генә үсте, рәхимле, шәфкатьле булып кына. Ул кыенга нихәлләр түзмәк кирәк?..

Зимагур, сәер генә итеп, башын тагын уңга, сулга каерып-каерып куйды:

— Ник түзә соң? Түзмәсен! Әнә шулай җебеп торганга күрә дә изәләр инде безне.

— Әйтергә генә ансат, нишли ала соң ул анда?

— Нигә шул дуңгыз мордага ыздачы бирмәскә? Солдатка сугарга аның ниткән правасы бар?

Сафа абый башын чайкап куйды.

— Бирерсең ыздачы, катыр китәсең килсә!

— Китсә тагы! Казарма каторга түгелмени? Дисвительнидә мин дә булдым. Беләм әзрәк. Әнә солдат бәетендә зерәгә генә әйтмәгәннәр: «Ант итмәдем, корьән үпмәдем, дип, генералның битенә төкердем, мыскыл иткән әфисәрне чәнчеп үтердем», дип. Менә иჩмасам, солдат!

— Кит аннан! Башкисәр булгандыр ул, разбойнек!

— Беләсең килсә, самый батыр кеше әнә шул инде! Андыйлар, бозау шикелле башын иеп, кыйнаучыга иңен биреп тормыйлар. Андый егетләр патшаның үзбашына җитәргә йөриләр. Белдеңме шуны!

Сафа абый, астына чәнечкеле әйбер кысылгандай, арлы-бирле селкенгәләп тамак кырды. Теге апай, улының хатын күкрәгенә кысып, гүя куып барган эттән курыккандай, артына борылып карый-карый ишеккә таба ашыкты:

— Тефү, тефү, әстәгъфирулла-тәүбә! Авызыңнан җил алсын! Катыр да Себер! Аллам сакласын! Син әйтмәдең, мин ишетмәдем!..

Зимагур аның артыннан кычкырып көлеп калды.

— Котың чыкмасын, бичара! Синең малаең ишеләр шулай көчек шикелле шыңшый гына беләләр алар!

Өйдәгеләр, күз алдында ниндидер ярамаслык нәрсә эшләнгәндәй уңайсызланып, тынып калдылар. Зимагур исә берсеннән-берсе сәер нәрсәләр сөйләп китте. Имештер, башка илләрнең күбесендә патшаларны әллә кайчан куып төшергәннәр инде, ә Рәчәйдә әле һаман утыра! Әле җитмәсә, үз янына җыен әрәм тамакларны, ат каракларын җыйган. Алар һәммәсе халык җилкәсен кимерә. Беләсезме, күпме ала патша жалунҗаны?

Китте чутлау-чамалау, санап карау.

— Аена бер өч-дүрт йөз аладыр әле,— диде берсе. Агайның бу үзенчә, бәлки, бик күпертеп әйтүе булгандыр да, әмма бүтәннәре аны да күпсенделәр.

— Алай ук булмас ла! Аны мужик ничек күтәрсен? Ел тәүлегенә бик күп җыела бит ул!

Зимагур, башын кыегайта төшеп, бүтәннәрнең сүз көрәштерүен тыңлап торды да йодрыгы белән тезенә сукты.

— Көненә унсигез мең!

Башта, авызларын ачып, тынсыз-өнсез калдылар. Аннары кайсыдыр сызгырып җибәрде.

— Фи-и-ю!

— Ай-ай! Ташкулчим!

— Бер көнгәме?

— Бер көнгә!

— Унсигез менме?

— Әйе, бер тиен артык та, бер тиен ким дә түгел, нәкъ унсигез мең тәңкә!

— Борчак! Борчак!

— Түгел икән шул! Питербурның үзеннән килгән бик башлы бер студент әйтте.

Кызыл сакал урыныннан ук сикереп торды:

— Син нәрсә, кара халык дигәч тә авыл кешесен гел тинтәккә санайсыңмени? — Ул чыгып китмәкче булып кузгалды да иренеп яңадан утырды.— Ел тәүлегенә шутлап чыгарсаң, аңа бит башыңдагы чәчең дә җитмәс!

— Әллә җитәме? Нигә башың недаюмкадан чыкмый! Нигә имана түләмәгән өчен самоварыңны саталар! Нигә бишмәтләрегез ямаулы?!

— Дөрес әйтә зимагур. Әле ул гынамы? Патшадан алып волостьтагы урәтникләргә тикле әллә тагын йөз мең түрә бар. Алар да бит, сөлек шикелле безнең канны суыра.

— Әй, чукынсын ла бөтен дөньясы! Булмады инде...

Һәммәсе дә күңелсезләнеп кайтырга кузгалдылар.

Мин бу абыйның озаграк утыруын телидер идем. Күренеп үк тора бит: әллә кайларда булган, әллә ниләр белә. Әмма күргәннәренең, бәлки, уннан берен дә сөйләми торгандыр әле ул! Барыннан да бигрәк мине чугунканың нигә салынуы кызыксындырды. Мин шул турыда сорадым:

— Абый, теге Корткачык янындагы чугунканы патша үзенә качарга дип салдыра, диләр. Ул да чынмы?

Зимагур башта нигәдер Сафа абыйга күз кысып алды.

— Һи, чын булмаска! Вәтке урысы бит ул. Арт ягына пишатыр кыстырсалар, кая барсын? Сукага ябышмаса, аның кулыннан бүтән пычагым да эш килми.

Минем чиркәүдә патшаның кеше буе рәсемен күргәнем бар иде. Зимагур әйткәнгә никадәр ышанырга тырышсам да, патшаның ялыкйолык итеп торган алтын погонлы, ефәк тасмалы киемнәре белән сука артыннан балчык ерып йөрүен һич күз алдына китерә алмадым.

## IX

Бер-ике айдан мин яңадан авылдагы хәлемә кайттым: яңадан китап-дусларым белән серләшү җаен таптым. Яңа хуҗага керү белән, аз гына форсат чыгуга, сәке өстенә менеп китап шүрлегендә актарына торган булдым. Әгәр дә тузан баскан «Коръән», «Һәфтияк» һәм башка шундый калын китаплар арасыннан мин укырдай берәр «дөньяви» китап табылса, ул көнне миннән бәхетлерәк берәү дә булмас иде.

Тегүченең ял итә торган вакытлары бар. Бу — жомга вакыты һәм әңгер-меңгер чак. Шул минутлар килеп житүгә, тегүче уймагын кәтүк кадагына элеп куя да урамга чыгып китә.

Сафа абыйның күләгәсе күмелүгә, мин китабымны алып кая да булса тәрәзә янына яки учак яктысына барып утырам. Шул минуттан башлап мин үземнең кайда утыруымны ук онытам.

Минем хыялымда күз алдына бөтенләй яңа һәм мавыктыргыч бер тылсымлы дөнья килеп туа. Мин диңгезләр уртасындагы маймыллар, алтын койрыклы тавислар яши, шәфталу һәм йөзем жимешләре үсә торган яшел утрауларга барып чыгам. Китапта язылган кызык вакыйгалар мине дөя дигән өркәчле хайваннарга атландырып, ком чүлләренә, аисә кеше аяк басмаган яшел урманнарга алып китә. Мин гомеремдә бер тапкыр да күрергә туры килмәгән зәңгәр диңгезләрдә йөзәм, китап геройлары белән бергә төрле гажәеп хәлләр кичерәм, баш әйләндергеч дәрәжәдә буталчык, әмма мавыктыргыч төрле вакыйгалар эчендә кайныйм.

Әмма ул рәхәт озакка бармый, иң кызык урынына житкәндә генә бүленергә туры килә. Шулай да ул рәхәтне озакламыйча тагын татыйсың барлыгын хис итү көне бүе сине рухландырып, күңелне күтәреп тора иде.

Минем китап белән болай чиктән тыш мавыгуым олыларның кайберләренә ошамады, кайберләренә сәер тоелды.

— Һай, малай! Юкка күз нурыңны түгәсең! — диләр иде.

Минем китапка башым-аягым белән кереп чумуыма, берничек тә аерыла алмыйча артык кичеренеп укуыма борчылучы кешеләр дә булгалады. Китаптагы көлкегә түзеп булмыйча кычкырып көлеп жибәрсәң, аньсы бигрәк тә сәерсенерә.

— Алай дөньяларыңны онытып укыма син, балам,— диләр.— Төшеңә әллә нинди куркыныч нәрсәләр кереп куркытырлар үзеңне, чирләп калырсың!..

Әмма китапсыз булмый. Алар миңа иптәш тә, сердәш тә, күңел ачкыч та, тәрбияче дә булдылар. Алар миңа өй жылысын, анам һәм туганнарым ягымлылыгын бирәләр. Анда тормыш күңелсезлекләреннән дә качып торырга була иде.

Минем бу мавыгуларыма остам әллә ни әйбер әйтмәде.

Шулай да...

Бер карт мулланың кызларына жикет тегеп бирдек тә бүтән йортка күчәргә жыена башладык.

Карт ястүдән кайткач, чалмасын чөйгә элде дә түргә менеп озак кына тәсбих тартты, догалар укып амин тотты. Иелсә дә, бөгелсә дә, утырса да, торса да телендә берөзлексез алла гына иде. Чыгып китәр алдыннан хужа белеп бирмәгәч, эш хакы турында Сафа абый үзе исенә төшерде.

— Кыйбат сорыйсың! — диде карт.

Үч иткәндәй, минем үзем белән йөрткән китабымны алып караштырырга тотынды.

— Кыйбат дип, кеше бәясе инде. Кемгә дә шул бәядән тегәбез.

Карт күзлексез күрми икән, китапны әле бер ягы, әле икенче ягы белән әйләндерергә тотынды.

— Әллә бисмилласыз китап инде!..

Китапның ничек тә абруен саклап калырга кирәк иде:

— Бар аның бисмилласы, мулла абзый, бар,— дидем.— Әнә иң беренче битенә бик матур иттереп челтәрләп язган.

Әмма картның хөкеме әллә кайчан ук әзер икән.

— Һем, тапкансың укыр китап! Хужа Насретдин! Нинди савап булсын аны укудан! Жыен әкият, жыен бидгат! Әстәгъфирулла-тәүбә!

Ил имамнарына тел тидереп, дин әһелләрен мәсхәрә итеп йөрүче шыр дивана булган бит ул! Дәһри!

Хәзрәт китапны шап иттереп сәкегә ыргытты. Сафа абый күзенең агы белән бер миңа, бер китапка карап алды. Кулыннан килсә, ул аны ертып ташлар иде. Әйтерсең, бөтенесенә Хуҗа Насретдин гаепле!

— Өч көнгә якын утырдык бит!

— Утырсагыз соң? Син безнең авылда ел саен кыш буе эшлисең. Мәчет кирәгенә күпме өлеш чыгарганың бар? Юк бит!

— Югары оч мәчетенә крачин алып бирдем.

— Менә монысы безнең мәчеткә булыр. Дога кылырмын.

Кече яктан, еларга житешеп, кызы килеп чыкты.

— Әти, дим, яхшы түгел бит, кеше ишетсә, хур булабыз.

— Кысылма! Мин үзем беләм!

Сафа абый кызарынып-бүртенеп бишмәтенә барып ябышты.

— Алла боерса, моннан соң йортына ике аягымның берсен атламам. Үзеңә генә түгел, бөтен нәсел-ыруыңа! Кыямәт көнне эш хакымны сорап якаңа ябышырмын!

Хәзрәт, ястыгына кырын ята төшеп:

— Һм! — дип көлемсерәп куйды.— Ябышырсың, якамда Чыпчык урысларыннан буш урын калса! Аларга бирәчәгем ун өлеш артык.

Сафа абыйның чырае усалланып китте. Ул, жилтерәп барып, жикетнен берсен алды да янып торган мич алдына килеп басты.

— Бирмәсәң, утка атам! Валлаһи!

Кызлар йөгерешеп килеп ялынырга тотындылар.

— Сафа абый, алла хакы өчен!

— Ачуым ачу! Рәнжетмәсен! Хәләл акчам!

Хәзрәт түзмәде, сәке кырыена төшеп, ачуыннан идәнгә типте.

— Керәшендәй кире икәнсең! Ярар, тавышың тыгылсын!

Шул көннән башлап минем остага ихтирамым тагын да арта башлады.

## X

Шулай да бу дорфалыкның ахыры алай бик үк күңелсез очланмады.

Икенче көнне жомга алдыннан, вәгъдә иткән хезмәт хакын алырга дип, әлеге кире картка яңадан киттем.

Бу вакытта яз якынлаша башлаган иде инде. Өй түбәләреннән озын-озын булып асылынып торган бозлардан тып-тып тамчы тама. Кояшның төсенә кадәр үзгәргән. Ул хәзер кыш көнеге төсле жансыз күгелжем түгел. Хәзер кояштан өй түбәләренә, коймаларга, урамнарга мул булып кешеләрнең битен коңгырт төскә бизи торган сыек кына алсу-саргылт нур сибелә.

Ислам бай кибете янына жыелган бер төркем егетләр, ташып торган яшь көчләрен кая куярга белмичә, шаярышып төртешәләр, бер-берсен карга егышалар.

— Тегүче егет кызлар янына китте! — диде берсе.

— Кесәсендә нәрсә икән, «Гөлжиһан» сабынымы, кызыл билле прәннекме?

— Ярый ла: кызлар, кочаклыйм дип, ялгыш кына кысып үтермәсәләр.

— Юк ла, тегүче хәйләкәр була бит ул, тәгаен берәр жирләренә посып калыр ул!

— Һа-һа-һа! — дип бөтен кибет яны бер кешнәп алды.

Бүтәннәрен көлеп кенә уздырсам да, соңгы сүзләре ярыйсы ук кытыгымны китерде. Аһ, чәнчелеп киткерләре!

— Кысылсам да, посынсам да, сезгә килеп ялынмам! — дигән булдым. — Белдеңме шуны!

Монысына тагын бер кешнәп алдылар.

Йомры атау ягына менеп җиткәч, без кайтасы юллар ачыграк күренә башлады. Әрлы-бирле борылгалап, үзәннән үргә, үрдән иңкелгә сузыла торгач, Яңа Сала юлы урман эченә кереп китә. Әллә нәрсә генә йөрәкне чеметеп алды. Безнең авыл да, менә шушы Ямаширмә шикелле, язгы кояш нурларында балкып ятадыр. Су буенда казлар каңгылдаша, үрдәкләр кычкыра торгандыр. Күз өстенә кулын куйган хәлдә, мин кайтасы якка — болын юлына карап торучы әни күз алдына килде. Кышын-җәен бергә уйнап, бергә укып үскән иптәш малайлар искә төште. Аннары — Миңниса... Аннан бер җан бизгән иде инде. Нигә ул һаман да искә төшә икән?

— Актык чана юлы белән кайтырбыз, — ди оста.

Кулымнан килсә, бу тау-тау карларны мин бер көн эчендә эретеп бетерер идем.

Шулай да хәзер көз көнегә кебек кәефләр гел болытлы түгел, күңел түрендә юаныч чаткылары күбрәк иде инде. Кайсы малайның читтә, минем кадәр озак йөргәне бар? Юк андый малай, юк! Кемнең шундый кызык кешеләр күргәне, төрле маҗаралар ишеткәне бар? Юк андый малай, юк!

Актык чана юлы!.. Һи, аңа әнә бит инде күпме генә калган! Тагын ун көн, бик күп булса унбиш, егерме!

Барып керсәм, өй эче кызлар белән тулган, кием котларга җыелганнар. Шау-гөр килеп, кичә без тегеп чыккан яңа җикетларны карыйлар. Берсе, биленә таянып, көзге янында бер-ике әйләнергә дә өлгерми, икенчесе, өченчесе салдырып ала. Телләре телгә йокмый, мактап сүзләре бетми.

— Ай, җаным, билләре лә, билләре! Өздереп кенә куйган, бер генә учларга сыярлык!

— Иңбашларын әйт син, күпертмәләрен!

Ул арада бу мактау сүзләре, кояшлы яңгыр кебек, көтмәгәндә генә минем өскә коела башлады. Арадан берсе минем аркама кулын салды.

— Әй, кызлар, нәрсә авызыгызны ачып торасыз! Менә бу егет тә теккән бит аларны!

— Әйе шул, әйе генә шул!

— Әнә бит, болын тугайлары шикелле бормалы-бормалы итеп эчен ул сырган, нинди килешле иттереп итәкләрен каеган!

— Чеметтереп-чеметтереп кенә төймәләрен таккан! Туләргә кирәк әҗерен, түләргә!

Ул да түгел, айгыр кебек бер тазасы мине кочаклап алды да, колаккола, колак төбемдә әлләниләр пышылдарга тотынды. Анысыннан көчхәл белән ычкынуга, тагын бер чаясы билемнән эләктереп алды да идән уртасында әйләндерергә тотынды.

— Тукта, сиңа гына димәгән, җитәр! — дигән булып, берсе күкрәгенә кысты, әллә ничәнчесе маңгаема, битемә үрелде, тагын берсе кочаклап сәкегә аударды. Алардан эссе бәреп тора, түшләреннән хушбуй исе, битләреннән иннек белән кершән исе бөркелә иде.

Өй эче шау-гөр килә, бөтенесе егылышып көлешәләр, кулларын чәбәклиләр. Аларга уен, әмма минем хәлем бик мөшкел иде. Мин оялуымнан яныл-пешеп чыктым.

Әмма шул вакытта, минем бәхетемә каршы, кайсыныңдыр тәрәзәгә күзе төште дә:

— Әйдәгез! — дип урамга йөгерде.

Капка төбенә чыксак, урамнан култык астына кечкенә генә төенчек кыстырган Мазлума узып бара. Аны шундук сырып алып, берсен берсе бүлдерә-бүлдерә сорашырга тотындылар:

— Каян болай?Ниләр булды, җаным?
— Ничек котылдың?
Мазлуманың түсе киткән, күзләре курыккан кешенекедәй ялт-йолт килә.
— Бармадым! — ди ул. — Ярты юлга җиткәч, теге убырлыдан качып, төнлә вагоннан төшеп калдым.
— Ай, җаным, ничек курыкмадың?
— Инде нишләрсең? Кая барырсың?
— Урматыма кайтам! Үз авылым, үз почмагым. Сыендырыр әле, ят итмәс.
Кызлар артыннан мин дә Мазлуманы урам буенча озата киттем. Капка төпләреннән аңа кул изәп, я берәр җылы сүз әйтеп калалар.
Безнең барыбызга да бик күңелле, бик рәхәт иде. Шунда Мазлуманың теге җыры янадан исемә төште.
Нишләп бәхетсез булсын икән Мазлума? Юк, бәхетле булырга тиешле Мазлума!

## Китап җене кагылган малай

### I

Ямаширмәгә икенче елны да бардык. Тагын шулай дүрт-биш ай өй борынча йөреп уздырдык. Ул кышны оста мине зуррак эшләргә дә кушкалый башлады. Үзем дә ияләшә төштем, бераз шомардым да. Һәрхәлдә, беренче елдагы кебек кояш баеган вакытларда капка төбенә чыгып Яңа Сала ягыннан күзне алмыйча моңаеп торулар булмады шикелле.
Бу елны кич утырулар зимагурсыз гына узды. Ул тагын каядыр эзсез-хәбәрсез чыгып югалган иде. Аның атасы Сафа абый янына килеп зарланып та утыргалады.
— Нинди малай булды бу? — ди. — «Өйләндерим, улым», — дим. Якын да килми. «Миннән башка да хаерче җитәрлек», — дип кенә җибәрә. Нәрсә кетә бу? Башында нинди уйлар йөртә бу? Уйны анысы йөртә йөртүен. Баш бик шәп эшли аның. Гел укый, гәзит укый да китап укый. Кайвакыт патшалар, министрлар турында сөйли башлый да шулай, кая ул андыйга безнең акыл җитү! Пүчтәк буласың да каласың.
Карт шулай борчылып утыра-утыра да Сафа абзыйдан шыпыртлап сорап куйгалый:
— Сиңа сиздермәдеме? Әллә теге катыр җиреннән качкан диюләре дөрескә чыгамы икән югыйсә?.. Кайда йөрүләрен тәки әйтми бит малай...
Мазлума турында да төрле хәбәрләр ишетелде. Ничек итсә иткән, мөгаллимә булырга укый башлаган диделәр.
Өченче елны мине тегүгә җибәрәсе итмәделәр. Нишләп? Ни сәбәпле мине тегүче итмәскә булдылар икән? Моның сәбәбен әйтүче булмады. Аны мин акыл белән аңлап белүдән бигрәк, күңел белән сизендем. Ул елларны әти еракка таба уйламый, бүгенгесен ничек үткәрәсен белмичә, иза чигә башлаган иде.
Хәер, тормыш як-якка каранырга да, балалык уеннары белән онытылырга да вакыт калдырмады. Ул кышны минем кулдан дилбегә төшмәде, ярты гомерем Арча юлында узды. Күрше Гайни абзый белән без, байга ялланып, урманнан Арчага утын ташыдык.
Карлар эреп чана юлы өзелдемә, җиргә аз гына эзлек төштеме, мин тагын кырда, урманда, болында, я алпавыт басуында. Ялгы пычрак кибәр-кипмәс чагында чыгасың, көзге кырпак төшкәч керәсең.

Миенне кайнатырдай эссе кояш астында да син басуда, җеп бөртегенә кадәр җебетеп, бөтен тәнеңне бөрештереп китергән салкын яңгыр астында да, боз яуса да, җил-давыл купса да.

Таш булып каткан пар басуын сөргәндә, сабан тоткасы сине — сабаннан аз гына калкурак үсмер малайны — чөеп-чөеп ыргыта, кигәвен вакытында атың, кая барып бәреләсен белмичә, урле-кырлы сикерә, чебенле торгач, сөйрәп су буена алып чаба. Эштән чыгып арыйсың, тез буыннарыңның хәле бетә, аякларың атламый башлый.

Кичен табын янына кайтып утыргач, кулларың бөгелми. Моны күреп әниниең күзләренә яшь килә:

— Буыннарың ныгып җитмәс борын ук имгәнеп бетәсең инде, балам! — ди.

Әнинең, билгеле, мине юньлерәк ашатасы килгәндер. Ләкин каян аласың? Гаепле кеше сыман башын түбән иеп табынга күбесенчә шул ук коры ипи белән сөтле чәйдән, бәрәңге белән сыек өйрәдән башка ризык китерә алмый торган иде.

Күршеләр тәкә суеп, сосла кайнатып җыен бәйрәменә хәзерләнгәндә, безнең казанга атналар буе итле аш керми башлады. Нигә без шул хәлгә калдык икән? Күрәсең, әти авыргалый башлаудандыр. Җир аз булганлыктан, безнең үз икмәгебез бервакытта да яңага җитми торган иде. Әти исә хәзер верстагында бераз кыштыр-мыштыр килгән була да, тыны бетеп, сәкегә барып ава. Бераздан ыңгырыша-ыңгыраша яңадан торып эшләргә ябыша. Ләкин озак та үтми, тагын сәкегә барып егыла иде. Миңа җир күрсәтергә дип басуга барырга чыкса да, шул ук хәл. Ындыр артына чыгып җиткәч, гыж-гыж килеп тагын кире борылып кайта.

Тик аның соңгы вакытта саулыгы гына түгел, күңеле дә сынган, гомер буе инанып йөргән изге иманы да җимерелеп төшкәнгә охшый иде.

## II

Бер көнне кичкә таба кайчандыр Төркиягә алып китәм дип акча җыеп та, аны кайтарып бирмәүче карт хәзрәт каядыр узып барышлый безгә төште. Әти үзебезнең авыл мулласы белән ни сәбәпледер килешә алмагангамы, ничекме, аңа ара-тирә күрше авылның шушы карт муллласы сугылгалый торган иде.

Әти мулланың теге вакытта акчаны изге юлга тоткан дип ышангандыр, күрәсең, ул аңа караңгы чырай күрсәтмәде. Тик кунакны сыйларга берни дә булмавына борчылуы ачык сизелә иде.

Хәзрәтнең атын тугарып, яхшы тарантасын лапаска кертеп куйганнан соң да кунакны өйгә дәшәргә ашыкмады. Әле генә баеган кояш ягына карап, гүя үз-үзенә сөйләнгәндәй:

— Кая соң, кунакны ни белән сыйларга инде? Шәригать кояш баегач терлек суярга кушмый бит! — диде.

Әмма карт мулла алай ук дип уйламый икән.

— Мондый чакта, мосафир хөрмәтенә, шәригать рөхсәт итә, кем, Бәшир, итә, итә! Минем өйнең морҗасыннан чыккан төтен күренмиме? Күренми. Бәс, шулай булгач, мин инде мосафир исәпләнәм.

Әтинең моңа ышанасы килмәде.

— Ай-һай, хаталанасыз булыр, хәзрәт. Мин хәтерлим, кояш баеганнан соң суйган терлек хәрәм була дип язылган.

Мулла чалара башлаган сакалын сыйпаштырып хәтта көлеп куйды.

— Бәрәкалла, Бәшир, ышанмыйсынмы?! Әстәгъфирулла диген! Безгә елына ничә тапкыр коръән чыгарга туры килә!

— Алайса, хәзрәт, хәрәм булса, моның гөнаһы сезнең өскә төшәр!
— Гөнаһ булмас, кем, Бәшир. Инде була калса, аллаһе тәбарәкә вә тәгаләнең рәхмәте зур, шәфкате диңгездәй киң.
Караңгы төшүгә карамастан, эти сарыкны суйды. Хәзрәтне ит белән дә сыйлады, һич караңгы чырай күрсәтмәде. Кунак хакы бар лабаса! Әмма иртәгесен озатканда эти карт мулланы гына түгел, өйдәгеләрне дә гаҗәпкә калдырды. Ул аның атын җигеп, тарантасына печән салды да саубуллашырга кулын сузды.
— Хуш, хәзрәт, — диде. — Моннан соң очрашмавыбыз хәерлерәк булыр. Минем рияланасым килми.
Карт мулланың гарьләнүдән иреннәре дерелдәп китте.
— Бәрәкалла, Бәшир! Син мине гаҗәпкә калдырдың. Ни сәбәп?!
Эти кулын аркасына куеп хәзрәткә таба иелде.
— Бер хата исәпкә алынмый дип әйтик. Бик тырышканда, ике хатаны да онытып була. Әмма ләкин синең эше карт хәзрәт күрә торып өч тапкыр хаталана икән, белмим, хәзрәт, моны инде шәригать кенә түгел, безнең ише надан мужик башы да сыйдырмый.
Хәзрәт кабаланып тарантасыннан ук төште.
— Хуш, хуш, ягъни, ничек инде ул? Нинди хаталар? Каян җыйдың аларны?
— Нинди ме? Менә шундый: Төркиягә күчәргә була дип халык күңеленә тәшвиш салдың. Булмаслыгын белә торып, шуңа акча да җыйдың. Бер булды! Ул акчаны кайтарып бирмәдең. Ичмасам, нинди эшкә тотылуын да әйтмәдең. Ике булды! Кояш баеганнан соң терлек суярга фәтвә биреп хәрәм ит ашаттың. Өч булды! Хуш, хәзрәт.— Шундук ничектер йомшарып киткән сәер тавыш белән миңа дәште: — Ач капканы.
Шуннан соң эти бик каты рәнҗеп, бик яман хәтере калган сыман, беркем белән дә сөйләшмичә, карасына көеп йөри торган булды. Мөхәммәтҗан солдат белән сөйләшкәндә дә ул, өметсез кыяфәт белән кулын селтәп, әледән-әле:
— Җыенысы ялган! Бөтенесе алдакчы, оятсыз! — дип әйткәли иде.

## III

Шул араларда булып узган тагын бер хурлыклы хәл картны аеруча какшатып җибәрде.
Безнең бер еллык имана акчасы түләнмәгән икән. Авылда андыйлар күбәеп киткәнлектән, староста Арчадан урятник чакырткан. Аның, җәмәгать җыены җыеп, түләмәүчеләрнең исемнәрен укырга тотынды:
— Керәшен Яңа Саласыннан имана акчасы түләмәүчеләр... — дип башлаган гына иде, Мөхәммәтҗан солдат арттан кычкырып аны ярты сүздә бүлдерде:
— Ваше благородие! Сез бит монда ялгыш менгән. Без бит Чукынган Яңа Сала түгел, бу як саф татар авылы.
Урятник «Как так?» дип ни әйтергә белмичәрәк торганда, староста халык ягына күз кыскалап, елмайгалап аның колагына нидер әйтте. Урятникнең йөзе кинәт яктырып китте. Ул Николай патшаныкы төсле итеп түгәрәкләп китергән җирән сакал-мыегы, күк күзләре белән бөтен тирәгә балкып көлә-көлә бармак янады:
— Шаяртмагыз! Император хәзрәтләренең ялгышуы мөмкин түгел! Юк! Ул һәр халыкны үз баласын кайгырткандай кайгырта. Белдегезме шуны?! Сезнең килочәгегезне күздә тотып шундый исем куйдырган ул. Кайчан да булса, барыбер православный буласыз бит!
Эти исемен дәшүгә, арттан «Мин!» дигән тавыш ишетелде. Халыкны ерып эти түгел, урятник каршысына башка чыккан абыебыз —

Вәли чыгып басты. Халык гөжләп алды, ләкин берәү дә берни дә әйтмәде, хәтта староста да эченнән генә тынды. Вәли абыйның мыегы урәтник мыегы шикелле үк кукраеп тормаса да, ул гәүдәгә аннан да эрерәк иде. Солдатта булып кайткан кеше, урысчасы да урәтникнең үзен сатып җибәрерлек икән.

— Без шаяртмыйбыз, — ди бу. — Мин үзем дә дисвительнидә булган кеше. Патшаларның безне ничек кайгыртуларын яхшы беләм... — дип тезеп китте дә халыкка борылып татарча өстәп куйды: — Аркадагы шомпол эзләре әле дә сызлап тора...

Урәтник, колакларын торгызып:

— Как, как? Нәрсә анда кәлә-мәлә киләсең? — диде.

— Мин әйтәм, патша хәзрәтләренең безгә ничек рәхим-шәфкатьләрен салуын сәгать саен, минут саен үз җилкәбездә тоеп торабыз. Тик шуңа гына түзә алмыйбыз: нигә безнең татар авылына Чукынган Яңа Сала дип кушканнар? Бабайлар чукынмый калган бит, безгә дә кирәкми. Әгәр дә мәгәр үзенең кече улын, тәхеткә утырасы Әләксине көчләп мөселман иттерсәләр, күз алдында кычкыртып сөннәткә утырта башласалар, патша әгъзәм хәзрәтләре үзе нишләр иде икән?

Халык шау-гөр килеп көлешергә тотынды. Кайберәүләр, «Ай, харап итә!» дип, котлары чыгып, урәтниккә текәлделәр. Ләкин ул күпне күргән, олайган кеше булгандыр, күрәсең, кабынып китмәде. Кылычының ялтырап торган җиз башлы сабына таяна биреп, әллә ни булмагандай, тыныч җавап бирде:

— Сез шаярткан булып хәтәр нәрсәләр әйтәсез. Якты дөньядан туйдыгызмы? — диде. — Ә мин сезгә ничек булса, шуны — чын дөресен әйтәм. Рус христианнары сезне, кочакларын җәеп, үз диннәренә кабул итәләр икән, моңа куанырга гына кирәк. Чукынсагыз, бөек рус милләте буласыз бит! Ул чагында патша гына түгел, алла да, тора-бара тел дә бер була. Юкса бит хәзер нәрсә килеп чыга? Держава бер, ә тел шайтан белсен ничә төрле. Менә мин сезнең белән бөек императорның үз телендә сөйләшәм, ә сез моңа каршы нииндидер кәлә-мәлә, кәлә-мәлә!..

Мөхәммәтҗан солдат, борылмас муенын катырып, әйтәсе сүзләрен бераз иреннәрендә тәмләп торганнан соң:

— Ә шул кәлә-мәлә безгә анабыз шикелле газиз булса, анда нишләргә? — диде.

Аңа Вәли абый өстәп җибәрде:

— Әйе. Безнең ул кәлә-мәләне ташлыйсыбыз килмәсә?!

Шунда урәтникнең кашлары җимерелеп китте дә, ул гайрәт чәчеп өстәлгә сукты.

— Җитте! Нәрсә сез монда крамола күтәрәсез! Монысы жандармерия эше! Калганын ул карар! Беләм мин сезне! Үзегез патша җиреннән тыгынасыз, ә хакын түлисегез килми. Староста! Йорт саен кереп әйберләрен җыеп алырга!

Җыен таралды, староста белән дисәтникләр, ат җигеп, имана түләмәүчеләрнең йорт әйберләрен җыярга чыктылар.

Безгә дә керделәр. Староста, дәү сары калай таккан күкрәген киерә төшеп, әтинең каршысына килеп басты. Ул әтинең аңа баш имәвен дә, «закон», «каты борын»[1] дигән сыман мыскыллы кушаматлар тагуын да яхшы белә, аңа күптән үк теш кайрап йөри иде.

— Мине бәреп төшермәкче булдың! — ди бу. — Я, кем аста калды да кем өскә чыкты? Кем яши белә дөньяда? Әнә, минем йортым гөрләп тора, эче тулы мал-туар, ашаганым синең төшеңә дә керми. Ә син нәрсә тоҗырдың[2]? Кемгә игелек күрсәттең? Халыккамы, балалары-

[1] Чучка дигән сүз.
[2] Тоҗыру — кылу, булдыруның ироник синонимы.

цамы? Көне- төне чиләнеп тамагыңны да туйдыра алмыйсың. Атаң салып калдырган өеңнең түбәсен ябарлык та чамаң юк, өстеңә янгыр сибәли.

Минем өстемә бозлы су койгандай булды. Моңарчы этине берәүнең дә болай мыскыллаганы юк иде әле. Эти аягын киң җәеп өйалды ишеге төбендә басып тора, муен тамырлары бүртеп чыккан, артына яшергән йодрыгы сизелер-сизелмәс кенә, тиенкы гына калтырана иде.

— Аның каравы минем күңелем ак, әчемне кеше хакы тырнамый, мир җирен попларга сатып әчмәдем.

Дисәтникләр, тамакларын кыргалап, бакчага таба киттеләр.

Староста кулларын кая куярга белми, аның иреннәре дерелди башлады. Шулай да ул сабырлыгын җуймады.

— Чәнечкеләреңне тирән батырам дип куанма, Бәшир, алар миңа барыбер үтми. Влач минем яклы. Мине менә нәрсә саклый! — Староста күкрәгендәге калаена сугарга тотынды. — Ә синең тәкәбберлегеннән башка нинди таянычың бар? Вәлиеннең бүгенге сүзләре өстенә тагын бер-икене тамызсак, фиит, китте-барды бит Себергә! Ничек синеңчә, Бәшир?

Әни үзеннән олы ирләр алдында кычкырып сөйләшми иде, ул өйалды ишегеп ачар-ачмас бик ашыгып һәм борчылып этигә чаж-чож нидер пышылдарга тотынды. Эти, тамагына нидер тыгылгандай, кылкынып куйды. Әмма шундук тыелып кына көлеп җибәрде.

— Һи, алай барып чыкмас ул, Йосыф! Таяк ике башлы була бит! Беләсең ич, Себер юлына үлән үсмәгән. Күңел биреп тотынганда, синең өстеңә дә шәп кенә тамызып була бит, Йосыф!

Староста як-ягына карангалап тамагын кыргалады.

— Һаман да шул кәпрәю, һаман шул! Янәсе, «Мин кем!» Менә килеп каптың лабаса инде! Нишлисең хәзер! Я тугыз сумны чыгарып саласың, я самоварыңны алып чыгабыз!

Әни өйалды ишеген шапылдатып бер ачты, бер япты, тагын ишек арасыннан пышылдарга тотынды. Эти аягын җәебрәк басты.

— Самоварны бирмәм инде мин сиңа, Йосыф! — диде. — Үзең беләсең, хәзер, картая төшкәч, чәй эчмәсәң, баш авырткалый башлаган.

— Нәрсә киреңә каттың? Синең өчен мин түләрменмени?

— Юк, син мәшәкатьләнмәссең, Йосыф! Акчам булу белән, үзем түләрмен, үзем! Аннары бик якын ук та килмә син миңа. Яшь чакларны онытмагансың бит? Минем бармак эзләре синең яңагыңда бер атна күперел торды. Юкмы, онытмадыңмы?

Староста, кире борылып, бакча караган булып йөрүче дисәтникләргә аяк тибеп кычкырды:

— Кая олактыгыз анда? Миңа гына әчелешле булырга дигәнмени?!

Теле белән рәнҗетсә дә, староста эшне зурга җибәрергә батырчылык итмәде. Әмма эти бу хәлне бик авыр кичерде.

## IV

Безнең йортта тоташ күңелсезлек башланды. Эти хәзер элеккечә эшкә тотынган булса да, ярты гомерен эшли алмыйча, сәкедә ятып уздыра. Чәй янында ара-тирә сүзгә кушылса да, күбесенчә бурычларыннан ничек котылу турында баш вата. Элек беркайчан да зарланырга яратмаган кеше хәзер еш кына сүзен, өметсезләнеп:

— Юк. Булмады инде, булмады, — дип бетерә башлады.

Шушы егылам-егылам дип торган чирле хуҗалыкны сөйрәп бару хәзер әни өстендә иде. Азык-төлекне ничек яңага кадәр сузарга? Терлек-туарны ничек асрап чыгарга? Кием-салымдагы ертык-тишекне ничек капларга?

Билгеле, хәлебезнең шулай авыр булуын мин олылар кебек аңламый идем әле. Миңа болар нindидер вакытлы бер кыенлык булып кына тоела. Менә нәрсәдер булыр да, без дә, кеше шикелле, итле аш та пешерә башларбыз, яңа бишмәт, яңа күлмәкләр дә алырбыз, җыенга кунаклар да чакырырбыз.

Шулай да мохтаҗлыкта узган бу куанычсыз, күңелсез тормыш торган саен күбрәк борчый, ныграк изә башлады. Күңел канәгать түгел, ул яңа гына канат чыгарган кош баласыдай, өзлексез талпына, нидер эзли, каядыр омтыла иде.

Башта мин иптәшләремә сыенырга, алар кебек көн уздырырга чамалап карадым. Ләкин аларның байтагысы, малайлыкка ялланып, башкорт ягына тегүгә чыгып киткән, калганнары, эштән бушаган арада, титарай[1] тибеп, кичләрен мунчада әкият сөйләп уздыра иде. Күңел боларга гына канәгать була алмады, мин яңадан китапка ташландым.

Нинди генә китаплар укырга туры килмәде! Аңлаганын да укыдым, аңлашылып җитмәгәннәрен дә, дөньявиен да. Тик укырга гына булсын, тик бераз булса да икенче дөньяга гына алып китсен. «Бакырган»ы да калмады, «Кыйссасыл әнбия» да, «Йосыф белән Зөләйха» да, «Науруз бәете» дә.

Кышкы озын кичләрдә китап шүрлегендә актарынудан да мавыктыргычрак, шуннан да рәхәтрәк бүтән берәр шөгыль булдымы икән? Безнең әти, үзе юньләп укый-яза белмәсә дә, яшьрәк чагында китап җыярга һәвәс булган. «Саваплы» китап, изгеләр, могҗизалар турында язылган китап» дип әйтсәләр, очраган бер җирдән алып кайта биргән.

Ул китапларның кайсыларының кәгазе, кышкы күк йөзе төсле, аксыл зәңгәр, кайберләренеке зәгъфран төсенә кергән. Аларның һәммәсеннән дә тузан белән тычкан исе килә, һәммәсенең дә почмаклары бөтәрләнеп беткән. Әмма аларда бик күп укыганда гына ачыла торган нindидер серләр, төрле-төрле искиткеч маҗаралар яшеренгәндер шикелле тоела иде.

Шулар арасында калын сары кәгазьгә кара кара белән, юл башы хәрефләрен кызыл кара белән сырлап-сырлап язган кулъязма китаплар да булгалый иде. Эти өйдә юк чагында, гүя моңарчы берәү дә аяк басмаган серле бүлмәгә керергә җыенгандай, сагаеп, як-ягыңа карангалап, бераз шүрли төшеп шуларны актарасың. Мондый китапны язучы абзый борынгыча озын ак күлмәк белән кыска җиңле казаки кигән түгәрәк сакаллы өлкән кеше булып күз алдына килә иде. Ул абзый нечкә генә каурый каләм белән хәрефләрне, сүзләрне шундый матур итеп тезеп барган, әфәккә нечкә җепләр белән парчалар чиккәнмени! Ник бер генә ялгышы булсын, ник бер генә урыны бозылсын! Бу китапны ул абзый ничә ел язып, моңа күпме күз нуры түкте икән?

Шундый китапны ачкан саен, мин үземне шушы акыллы һәм зирәк абзый каршында сабак тыңлатучы кечкенә шәкерт кебегрәк хис итәм. Кайчандыр, вакытында, белемен дә, күз нурын да аямыйча безгә шундый калын китаплар язып калдырган шул абзый шикелле минем дә яхшы кеше буласым, әллә кемнәргә, әллә нинди яхшылыклар эшлисем килә башлый.

Дөрес, гарәп белән фарсыга минем тешем үтми. Ләкин әлеге абзый, язганнарының мәгънәсе минем ишеләргә дә азмы-күпме ачылсын диптер инде, бит кырыена кыеклатып ярым безнеңчә китапның эчтәлеген дә язып барган. Шуларны кат-кат укый торгач, моңарчы мин белмәгән, юк, мин генә түгел, безнең авылда берәүнең дә башы

[1] Титарай — көз, кыш көннәрендә аяк белән тибеп уйнала торган кечкенә туп уены.

житмәстәй акыллы фикерләр, гыйбрәтле хәлләр аңлашыла башлый. Миңа-мина синең алдында искиткеч серләр ачылып китәр, син әллә ниләр белерсең, мина-мина син хайваннар, кошлар телен аңлый башларсың шикелле тоела. Әмма миңа акка кара белән язылганның һәммәсе дә ап-ачык булып ярылып ятуга караганда, менә шулай бераз серлерәк тә, тирәнрәк тә булып, ачылмыйчарак калуы ошыйрак төшә иде. Әйтик, бик матур төш күрә башлап та күреп бетермичә уянып киткән кебегрәк. Андый китап уйландыра, кызыктыра, нидер вәгъдә иткәндәй өмсендереп тора.

Кечкенәрәк хикәяләрне, бәетләрне кич утырган өйләрдә, малайлар һәм егетләр җыелганда мунчаларда укыштыргалый башладым. Җәйгә чыккач, ат ашатырга барганда икмәк сыныгы белән янәшә куенымда берәр китапчык та була иде.

Әмма иптәш малайлар миңа укырга ирек бирмичә уенга сөйриләр иде. Үзем уйныйм, әмма башымда һаман да китап сүзләре белән төрле кызыклы хәлләр кайнаша. Уйный торгач, үзем дә сизмәстән, төрле ят сүзләр ычкындыргалыйм икән:

— Бәли [1], янсә шимди [2], — дип. Кайчагында берәр малайны тимсах [3], хинзир [4], ганкәбүт [5] дип тиргәп ташлаган чаклар да булгалады.

Андый чакта иптәшләрем күзләрен акайтып аптырап калалар иде.

— Нәстә, нәстә?

Әмма безнең тирә малайлары моны бик тиз аңлатып бирәләр иде.

— Ә, аңа китап җене кагылган, ара-тирә шулай ычкынып киткәли ул.

Малайлар минем шулай кая барсам да үзем белән китап йөртүемә, буш вакытта кулымда һаман китап булуга бик аптырый торганнар иде.

— Нишләп һаман укыйсың да укыйсың син, ә? Беләсең ич, китапны муллалар гына укый. Мулла булу сиңа барыбер тәтеми. Син бит чеп-чи мужик малае.

Мондый вакытта иң каныкканы күрше малае Нимҗан була торган иде. Саргылт кашлы сыек-зәңгәр күзләрен челт-челт йомгалап, сеңгәсен җыя-җыя, Нимҗан:

— Укыгач нишләп мулла итмәсеннәр? — дигән була. — Кем белә, бәлкем әнә аргыяк чиркәвенә пунамар итеп куярлар. Бер кулы белән чаң кагар, икенчесе белән чукыныр.

Малайлар егылышып көләләр. Мин, еларга житешеп, Нимҗанны тукмакларга тотынам. Мин аңа карап китап укуны ташлый алмаячагымны яхшы беләм. Тик моны аңлатырга сүзем житми иде.

— Сез белмисез генә, — дим мин. — Китап уку бик рәхәт тә, күңелле дә ул. Китапка бик гыйбрәтле нәрсәләр язалар, безнең Яңа Салада гомер дә булмый торганнарны. Үзең менә монда утырасың, ә үзең әллә кайларда, диңгез буйларында, әллә нинди чит патшалыкларда йөрисең.

Миннән тик көләләр генә иде.

— Һа, һа! Тапкан кызык! Чынмыни ул? Китапка бит күз буган шикелле алдап кына язалар.

Хәтта минем Хәкимҗан да якламый башлады:

— Күп укысаң, башың түнә башлар әле менә, шул булыр.

Нимҗан тагын эләп алып китте:

— Әнә Казакларның бер егете «мулла булам» ди-ди әллә ничә ел буе көне-төне укыган икән, гүпчи дә акылыннан язган. Өйләндермәкче булып кыз куенына кертсәннәр икән, «кияү булмыйм!» дип кычкыра-кычкыра тәрәзәдән чыгып качкан, ди.

[1] Әйе, шулай. [2] Хәзер. [3] Крокодил. [4] Дуңгыз. [5] Урмәкүч.

## V

Әбугалисина турындагы китап кулга төшкән көн минем өчен бәйрәмгә әверелде. Укый торгач, кич булды, караңгы төште, өйгә ут алдылар. Мин чәй янына да килмичә һаман укыдым. Төн житте, өйдәгеләр йокларга яттылар. Мин һаман китаптан аерыла алмыйм. Әти орышып ташлады. Никадәр китап сүзе тыңларга яратса да, әни дә ачулана башлады:

— Житте сиңа, тилемсә! Башыңа бәрер! — диде.

Мин алай да китапны куя алмадым, ут сүндергәч, ай яктысында укып бетердем.

Бу китап мине шулкадәр хәйран калдырды, мин анда язылган хәлләрне иптәшләрем дә тизрәк белергә тиеш дигән уйга килдем.

Хәкимжан түр якларында чабата ясап утыра иде. Кечкенә яктан аның авыру апасы Мәрьямбикә белән кечкенә сеңелесенең мыдырмыдыр сөйләшкәннәре ишетелде. Мәрьямбикә моннан берәр генә ел элек озынча алсу битле, кая басарын белмичә тыпырдап торган уналты яшәр кыз иде. Аңа үпкә авыруы эләккән дә менә ул байтактан бирле урын хастасы инде. Аңа хәзер карчыклар төсе кергән. Ул көннәр буе ялгыз ята. Минем уемча, бу китап аның да бераз күңелен ачарга тиеш иде.

Хәкимжан миңа укы дип тә, укыма дип тә әйтмәде. Аның гадәте шундый. Менә ишеткәч әле үзе дә шаккатыр. Мин дустыма китапның иң кызык урыннарын гына укып күрсәтергә булдым.

Киттем укып, киттем укып! Күз алдына зиннәтле патша сарайлары, ефәктән дә атластан киенгән вәзирләр, галимнәр, чибәр кызлар, матур бакчалар килеп басты. Шушы сокланып туймастай байлык һәм матурлык эчендә Әбугалисина үзенең искиткеч маҗаралары белән халыкны шаккатыра. Ул бер әфсен уку белән кешене агачка, агачны кешегә әйләндерә, патша сараендагы җилне икенче бер кешенең йортына борып җибәрә. Тагын шундый кырык төрле шаккатарлык маҗара. Шаулатып укып барам. Шундый күңелле! Бөтен шәһәрдәге утны бер карчыкның чалбар төбенә яшерүе турында укыганда, түзә алмыйча хәтта кычкырып көлеп җибәрдем.

Тик шунда Хәкимҗан каты гына итеп минем теземә төртте:

— Фу, бигрәк әллә нинди инде син! Ишетмисеңмени?!.

Күтәрелеп карасам, әллә нишләп киттем. Дәүтәтәй, ике битен каплап, бүлмә кырыенда елап утыра. Хәкимҗанның да күңеле тулган. Тыңлабрак карасам, кечкенә якта Мәрьямбикә, бик тә бетерешкән зәгыйфь тавыш белән, сеңелесенә васыятьләрен әйтә икән.

— ...яме, сеңелем, син минем янымда озаграк утыр, — ди ул. — Әле минем җир астында озак-озак, гомер буена ялгыз ятасым бар. Миңа анда да күңелсез булыр, менә монда да бик күңелсез. Һаман ялгыз да ялгыз. Минем яныма бер кеше дә керми. Миннән куркалар. Ә син курыкма. Мин сиңа менә шушы зәңгәр яулыгымны бирермен. Дәү үскәч, яңа күлмәгемне дә син киярсең, апаем төсе дип.

Тавыш-тын булмагач, Мәрьямбикә, күрәсең, бу якта кеше юк дип уйлагандыр, озак кына йөткергәннән соң бераз гыжылдап яткач, аның хәлсез тавышы яңадан ишетелә башлады:

— Киләсе яз, үләннәр борын төртә башлагач та, сез минем баш очыма нәни генә каен утыртыгыз, яме! Теге яшел толымнарын кызлар шикелле асылындырып утыра торганын. Аңа син җомга саен су сибеп китәрсең. Ә мин күбәләк булып кайтырмын да, шул каенның ботагына утырып, сине карап торырмын. Син килсәң, миңа да рәхәт булып китәр.

Шунда нечкә генә икенче тавыш ишетелде:

— Мин дә сине күрермен_ме соң?

— Юук. Син күбәләкне генә күрерсең. Ә ул минем җаным булыр.

Дәүтәтәй тавышсыз гына һаман яшь түгә, Хәкимҗан ясый торган чабатасына иелеп төшкән дә кайгысын йотып утыра.

Мин, урынсызга кеше рәнҗеткәндәй, нахакка туганымны мыскыл иткәндәй, әчтән янып, кыйналып, ишеккә атладым. Миңа берсе бер күтәрелеп карамады.

Хәкимҗанның «бигрәк әллә нинди син» диюе бик озак онытылмыйча йөрде. Байтакка кадәр китап укый алмадым. Шул китаплар «әллә нинди» итте бит...

## VI

Шулай да Арча базарында китап сатучыны күргәч, аның янына туктамыйча булмады. Шунда гомеремдә беренче тапкыр зур гөнаһ та эшләдем.

Базар һәрвакыттагыча айкала да чайкала, гөрли дә шаулый. Китапчы агай да кечкенә чанасын Бирәзә байларының базар уртасындагы кызыл кирпеч кибете ышыгына туктаткан да кәсеп иткән булып маташа.

Балалар шуа торганнан бик аз гына зуррак җәяүле чана. Чана төбенә капчык җәйгән дә зәңгәр, яшел, кызыл, бишни төсле матур тышлы китапларын шуның өстенә катлы-катлы итеп тезеп салган. Ул китаплардан авылда булмый торган ниндидер затлы ис, кала исе бөркелеп тора, мондагы чүп-чар, пычрак һәм печән калдыклары арасында бу китаплар әйләнә-тирәгә ниндидер пакьлек, затлылык төсе кертәләр. Гәрчә авылча гына киенгән булса да, китаплары янында әлеге агай да бүтәннәрдән аерылып тора, ничектер, килеш-килбәте дә бик әдәпле, үзе дә «гыйлем» кеше булып күренә.

Ниләр генә юк иде бу кечкенә чанада! Төрле исемдәге җыр китаплары дисеңме, Бәдәвам, Ясин, догалыклар, төрле горнәлекләр[1] дисеңме, «Сак-Сок» бәете, «Суга баткан Гайшә» бәете, төрле хикәятләр дисеңме, ни җаның тели! Ә бәяләре ике тиен дә өч тиен.

Абзый яныннан кеше өзелеп тормый. Кайбер кешеләр берьюлы бишәр-унар китап ала, кайберләре, минем кебек, бик озаклап актарынса да, башын кашып, алмыйча гына китеп бара.

Шулай берсен алып, берсен куеп актарына торгач, арадан миңа таныш булмаган «Ана арслан» дип исемләнгән кызыл тышлы бер китап килеп чыкты. Өстән-өстән күз йөгертеп кенә мин аның ни турыда икәнлеген дә шәйләп алдым. Ниндидер балаларны явыз бәндәләр урманга илтеп ташлаганнар. Әмма алар анда үлеп бетмәгәннәр, аларны бер ана арслан үз сөтен имезеп кеше иткән. Менә сиңа мә! Мондый китап безнең авылда бер генә кешедә дә юк. Минем хәтта йөрәгем ешрак тибә башлады. Яңа бит бу, искиткеч бит бу! Үзе бик үк юка да түгел.

Тик шунда ук башыма кайгы төште. Акчам юк бит! Мин инде аласы вак-төякне алган, әти биреп җибәргән тиеннәрне тотып бетергән идем. Китапны бер алам, бер куям. Башка китапларны актарган булып маташканда да тегеннән күземне ала алмыйм. Ул бит бары бер генә! Менә кемдер килер дә биш тиенен биреп алыр да китәр. Миңа гомер буена үкенече генә калыр.

Тора-бара минем бу китапны шулкадәр аласым килә башлады, әйтерсең, ансыз дөньяның яме дә, тәме дә булмаячак, кыскасы, аны укымыйча калу мөмкин дә түгел. Ләкин нишләргә?

Шунда башыма бик шәп уй килде дә авылдашларымны эзләргә тотындым. Әле берсеннән барып үтенәм, әле икенчесеннән.

— Биш кенә тиен биреп торыгызчы, зинһар! Биш кенә тиен!

Ләкин алай да булмады. Кайсының вак акчасы юк икән, кайсы

[1] Горнәлек, горрәлек — календарьны бездә шулай атыйлар иде.

малайсытты, күрәсең, кайсы-берсенең бирәсе килмәде. Китапчы янына буш кул белән әйләнеп кайттым.

Кешеләрнең берсе килә, берсе китә. Ә мин һаман таптанам. Китеп кенә булмый бит! Азаплана торгач, нидер булды. Нилэр кылуымны үзем дә белештермичә сатай-матай килгән арада китапчык куенга килеп керде. Шунда ук бурлат төсле кызаруымны да сиздем.

Минем болай телсез калып китә алмыйча катып торуыма, күрәсең, абзый да игътибар иткәндер.

— Я, улым, кайсын бирим? — диде. — Хикәят китабы кирәкме, әллә җыр китабы аласыңмы? Алып кына җибәр әле иң әгъләсен!

Мин ык-мык иттем. Абзый миңа улым дип дәшә. Ә мин... Шушы әшәкелегемә мең мәртәбә үкенеп, китапны шунда ук кире чыгарып атар хәлгә җиттем. Лэкин, я китапны чыгарып сала алмыйча, я кузгалып китә алмыйча, тагын байтак таптандым.

Арчадан чыгып байтак җир киткәч, затлы ис аңкытып торган шул газиз китабымны кулыма алып һәйбәтләбрәк карыйсым, аның үземдә булуының рәхәтен татыйсым килә башлады. Лэкин китапка кулым тиюгә тагын кире алдым.

Тик гомер буе болай азапланып та булмый бит!

Кайта торгач, үземне аклар өчен төрле сәбәпләр эзләргә керештем.

— «Әй, исең киткән икән! Сәүдәгәр ич ул! Малмыни аңарга биш тиен! Һи! Нәрсә соң ул биш тиен?.. Биш кадак кара ипи, биш стакан икмәк куасы...»

Тик шунда агайның калын олтан салган иске киез итеге, җиң төпләренә кара ямау салынган кызыл бәс тышлы иске туны, кырыйларыннан сары йоннары тырпаеп торган арзанлы мескен бүреге күз алдыма килде. Кем белә? Әллә азрак файда чыга ул өч тиенлек китаплардан, әллә юк. Бәлки менә минем шикелле иске карак малайларны тәүфикъка утыртып булмасмы, халыкның азрак аңын күтәрә алмаммы дип шулай базардан-базарга чана сөйрәп, бер тиенсезгә азапланып йөри торгандыр әле.

Тора-бара бу оятны берәр ничек капламыйча күңел тынычланмаячагын аңладым. Уйлана торгач, киләсе базарга китапның хакын илтеп түләмәкче булдым. Әмма кайта торгач, ул фикерем дә ошамый башлады.

## VII

Карлар эреп, юллар өзелә башлаган вакыт иде, базарга атка атланып кына китәргә туры килде. Юл буе борчылып бардым: «Ай-һай, бу пычракта чана сөйрәп йөрерме икән китапчы абзый?!»

Миңа бераз оят та, шул ук вакытта китапны алып киткәндәгегә караганда, бераз җиңелрәк тә иде. Үз кулым белән илтеп бирәм бит! Бу инде урлау түгел бит! Китапчы абзыйга нилэр әйтәсемне юл буе уйлап бардым.

— Мин синең китабыңны алып торган идем, — диярмен.

Абзый кеше шаккатар.

— Ничек алып тордың? — дияр. — Укып карарга дип алдыңмы? Кызыгыпмы? Мин читкә борылган арадамы?..

Мин инде абзыйның орышуына да, шелтәсенә дә риза идем. Тик рәнҗемәсен, бәхилләсен генә!

— Әйе, әйе, укып чыктым инде мин аны, абзый! — диярмен. — Малайларга да укып күрсәттем. Зерә дә әйбәт китап. Үзе кызык, үзе гыйбрәтле.

Китапчы агай килгән иде, рәхмәт төшкере. Мин аның кызыл бәс тышлы туның, озын гәүдәсен ерактан ук күрдем. Ул бу юлы да базар уртасындагы әлеге кызыл кибет янына туктаган. Тик бүген нигәдер

аның тирәсенә халык күп җыелган булып чыкты. Шуна гаҗәпләнеп мин дә аның тирәсендәге шул зур төркемгә барып кушылдым. Агайларның кайсылары аркаларына капчык, кайберләре берничә кием чабата аскан, култык астына манылган киндер, я берәр төенчек кыстырган. Һәммәсе дә башларын сузып китапчы сөйләгәнне тыңлыйлар.

Хәнәфи абзыйда бүген китап сату кайгысы юк иде шикелле. Аның чырае шул тикле кайгылы, әйтерсең, менә хәзер елап җибәрер шикелле. Ул намазга оегандагы кебек кулларын кушырган, басынкы тавышы ара-тирә калтыранып киткәли.

— Безнең як тумасы[1] иде бит, мәрхүмкәй, үзебезнең як егете. Менә шушы урамнардан ничә узганы бар. Әле Кырлайга кайтып китәр иде, әле Өчилегә. Ничә мәртәбәләр Казанның китап кибетендә очраштык. Күргән саен әйтер иде, мәрхүм: «Ташы мәгърифәтне авылга, Хәнәфи абзый, кашыклап кына булса да ташы. Күп тамчыдан күл булыр»,— дияр иде. Хәзер менә язган китаплары белән баскан эзләре генә калды.

Әле генә килеп кушылган кайбер агайлар, үзара пышылдап, күршеләреннән сорашырга керештеләр:

— Кемне әйтә үзе, кем үлгән?

Хәнәфи абзый тагын төшендереп бирде:

— Габдулла Тукаев вафат, шигырьләр язучы. Кем генә белмәс икән аны? Ул гомер буе безнең өчен янып-көеп яшәде. Безнең ише кагылган-сугылганнар турында өзелеп-өзелеп, күз яшьләре белән язып калдырды.

Көзге төн. Мин йоклый алмыйм. Өй түрендә җил җылый.
Җил җыламый, ач үлемнең куркусыннан ил җылый.

— Аның язганнары халыкның күңеленә сары май булып төште. Изге җан иде ул безнең Габдуллабыз. Әйдәгез, җәмәгать, аның рухына бер дога кылыйк!

Китапчыны төрле яктан әйләндереп алган агайлар, дәррәү тезләнеп, ихлас күңелдән дога кыларга тотындылар. Минем тамак төбен нидер кытыклый башлады, йөрәккә нииндидер җылы дулкыннар коелды. «Сабыйларның догалары кабул була икән» дигәнне күп ишеткәнем бар иде. Минем догам күккә менеп житәчәгенә чын күңелдән ышанып кулларымны күтәрдем. Ләкин никадәр тырышсам да, доганың гарәпчә сүзләрен исемә төшерә алмадым, үзебезчә теләргә керештем:

— Ярабби, Габдулла абыйны көлле газаплардан азат ит. Ярабби, аның һәммәки гөнаһларын ярлыка, үзен мәңге җәннәтле ит. Амин!

Агайлар, ачык кабер яныннан киткәндәй, тирән кайгы баскан хәлдә, башларын иеп китә торалар, алар урынына бүтәннәре килә. Хәнәфи абзый аларга да шул ук хәбәрне әйтеп кайгысын белдерә, ара-тирә чанасыннан китап алып берәр шигырь дә укып күрсәтә иде.

— Йөрәк ялкыннары кабынып дөрли генә башлагач та сүнде китте, бичара. Шундый яшь чагында ук дөнья куяр дип кем генә уйлаган? Әле былтыр гына Хөсәен үлгәч менә нәрсә язган иде бит:

Бармыни бездә гомумән чын кеше кадерен белү?!
Без аны кайдан белик, мескен, үлеп аңлатмагач?

Агайлар чабата башларына карап кайгы йотып торалар. Кайберләренең керфек төпләре юешләнә, кайберсе нәрсәдер уңайсызлагандай, тамак кырып куя. Миңа алар бүгенге базардан җилкәләренә йорт кирәкләре генә түгел, зур кайгы да күтәреп кайталар шикелле тоела.

Шунда күтәрелеп карасам, исем-акылым китә язды. Менә сиңа тамаша! Миннән ерак та түгел, Ямаширмәнең теге зимагуры белән читекче кыз Мәзлүма басып торалар. Исәнләшергә дип кулымны су-

[1] Безнең якта туган дигән.

зарга белмим, исәнләшмәскә белмим. Әмма аларның чырайлары шундый кайгылы иде, мин аларны борчымаска булдым.

Зимагурның өстендә Сафа абый тегеп биргән шевиот бишмәт, башында шул элекке озын бүрек. Аягына күн итек киеп, билен билбау белән буып җибәргәч, ул хәзер авылның ярыйсы гына көн күрүче йортлы-җирле хуҗа кешесенә охшый калган.

Башыма төрле сораулар килә башлады. Ничек була соң әле бу? Читкә китеп югалды дигәннәр иде, ә ул монда йөри. Мазлума нигә аның белән? Әллә югыйсә зимагурга кияүгә чыкканмы? Аннары китапчыда зимагурның нинди йомышы булсын икән? Алай дисәң, зимагурга күзе төшүгә китапчының йөзе, якын кешесен очраткандагы кебек, үзгәреп китте. Хәнәфи абзый: «Менә шулай инде эшләр!» дигәндәй, хәсрәтле күзләрен җиргә текәде.

Шулвакыт кинәт кенә теге безгә имана җыярга килгән, саргылт сакалын нәкъ патшаныкы кебек итеп төзәттергән урәтник килеп чыкты.

— Нәрсә бар монда, ә? Нәрсәгә җыелган бу толпа? — дип кычкырды.

Китапчы агай аны күрүгә, кулларын йөзенә китереп, дога укырга тотынды. Зимагур урәтникнең колагына пышылдап:

— Знаш, ваш благарудий, — диде. — Казан-город татарский святой помирал. Ми наш магометанский бог малитва читайт.

Урәтник ышаныргамы, юкмы дигәндәй бер зимагурга, бер тезләнеп дога кылып торган халыкка карап торды да тагын сорап куйды:

— Святой говоришь? Какой?

— Бальшой, бальшой! — Зимагур шунда ук уч төбен ачып аңа кулы белән язып та күрсәтте. — Книгам писал. Многа, многа.

Миңа ничектер урәтник зимагурның русчаны белә торып шулай бозып әйтүен дә, изге кеше үлде дип күз буяр өчен генә сөйләвен дә яхшы белә, тик нилектәндер белмәмешкә генә салыша кебек тоелды. Ул зимагурга баштанаяк сөзеп карады да кулын селтәп китеп барды:

— А ну, валяй, валяй!..

Мин бу «вәләй»нең нәрсә икәнен аңламасам да, начар сүз булмаска тиешлеген чамаладым.

Мазлума апай Төркстан ягына барырга чыккач, теге убырлы карчык кулыннан ычкынып, качып кайтканнан соң, туган авылында бераз гына торган да, тырыша торгач, Иж-Бубидагы кызлар мәктәбенә укырга кергән. Тик анда ниндидер чуалыш кузгалганнан соң, хәзер анда укучыларның байтагысы «күздән югалып» торырга тиеш икән. Менә тагын бу якларга кайткан. Кулын селтәп, еларга җитешеп сөйли Мазлума.

— Ай, энем, — ди. — Габдулла абый да әнә шул кысынкылыкны күтәрә алмаган, шуңа тыны бетеп, буылып үлгән!.. «Кая барсаң да бер кояш, күбәләктәй газиз җанга көч».

## VIII

Мин юл буе шул авыр кайгыдан арына алмыйча иләс-миләс хәлендә кайттым. Базарчы агайларның, иң газиз кешеләрен күмгәндәге кебек, авыр кайгыга батулары юл буе күз алдымнан китмәде.

Каенсардан узганда да миңа бик моңлы булып, күңелләрне тетрәтеп бөтен мәдрәсә белән көйләнә торган әлеге «Туган тел» шигыре ишетелгән кебек булды.

Тора-бара минем китаплар белән балаларча иксез-чамасыз беркатлы мавыгуым бөтенләе белән Габдулла Тукайга күчте. Әле берәр ай гына элек Әбугалисина белән ничек җенләнгән булсам, хәзер шулай ук алны-ялны белмичә тоташтан Тукай шигырьләрен укый башла-

дым. Аның сүзләре нәкъ кирәк вакытында, күктән иңгән кебек, ничектер үзеннән-үзе көнгә килеп керә башлады. Әллә ничек кенә искә кил дә яраткан җыруың шикелле, үзеннән-үзе көйләнә. Күбәләк янсә карлыгач күзгә чалындымы, аның шигырьләре искә төшә. Берәр агайның сука артыннан икегә бөгелеп атлавын күрдеңме, тагын аның шигырен хәтерлисең. Ул үзенең әлеге «Бетте көч, сынды кылыч. Шул булды эш»... дигән шигырен язганда да, мөгаен, безнең эти кебекләр булып та уйлагандыр. Әнә эти дә шулай, тыны бетеп сәкегә ауганда, үзәкләрне өзәрлек итеп:

— Булмады инде, юк инде, юк,— дип ыңгыраша бит.

Тик минем бер нәрсәгә башым җитми иде. Габдулла Тукай шул япь-яшь башы белән нинди вакытта, нәрсә әйтәсен каян белә алган? Ничек шулай йөрәкнең түренә үк кереп утыра торган итеп, тирән мәгънәле дә, килешле дә итеп яза алган? Бөтен халыкны авызына каратырлык иң кадерле, иң үтемле сүзләрне каян табып бетергән?

Зәбихулла абыйдан сорарга кыймадым. Ул әллә әйтә, әллә юк. Мин бу турыда үземнең өлкән туганым Вәли абыйдан сорап карадым. Ул да китаплар укыштыргалый иде. «Вәли бик килештереп, бик ягымлы итеп яза» дип, күрше-күлән аңа солдат улларына, я читтәге туганнарына хат яздыра торган иде.

Вәли абый мин сораганга бик ансат җавап тапты:

— Китап язучы кешеләр, халыкның нәрсә сөйләшүен, нәрсә уйлашуын, үзләренә сиздермичә генә, читтән-чоттан гына тыңлап йөриләр. Шуны мыегына чорнап йөри-йөри дә, «чап» иттереп ябыштыра куя кирәк чагында! Дисвительнидә минем бәетләр, мөнаҗәтләр чыгара торган бер иптәшем шундый ишеткән-белгәннәрен җиде төн уртасында торып яза торган иде.

## IX

Шул яшьләрдә күңел дөньясында элек ул кадәр үк сизелмәгән сәер тойгылар уяна башлады. Берәр юньлерәк китап укырга тотындыңмы, ул элек иста-оста да булмаган яңа тойгылар уята. Күңел нидер эзләнә, нидер җитмәгән дә кебек, нидер күңелдәгечә үк түгел, нәрсәдер көтәсең, каядыр омтыласың. Үзең тырма тырмалыйсың, сабан артыннан йөрисең, ә күңелең әллә кайларда.

Киек казлар белән торналар җылы яклардан кайтканда, синең дә алар янына күтәреләсең, «кыйгак-кыйгак!» дигән шул моңсу авазларны тыңлый-тыңлый, алар белән бергә зәңгәр күктән әллә кайларга очасың килә.

Кич-иртә кошлар сайравы да дулкынландыра, таң беленгәндә кырлар-болыннар өстенә иңгән тирән, моңсу тынлык та, күк читендә төрле төстәге нурлар уйнавы да. Шуларның һәммәсен күзең күреп, күңелең сизгәнчә, бөтен яме, тетрәнүләре, җанлы күркәмлеге белән, бер генә бизәген дә әрәм итмичә, кәгазьгә төшереп аласы килә башлый. Ләкин ничек итеп?... Басуларга, болыннарга чыкканда күңелең сизеп тә теләң белән әйтеп бирә алмаган әнә шул ярсу тойгылар дәртле җыр булып җырланмадымы икән?

Шулай укый, хыяллана һәм нәрсәдер көтеп, нәрсәдер эзләнә торгач, бервакыт өзелеп-өзелеп гармунда уйныйсым килә башлады. Ләкин гармун алырга акча юк. Хәер, ала калсаң да, эти аны йортка якын да китермәс иде. Нишләргә икән? дип кырык төрле планнар кора, эзләнә торгач, җае табылды. Минзайның әлеге келтер-келтер он тартып торган кечкенә җил тегермененә тәрәзәләр ясап бирдем. Шуның өчен Минзай миңа кичләрен эштән бушаганда гармун уйнарга рөхсәт бирде. Тик Минзай кулында сандугач булып сайраучы бу көйле тартма миндә гомер буе ач торган кәҗә бәтие шикелле колакны рәнҗетердәй шыксыз тавышлар чыгара иде. Минзай бу хәлгә түзәргә киңәш бирде,

— Башта гел шулай була ул. Син караңгыда гел үзең генә кара мунчага кереп уйна, көйне бармакларың үзләре капшанып тапсын,— диде.

Анысын да эшләдем. Азапләнә торгач, ниндидер ярым-йорты көй сымак нәрсә дә чыга башлады.

Әмма беркөнне басу ягыннан җырлаган тавыш ишетелде. Агачтан самокат ясап маташкан келәтеннән Минзай да йөгереп чыкты.

— Әхмәт китә бит! — диде.

Әхмәт узган елдан бирле Судебный дип йөртелә торган күрше алпавытта тамак ялына диярлек хезмәтче булып эшли иде. Ул бер генә кичкә кайткан да менә хәзер китеп бара икән. Без аны озата чыктык.

Әхмәтнең өстендә киндер күлмәк, аягында алпавытның бүтән хезмәтчеләренеке төсле үк ыштыр белән чабата, әмма башында укучы бай малайлары гына кия торган зәңгәр читле шәп картуз иде, тик аның маңгай өстенә салынып торган ялтыравыклы «кәрнизе» генә урталай сынып эшне бозган. Әхмәт аны нәни генә кырынрак салган. Шунда Әхмәтнең ике ирен кырыена кыюсыз гына булып төртеп чыккан кара төкләргә күз төште. Аны күргәч, нишләптер, Минзай да үз борын астына бармагын тидереп алды.

Әхмәт кечкенә генә төенчеген таяк башына элеп иңенә салган килеш тын гына барды-барды да:

— Өченче көн безнең бай Әхмәтша абзыйны уңлы-суллы яңакла-ды, — дип әйтеп куйды.

— Кит аннан? Ни өчен?

— Бер аты икенче атының улагына тыгылган өчен.

— Булыр инде!

— Валлаһи менә!

— Әхмәтша абзый нишләде соң?

— Нишләсен? Берни эшләмәде. Кая барсын? Җире юк, йорты юк. Соңыннан бай бер чокыр аракы эчертеп чыгарган иде, «Идрит-виртит бөтен дөньясын! Безгә шулай язгандыр инде...» дип кенә әйтте.

Әхмәт борынын тартып куйды. Минзай кулындагы чыбыгы белән җенләнеп, зәһәрләнеп чаж да чож юл буендагы әремнәрне кыйнарга кереште.

Тагын бераз шулай сөйләшмичә генә бардык. Иске зират турысыннан узгач, Әхмәт:

— Кичә безгә, алпавыт хатынының туган көне итеп, өч тиен акча бирделәр, — диде. Минзай нигәдер көлеп җибәрде дә чыбыгын атып бәрде.

Алпавыт йорты ягыннан бурзайлар өргәне ишетелгәч, Әхмәт туктады. Әмма аның да, безнең дә аерыласы килми иде. Әхмәт, түбән карап, чабата башы белән юлдагы кантарларга типкәләргә тотынды.

— Җыенга туп-туры безгә кайт! — диде Минзай.

— Безгә дә килмичә калма!

— Ычкынып булса...

Кире борылып бераз гына кайткан идек, Әхмәт җырлый башлауга туктап калдык. Ул безнең баш очыннан авыл өстенә карап җырлый иде. Хәер, бәлки ул безне бөтенләй күрмәгәндер дә. Бәлки ул якты тәрәзәләренең сөйкемле карашы белән иркәләп аны үз улы итеп озатып калучы Яңа Саланы, үз очының яшел урамнарын, шул урамга аны ике яктан ике кулына ябышып тыкрык башына кадәр озата чыккан ап-ак чырайлы, дәү башлы, дәү корсаклы яланаяк энесе белән, чәче тузгыган, аяклары чебиләгән кечкенә сеңелесен генә күргәндер, бәлки шулар өчен генә җырлагандыр. Җирдә Әхмәт җырлый, күктә бөтерелә-бөтерелә тургайлар сайрый. Әмма Әхмәт җырының уртасында моңы-сагышы ташып торган көчле яшь тавышы белән күкләргә-җирләргә инәлү авазы салгандай:

— Һа-а-а-й-й-й!.. — дип сузганда, бөтен дөнья тынсыз-өнсез калды. Йөрәк-бәгырьләрне авырттырып кысып китергән бу татлы моң күпереп үсеп яткан яшел игеннәр өстенә, ягымлы җылы бөркегән зәңгәрсу күк йөзенә күз яшедәй мөлдерәп торган авыр сагыш булып җәелде. Күзләргә яшь тулды. Буыннары да ныгып җитмәгән килеш Әхмәтне туган авылын ташлап китәргә, көн-төн алпавытка бил бөгәргә мәҗбүр итүче ниндидер явыз көчләргә күңелләрдә каргыш уянды.

Җырның татлы газабыннан арына алмыйча, авылга кадәр бер сүз дә сөйләшми кайттык. Минзай ачынып янтавына сукты:

— Их, малай! — диде. Кулын селтәп өенә кереп китте.

Шуннан соң мин гармунны кулга алып көй эзли башлауга, күңел түреннән Әхмәтнең соңгы җыры ишетелә дә кемнедер рәнҗеткән, ниндидер тупаслык эшләгән кебек, кыенсынып гармунны кире куя торган булдым.

Шулай нәрсәдер эзләнеп, тынгысыз җанга азык таба алмыйча иләс-миләсрәк йөргән көннәрдә Арча юлындагы чардуган яныннан узарга туры килде. Каенсарның бер агае кышкы буранда адашкан да үзләренең зиратларына кайтып җитәр-җитмәс кенә кырда өшеп үлгән. Аны шул үлгән урынында күмгәннәр дә кабер өстенә чардуган корганнар.

Бу хәлне мин элек үк ишеткән идем. Әмма бу фаҗига мине нигәдер менә хәзер дулкынландыра башлады. Мин берничә көн шул турыда гына уйланып йөрдем. Ниһаять, бер көнне шушы хакта хикәя сымак бер нәрсә яздым. Бәлки аның «атасы-анасы да», хикәя дип атарлыгы да булмагандыр. Шулай да ул язмада әлеге агайның Арча базарыннан кайтканда адашуы, кычкыра-кычкыра, бата-чума юл эзләве, ахыр чиктә, арып-талып чанасына килеп утыргач, тәнендә рәхәт бер җылы сизә башлавы, бу вакытта авыл кешеләренең манара тәрәзәсеннән фонарь белән яктыртулары, балалары белән хатынының әтиләрен җылый-җылый көтүләре шактый ук тәфсыйллап, булдыра алган кадәр кызганычрак итеп язылган иде.

Мин аны, әти юк вакытны сагалап торып, башта әнигә укып күрсәттем. Ул борынын тарткалап елап алды.

— И бичаракай, үзе дә бик кызганыч, хатыны белән балалары да, — диде.

Баштарак берникадәр тынычлангандай булсам да, соңыннан хикәя миңа ошамый башлады. Мин укый торган китапларның күбесендә ямь-яшел гөлбакчалар, зифа буйлы матур кызлар, чәчәкләр, төрле-төрле җимешләр, киң дәрьялар турында язылган була иде. Андый китапны укыганда, син үзеңне дә шундый кайгы-хәсрәтсез ямьле якларда йөргән кебек, дөньясында бер генә борчуың да юк кебек хис итә башлыйсың. Мин язган нәрсәдә исә шыксыз буран уйнап торган куркыныч караңгы басу, ярлы кешенең кечкенә генә караңгы өе, анда тараканнар мыжлый, кешеләрнең ачы күз яше мөлдерәп тора.

Бер-ике көн үткәч, эштән кайтуга атны капкадан гына кертеп җибәрдем дә инеш буена, Вәли абыйларга төшеп киттем. Әлеге нәрсәне, әгәр кыюлыгым җитсә, аңа да укытасым килә иде. Каян беләсең? Бәлки ул өметле сүз әйтер!

Әмма Дәү абый барып керүгә мине орышып чыгарды.

— Нинди малай син, әй! Шундый чакта ниндидер әкият күтәреп килгән. Пөгер хәзер үк өегезгә!

Мин кайтып җиткәндә, лапаста тау кадәр күпереп безнең бердәнбер сыерыбыз үлеп ята, аның янында әни елап тора, әти битен каплап җиргә чүгәләгән иде.

*(Дәвамы унберенче санда)*

## *Сажидә Сөләйманова*

●

Балкыды да сүнде —
яшенме бу,
Күкрәүләре һаман яңгырый.
Күкрәгемә тамды —
яшемме бу,
Әллә ява ләйсән яңгыры?

Су ерып яз килә яланаяк,
Парча-парча яшел күлмәге.
Тамчы алка — минем сөйгәнемнең
Яз кызына яшерен бүләге.

●

Бу диңгезгә төшеп югалмыйсың,
Көймәчеләр суда күзәтә.
Кызыл буйны узу тыелганын
Яр буенда диктор кисәтә.

Буйлар, чикләр —
шикләнгәннәр өчен.
Зәңгәр дөнья ята арырак.
Кисәтүсез, күзәтүсез киңлек,
Таулар гына үрелеп карыйлар.

Иңсез, буйсыз,
тыелгысыз диңгез,
Куеныңа дулкын сарыла...
Кеше, куркып чиксез иркенлектән,
Кире кайта шаулы ярына.

●

Таулар кичтем, диңгезләргә төштем,
Басылмасмы йөрәк януы.
Диңгез суы парга әйләнде дә
Ак болытлар булып агылды.

Сулышларым,
болытларны куып,
Кайнар җилләр булып истеләр.
Кайтсам,
күктә йөзә шул болытлар
Явар өчен минем өстемә.

# Мәхәббәт фонтаны

*Фонтан любви, фонтан живой,*
*Принес я в дар тебе две розы.*
*А. Пушкин.*


Бакчасарай. Шигъри томан аша
Барыр юллар таулы, бормалы.
Борылмалы тау сукмагы түгел,
Алып килде шагыйрь юллары.

Фонтан. Күккә ургылмыйлар сулар,
Көмеш тамчы саран тамчылый.
Яңа тапкан мәхәббәтен җуйган
Ир йөрәге булып таш елый.

Хан йөрәген әсир иткән сылу
Томкынлыкта үлгән сагыштан.
Фонтан. Яшь эчендә ике роза,
Берсен-берсе каян табышкан?

Шагыйрь салган ал һәм кызыл роза —
Мәхәббәткә һәйкәл, иреккә.
Тәнне алып була,
җанны булмый,
Хан йөрәген хәтта биреп тә.

Сабагыннан сынган гөлләр сыман
Җарияләр сулган сагыштан...
Яшь эчендә ике тере роза,
Гүя ике йөрәк кавышкан.



# Яшьләр иҗаты

*Бөек ватаныбызның илле еллыгы алдыннан республикабызның башкаласы Казанда шушы елның май аенда үткәрелгән Идел буе яшь язучылары семинары — игътибарга лаек вакыйгаларның берсе. Аны РСФСР Язучылары союзы һәм ВЛКСМ Үзәк Комитеты үткәрде. Семинарда Татарстаннан да күп кенә яшь язучылар катнашты. Без журналыбызда аларның әсәрләре белән укучыларыбызны таныштырып барырга булдык. Бу санда сүз шул семинарда үзенең әсәрләре белән катнашкан яшь язучы Фаил Шәфигуллинга бирелә.*

*Фаил Шәфигуллин*

## Эшче горурлыгы

Мин заводтан китәрмен, дип,
Үйлап куйган идем.
Цехка килеп бер көн: Сау бул,
Станогым, — дидем.
Борылдым...
Тик китәлмадым. —
Кемдер тотты мине.
— Цехташларга, дус-ишләргә,
Мәхәббәтем, синме?
— Түгел, — диде тавыш.
Ә мин:
— Синме, намус? — дидем.
— Туган көннән алып һәрчак
Син намуслы идең.
— Кем соң, кем соң алай булгач,
Шундый каты куллы?
— Танымыйсың?!
Мин — горурлык,
Эшче горурлыгы.

## Унҗидедә

Куркам, дисең, синең сүзләрдән,
Үзгәргән син, дисең, үзгәргән;
Күңелләрең мине ник сөйде,
Миңа, дисең, фәкать унҗиде.
Урау юллар, еллар үтсәм дә,
Сине эзләп зарыгып бетсәм дә,
Хисләремнең иң-иң сафларын
Унҗидедә килеш сакладым.

## Туып – үскән нигез ташларына

Баһадирдай ташлар тып-тын ята,
Кычытканнар шашып чәчәк ата,
Ят бакчачы бага бакчаны.
Бар тирә-як чумган тирән моңга,
Ни өчендер тормыш сүнгән монда,
Кычытканнар җиңгән ташларны.
«Ничә еллар сезне иңебездә
Тотсак та, юк рәхмәт сүзе безгә,
Апа, абый, сеңел, туташлар,
Калдырдыгыз ласа безне ятим,
Кычытканнар хәзер безгә хаким», —
Диярләрдер сыман бу ташлар.
Авыру аккошлар күк боек ташлар,
Кем ул анә (күзләрендә яшь бар),
Сезгә башын салып ник елый?
Йөрәгендә лә сез кемнәрнеңдер,
Кемдер күрә сезне төшендә гел:
Туып-үскән нигез онытылмый.

## Сиксән яшьлек Тукай

Бертуктамый сайрый,
И сайрый ла,
Һаман сайрый тургай.
Сау, таза карт икән Толстойдай
Сиксән яшьлек Тукай.
Чәчләр генә азрак көмешләнгән,
Күзләр шул ук аның.
Бер атлый да туктап тыңлап тора
Тургай тавышларын.
«Нинди аяз, нинди зәңгәр күгең,
Нинди якты иртәң,
И туган җир, синме соң бу?» — диеп
Гаҗәпләнә микән?
Сөенә микән күреп һәр тарафта
Муллык ташыганын?
Танымый да микән әллә инде

Туган Кырлай ягын?
Узып барган бер малайга әнә
«Балакаем, — ди ул, —
Кем җырлары анда ишетелә,
Әйтче, нинди көй ул?»
«Кайсы яктан соң син үзең, бабай?
Ай-һай, кара, кара...
Соң Тукайны юкмы ишеткәнең?» —
Дип елмая бала.
Әллә елый шул мәл, әллә көлә
Сиксән яшьлек Тукай.
Һаман коела җиргә гүзәл моңнар,
Һаман сайрый тургай.

## Алтын эзләүчеләр

Яшьлектерме, белмим, ашкындырды,
Романтика микән?
Без иптәшем белән кара төндә
Чыгып киттек өйдән.
Ару-талу һич белмәдек. Кичтек
Я чүл, я саз, я су
Алтын табу иде безнең хыял,
Фәкать алтын табу.
Көне-төне эзләдек без аны
Ташлар, таулар айкап.
Җир куеныннан асыл метал безгә
Күзен кысты кайчак.
И сөендек шул чакларда, башлар
Тәмам күккә тиде:
Яшерсә дә йөзен әрсез комга,
Ул бит алтын иде...
Ә беркөнне иптәшемнең бәхете
Кинәт тулып ташты:
(Йодрык чаклы булыр) бер шурфтан
Ул саф алтын тапты.
Алтын тапты... Әмма шул ук көнне
Ул югалтты үзен:
Китеп барды ашыгып минем яннан:
«Юк, — дип — уртак безнең».
...Көннәр үткәч кайтты... юк инде тик
Электәге ялкын.
Күз дә салмый ташлар, рудаларга, —
Эзли гел саф алтын.
Ә саф алтын аңа (ни үкенеч)
Очрамады бүтән...
Ул үзе дә табылдыгы белән
Онытылды күптән.
Мин алтынны һаман эзләп-эзләп
Юып алам комнан;
Минем алтын инде күп мәртәбә
Артык аныкыннан.

— — □ — —

## ДЕЛЕГАТЛАР СӨЙЛИ

*Майның 22 сеннән 27 сенә кадәр Кремльнең Зур сараенда СССР язучыларының IV съезды эшләде. Съездда күп милләтле совет әдәбиятының илле ел эчендә ирешкән уңышларына, бүгенге торышына, әдәбияттагы аерым жанр һәм тармакларның үсешенә төпле бәя бирелде, язучылар алдында торган актуаль мәсьәләләр, мөһим бурычлар турында җитди һәм эшлекле сөйләшү барды.*

*СССР язучыларының IV съездында Татарстан язучыларыннан М. Әмир, Х. Туфан, Г. Бәширов, С. Хәким, Х. Госман, Х. Вахит, Л. Ихсанова, З. Нури һәм А. Булгаков иптәшләр катнашты.*

*Журналыбызның бу санында сүз делегатларга бирелә. Алар бу зур вакыйга турындагы фикерләре, съездан алган тәэсирләре белән уртаклашалар.*

### *Гомәр Бәширов*

Язучыларның дүртенче съезды бик әһәмиятле зур вакыйга булды. Ул турыда бик озын да, озак та сөйләргә мөмкин булыр иде. Мәгълүм ки, бу съезд Бөек Октябрьның 50 еллыгына әзерләнү вакытына туры килде. Билгеле, бу бөек тарихи дата съездның бөтен эшчәнлегенә юнәлеш бирмичә, анда сөйләнгән докладларга да, шулай ук чыгышларга да тәэсир итмичә кала алмады. Шундый шартларда, табигый, һәркемнең — докладчыларның да, сөйләүчеләрнең дә шушы илле ел эчендә узган тарихи юлга Кремль сарае биеклегеннән торып бер әйләнеп карыйсы, әдәбиятның үткән чорына азмы-күпме йомгак ясыйсы, киләчәккә таба барасы юлны ачыграк итеп күз алдына китерәсе килде.

Шуның өстенә, съезд эшенә бөтен дөнья күләмендә танылган чит ил язучыларының катнашуы да билгеле бер дәрәҗәдә йогынты ясады. Съезд күп милләтле совет әдәбияты алдында торган проблемаларны, чит илләрдәге прогрессив әдәбият агымын да күз алдында тотып, киңрәк күләмдә алып тикшерергә тырышты.

Съезд әдәбиятның төп мәсьәләләре белән шөгыльләнде һәм бер үк вакытта, бөтен кешелек җәмгыятен борчып, дулкынландырып торган җитди халыкара мәсьәләләр турында да үз фикерен әйтте. Вьетнамдагы канлы сугыш, Греция һәм Кытайдагы вакыйгалар һәрвакыт съездның игътибар үзәгендә булдылар. Бу мәсьәләләр турында аерым мөрәҗәгать кабул ителде.

Инде съездагы чыгышларга килгәндә, минем үземдә Украина язучысы О. Гончар, А. Чаковский, К. Симонов һәм В. Кетлинская чыгышлары аеруча яхшы тәэсир калдырды. Бу иптәшләр әдәбиятның бик җитди проблемаларын күтәрделәр һәм уйланырга, эзләнергә мәҗбүр итәрдәй тирән фикерләр әйттеләр.

Чит ил кунакларының тәбрик сүзләрен без аеруча игътибар белән тыңладык. Бөтен дөньяга танылган Чили шагыйре Пабло Неруданың чыгышы Кремль сараенда да, нәкъ шигырьләре кебек үк, тирән аһәң белән, ифрат шигъри яңгырады. Совет әдәбиятының күптәнге дусты — немец язучысы Анна Зегерс һәрвакыттагыча үзенең йомшак, җылы тавышы, дустанә әйтелгән ягымлы тәбрик сүзләре белән бөтен съездның игътибарын җәлеп итте. Минем үземдә Вьетнам язучысы Нгуен Динь Тхи белән икенче мәртәбә очрашу күңелле бер истәлек булып калды. Без аның белән узган елның сентябрь аенда Бакуда булып узган Азия — Африка язучыларының киңәйтелгән киңәшмәсендә очрашкан идек. Шул вакыт мин аңа Тукайның 80 еллыгына чыгарылган значогын бүләк итеп, аның Көнчыгыш халыкларының азатлыгы турында,



М. Әмир каләмдәш дуслары белән.

гомумән хөррият хакында нинди ялкынлы шигырьләре булуы, ул шигырьләрнең бүгенге көндә дә көрәшкә өндәве, шулай ук Татарстан халкының Вьетнамга чын күңелдән туганнарча ярдәм итүе, аның Америка сугыш чукмарларына каршы бу авыр көрәштә җиңеп чыгуын теләве турында сөйләгән идем. Алты айдан соң бу иптәш белән яңадан очраштык, яңадан кул кысышып, бер-беребезне тәбрик иттек. Кечерәк кенә гәүдәле, көләч йөзле бу кеше, ялкынланып һәм шул ук вакытта борчылып, Вьетнам халкының сокландыргыч батырлыгы турында сөйләде.

## *Хәй Вахит*

Мин язучыларның Бөтенсоюз съездында беренче тапкыр катнаштым. Миңа бары да яңа, бары да әһәмиятле, бары да зур мәгънәле булып тоелды. Исемнәре бөтен дөньяга таралган мәшһүр әдипләр белән очрашу, аларның чыгышларын, әдәбиятыбызның бүгенге хәле турындагы фикерләрен ишетү, чит илләрдән килгән кунакларның сәламнәрен тыңлау, әлбәттә, көчле тәэсир итте.

Съездның өченче көне аеруча истәлекле булды. Бу көнне СССР Верховный Советы Президиумы председателе Н. Подгорный Язучылар союзына Ленин ордены тапшырды. Партиябез һәм хөкүмәтебезнең язучылар хезмәтенә шундый зур бәя бирүләре һәркемдә тирән рәхмәт хисләре уятты. Бу бүләкне без коммунизм төзелешенә совет әдәбияты керткән өлешне билгеләп үтү һәм язучыларга тагын да зур җаваплылык өстәү, ышаныч белдерү дип кабул иттек.

Съездда әдәбиятның һәр жанры буенча эшлекле, җитди сөйләшү барды. Миңа, драматург кешегә, бигрәк тә драматургия турындагы сөйләшү әһәмиятле иде. Докладчы Л. Салынский да, чыгыш ясаучылар да драматургия өлкәсендә ирешелгән уңышларга, хәл ителәсе мәсьәләләргә киң һәм тулы тукталдылар. Революциябезнең 50 еллык юбилее якынлашып килгән көннәрдә тартынмыйча әйтә алабыз: безнең театр

сәнгате, драматургиябез күзгә күренерлек уңышларга иреште. Н. Погодинның «Мылтыклы кеше», «Кремль курантлары», «Өченче патетик» әсәрләре әдәбиятыбызның алтын фондына керде. Соңгы елларда тудырылган әсәрләрдән Шатровның «Алтынчы июль», Штейнның «Давыллар эчендә» исемле пьесалары да уңышлылар рәтеннән телгә алынды. Ленин образын тудыру өлкәсендә милли әдәбиятларда да телгә алырлык уңышлар бар. Шуның белән бергә, чыгыш ясаучылар Ленин образын тудырудагы җаваплылык турында да әйтеп үттеләр.

Үзебезнең драматургиянең үткәне, бүгенге хәле турында фикер йөрткәндә, барыбызны да күптәннән борчып килгән кайбер мәсьәләләр хакында берничә сүз әйтәсе килә. Минем уемча, безнең драматургиядә әле һаман да тема тарлыгы, мәхәббәт иллюзияләре белән артыграк мавыгу үзен нык сиздерә. Инде олырак проблемалар күтәрә, зуррак темаларга алына башласак, безнең әсәрләрдә иллюстрациячелек, схематизм кечәя. Димәк, безнең драматургларга бу турыда да җитдирәк уйланырга кирәк икән.

## *Ләбибә Ихсанова*

Съезддан алган тәэсирләр зур, әлбәттә. Шулардан мине иң нык дулкынландырганы кешелек язмышы, дөньяның иминлеге турында кайгыртып сөйләнгән сүзләр булды. Язучыларның сугыш елларында иҗат иткән әсәрләре турында әйтелгән җылы сүзләр дә, Вьетнам, грек язучыларының чыгышларын аяк үрә басып, озак алкышлар белән каршылаган вакытта туган хисләр дә күңелдән тиз генә китмәс, мөгаен. Грек шагыйре Костас Кодзияс үз илләрендәге вакыйгалар турында әрнеп сөйләде. Грек фашистларының ул илдә тудырган вәхшәтләрен тыныч күңел белән тыңлап утырырга мөмкин түгел иде.

— Бөтен ил концлагерьлар белән тулды. Юра утравы тоташ концлагерьга әйләнде. Фашистлар беркемне дә — яшьләрне дә, картларны да, бала-чагаларны да — кызганып тормыйлар. Төрмәләргә, концлагерьларга ябылган ул кешеләрнең язмышы беркемгә дә билгеле түгел. Фашист радиолары: илдә 3000 кеше кулга алынган иде, аларның да яртысы иреккә чыгарылды, дип хәбәр тараттылар. Ышанмагыз! Кулга алынган 7000 нән артык кешенең язмышы билгесез, — дип сөйләде ул.



Татар, башкорт делегатлары тәнәфес вакытында. Сулдан: Сәйфи Кудаш, Ләбибә Ихсанова, Зәйнәп Биишева, Хәй Вахит, Назар Нәҗми.



Делегатлар Кызыл Мәйданда.

Моннан нәкъ егерме алты ел элек Акрополь өстеннән фашист флагын алып аткан грек патриоты Манолис Глезос та кулга алынган. Аның һәм аның кебек бик күп прогрессив кешеләрнең — язучыларның, артистларның, галимнәрнең язмышы, ничек яшәүләре турында без бернәрсә дә белмибез, диде ул.

Вьетнам язучылары белән мин Мәскәүгә килгән көнне очраштым. Әле съезд башланмаган, делегатларның җыелып кына килгән чагы. Күрешүләр, сөйләшүләр, хәл белешүләр... Шул вакыт мине башкорт язучылары чакырып алды. Алар, Вьетнам язучылары белән бергәләп, Ленин мавзолеена барырга җыеналар икән. Кремль янындагы бакча буйлап сузылган озын чиратка килеп бастык. Акрын гына алга атлыйбыз. Менә билгесез солдат истәлегенә салынган һәйкәлгә якынлаштык. Аны чәчәкләр белән күмгәннәр. Пионерлар китергән кочак-кочак розалар да, солдатлар куеп киткән зурзур веноклар да, кемнәрдер калдырган ландыш бәйләмнәре дә бар анда...

Аннары без Ленин янында булдык. Тәэсирләр зур, тирән. Аларны күңелдә генә калдырырлык түгел. Мин янәшәмдә килгән Вьетнам язучысы Фан-Тыдан: «Сез Ленинны беренче тапкыр күрәсезме?» — дип сорарга телим. Әмма тәрҗемәче арттарак калган. Шул вакыт, әйтерсең минем уйларымны сизеп барган, Фан-Ты русчалатып: «Мин Ленинны өченче тапкыр күрәм», — диде. Аның Советлар Союзында өченче мәртәбә булуы икән. Ул Африка — Азия илләре язучыларының Ташкентта һәм Бакуда үткәрелгән конференцияләрендә катнашкан. Ә менә хәзер язучыларның Бөтенсоюз съездына да килгән.

— Бу съездда катнашу өчен, — ди ул, — мин, җәяүләп, өч ай буе таулар аша Ханойга килдем. Хикәяләр язам, ләкин вакыт юк, сугышырга кирәк.

Мин аның рус телен ярыйсы ук яхшы белүенә гаҗәпләндем. Сез рус телен ничек өйрәндегез, дип сорадым. Үзлегемнән, сүзлекләр ярдәмендә өйрәндем, ди юлдашым.

Чит ил кунакларының күбесе совет әдәбиятының бөтен дөньяга киң танылган олы әдәбият, гуманистик әдәбият икәнен басым ясап әйттеләр. Әдәбиятыбызның илле ел эчендә ирешкән уңышларына дусларыбызның шулай шатлануын күрү бик куанычлы хәл булды.

Совет властенең 50еллыгына

# ТАТАР МӘДӘНИЯТЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ДӘФТӘРЕННӘН

## 1919 ел

**1 январь.** «Эш» газетасында Вәли Шәфигуллинның «Советлар Россиясендә татар матбугаты вә әдәбияты» дигән мәкаләсе басылды.

**15 январь.** Астрахань татар театры Гогольнең «Өйләнү» пьесасын сәхнәгә куйды. Спектакльнең режиссеры Зәйни Солтанов.

**7 февраль.** Татар драма артистлары труппасы Гафур Коләхметовның «Кара һәм кызыл» драмасын сәхнәгә куйды.

**9 февраль.** Казан Журналистлар союзы «Красные зори» исемле әдәби һәм сәяси журнал чыгара башлады.

**21 февраль.** Казанда Мөселман матбугат комиссиясе төзелде. Председателе Рәүф Алмаев.

**21 февраль.** Ф. Бурнашның «Яшь йөрәкләр» пьесасы буенча эшләнгән спектакльнең премьерасы булды. Режиссеры К. Тинчурин.

**28 февраль.** Шамил Усманов Үзәк мөселман хәрби коллегиясендә эшли башлады.

**10, 11 һәм 12 март.** «Эш» газетасында Г. Ибраһимовның «Иҗтимагый революция һәм татар зыялылары» исемле зур мәкаләсе басылды.

**10 март.** Сәнгать хезмәткәрләрен оештыру максаты белән, Казанда артистларның, музыкантларның һәм һәвәскәрләрнең гомуми җыелышы уздырылды. Җыелышта, шәһәрдәге сәнгать эшчеләрен барлау һәм киләчәккә бурычлар билгеләү өчен, вакытлы комиссия төзелде.

**18 март.** Журналистлар союзы янында мөселман секциясе төзү максаты белән, «Эш» газетасы редакциясендә татар язучылары, шагыйрьләре, тәрҗемәчеләре һәм журналистларының гомуми җыелышы булды.

**24 март.** Беренче Идел буе татар укчылары бригадасы төзелә башлады. Бригаданың комиссары Шамил Усманов.

**4 апрель.** Танылган трагик Мөхтәр Мутин бенефисына Нариман Наримановның «Надир шаһ» трагедиясе куелды.

**16 апрель.** Укучы яшьләрнең «Берек» оешмасы Габдулла Тукайны искә алу кичәсе оештырды.

*«Эш» газетасы, 13 апрель*

**18 апрель.** Драматург һәм шагыйрь, большевистик «Көн» газетасының (Сембер) редакторы Фәтхи Бурнаш Коммунистлар партиясе сафына керде.

**24 апрель.** Коммунистлар партиясе мөселман секцияләренең Казан өлкә бюросы «Интернационал»ның иң яхшы тәрҗемәсенә конкурс игълан итте. Конкурста беренче урынны С. Сүнчәләй алды.

**23 май.** Зур театрда «Галиябану» драмасының премьерасы булды. Халил ролендә С. Айдаров, Галиябану булып Г. Болгарская уйнады.

**30 майга кадәр.** «Мәгариф» һәм «Бертуган Кәримовлар» исемле шәхси типографияләр конфискацияләнде.

**10 июнь.** «Эш» газетасында М. Максудиның «Изге көрәшкә» дигән нәсере басылып чыкты.

**Июньнең беренче яртысы.** Татар һәм башкорт халыкларының уртак шагыйре Шәйхзадә Бабич ак фетнәчеләр тарафыннан җәзалап үтерелде.

*«Кызыл Армия» газетасы, 16 июнь.*

**16 июньгә кадәр.** Самарада (хәзерге Куйбышев) «Таң» исемле театр труппасы оештырылды.

*«Яңа көч» газетасы, 16 июнь.*

**25 июнь.** «Эш» газетасында түбәндәге игълан басылды:

«Татарлар арасында театр вә музыка эшенең куелуы һәм аның киләчәктә өмет ителгән барышы хакында 26 июньдә кич 7 дә булачак киңәш мәҗлесенә Казанда булган оешмаларның һәркайсыннан 1—2 шәр вәкил чакырыла. Шулай ук татар театры һәм аның барышы хакында үз фикерен әйтәчәк һәрбер кеше килергә тиеш. Мәҗлес Тукай урамында «Эш» конторасының идарәханәсендә булачак».

**25 июнь.** Танылган революционер, коммунист Камил Якуб фетнәчеләр тарафыннан үтерелде.

**Июнь — сентябрь.** Г. Ибраһимов, махсус задание буенча, дошман тылында йөрде. Соңыннан ул, бу сәяхәт-командировкасының хисабы төсендә, «Дошманнар арасында дүрт ай» исемле очерк язды. Очерк «Кызыл юл» газетасының 7 сентябрь, «Эш» газетасының 15 сентябрь, «Кызыл Армия» газетасының 16 сентябрь саннарында басылды.

**6 август.** Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең сәяси бүлеге, Казан өлкәсе һәм шәһәренең бер төркем интеллигенциясе, руханилары һәм мөгаллимнәре өчен, аңлашу мәҗлесе үткәрде. И. Казаков, С. Сәетгалиев, Р. Рәхмәтуллин җыелышка килүчеләргә (30 кеше) Совет властеның асылы, тоткан политикасы турында аңлаттылар.

*«Эш» газетасы, 8 һәм 14 август*

**8 август.** Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең сәяси бүлеге карамагындагы татар драма артистлары труппасы Ш. Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» исемле комедиясен сәхнәгә куйды. Спектакльнең режиссеры К. Тинчурин.

**19 августка кадәр.** Зөя өязендә дәүләт театр труппасы төзелде.

*«Эш» газетасы, 19 август.*

**19 август.** «Кызыл юл» газетасында «Матәм маршы»ның татарча тәрҗемәсе басылды.

**24 август.** Казан югары сәнгать мәктәбендә күргәзмә ачылды. Ул өч бүлектән (рәссамчылык, скульптура һәм монументаль-декоратив сәнгать) тора.

**7—14 сентябрь.** Казанда һәм губернада китап атналыгы үткәрелде.

Китап атналыгының максатлары: 1. китап җыю; 2. халыкка китапның мәдәни ролен аңлату һәм 3. китапханә эшләре белән халыкны таныштыру.

14 сентябрьдә Казанда 20000 гә якын китап җыелды.

*«Эш» газетасы, 11 һәм 17 сентябрь.*

**21 һәм 29 сентябрь.** «Кызыл Армия» һәм «Эш» газеталарында түбәндәге мөрәҗәгать басылды:

«Урыннардагы партия оешмаларына һәм язучылар дикъкатенә!

Октябрь революциясенә 2 ел тулу мөнәсәбәте белән, Казандагы мөселман журналистлары һәм язучылар катнашы белән түбәндәге темаларны эченә алган зур бер җыентык чыгарылачак:

1. Революция корбаннары (кыскача тәрҗемәи хәлләре, революция дәверендәге хезмәтләре, мөмкин булса рәсемнәре);
2. Революция тарихы (Февральгә кадәр, Февраль — Октябрь арасы, Октябрьдан соң);
3. Учредительное собрание;
4. Гражданар сугышы (төрле дәверләре);
5. Мөселманнар арасында милли хәрәкәт (съездлар дәвере, Милли шуралар, Хәрби шура, Милләт мәҗлесе вә башка дәверләр);

6. Мөселманнар арасында сәяси агым (эшчеләр оешмалары, социалистлар комитетлары, большевиклар партиясе комитетлары, сул эсерлар, конференция, съезд, комиссариатлар вә башкалар)...

Материаллар «Эш» яки «Кызыл Армия» идарәсенә җибәрелергә тиеш».

**Сентябрь.** Стәрлетамакта Башкортстан Ревкомы органы «Башкортстан хәбәрләре» газетасы чыга башлады. Ул 1922 елда Уфага күчте һәм РКП(б) ның Башкортстан өлкә комитеты органына әверелде. 1924 елда «Башкортстан хәбәрләре» нигезендә 2 газета чыга башлый: башкортча «Башкортстан» һәм татарча «Яна авыл». (Хәзерге көндә бу газеталар «Совет Башкортстаны» һәм «Кызыл таң» исемнәре астында чыга.)

**Сентябрь.** «Кызыл йолдыз» газетасының 65 санында Муса Җәлилнең «Бәхет» исемле беренче шигыре басылды.

**Октябрь башы.** Казанда шәрык консерваториясе ачылды.

**18 октябрь.** Ф. Бурнаш рус совет шагыйре Д. Бедныйның «Ачлык-патша» исемле поэмасын тәрҗемә итте.

**5 ноябрь.** «Эш» газетасында түбәндәге игълан басылды:

«Ноябрь урталарында Төркстанга китәчәк «Шәрык поезды»нда чыгарылачак газета идарәсенә казакъча (кыргызча), сартча, фарсыча яхшы белә торган һәм шул телләргә русчадан тәрҗемә итә ала торган язучылар кирәк. Шулай ук югарыда күрсәтелгән телләрдә яхшы сөйли белә торган хатиблар һәм лекторлар кирәк...»

**7 ноябрь.** Октябрь революциясенең 2 еллык бәйрәме хөрмәтенә Пороховой бистәдә Шамил Усмановның «Беренче адым» исемле 3 пәрдәле пьесасы куелды.

**27 ноябрь.** «Эш» газетасы игълан итте:

«Казан губернасы Мәгариф бүлегенең мәктәптән тыш мәгариф эшләрен карау бүлекчәсе тарафыннан, сәхнә эшчеләре җитештерү максаты белән, «Драматический студия» ачыла. Шул студиягә керергә мөселманнардан русча яхшы аңларлык, сәхнә эшенә мәхәббәтле 4 һәвәскәр кирәк... Студиянең башлануы декабрь башында».

**22 декабрь.** «Мәркәз мөселман хәрби һәйәтенең... аң-белем вә сәнгать тарату бүлеге тарафыннан түбәндә исемнәре күрсәтелгән пьесалар русчадан татарчага тәрҗемәләнергә тәгаен ителде: 1) «Отелло»; «Гамлет» (Шекспир); 3) «Ревизор» (Гоголь); 4) «Мещаннар»; 5) «Тормыш төбендә» (Горький)»...

*«Кызыл Армия» газетасы, 22 декабрь.*

**23 декабрь.** Омскида «Азат Себер» газетасының беренче саны чыкты. Газета 1921 елда Новониколаевск (хәзерге Новосибирск) шәһәренә күчерелә һәм 30 елларның башларына кадәр яшәп килә.

## 1920 ел

**15 январь.** «Кызыл Армия» газетасында Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең аң-белем һәм сәнгать бүлегендә саклана торган «бу көнгә кадәр матбугатта чыкмаган татарча кульъязма пьесалар» исемлеге басылды. Анда барлыгы 35 әсәр күрсәтелә.

**15 январь.** «Кызыл фронт атнасы» исемле бер көнлек газета чыкты. Газетада Сәлах Атнагулов, Ф. Бурнаш, К. Әмири мәкаләләре һәм Ф. Бурнашның «Теләк, бүләкләр ул көтә...» К. Әмиринең «Без кызыллар» исемле шигырьләре урнаштырылган.

**16 январь.** Зур театр бинасында «Сәяси сакал» исемле 3 пәрдәлек комедия уйналды. Әсәрнең авторы һәм спектакльнең режиссеры — К. Тинчурин.

**18 январь.** «Кызыл Армия» газетасында М. Гафуриның «Татар егетенә» исемле шигыре басылды.

**28 январь.** «Кызыл Армия» газетасында Ф. Әмирханның «Революциядә яңа дәвер» исемле мәкаләсе басылып чыкты.

**30 январьга кадәр.** Казан губерна журналистлар комитеты янында татар журналистлары секциясе төзелде.

**Январь.** «Кызыл шәрык» журналының беренче саны чыкты. Журнал 1921 елның җәй айларына кадәр яшәп килде. Аның битләрендә Г. Ибраһимов, Ф. Сәйфи-Казан-

лы, В. Шәфигуллин, С. Атнагулов, Ф. Бурнаш, К. Әмири, Ә. Сәгыйди, С. Кудаш һ. б. актив язышты.

**14—16 март.** Казан шәһәрендәге татар артистлары һәм музыкантларының беренче конференциясе эшләде. Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең аң-белем тарату бүлеге тарафыннан оештырылган бу конференцияне К. Тинчурин ачты. Анда түбәндәге мәсьәләләр каралды:

1. Агымдагы хәл (С. Атнагулов доклады).
2. Татар театрының үткәне, киләчәге һәм хәзерге хәле (К. Тинчурин).
3. Татар театрын юлга салу (М. Мутин).
4. Татар музыкасын юлга салу (Яушев).
5. Татар артистларын оештыру һәм аларның бер-берсенә мөнәсәбәтләре (М. Мутин).
6. Көнчыгыш сәхнә эшчеләренең вакытлы Үзәк бюросын сайлау.

**22 март.** С. Сәетгалиев, Б. Мансуров һәм башкалар В. И. Ленин янында булдылар.

С. Сәетгалиевнең Казанга җибәргән телеграммасында шундый сүзләр бар:

*«Ленин, Татарстан җөмһурияте мәсьәләсе нигездә хәл ителде, фәкать тормышка гына куясы калды; моның партия съездына кадәр булуы теләнә, диде».*

*«Эшче» газетасы, 29 март.*

**24 март.** 6 апрельдә Казанда әдәбият һәм журналистика курсы ачыла. Анар 30 кеше, шул исәптән татарлардан Гали Хәбиб, Мөхәммәт Гали, Мөхәммәтҗан Зәбиров, кабул ителде.

**27 май.** Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын төзү турында декрет кабул итте. Бу декрет «Эш» газетасының 3 июнь, «Знамя революции» газетасының 4 июнь саннарында басылды.

**8 июнь.** Кинематограф лентасына алу өчен сценарий... язучыларның ярышы игълан ителәдер.

Сценарий, әлбәттә, татар тормышыннан, революционный рухта булырга тиеш. Авыл һәм гомумән халык тормышыннан алынган әсәрләр..., шулай ук матбугатта булган әсәрләрдән берәрсен (мәсәлән, «Солдат», «Кәләпүшче кыз», «Галиябану», «Яшь йөрәкләр») сценарийга әйләндереп язу да оригинал белән беррәттән кабул ителә...

*«Шәрык ярлылары» газетасы, 8 июнь.*

**25 июнь.** «Кызыл Армия сараенда Казан губерна башкарма комитетының властьны ТАССРның Вакытлы революцион комитетына тапшыру тантанасы булды. Бу көнне зур митинг һәм парад оештырылды, эш өмәсе уздырылды, М. Вахитов һәйкәленең һәм беренче татар театрының нигезе салынды, ачык спектакльләр һәм бәйрәм концертлары күрсәтелде.

**4 июнь.** Англия, Франция, Америка, Италия, Норвегия, Испания, Болгария һәм башка илләрдән III Интернационалның II конгрессына килгән вәкилләр Казанда булып киттеләр.

**9 июль.** Университетның Актлар залында А. Безыменский житәкчелегендә «Интеллигенция һәм революция» дигән темага диспут үткәрелде.

**16 июль.** «Аң» труппасы Татарстан авылларына гастрольләргә чыгып китте. Труппа Чистай, Тәтеш, Лаеш, Минзәлә, Арча, Мамадыш, Бөгелмә, Буа шәһәрләрендә һәм авылларында спектакль һәм концертлар куйды.

**4 август.** Әгерже шәһәрендә Шамил Усманов хөрмәтенә клуб ачылды.

**26—28 сентябрь.** ТАССР эшчеләр, кызылармеецлар һәм крестьяннар депутатлары Советларының I Учредительный съезды эшләде.

Съездда Г. Ибраһимов та катнаша һәм Татарстан Үзәк башкарма комитетына член итеп сайлана. Съезд делегатларына әдипнең яңа гына басылып чыккан «Безнең көннәр» романы таратыла.

**Октябрьның беренче яртысы.** Г. Ибраһимов «Яңа кешеләр» драмасын язып бетерде. Әсәр әдипләр, журналистлар һәм артистлар алдында укылды, һәм аны сәхнәләштерү чарасына керешелде.

*«Эшче» газетасы, 18 октябрь.*

**Октябрь ахыры — ноябрь башы.** К. Маркеның «Капитал»ын татарчага тәрҗемә итү өчен махсус комиссия төзелде.

**Октябрь.** М. Гафури «Эшче» поэмасын тәмамлады. Бу поэма озакламый, Г. Ибраһимовның сүз башы белән, аерым китап булып басылып чыкты.

**8 ноябрь.** Зур театр бинасында «Яңа кешеләр» драмасының премьерасы булды.

**17—20 ноябрь.** Казанда көнчыгыш журналистларының һәм матбугат хезмәткәрләренең киңәшмәсе булды. Анда Татарстан, Башкортстан, Кыргызстан, Самара, Саратов, Мәскәү һәм Екатеринбург (хәзерге Свердловск) шәһәреннән килгән 46 вәкил катнашты.

**25 ноябрьга кадәр.** Казан Журналистлар союзы «Тимер каләм» исемендә журналистлар клубы ачарга карар чыгарды.

**1 декабрь.** «Эшче» газетасында түбәндәге белдерү чыкты:

> «Шәрык журналист, матбугат эшчеләренең киңәш мәҗлесенә таянып, Мәркәз бюро нәшрият бүлеге янында Истилах (термин) комиссиясе төзелә. Истилах комиссиясенең оештыру җыелышына чакырылалар: Галә Ходаяров, Галимҗан Ибраһимов, Фатих Сәйфи, Галимҗан Шәрәф, Ибраһим Кулиев, Вәли Шәфигуллин. Җыелыш 3 декабрьда булачак...»

**8 декабрь.** Җирле труппа тарафыннан Екатеринбургта (хәзерге Свердловск) беренче тапкыр «Галиябану» спектакле куелды.

*«Коммунист» газетасы», 25 декабрь.*

**1920 ел.** Урал хәрби комиссариатының Сәяси агарту бүлеге «Инкыйлап чаткылары» исемле шигырьләр җыентыгы бастырып чыгарды.

Казанда «Чаткылар», «Фәтхи Бурнаш шигырьләре» дигән җыентыклар чыкты.

*(Дәвамы бар.)*

*Хәниф Хәйруллин*

# АЛМАЗ ИХТЫЯР

## ДАВЫЛГА ТАБАН БЕРЕНЧЕ АДЫМ

XX нче гасыр башын Федя Алабуга урамында каршылады. Шушы кышны шәһәрдә затлы туташлар институты[1] сала башладылар. Малайлыкта, пекарняда йомыш-югла йөреп тинтерәгән Федяның ничек тә менә шул зур төзелештә эшләүчеләргә барып кушыласы килде. Тамак ялына теләсә нинди хезмәткә риза булган, соры чәчле, вак кына сипкелле, йомры гына бу малайны эшчеләр дә бик тиз үз иттеләр. Ул ташчылар артеленә кушылды. Артель җитәкчесе Белобородов аны аеруча якын итә, улым дип кенә йөртә иде. Кыш һәм җәй тачка белән таш, кирпеч ташып, ком һәм цемент измәсе изеп узды. Көзгә, институтның стеналары өелеп беткәч, калайчылар артеленә кушылды. Институт түбәсен калай белән ябышты. Тимер мичләр, чиләк, таз кебек әйберләр ясау серенә дә төшенде. Хуҗа кеше булса да, үзе дә өч-дүрт эшче белән көне-төне бил бөккән мастер Конкин малайны кыерсытмый иде. Ләкин бәхет кошы дигән нәрсә тагын кулдан ычкынды: Конкин бөлде, мастерской ябылды.

1901 елның көзе... Күктә кургаш болытлар йөзә. Алар Каманың ике ягы буйлап үскән наратларның очларына эләгеп-эләгеп китәләр. Пыскаклап яңгыр сибәли. Аяк асты пычрак.

Әнә шундый көннәрнең берсендә аркасына котомка аскан 14—15 яшьлек үсмер пароходтан Чаллы пристанена төште. Ком түшәлгән Чаллы урамнарын таптап хәлдән тайгач, төнне ул пристаньда үткәрде. Иртәгесен дә эш табылмады. Ахырда, навигация ябылыр алдыннан, ул купец Западновка ялланды. Башта кибеткә тимер-калай әйберләр ташыды, аннары шул ук купецның кечкенә мастерскоенда чиләк, таз кебек әйберләр ясый башлады. Биредә ул Василий Митрофанов дигән үсмер белән нык кына дуслашты. (Василий Егорович хәзер дә исән, Чаллы шәһәрендә яши.) Алар бу елларда дөньяның әчесен-төчесен бергә татыдылар, нужа камытын бергә сөйрәделәр. Мастерскойда хезмәт шартлары бик авыр иде. Эш сәгате, ял көне дигән нәрсә белән беркем дә хәбәрдар түгел. Атналар, айлар буе күмер, тимер тузаны эчкән эшчеләр дини бәйрәмнәрдә генә бераз тын алалар. Хуҗа бу көнне аларга ял бирә. Әмма ул көнне эшчеләр, кулларында авыр чүкечләр юклыкка ышанып җитмичәме, йөгәннән ычкынган өйрәтелмәгән тайлар кебек, тилерәләр, аяктан егылганчы эчәләр, дөнья мәшәкатен аракы белән каплап, үз-үзләрен оныталар.

1905 елгы революция дулкыннары Кама ярларына да килеп җитте. Эшчеләр арасында: «Мәскәүдә коралллы восстание булган», «Эшчеләр патшага каршы чыкканнар», «Казанда Алафузов заводы эшчеләре эш ташлаган», «Стахиев амбарларына кызыл әтәч җибәргәннәр», дигән сүзләр ишетелде. Кыюрак эшчеләр моның белән генә чикләнмичә, үй-фикерләрен кычкырып, бөтен кеше алдында да әйтә башладылар.

— Җитәр, күп түздек!

— Западновның да бугазыннан алырга кирәк!

— 8 сәгатьлек эш көне кертелсен!

— Атнага бер көн ял бирелсен.

1905 ел үзара әнә шулай өзеп-өзеп сөйләшүләр, зарланулар белән үтеп китте. Инде егет булып җиткән Федя бу сүзләргә колак сала һәм бу таләпләрнең никадәр

---

[1] Институт благородных девиц, хәзерге педагогия институты бинасы.

дөрес булып та, аның тормышка ни өчен ашырылмавын, хуҗаның шулкадәр гадел сүзләрне ишетергә дә теләмәвен аңлый алмый гаҗизләнә иде. «Ни өчен?».

Башта туган мең төрле сорауларга ул өлешчә җавапны очраклы тапты. 1906 елның җәендә Федя әти-әнисенең хәлен белергә дип туган авылы Орловкага (хәзерге Чаллы районы) кайтты. Аны яшьтәшләре Медведев дигән кеше белән күрештерделәр. Ул үзен РСДРП Үзәк Комитеты члены дип таныштырды. Моның чыннан да шулай булуы белән ул вакытта Федя кызыксынмады, хәер, моның аңа кирәге дә юк иде.

Кич белән алар Дмитрий Филимоновларга җыелдылар. Анда Дмитрийның энесе Иван, сеңелесе Александра, Михаил Колбышин, Петр һәм Василий Сергечеевлар, Кузьма Белопухов, Федя һәм Ваня (Федяның абыйсы) Осетриннар бар иде.

Сыйнфый көрәш әлифбасының беренче хәрефләрен Федя шушы көнне күрде. Медведев аларга революция, изүчеләр, изелүчеләр турында озак сөйләде. Әмма күз алдындагы томан пәрдәсе аша әллә ни күренмәсә дә, Федя дус белән дошманны аерырга һәм бәхетне үз кулың белән, көрәшеп яуларга кирәклеген аңлады.

Саубуллашыр алдыннан Медведев яшьләргә ничек эш итәргә кирәклеге турында аңлатма бирде һәм: «Сезнең түгәрәк РСДРПның урта Кама группасына караячак, алга таба безнең белән тыгыз бәйләнештә торыгыз»,— диде.

...Эшчеләр хуҗа алдына ультиматум куйдылар: «8 сәгатьлек эш көне һәм атнага бер ял көне бирелсен, югыйсә, эш ташлыйбыз!»

Елларның тыныч түгеллеген белгән һәм революциядән коты алынган хуҗа ташлама ясарга мәҗбүр булды: эш сәгате көнгә 10 сәгать итеп билгеләнде, атнаның һәр якшәмбесе ял көне дип игълан ителде.

Бу кечкенә генә экономик җиңү группага керүче яшьләрне канатландырып җибәрде, яңа көрәшкә дәрт өстәде. Алар үз эшчәнлекләрен көчәйттеләр, тегермәндә, пристаньда эшләүчеләр, приказчиклар арасында да аңлату эшләре алып бара башладылар.

Ләкин шымчылар тәҗрибәсез Федорның эзенә тиз төштеләр. Аның артыннан күзәтеп, квартирасында, Орловкада тентү үткәрделәр. Чаллыда калу куркыныч иде инде һәм Федор, бәхет эзләп, Кузнецк шәһәренә китеп барды. Анда ул Носков дигән байның сабын кайнату заводына эшкә керде. Носковның үз гостиницасы, тимер-калай әйберләр белән сәүдә итүче кибете булып, андагы 20 ләп эшче Федорны каяндыр, ерак Себердән, Урал промышленность үзәкләреннән килгән эшче дип кабул иттеләр. «Бездә хуҗаларга бик шаккатып тормыйлар, эшчеләр таләбенә колак салмый башласалар, сүз берләшәләр дә, забастовка игълан итәләр»,— дип сөйләде ул эшчеләргә.

Эшчеләр арасында да кемнәр генә булмый. Бертуган Василий һәм Иван Кирсановлар аны хуҗага саталар. «Уралдан килгән Федор Осетрин эшчеләрне забастовкага өнди, коткы тарата», — дип хәбәр итәләр алар.

Носков тиз генә полициягә хәбәр итә. Икенче көнне аны бер атлы, ике җәяүле полицейский тимер юл станциясенә китереп, поездга утыртып, Сызраньга озаталар. Федор промышленность үзәкләрендә яшәү һәм эшләү хокукыннан мәхрүм ителә. Ул шактый вакыт Орловкада яши, крестьян эше белән шөгыльләнә.

Әмма ишле семьяда, әти җилкәсендә яшәргә артык мөмкинлек булмый. Федор яңадан Алабуга шәһәренә юл ала һәм, озак та үтми, купец Николаев-Шеваровка ялланa. Анда ул авылдашы, чиркәү каршындагы мәктәптә бергә укыган иптәше А. Воровьевны очратып, аның белән дуслашып китә. А. Воровьев Федорны үзләренең профсоюз оешмасы белән таныштыра. Социал-демократлар изүче сыйныфларга каршы көрәштә бу легаль оешманы оста файдаланалар иде. Профсоюз оешмасы исеменнән забастовкалар, демонстрацияләр оештырыла, анда инде политик таләпләр дә куела иде.

Петербург һәм Мәскәүдә забастовкалар барган көннәрдә Алабугада да эшчеләр эш ташладылар һәм, флаглар күтәреп, демонстрациягә чыктылар. Федор кызыл флаг күтәреп барды. Демонстрациячеләр «Марсельеза» җырлап, зур төрмә капкасы янына килделәр. Шунда ук митинг башланып китте. Иске ящиклардан әөп ясалган трибунага бер-бер артлы ораторлар күтәрелде.

— Патшаны бәреп төшерергә!

— 8 сәгатьлек эш көне кертелсен!

— Крестьяннарга җир бирелсен!

Һәр ораторның чыгышы әнә шундый сүзләр белән тәгалләнде.

Ул да булмады, төрмәдән ыгы-зыгы тавышы ишетелде, тимер рәшәткәләр каерып алынды, тәрәзәдән сәке такталары оча башлады.

Кинәт кемдер: «Полиция!» — дип кычкырып җибәрде. Мәйданга ялангач кылычлар уйнатып атлы полиция бәреп керде. Кешеләр шунда ук төрлесе төрле якка таралып беттеләр.

Федорның демонстрациядә кызыл флаг күтәреп йөргән кемдер хуҗага житкергән. Хуҗа эшне кыска тотты: Федор һәм демонстрациядә катнашкан барлык приказчиклар, йөк ташучылар эштән куылды. Егет — тагын туган авылында. Ләкин әтисе аны шомлы хәбәр белән каршы алды.

— Улым, Федя, кая булса да кит,— диде ул, пошынып,— синең арттан тагын килделәр, бөтен өйнең астын өскә әйләндерделәр, малаеңның коралы кая? дип бәйләнделәр.

Сүзгә әнисе дә кушылды:

— И-и, улым, улым, сиңа ни житми, нигә башкалар кебек бил бөгеп кенә эшләмисең? Суга каршы кемнең йөзә алганы бар?

— Ә йөзәргә кирәк, әни!

Туган йортында кунарга да туры килмәде Федорга. Ул Чаллыга китте һәм пароход белән Уфа шәһәренә таба юл тотты.

## ФЕДОР ПУЛЯ КОЯ

Тау башларына сибелеп, язын ап-ак алмагач чәчәкләренә күмелеп утырган Уфа шәһәре дә аны колач җәеп каршы алмады. Кара сакалың кая барсаң да артыңнан калмый дигәндәй, Федорны да нужа өрәге үкчәсенә басып куа килде. Шулай беркөнне эш эзләп, шәһәр урамнары буйлап каңгырып йөргәндә, аңа күптәнге бер танышы очрады. Аның ярдәме белән Федор «Бертуган Калмацкийларның сәүдә йорты»на эшкә урнашты. Бу бик күп төрле әйбер белән сәүдә итүче зур компания иде. Федор башта тимер юл буенча килгән товарларны ат белән складка ташыды, аннары упаковщик булып эшли башлады. Биредә эшчеләрнең үз профсоюз оешмалары бар иде. Эшчеләр комитеты аша Федор РСДРПның Уфа шәһәре комитеты членнары белән элемтәгә керде, аны яшерен җыелышларга да чакыра башладылар. Озакламый ул РСДРПның Уфа шәһәр комитеты теләктәшлек группасына член булып язылды. Аңа партия поручениеләрен ышанып тапшыралар иде.

Федор Уфа тимер юл деподында эшчеләр забастовкасын оештыручыларның берсе булды. Бу забастовка җиңелү белән тәмамланганнан соң, илдә инде Столыпин реакциясе хөкем сөрә башлаганда, РСДРПның Уфа шәһәр комитеты, РСДРПның IV съездында кабул ителгән кораллы восстание турындагы карарына нигезләнеп, эшчеләрне коралланырга чакырды. Ике иптәше белән Федорга корал сатып алу өчен акча табу һәм револьверлар, берданкалар өчен пуля кою бурычы йөкләнде. Федор, депо эшчеләре ярдәме белән, күреге һәм учагы үзендә булган тимерчелектә кургаштан пуля коярга кереште.

Алар эштән соң бу тимерчелеккә, шәһәр читенә, Агыйдел яры буена урнашкан йортның подвалына, һәркөн диярлек киләләр иде. Бу йортка алар өчесе өч яктан, төрле вакытта, һәр көн төрле юнәлештән килсәләр дә, үз артларыннан шымчы күзәткәнен белмиләр иде. Фаҗига көтмәгәндә килде...

## БӨРКЕТ КАНАТЫН КАЕРДЫЛАР

Алар ул көнне эшкә тотынырга да өлгермәделәр, ишекне бик каты дөбердәтергә керештеләр. Аннары: «Ачыгыз! Коралларыгызны ташлагыз!» — дигән тавышлар яңгырады. Федор тәрәзәгә ташланды, иптәшләренә дә үз артыннан ияреpгә ымлады. Алар өчесе өч тәрәзәдән тышка сикерделәр. Федор алдында шунда ук таудай бер жандарм калкып чыкты. Егет аңа, револьверын терәп диярлек, атып җибәрде. Теге, күп ашаган үгездәй, гөрселдәп җиргә ауды. Ул арада тагын берничә тапкыр револьвер

һәм мылтыктан аткан тавышлар яңгырады, тагын кемдер егылды, кайсыдыр үзәк өзгеч үлем әчесе белән кычкырып җибәрде. Ул арада якыннан гына «Тукта, ат-а-ам!» — дип акыра-акыра, калын табанлы, дагалы итек белән лап-лап басып, ике жандарм үтеп китте. Федор койма куләгәсенә сузылып ятты. «Бәлки, күрми узарлар». Ләкин дошман күп һәм ул бу операциягә алдан ныклап әзерләнгән булып чыкты. Әнә жандармнар: «Икесе шушында булырга тиеш, берсе елгага сикерде. Ләкин барыбер тоннчыкты. Һәр адым җирне карарга кирәк!» — дип, үзара сөйләшәләр. Түгәрәк боҗра һаман кысыла бара. Менә алар юл өстендә яткан бер гәүдәгә сәртенделәр. Аны, «Әһә, эләктеңме», дип сөйрәп торгызырга азапландылар. Тик арадан берсе: «Атакаем, ул җанын теге дөньяга озаткан ич!» — дигәч, аны ташлап, өченче кешене эзләргә керештеләр. Алка тагын да кысылды. Федор, әле һаман котылырга өметен өзмичә, елга ярына таба шуышты. Әмма соң иде инде. Аны күреп алдылар һәм, табышка ташланган ач бүреләр кебек, ыргылып килделәр. Тик үч ялкыны белән кайнаган йөрәк бу минутта да югалып калмады: Федор, револьвер барабанындагы патроннарын атып бетермичә, жандармнарны үзенә якын җибәрмәде. Соңгы пуля тагын кемнедер яралады. Жандармнар өелешеп яшь бөркет өстенә ташландылар һәм, кулларын артка бәйләп, аны шәһәр төрмәсенә илтеп яптылар.

## ҮЛЕМ КӨТЕП 32 КӨН

Уфа төрмәсендә Федордан рәтләп сорау алмадылар:

— Большевик?

— Оешмагыз кайда, сезнең белән кемнәр?

— Патша тәхетенә кул сузасыңмы, мерзавец!

Әнә шундый бәйләнчек сораулардан соң, аны канга батырганчы кыйнадылар да янадан цемент идәнле, юеш карцерга кертеп ташладылар... Менә ул юеш таш идәндә ята. Кургашындай авырайган баш бөтен гәүдәсен ниндидер тирән упкынга сөйрәгән кебек. Кулбаш сөякләре сулкылдап-сулкылдап сызлый.

«Әйе, аңа ничек тә күбрәк корал табарга куштылар. Пуля кою өчен әзерлек... Барысы да тәртипле кебек... Аннары ул ау мылтыклары белән сату итүче бер магазинга керде. Анда һәр әйткән сүзне йотарга торучы бер приказчик белән таныште. Аннан стенада эленеп торган 10 зарядлы ау мылтыгын сорады. Тегесе бирде, ләкин чыннан да үзенең аучы икәнлеге турында полиция участогыннан таныклык алып килүен үтенде. Ә ул таныклыкны ничек алсын? Тукта, ни өчен ул миңа таныклык китермичә мылтык бирде соң? Яшел күзләре ни өчен ялкынланып китте? Аннары ни өчен ул аны ишек төбенә чаклы озата чыкты?.. Яшел күзләр»...

Бернична көннән Федорны, башка политкаторжаннар белән бергә, Пермь шәһәре төрмәсенә озаттылар. Биредә, патша хәзрәтләре алдында җинаятьне ничек тә күбрәк итәргә теләп, төпченеп тикшерделәр. Федор РСДРПның Уфа шәһәр комитетының тәләктәшлек группасында член булып торуын яшермәде. Кулга алыну вакытында бер жандармны теге дөньяга җибәргән, икенчесен каты яралаган «бу куркынычлы политик җинаятьченең» коеп куйган большевик булуына тикшерүче дә, гаепләүче-прокурор да шик тотмады. Аны Пермь губернасының хәрби кыр трибуналына судка бирделәр.

...Суд бара. Бронза белән каймаланган биек креслоларда — судья һәм хәрби утырышчылар. Алар артында, алтынланган рам эчендә, бөтен гәүдәсе белән эшләнгән Николай II нең рәсеме. Аның күзләре нурсыз... «Теге приказчик күзләре кебек»,— дип уйлап алды Федор. — Хәер, ул мине сатса, Николай патша барлык Россия халкын сата. Ләкин бер көн килер!..»

— Суд килә!

...Федорның уйлары кинәт ярты юлда өзелде.

Хөкем кыска булды:

«Патша галиҗанәпләренә каршы һәр урында бунт оештырганы, законнан тыш политик оешмада член булып торганы, Уфа шәһәрендә кулга алынганда закон сагында торучы бер жандармны үтергәне, икенчесен авыр яралаганы өчен Федор Осетринны, асу аша, үлем җәзасына хөкем итәргә! Югары дистанцияләргә мәрхәмәт сорап мөрәҗәгать итү тыела. Хөкем карары катгый!»

Җан өшеткеч бу шомлы сүзләрнең мәгънәсенә башта Федор ышанырга да, ышанмаска да белмәде. «Ничек, инде барысы да беттеме?» Аның күз алдыннан, кинокадрлардагы кебек, бер-бер артлы дуслары, Федорның бу хәлен белгән һәм аны кызганудан күзләрен яшь пәрдәсе каплаган, ләкин кычкырып, ачыргаланып, үксеп елап җибәрү өчен тыны буылган, сулуы капланган газиз әнисе, башын түбән игән, җилкәсен дөнья авырлыгы баскан әтисе, абыйсы Ваня, дуслары, тагын әллә кемнәр үтте.

Ул, як-ягындагы ялангач кылычлы ике солдаттан тыш, кулларына богау тоткан өченче солдат алдына килеп баскач кына «үз дөньясына» кайтты. Аны көчле сак астында үлемгә хөкем ителгәннәр камерасына илтеп яптылар. Таш капчыкта тагын ике кеше бар иде. Алар броненосец «Потемкин» крейсеры восстаниесенә кушылган матрослар булып чыктылар. Аларны Федордан ике көн элек үлемгә хөкем иткәннәр. Матрослар соңгы көннәренә кадәр төшенкелеккә бирелмәделәр. Иртән керткән ике кадак икмәктән алар шахмат ясадылар, шуның белән көне буе бер-берсенә мат куйдылар. Федор белән утыруга 28 көн тулганда, аларның өчесен дә төрмә ишек алдына алып чыктылар. Ялан баш, каторжан чикмәне кигән матрослар алдына төрмә побы килеп басты һәм:

— Хода бәндәләре, бу фани дөньяда кылган гөнаһларыгыздан тәүбә итегез, чын күңелдән тәүбә итсәгез, бәлки, аллаһе тәгалә ярлыкар,— дип, көмеш тәресен югары күтәрде.

Ләкин тәрене берсе дә үпмәде. Киң җилкәле, чегән кебек кара матрос, түзмәде, кычкырып җибәрде:

— Атакай, тәрегез белән җәһәннәмнең үзенә олагыгыз!..

Шул вакыт команда яңгырады.

— Матрослар, уң адым алга!

Федор баскан урынында катып калды. Матросларны солдатлар урап алдылар. Кинәт төрмә ишек алдының төньяк почмагындагы дар агачы янында барабан кага башладылар. Көчле конвой астында матросларны шунда таба алып киттеләр. Федор янында өлкән яшьтәге бер жандарм һәм мылтыклы ике солдат калды.

...Кешене ничек дар агачына асканнарын, үлем белән тартышучы гәүдәнең, бик нык туңган кешедәй, кисәк-кисәк дерелдәп китүен беренче күргән Федор башта аңын югалта язды, күз аллары әлҗе-мөлҗе килде. «Чират миңа да җитте, бәхил булыгыз, туганнар!» дип аяз күккә карады. Ә зәңгәр күктә март кояшы көлә. Бу 1908 елның марты иде.

Ләкин аны бу көнне асмадылар. Жандарм, Федордагы әчке дулкынлануны сизепме, күзләре белән генә елмайды да солдатларга «бу тере мәетне» кире илтеп ябарга боерык бирде. Үлем көтүнең 32 нче көнендә аны төрмә начальнигы дежуркасына — икенче катка алып менеп киттеләр.

## ГОМЕРЛЕК ПОЛИТКАТОРЖАН

— Үлемгә хөкем ителгән Федор Петрович Осетринмы?

— Так точно, галиҗанәп...

— Падишаһыбыз Николай II нче шәфкать һәм киң күңеллелек күрсәткән. Үлем җәзасы гомерлек каторга белән алыштырыла.

Федор исенә дә килергә өлгермәде, шул арада бүлмәгә ике жандарм килеп керде һәм алар, Федорның аякларына богау кидереп, аны кулындагы богауларга чылбыр белән тоташтырдылар.

Үлем җәзасын гомерлек каторгага калдырган приговорны укыган жандарм, Федорны алып чыгып киткәндә, тагын бер «мәрхәмәт» күрсәтте:

— Урының оҗмах — Тобольск,— дип кычкырып калды. Бу «Столыпин сандыгы» дип йөртелә торган, бөтен Россиягә билгеле төрмә иде.

Аларны, 10—15 елга һәм гомерлеккә хөкем ителгән бер группа политкаторжаннарны, март аеның себереп торган буранлы көнендә этап белән Тобольскига алып чыгып киттеләр. Конвойлар барысы да җайдак, арттан өч атка төялгән обоз килә. Ә алдан куллар һәм аяклары богауланган каторжаннар атлый. Алар, парлап, чылбырлар белән бер-берсенә бәйләнгәннәр. Богау тавышлары көрәшкә чакыру набаты булып яңгырый...

Богаулы аяклар көнгә 10—12 километрдан ары бара алмыйлар. Шактый кеше инде азык-төлеге бушаган обозда ыңгырашып ята. Тайгада, учак янында ял итә-итә, 80—100 чакрымга бер очрый торган авылларда куна-куна, ниһаять, мең дә бер бәла белән Тобольскига килеп җиттеләр. Икенче көнне, богауларны салдыргач, гомерлек каторгага хөкем ителгәннәрне калдырып, башкаларны каядыр алып киттеләр. Бераздан Федорны цемент идәнле, түшәм кырыендагы тимер рәшәткә аша гына көн яктысы төшә торган бер камерага кертеп яптылар...



Ф. П. Осетринның 1908 елны Тобольск төрмәсендә төшерелгән рәсеме.

1909 елның җәендә политкаторжаннар, өчәр, бишәр кешелек төркемнәргә бүленеп, үзара ни турындадыр киңәшә башладылар. Бер көнне кич Федор янына өлкән яшьтәге, көрәк сакал үстергән бер каторжан килде. Федор аскы нарда, салам тутырылган матраста йоклый алмыйча борсалана иде.

— Әллә йокы алмый, якташ? — диде ул, Федорның иңбашына кулларын салып.

— Ыһы!

— Йокы алмау яхшы, димәк, нидер уйлыйсың...

— Уй бер инде безнең...

— Әйе, кешеләр уйлыйлар, тик ятмыйлар.

Федор терсәкләренә таянды. Тегесе аңа таба иелде һәм бу таш капчыктан котылу планы уйлануы, ләкин аны тормышка ашыру өчен камерадагы барлык каторжанның бер сүздә булырга кирәклеге турында сөйли башлады. Федорның күзләре очкынланды.

— Мин риза!

Бу сөйләшүдән соң ике-өч көн үтмәде, каторжаннар эшкә керештеләр. Камера уртасында тимер аяклы зур өстәл тора. Ул асфальт идәнгә бик нык беркетелгән. Качуны оештыручылар казуны шуннан башларга булганнар. Аннары стена, ишек алдын, аның таш коймасы астын казып үтеп, текә ярга таба чыгарга кирәк.

Каторжаннарга иртә-кич калай чәйнекләр белән кайнар су бирәләр. Хәзер ул бик кирәкле коралга әверелде. Чәй эчкәнче, чәйнекләрне өстәл астындагы асфальт идәнгә куялар. Ул әкренләп җылына. Аннан, ничектер кулга төшерелгән калын пычак очы белән, 4 кисәк плитә кисеп алдылар. Ә казыган балчыкны кая куярга? Монысының да җае табылды. Балчыкны оекбашларга, очлары бәйләнгән җиңнәргә тутырдылар. Билгә урап бәйләнгән оекбашларны, арестант чикмәнен бөркәнеп алгач, надзирательләр сизмиләр иде. Көнгә ике тапкыр, иртә һәм кич, бәдрәфкә алып чыкканда алар казып алынган балчыкны бәдрәф чокырына ташладылар. Кырык көннән артык, сукыр тычканнар кебек, азатлыкка юл салдылар алар. Ләкин унбер метрлап казып үткәннән соң, барысы да юкка чыкты. Кинәт барлык камераларда тоташтан тентү үткәрделәр. Шул вакытта бер жандарм, өстәл астын караганда, элеге «квадрат» сызыкларын күреп алды һәм өстәл астына үрмәләп кереп тә китте...

Бу турыда шунда ук төрмә начальствосына хәбәр иттеләр. Көтүе белән комиссия килде, акт төзелде. Камерадагыларны ишек алдына чыгарып тезделәр.

— Качуны кем оештырды?

Төрмә начальнигының бу соравы, биек стеналарга бәрелеп, кире яңгырады. Җавап бирүче булмады.

— Һәрберсен богауларга, карцерга утыртырга, чыбык белән туксан тугыз тапкыр сугарга!

Хөкем әнә шулай кыска булды һәм аны тормышка да ашыра башладылар. Иң беренче «Потемкин» крейсеры матросы Михаил Спрыгинны чакырып алдылар. Ул Федор белән янәшә карцерда утыра иде. Алып киткәндә, ул карцерның борын сыярлык «тәрәзәсенә»:

— Федор, мунчаның беренчесенә, пар башларга киттем! Ул-бу булса, бәхил бул! — дип кычкырды. Ә «пар башлауның» Федор нәрсә икәнен ишетеп белә иде инде.

Пар башлаучыны төрмә ишек алдындагы зур таш мунчага алып баралар. Аның цемент идәнле өйалдысында киң генә бер эскәмия, ә бер читтә зур тәпән тора. Гадәти вакытта алар берсе утыру, берсе су тотыру өчен хезмәт итәләр. Ә мондый вакытларда?.. Тәпәнгә тозлы кайнар су тутыралар, аңа тал чыбыгы бәйләме батыралар. Ул суда 2—3 сәгать «пешерелә».

Менә шул парга беренче булып Михаил Спрыгин эләкте. Аның күлмәген салдырдылар, эскәмиягә йөзтүбән яткырып, кулларын алга суздырып бәйләп куйдылар. Аякларына аю кебек таза надзиратель менеп атланды. Ике яшь кенә казак, кулларына сыек чыбык алып, аның саллылыгын һава кистереп сынап карады. Аннары:

— Әйдә, казак, түз. Атаман булырсың! — дип, шәрә тән өстендә чыбыкларын чажчож биетә башладылар. Чыбык белән беренче сугу бөтен тәнгә кинәт шаулап торган кайнар су сипкәндәй, икенчесе, өченчесе кабырга араларына утта кыздырылган озын без батыргандай булды. 20—25 тапкыр сугуга каторжан әле түзә, аңын югалтмый. Пар башлау гадәттә шушы тирәдә туктый. Аннары начальство килә. Казакларга:

— Башларга! Тик уң кулдан! — дигән команда бирелә. Моның үз сере бар. Эскәмиядә инде аңын югалтыр хәлдә яткан кешене ике кулга да сыек чыбык тотып кыйный башлыйлар. Тик уң кул белән сукканы гына «законлы», ә сул кул белән кыйнау исәпкә керми.

Качарга омтылучыларның һәрберсе туксан тугыз чыбык тәмен татырга тиеш иде. Шушы рәвешле суктыру атнага якын дәвам итте. «Пар башлаган» Михаил Спрыгин бернечә көннән үлде. Җәзасын алучыларны карцердан камераларга күчерделәр. Менә Федор да коры сәкедә йөзтүбән ята. Тоташ чи иткә әйләнгән аркасына киндер арестант күлмәге ябышкан. Аз гына кыймылдау белән ул тирене кубарып ала, күлмәккә тагын алсу кан йөгерә. Утырып тору, кырын, чалкан яту турында башка да китереп булмый...

Камерадагы политкаторжаннар шул хәлләрендә дә шаярталар.

— Нәрсә, Федя, әллә пляжда булдыңмы?

— Берьюлы, күрмәгәндәй, кызынмыйлар аны.

Аларның шулай шаяртып алуларыннан соң, сызланулар бераз кимегәндәй тоела иде. Кеше кебек утыра, ята алмыйча алты ай газапланды Федор.

Ара-тирә политкаторжаннар төрмәсенә патша сараенда изге дип саналучы, элекке ат карагы Гриша Распутинның ахирәте — изге ата Макарий да килеп чыккалый. Ул надзирательләр белән камерадан камерага йөри һәм гөнаһларыннан тәүбә итүчеләрне эзли.

— Я, кайсыгыз үз гөнаһларын юарга тели, хода бәндәләре? — ди ул, ишектән керүгә.

Федор Петрович утырган камерага кергәч тә ул шундый сорауны бирде. Моңа җен ачулары чыккан, бу дин козгыныннан тәмам туйган каторжанның берсе, яшь кенә егет Тулубаев, кинәт богаулы кулларын югары күтәрде һәм:

— Изге ата, тагын безнең нәрсә юасы калган? Әнә кара, төрмәнең барлык стеналары безнең кан белән юылган! Бездә бер гөнаһ та юк, сезнең үз гөнаһларыгызны кандалалар кебек сыта-сыта, юарга кирәк! — дип кычкырып җибәрде.

Надзирательләр аңа сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәделәр, камерадан өстерәп алып чыгып киттеләр.

## КАРЦЕРГА!.. КАРЦЕРГА АЛЛАСЫЗЛАРНЫ!

Политкаторжаннарны төрмә ишек алдына чыгарып тезделәр. Төрмә конторасының икенче катында, болдырда, комендант басып тора иде.

— Күрәсезме,— диде ул каторжаннарга, ишек алдында таудай өелеп торган утын

әрдәнәләрен күрсәтеп,— ут-мазар булса бик куркыныч бит, ун-егермешәр кубометр итеп таратып өяргә кирәк. Җитәр казна икмәген бушка черетергә!

Берничә көн аны таратып, вак өемнәр ясадылар. Инде эш бетте дигәндә, ниндидер жандарм офицеры: «Бу нинди тәртипсезлек? Анда да, монда да утын өеме? Әллә делянкамы бу? А ну-ка, өегез бер урынга!» — дигән приказ бирде. Тагын өйделәр.

Аннары тоткыннар күбәйде, ахрысы, төрмәнең бер як стенасына терәп, казарма сала башладылар. Политкаторжаннарны монда да «файдаландылар». Иртән, төшкә кадәр, стена кырыендагы ташларны кырык-илле метр ераклыкка күчерттеләр, ә төштән соң яңадан кире үз урынына ташыттылар.

Мыскыл итүгә ачуы чыккан тоткыннарның кайберләре түзми:

— Нигә көләсез, мәсхәрәлисез? — дип кычкыра иде. Шуны гына көткән надзиратель:

— Ә, ошамыймы? Биш тәүлек карцер! — дип, аның өстеннән рапорт яза. Елга ике тапкыр губерна күләм инспектор тикшерүләре була. Минем өсләремә чикмән кигән арестантлар строе алдыннан, ата күркә кебек кукраеп, үзенең күп санлы нирченнәре белән жандармерия полковнигы, ә кайчакта генерал атлый. Кинәт ул бер арестант алдына килеп туктый һәм, аның күзләренә керердәй булып, сорау бирә:

— Я, ничек, режимнан зарланмыйсыңмы?

— Юк, яхшы, ваше превосходительство.

— Ә бу нәрсә, сәдәпләрең өзелергә тора! Казна киемен шулай йөртәләрмени?

— Гаеплемен, күрмәдем.

— Ә, шулаймы? Күрмәдеңме? Биш тәүлеккә карцерга!

Инспектор тагын алга атлый һәм чираттагы табышына ташлана.

— Әй, син, аллага ышанасыңмы?

— Ышанам.

— Крест йөртәсеңме?

— Муенымда.

— Алдыйсың, мерзавец! Үзең аллага ышанам, крест йөртәм дисең, үзең алланың җирдәге илчесе — патша хәзрәтләренә каршы барасың, бандит! Ун көнлек карцерга!

Минем инспектор Федор Осетрин алдына килеп басты:

— Аллага ышанасыңмы?

— Юк!

— Крестың да юкмы?

— Юк.

— Ах, син, алласыз! Унбиш көнлек карцерга үзең!

Инспектор кем белән генә сөйләшмәсен, аның белән әнә шулай бәрәү дә «уртак тел» таба алмый.

## «ТУГАННАР, СЕЗ АЗАТ!»

1917 елның февралендә камерага бер надзиратель килеп керде һәм:

— Федор Осетрин, әйберләреңне жый! — диде. Коридорга чыгып бераз торгач, яңадан керде һәм: «Кирәк түгел инде»,— дип, ишекне бикләп, үзе каядыр йөгерде. Ул арада төрмә ишеге алдында шау-шу купты. Ул да булмады, коридорларга кешеләр кереп тулды һәм камераның тимер ишекләрен каера, җимерә башладылар. Минем ишек каерылып килеп төште. Бусагада урта яшьтәге бер эшче күренде, ул камерага атылып керде һәм кулындагы револьверын югары күтәреп:

— Туганнар! Сез азат, Николай икенче тәхеттән ваз кичте! Петербургта, Мәскәүдә — революция! Бөтен власть вакытлы хөкүмәт кулында! — дип кычкырып җибәрде.

Федорның күзеннән яшь бөртекләре атылып чыкты. Әлеге эшчене ул бөтен көченә кочаклап үпте.

Федор барлы-юклы өс киемнәрен җыештырды да, эшчеләргә ияреп, ишек алдына чыкты. Анда төрмә канцеляриясен туздырып яталар. Кинәт аның күзе политкаторжан поляк Пшхадзига төште. Ул Федорга кул болгый иде. Федорның килеп җитүе булды, ул тезеп китте:

— Әйдә, политкаторжаннарның делоларын яндырыйк. Белмәссең, дөнья тагын үзгәреп куяр. Аннары эзләсеннәр җилнекен давылдан!

Алар куркынып почмакка баскан писарьлардан делоларның кайда саклануларын белделәр һәм зур шкафлардан гомерлеккә хөкем ителгән җитмеш ике политкаторжанның делоларын канцеляриянең төрле мичләренә ягарга тотындылар. (Федор Осетрин богаулы килеш төшерелгән рәсемен әнә шул вакытта үзенең гаепләнү делосыннан ала.)

Федор Тобольскида озак тормады, ничек булса да тизрәк туган якларына кайтырга тырышты һәм, февраль салкынында җәяүләп, берничә иптәше белән бергә, шәһәрдән чыгып китте. Алар мең бәла белән Төмәнгә килеп җиттеләр. Биредә каторжаннарны әйбәт каршыладылар. Арестант киемнәрен салдырып ташлаттылар, өскә яңа кием, аякка кирза итекләр бирделәр, ашаттылар, эчерттеләр. Аннары кемнең кайсы якка юл тотуы белән кызыксындылар. Федор Уфа шәһәрен атады. Күп тә үтмәде, аңа Уфага кадәр билет китереп тоттырдылар.

Төмәннән хәбәр иттеләрме, әллә шундый тәртип кертелгәнме — Федор анысын анык белә алмады — ләкин вагоннан төшүгә, аның каршысына ук диярлек кыршылып беткән күн фуражка кигән кеше килеп басты һәм кычкырып җибәрде:

— Амнистия белән кайтучы кем бар?

— Мин!

Ул Федорга ялт итеп борылды һәм аны күзләре белән «бораулады», аннары озын, ябык кулларын сузды да:

— Уфада танышларың бармы? — дип сорады.

— Бар.

— Ул вакытта бүген син шул танышларыңда кун, ә иртәгә шәһәр профсоюз оешмасына кил, анда эш ягын рәтләрбез.

Таныш булмаган кеше шулай дип, серле генә итеп күзен кысты да саубуллашып китеп барды.

Иртәгесен иртүк, кырынып, юынып, юлдан соң адәм рәтенә кереп, Федор бирелгән адрес буенча чакырылган урынга килде.

— Кайда эшләргә, төпләнергә уйлыйсың? — дип сорадылар аннан.

— Бирелә, Уфада эшләргә телим, мин шушыннан кулга алындым,— дип җавап бирде Федор һәм башыннан үткәннәрне кыскача сөйләп бирде.

— Ә, политкаторжан! Сиңа бездә бик әйбәт эш бар. Шәһәрдә большевистик «Вперед» газетасы чыгарыла. Хәзер без сезне аның редакторы Н. П. Брюханов белән таныштырабыз,— диделәр аңа һәм кирәк-яракка дип 200 сум акча да бирделәр.

Әңгәмә алып баручы Федорны шушы ук бинаның бер бүлмәсенә алып кереп китте. Өстәл артында кәгазь өемнәренә чумып утыручы таза гына кеше аларның сәламенә ияк какты да, урыныннан торып, кул биреп күреште. Озатучы кеше:

— Иптәш Брюханов, менә сезгә бер кулай кеше таптык, үзегез сөйләшеп карагыз,— диде дә чыгып китте.

Федорга баштан кичергәннәрен тагын бер кат сөйләп бирергә туры килде. Брюханов аны бик дикъкать белән тыңлады. Аннары:

— Иң мөһиме — патша казаматлары сыйнфый дошманны әллә кайдан ук танырга өйрәткән сине. Безгә нәкъ шундый кеше кирәк тә. Әйдәгез, мин сезне Иван Дмитриевич Цюрупа[1] белән таныштырам. Сез турыдан-туры аның кул астында эшләрсез,— диде.

— Менә, Иван Дмитриевич, сезгә бер егет, әле генә каторгадан,— дип таныштырды аны Брюханов тәҗрибәле большевик белән.— Политик эш өчен тугыз ел Тобольск төрмәсендә утырган.

И. Д. Цюрупа, кулындагы каләмен шалт итеп өстәлгә куйды, күзлеген маңгаена күтәрде һәм урыныннан торып:

— Бик шәп, хәзер безгә нәкъ шундый, канатлары ныгыган бөркетләр кирәк,— дип,

---

[1] **И. Д. Цюрупа — 1898 елдан РСДРП члены. Партиянең XII—XV съездларында КПСС Үзәк Комитеты члены итеп сайлана. И. Д. Цюрупа В. И. Ленин белән һәрвакыт тыгыз элемтә тота.**

йомшак кулларын сузды. Күрештеләр. Берничә сорау бирде, аның җавапларыннан соң, И. Д. Цюрупа кинәт яктырып китте һәм Брюхановка карап:

— Аны бик тиз партия сафына алырга кирәк, сыналасы сыналган! — диде.

Бу сөйләшүдән соң ике көн үткәч, 1917 ел март аенда Федор Петрович Осетринны партия сафына кабул иттеләр. Аңа билетны И. Д. Цюрупа үзе тапшырды. Ул редакциядә эшләү белән бергә, РСДРПның Уфа шәһәр комитеты секретаре хезмәтен дә башкара иде.

## ПОЛИТКАТОРЖАННАР КОМИТЕТЫ ЧАКЫРА

1917 елның май аена кадәр Федор, И. Д. Цюрупа белән бергә, «Вперед» газетасында эшләде. Бу вакытта ул каторгада бергә булган иптәшләре белән элемтәгә керергә дә өлгерде.

Көннәрнең берендә Одессадан хат килеп төште. Тобольск төрмәсендә бергә утырган дусты Гифон:

«Федя, синең хатыңны алгач, бик сөендем. Син нәрсә анда кәгазьгә чумдың? Безгә — Одессага кил. Монда әлекке политкаторжаннар комитеты төзелә. Эш бик күп булачак, муеннан! Мине шул үзеңдәге адрес белән эзләп табарсың»,— дип язган иде.

Бу хатны алгач, Федорның күңеле Одесса якларына җилкенде. Хатны Н. П. Брюхановка да, И. Д. Цюрупага да укытты, рөхсәт сорады. Алар риза булдылар. Одессага барышлый, Федор туган авылы Орловкага кереп чыкты, әти-әнисенең хәлен белеште.

— Исән күрербез дип уебызга да китерми идек! — дип, аны кочаклап еладылар.

Одессага хәвеф-хәтәрсез барып җитте. Поездан төшү белән, Гифон квартирасына китте. Кич иде. Хуҗа өйдә булып чыкты. Алар кочаклашып күрештеләр. Төне буе сөйләшсәләр дә, сүзләре бетмәде. Таң алдыннан гына бераз черем итеп алдылар.

Политкаторжаннар комитетында аларны шәһәрнең хезмәт комиссары Старостин каршы алды, бер үк вакытта ул комитет җитәкчесе дә икән.

Ә бер атнадан аны Одесса шәһәре эшче һәм солдат депутатларының Молдован район Советы карамагына җибәрделәр. Бу 30 меңнән артык эшче яши торган зур район иде. Анда аны эшче-солдат депутатларының район Советы члены һәм башкарма комитет секретаре итеп сайладылар.

## ТАГЫН ПОДПОЛЬЕДА

Кара диңгез флотының «Алмаз», «Синоп» һәм «Ростислав» корабльләре матрослары, Ахтырский полкы солдатлары һәм Кызыл Гвардия отрядлары гайдамаклар өерен Одессадан куганнан соң, шәһәрдә Совет власте әкренләп урнашып килә иде инде. Әмма бу Украина үзәк радасы директория җитәкчесе С. Петлюраның күңеленә бер дә ошамады. Ул, радаңы большевиклардан чистарту өчен ярдәм сорап, кайзер Германиясенә мөрәҗәгать итте. 1918 елның мартында Одесса урамнарына тимер каскалы немец «рыцарьлары» бәреп керделәр. Шәһәргә немецлар кергәндә, Ф. П. Осетринның башкарма комитет бинасында, үз бүлмәсендә утырган чагы иде. Ул немецларның шәһәргә якынлашуларын белеп, Михайловский урамындагы башкарма комитет балконына пулемет урнаштырган иде. Федор балконга чыкты. Тротуарда бала-чагалар: «Немецлар килә, немецлар килә!» — дип кычкырып йөгерәләр. Чыннан да, немецлар башкарма комитетка таба атлыйлар. Үзләрен шәһәрнең хуҗалары кебек тоталар. Менә алдан килүче офицер тротуардан баручы бер яшь кенә кешене туктатты һәм, рус телен ватаҗимерә, урам яңгыратып сорады:

— Син, рус дуңгызы, кем, коммунистмы?

— Юк...

— Алайса, большевик!

Пистолеттан ату яңгырады һәм егет, көлтәдәй, җиргә ауды.

Артык «тамаша» кылу хәвефле иде. Федор, башкарма комитет утырышы протоколларын, документларын җыештырды да пулеметны балконнан сөйрәп алды һәм, ишек алдына алып чыгып, тиз генә утын сараеның бер почмагына яшерде. Аннары тар, аулак урамнар, ишек аллары аша Гифон квартирасына китте. Гифон өйдә иде.

— Яндырырга яки шәһәр Советы председателе Шмуряковка тапшырырга кирәк,— диде ул, документларны күргәч. Ләкин Шмуряков заводта оешкан Кызыл Гвардия

отряды белән шәһәрдән чигенгән иде инде. Документларны яндырырга булдылар. Ләкин аларга бу квартирада калырга ярамый иде. Гифон Федорга яһүдләр больницасының баш врачы Пурецка барырга тәкъдим ясады. Пурец ике катлы йортның өске катында тора иде. Аста — кабул итү бүлмәсе. Гифон һәм Федор көндез Пурецның кабул итүен «көтеп» вакыт уздырдылар, ә төнлә шунда кундылар. Шулай ике атна чамасы алар Пурецта «дәваландылар». Ниһаять, Гифон шәһәргә чыгып йөри башлады һәм бер көнне яңа квартира тәкъдим итте. Ул Молдован районының Малороссийский урамындагы кечкенә генә ике катлы йорт иде. Монысының да икенче катында йорт хуҗасы үзе яши иде. Ә аскы каты аның кайчандыр кибет кебек нәрсә булган булса кирәк, парадный ишеге урам якта. Ике дус моннан оста файдаландылар: ишек өстенә «Водопроводная мастерская» дигән белдерү язып куйдылар. Бу һөнәрне Гифон чыннан да яхшы белә икән. Әкренләп кирәкле коралларны булдырдылар да, самовар, таз һәм башка шуның ише вак-төяк әйберләр төзәтеп, әлеге вывеска астында яшеренеп яши башладылар.

Партиянең Одесса шәһәр комитеты элекке политкаторжанны онытмады, аңа легаль эш табу чарасын күрде. Чөнки аны белүчеләр аз иде.

Шәһәр тормышын нормаль тоту өчен бер кадәр эшчене эш һәм азык белән тәэмин итәргә кирәк иде. Шуны күздә тотып, шәһәр управасы эшчеләр өчен ябык сәүдә кооперативы оештырырга рөхсәт сорап немец комендатурасына мөрәҗәгать итте. Немец комендатурасы моңа каршы килмәде.

## «СЕЗДӘ БРАЗИЛИЯ ПАТОКАСЫ БАРМЫ!»

Ф. Осетринны әнә шул ябык сәүдә кооперативына мөдирлеккә тәкъдим иттеләр.

Ике-өч көн эшләгәч, кооператив кибетенә Карпов кушаматлы элемтәче килде. Федорның аның белән элек тә очрашканы бар иде һәм алар бер-берсен тиз таныдылар. Документларны рәтләргә дигән булып, алар склад ягына үттеләр.

— Менә нәрсә,— диде Карпов, ишекне ябу белән,— безгә яшерен квартиралар белән эш итүче, подпольедагыларга яшерену өчен ышанычлы адреслар бирүче, шул адресларны үзеңдә саклаучы кирәк. Адресларны без сиңа бирербез. Кирәк кешеләр сиңа килерләр. Бу — партия поручениесе.

— Аңлыйм.

— Пароль — «Сездә Бразилия патокасы бармы?» — дип сорарлар. Сез, бар, диярсез һәм шушы парольне әйтүчегә квартира адресы бирерсез. Я, уңышлар телим. Тик, Федя, бик сак эш ит, шпиклар гаять күп.

Көннәрнең берендә кооператив кибетенә бер яшь егет килеп керде. Ул үзенә очраган беренче сатучыдан Бразилия патокасы сорады. Тәҗрибәсезлеге күренеп тора... Федор ашыгып аның янына килде дә: «Бәхетең бар икән, менә складтан соңгысын бирәм»,— дип, җиңеннән тотты. Саксызлыгы өчен «мунча кертеп» тә алды!

Бер көнне магазинга Карпов үзе килде. Тагын ниндидер документлар күрсәткән булды һәм алар мөдир бүлмәсенә үттеләр.

Шәһәрдә легаль булмаган «Большевик» газетасы чыгарыла иде. Шуны таратуда Федорның ярдәм итүен үтенде, Осетрин газетаны товар сатып алучы эшчеләрнең әйберләренә төреп бирергә тиеш иде. Пароль — «Мин заводтан ук килдем».

— Хәвефле дә, ләкин тырышырга туры килер инде...

— Түзик, Федор!

Тагын бер эш артты. Әмма Федор Петрович бу имтиханны да уңышлы үтте. Башта газета һәм листовкаларны махсус элемтәчеләр китерделәр. Менә ике-өч көн инде кибеткә бу кыйммәтле «товарның» килгәне юк. Бу Федорны шиккә төшерде. Шундый уйларга бирелеп торганда, ишектә тагын Карпов күренде.

— Сафлар нык сирәгәйде,— диде ул, сөйләшергә беренче мөмкинлек туу белән.— Сәбәп: тимер юлчылар немецларның халыктан талап җыелган малларын Германиягә озатуда катнашырга теләмиләр, барысы да тирә-як авылларга таралып бетте. Ә немец командованиесе, Петлюра белән берләктә, моның кем кулы белән эшләнгәнен сизенгән. Шәһәр буенча гомуми тентү бара. Сак бул. Менә яшерен типографиядән газета һәм листовкаларны да монда алып килергә кеше калмады. Ышаныч синдә!

һәм ул подпольедагы «Большевик» газетасы типографиясенең яшерен адресын әйтте, бару юлларын һәм парольне өйрәтте. Бу хәтәр көннәрдә Федор дүрт тапкыр типографиягә барды һәм газеталарны биләнә урап, магазинга алып кайтты. Аннары тагын элемтә әкренләп юлга салынды.

Федор ябык сәүдә кооперативы кибете мөдире булып эшләгәндә дә Гифон «мастерскоенда» яшәде. Кайтып шунда куна иде. Бер көнне, эшкә барырга чыгыйм дигәндә генә, мастерскойга немец патрульләре килеп керде. Федор тиз генә эчке ишек артына качты һәм, мастерскойдагы патрульләргә сиздермичә, урамга чыкты. Патрульләр тышкы ишек янында да калган икән — аны эләктереп алдылар. Шәһәр управасы тарафыннан бирелгән мандатны күргәч кенә аны җибәрделәр.

Ә бу вакытта мастерскойда патрульләр тентү ясарга керешәләр. Гифонның документларын тикшерәләр. Мастерскойны тентеп бетергәч, озын немец капралы Гифон хатынына почмактагы чолан ишеген ачарга һәм ут алып килергә куша. Гифон хатыны: «Ярар, Ярар!» — дип, түшәмгә асылган куыклы утны кабызу өчен урындыкка баса һәм шул вакыт ул иренең күзләре белән очраша. Иренең карашын шунда ук аңлап ала һәм, һуштан язган булып, урындыктан гөрселдәп идәнгә ава. Ыгы-зыгы китә. Немец телен бераз сукалаган Гифон: «Су, су!» — дип кычкыра башлый. Ул арада патрульләрнең берсе почмакта торган сулы чиләкне күтәреп килә. Гифон, хатыны баш очына тезләнеп, «үкерергә» керешә. Немецлар, монда эш беткәнгә хисаплап, ишеккә юнәләләр...

Ә чоланда, ярма пакетлары эчендә, подпольеның револьверлары һәм патроннары яшерелгән була...

1918 елның ноябрь урталарында Одессага Англия-Франция гаскәрләре десанты төшерелә. Тимер юлы вокзалы буендагы каты бәрелештән соң, немецлар шәһәрдән чигенәләр. Англичаннар һәм французлар артыннан Одессага румыннар, греклар да килеп керәләр. Менә Одесса урамнары буйлап Мәскәүнең үзенә кадәр дип «походка» чыккан Англия танклары үтә. (Аларның берсе дә кире үз иленә кайтмый, Россия кырларында җимерелеп калалар.) Ишәккә атланган греклар, шапырынган французлар белән урамнар тула... Француз революционеркасы Жанна Лябур, Одесса революционеры, подполье җитәкчесе Николай Ласточкин (И. Смирнов) җәзалап үтерелә.

Ниһаять, коралланган шәһәр эшчеләре һәм Кызыл Гвардия отрядлары Англия һәм Франция оккупантларын 1919 елның 6 августында шәһәрдән куалар.

Одессада яңадан Совет власте урнаша. Федор Осетрин партиянең Одесса шәһәре Молдован райкомы члены итеп сайлана. Аннары эшче һәм солдат депутатларының район советына сайлауларга әзерлек башлана. Федор Петрович шушы ук районда сайлау комиссиясе председателе итеп билгеләнә. Сайлаулар сул эсерлар белән бик каты көрәш шартларында үтә. Федор Осетринны биредә район Советы башкарма комитеты президиумы члены итеп сайлыйлар. Беренче утырышта ук Федор Петрович ул вакытта иң җаваплы участокка — район башкарма комитетының азык-төлек бүлегенә — мөдир итеп раслана.

Партиянең шәһәр конференциясендә аны шәһәр комитеты члены итеп сайлыйлар һәм бер үк вакытта профсоюзларның шәһәр кооператив работниклары секциясе председателе вазифасын да йөклиләр.

## ДЕНИКИНГА КАРШЫ

1919 елның июль ахырларында Одесса өстендә тагын кара болытлар куера башлый. Шәһәргә Англия-Франция империалистлары ялчысы, алар тарафыннан баштанаяк коралландырылган ак генерал Деникин гаскәрләре якынлаша. Иң хәтәр вакытта «Ирекле казак» корпусының Совет властена хыянәт итеп, Деникин ягына чыгуы хәлне тагын да кискенләштерә. Деникинның максаты бик ачык: ул Кызыл Армия частьлары көчен үзенә җәлеп итеп, көнчыгыштан һөҗүм итеп килүче Колчак гаскәрләренә ярдәм кулы сузарга тели. Аннары, Иделдә Колчак белән очрашып, бердәм көч белән революция бишеген басып алырга план кора. Троцкийның көньяк фронтта җимерү эшләре алып баруы хәлне тагын да катлауландыра. Менә шушы вакытта В. И. Ленин

РКП(б) Үзәк Комитеты исеменнән, 1919 елның 9 июлендә барлык оешмаларга үзенең: «Бөтенесе дә Деникин белән көрәшкә!» — дигән чакыруы белән мөрәҗәгать итә. Көньяк фронтка К. Е. Ворошилов, Г. К. Орджоникидзе һ. б. кебек партиянең җаваплы работниклары җибәреләләр. Август ае азагында Одессага К. Е. Ворошилов килә. Ул барлык районнарның партия комитеты, башкарма комитет президиумы членнарын җыя, аларга атаман Григорьев, Махно бандаларының тоткан төп политикалары турында сөйли, Деникинга каршы көрәшнең гаять житдилеген аңлата. Бу утырышта Ф. П. Осетрин да катнаша һәм, залда Деникинга каршы көрәшү өчен партия мобилизациясе игълан ителү белән, беренчеләрдән ирекле булып язылa. Шәһәрдә шунда ук 49 нчы украин укчы полкы оештырыла.

К. Е. Ворошилов житәкчелегендәге армия составында бу полк Николаев шәһәрен Махно бандаларыннан азат итүдә актив катнаша.

Федор Петрович бу вакытта кулына корал тотып көрәшү белән бергә, партиянең полк ячейкасы председателе хезмәтен дә үти. Аннары аны бригаданың партия җыелышына җибәрәләр. Анда ул партиянең бригада ячейкасы члены итеп сайлана. Икенче көнне РКП(б) Үзәк Комитеты вәкиле, Ильичның турылыклы шәкерте Н. И. Подвойский Федор Петровичны полкның ревтрибунал председателе итеп билгели.

Николаев шәһәрендә ун көн торганнан соң, полк Запорожьены, Ростов-Донны азат итү сугышларында катнаша.

Аннары Федор Петровичны яңадан бригада штабы политбүлегенә чакырып алалар һәм аңа бригаданың культура-агарту эшләре белән җитәкчелек итүне йөклиләр. Ул, полктан полкка йөреп, солдатлар арасында культура-агарту эшләре алып бара, бер үк вакытта кулына корал тотып, революция дошманнарына каршы көрәшә...

Гражданнар сугышы тәмамлангач, ул Татарстанга кайта, республикабыз районнарында партия-совет органнарында төрле җаваплы эшләрдә эшли.

Бөтен гомерен хәзерге матур тормыш, коммунизм тантанасын якынайту өчен көрәшкә багышлаган Федор Петрович Осетрин хезмәтенә хөкүмәтебез зур бәя бирде: ул Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм медальләр белән бүләкләнде. 1955 елдан бирле Федор Петрович — персональ пенсионер.

* * *

...Сарман урамы буйлап бер карт атлый. Адымнары инде аның сак. Ләкин гәүдәсе төз. Ап-ак кашлары астындагы күзләре һәрнәрсәгә, монда минем дә өлешем бар дигән кебек, куанып карыйлар. Очраган һәркем аңа ихтирам белән баш ия. Ә укучылар, пионерлар аны баш киемен салып сәламлиләр. Чөнки ул данлы революция еллары, партиябезнең көрәш юллары турында мәктәпләрдә, клубларда бик еш чыгышлар ясый, хәзер дә, сиксән ике яше тулуга карамастан, яшьләрне революцион традицияләр үрнәгендә тәрбияләүгә үзеннән өлеш кертә. Революция елларында чыныккан алмаздай нык ихтыярлы давыл бөркетенең йөрәге хәзер дә әнә шулай тынгы белми.

——□——

# *Гариф Гобәйгә 60 яшь*

## КАЙГЫРТУЧАН ДУС



Кызык бу тормыш. Көтелмәгән бер хәл, очраклы вакыйга кеше язмышын ул үзе дә уйламаган бөтенләй башка якка борып җибәрә. Г. Гобәй белән дә шулай була. Яшьлегендә ул төрле җирләрдә: трампаркта, типографиядә эшли. Әммә аны, барысыннан да бигрәк, артистлар тормышы мавыктыра. Егет артист булырга хыялллана. Һәм була да. 17 яшендә зур гына бер үзешчән труппада артист, соңрак шул труппада режиссер булып эшли. Ә тормыш аңа бөтенләй икенче язмыш әзерләп куйган икән.

Бервакыт ул, Серебряков дигән рус язучысына ияреп, «Көмеш канат» исемле әсәр яза һәм аны шул вакытларда нәшриятның балалар әдәбияты секторында редактор булып эшләүче Фатих Кәримгә күрсәтә. Шагыйрь, күрәсең, яшь авторда балалар язучысы өчен кирәкле сыйфатлар барлыгын сизеп алган. «Синнән менә дигән балалар язучысы чыгачак, Гариф, тагын яз», ди ул.

Ф. Кәримнең ышанычы бушка китми. Г. Гобәй хәзер татар совет балалар әдәбиятының күренекле вәкилләреннән берсе санала. Балалар әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләрен искә алып, хөкүмәтебез аны ике мәртәбә Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләде.

* * *

Г. Гобәй әдәбиятка 30 елларда килде. Бу еллар исә тормышның һәр тармагында сыйнфый көрәшнең кискенләшә баруы белән характерлы иде. Татар балалар әдәбияты да сыйнфый көрәш темасыннан читтә кала алмады. Яшь буынның социализм төзелешендә актив катнашуын, искелек калдыкларына каршы көрәшен сурәтләү балалар әдәбиятында төп урынны алды, дияргә була.

Иҗатының беренче адымнарыннан ук Г. Гобәй чорның зур социаль проблемаларына мөрәҗәгать итте. 1934 елда ул колхоз төзү елларындагы пионерлар тормышына багышланган «Каланча» повестен бастырып чыгарды. Аннары Германия балаларының фашизмга каршы көрәшен сурәтләгән «Без әле очрашырбыз» исемле әсәр язды. Каләмдәшләре аны бер дә юкка гына А. Гайдар белән чагыштырмыйлар. А. Гайдар күтәргән темаларны Г. Гобәй татар балалар әдәбиятына алып керде. Шундый темаларның берсе — гражданнар сугышы вакыйгалары.

30 елларның икенче яртысында әдип аеруча күп һәм киеренке эшли. «Маякчы кызы» (1938), «Ялгыз йортта» (1939) повестьларыннан тыш, ул «Аклар лагеренда» (1937) исемле пьеса да яза. Саналган әсәрләрнең барысында да гражданнар сугышы вакыйгалары сурәтләнә, яшь буында уяулык хисләре үстерүгә басым ясала. Моны очраклы хәл дип булмый. Бу елларда халыкара хәлләр кискенләшүгә таба бара. Европадан фашизм куркынычы яный. Шушы җаваплы чорда, күп санлы язучыларыбыз белән бергә, Г. Гобәй дә халкыбызны сугышка каршы көрәшкә, уяулыкка өнди. Инде сугыш башланырга санаулы көннәр калган бервакытта аның «Өч бөркет» исемле пьесасы дөньяга чыга.

Г. Гобәйнең таланты проза жанрында аеруча тулы һәм тирән ачылды. Татар со-

вет балалар әдәбияты тарихына ул нигездә прозаик буларак кереп калды. Аның гражданнар сугышының дәһшәтле күренешләрен реалистик тирәнлек белән тасвирлаган «Маякчы кызы» һәм «Ялгыз йортта» повестьлары бүгенге бәхетле тормышның зур корбаннар хисабына яулап алынганлыгы турында сөйләделәр, революция казанышларының җиңелмәслегенә ышаныч тәрбияләделәр. Бу әсәрләрдә патриотизм, Ватанны саклау темасы кискен иҗтимагый конфликтлар җирлегендә хәл ителде.

Һәр ике әсәрдә дә кечкенә геройлар алдында көрәш романтикасы ачыла, алар чорның зур вакыйгаларына үзләре дә актив катнашалар. Патриотизм, чорның иҗтимагый хәлләренә үзләренең мөнәсәбәтләрен белдерергә омтылу — Г. Гобәй геройлары өчен характерлы бер сыйфат. Шунда ук кечкенә геройлар үзләренең балалык сыйфатларын да югалтмыйлар. Мисал өчен «Маякчы кызы» повестендагы Илсөяр образын алырга була. Повесть укучылар тарафыннан хуплап каршы алына. Авторга күп санлы хатлар килә. Әдәби тәнкыйтьче Г. Гобәйне үз стиле, үз тавышы булган өлгергән язучы, ә повестьны моңа кадәрге әсәрләре арасында иң уңышлысы дип бәяли. Тәнкыйть мәкаләләрендә дә, күп санлы хатларда да Илсөяр образы югары бәяләнә. «Илсөяр образын эшләгән чакта автор көчен кызганмаган. Илсөяр күп эшләр эшли, зур батырлыклар күрсәтә, ләкин ул эшләр, ул батырлыклар ясалма рәвештә килеп чыкмыйлар. Илсөяр һаман да табигате белән бала булып кала», — ди повестька рецензия язучы Г. Әпсәләмов. Чыннан да, Совет власте елларында Илсөяр образы үрнәгендә берничә буын яшьләр тәрбияләнде. «Маякчы кызы» мәктәп дәреслекләренә керде, балалар иң яратып укый торган әсәрләреннән берсенә әйләнде.

Ватан сугышы елларында Г. Гобәй төрле җаваплы постларда эшли. Татарстан радио комитетының председателе була. Партиянең ышанычлы вәкиле сыйфатында колхозларга еш кына бара. Фашизмны җиңү өчен хәтта балаларның да ару-талуны белми тырышып эшләүләрен, һәркемнең фронтка ярдәм итү теләге белән янып яшәвен күреп, әдип гаять дулкынлана. Ләкин бу хисләрен ул елларда кәгазь битләренә төшерә алмый. Тормыш фактларыннан тирән гомумиләштерүләр ясап, типик картиналар тудыру өчен, иркен вакыт кирәк. Әйткәнебезчә, бу елларда Г. Гобәй оештыру эшләре белән мәшгуль була. Гыйбрәтле вакыйгаларга, кискен ситуацияләргә аеруча бай бу чорда ул киләчәктә язылачак әсәрләре өчен материал туплый. Дөрес, Г. Гобәй иҗат эшен дә онытып бетерми. Төрле язучыларның фашизмга каршы язылган сатирик хикәяләрен туплап, «Сукбай армия» исемле китап бастырып чыгара. Сугыш кырларында геройларча һәлак булган пионерлар турында язылган очеркларны тәрҗемә итеп, «Яшь патриотлар» исемле җыентык төзи. Бу урында өстәп әйтергә кирәк: әдәби тәрҗемә — Г. Гобәй эшчәнлегенең аерылмас бер өлеше. Ул моны үзе өчен зарури бер эш, әдәби осталыкка өйрәнү мәктәбе итеп саный. «Гали баба һәм кырык карак», «Мең дә бер кичә» кебек гарәп әкиятләрен, «Полк улы» (В. Катаев), «Путивльдән Карпатка кадәр» (С. Ковпак), «Улым турында хикәя» (Е. Кошевая), «Бәхет орлыклары» (А. Мусатов) һәм башка күп кенә әсәрләрне без Г. Гобәй тәрҗемәсендә укыйбыз.

Сугыш туктап күп тә үтми, 1948 елда аның «Замана балалары», бераз соңрак «Маратның язмышы» (1956) кебек Ватан сугышы вакыйгаларын яктырткан повестьлары басыла.

«Замана балалары» повестен әдәби тәнкыйть төрлечә бәяләде. Уңай бәяләр белән бергә (М. Әмир, Б. Зернит һ. б. мәкаләләре), әсәрнең кимчелекләре күрсәтелгән рецензияләр дә чыкты. Рус язучысы Н. Богданов повестьтагы сюжет таркаулыгын, әсәрнең ахырын кирәкмәгәнгә озынга сузу кебек кимчелекләрне хаклы рәвештә билгеләп үтте. Дөрес, Г. Гобәй моннан соңгы әсәрләрен язганда, динамик сюжет коруда булсын, вакыйгаларны бердәм композицион җепкә тезүдә булсын, сизелерлек уңай тәҗрибә туплый.

«Замана балалары» повестенда сугыш һәм хезмәт темасын бергә бәйләп чагылдыру бурычы куела. Әмма автор бу бурычны уңышлы башкарып чыга алмый: сугышны һәм хезмәтне сурәтләгән бүлекләр һәрберсе үзенә аерым әсәр тәэсире калдыра. Шуңа да карамастан, повесть кыска гына вакыт эчендә яшь укучылар арасында зур популярлык казана. Моның сере нәрсәдә соң? Бу, барыннан да бигрәк, совет пионерының батыр образын җанлы һәм кызыклы итеп бирә, тормыш күренешләрен романтик югарылыкта торып тасвирлый белүдә. Ә батырлык турында романтик рухта язылган китапларны балалар аеруча яраталар.

Г. Гобәй илебез үсешендәге һәр чорның үзенә хас көчле характерлы героен иҗат итә килде. Колхозлашу чорының яшь пионеры Сәлим, гражданнар сугышы елларының яшь көрәшчесе Илсөярдәге героик башлангычны Ватан сугышының авыр көннәрендә Хәлим тагын да үстерә төшә. «Каланча», «Маякчы кызы», «Замана балалары» повестьларында автор геройны тормыштагы вак-төяк хәлләрдән югарырак күтәреп сурәтли. Моның өчен күбрәк тормышның героик якларына мөрәҗәгать итә, гадәттән тыш хәлләрне, кискен ситуацияләрне сайлый. Дөрес, «Без әле очрашырбыз» һәм «Каланча» повестьларында сурәтләнгән вакыйгаларның кайберләре укучыны бик үк ышандырып җиткермәгән иде. «Маякчы кызы», «Замана балалары»ндагы геройларның эшләре инде укучыга бик хуш килә. Алардагы романтик рух тормыш чынбарлыгына нигезләнгән.

Укучыны ышандырырлык тормышчан образларны, героик характерларны язучы ничек тудыра соң? Ул әсәрдәге барлык чараларны рухи ныклыкны, характер көчлелеген күрсәтү максатына буйсындыра. «Замана балалары»ндагы Хәлим, мәсәлән, үз иптәшләреннән шактый көчлерәк малай. «Гәүдәгә бик әйбәт бит. Пәһлеван була бу дүрт елдан», — дип мактый аны хәрби комиссариатта карау вакытында доктор. Күрәсез, геройның физик тазалыгы һәм сәламәтлеге ассызыклап күрсәтелә. Портретны шулай ачык буяулар белән сурәтләүнең зур әһәмияте бар. Ачык төсләр баланы үзләренә ныграк тарталар һәм хәтердә озаграк сакланалар. Хәлимнең һәр сүзеннән, һәр җөмләсеннән үз көченә ышану, оптимистик рух аңкый: «Мин синең өчен үч алырмын әле, абый. Бик каты итеп. Гитлерның күзләре акаеп чыгарлык итеп алырмын үчне». Димәк, сөйләм дә геройның көчле рухлы икәнлеген күрсәтеп тора. Автор геройны авыр хәлләргә куя, кискен ситуацияләрдә хәрәкәт иттерә. Әйтик, дошман самолетлары шәһәр өстендә очып йөргән чакта, Хәлим госпитальдә немец шпионын фаш итә һ. б., һ. б. Әсәрдә шундый гадәттән тыш вакыйгалар шактый күп. Һәм бу — табигый. Монда тормыш материалы үзе, сурәтләнә торган чор киеренкелек, героик вакыйгалар таләп итә. Ул вакыйгалар, үз чиратында, Хәлим образын калку итеп, романтик югарылыкта күрсәтергә булышалар.

«Ләйсән яңгыр», «Без үскәндә» кебек көндәлек тормыш күренешләрен тасвирлаган әсәрләрендә Г. Гобәй җитди, реалистик алымга күчә. Геройны гади укучы белән тигезли. Вакыйгаларны ашыкмыйча, иркенләп тасвирлый. Гади, көндәлек тормыш кешедән зур тырышлык һәм ихтыяр сорый: әсәрләр әнә шул хакыйкатьне исбат итәләр. Әмма авторның образ төзүдәге бөтен әсәрләренә хас бер үзенчәлекне әйтеп китми булмый. Г. Гобәй һәр әсәрендә төп геройны сюжетның үзәгенә куя, калган барлык персонажларны шуның тирәсенә туплый. Бу, әлбәттә, яңа алым түгел. Г. Гобәй әсәрләрендә шунысы кызык: үзәккә куелган образ китапның бер битеннән дә төшеп калмый. Аннан соң ул үз әсәрләрендә характер формалашу процессын, геройдагы эчке үзгәрешне оста чагылдыра белә. Аның, балалар язучысы буларак, көче дә шунда. Мәсәлән, Хәлим хакыйкатькә ээләнүләр аша килә. Ул башта сугышны романтик яктан гына күз алдына китерә. Аныкча, немецларны кыйнау өчен белем кирәкми, батырлыкны тик сугышта гына күрсәтергә мөмкин. Ахырда малай тормыш тәҗрибәсе туплый, һәрнәрсәгә аек күз белән карый башлый. Үзенең тырыш хезмәте белән монда, туган авылында фронтка күбрәк ярдәм итә алачагына төшенә.

* * *

Геройларын кешелеклелек идеясе, гуманизм хисләре белән сугарып бирү — Г. Гобәй иҗатындагы тагын бер матур сыйфат. Бу — язучының үз табигатеннән үк килә булса кирәк. Көче күңеллелек күрсәтеп, бераз елмайган хәлдә, тыныч һәм ягымлы сөйләшүе, игътибар белән тыңлап, сорауларыңа чын күңелдән җавап кайтаруы Г. Гобәй белән беренче очрашканда ук сине әлеге карашка китерә. Кешегә карата мәхәббәт хисләре Г. Гобәй күңелендә кече яшьтән үк туа. «Г. Тукайның балалар өчен язылган әкият-поэмаларын һәм шигырьләрен сабый чакта ничек мавыгып укуым бүгенгедәй хәтеремдә. Ул гәүһәрләр мине кеше акылының бөеклеген танырга өйрәттеләр», — ди язучы. Г. Ибраһимовның «Карт ялчы», «Кәтүчеләр», Ф. Әмирханның «Нәҗип» хикәяләрендәге якты идея әдипкә көчле йогынты ясый. Г. Гобәй әсәрләрендә гуманизм илебез тарихындагы киеренке моментларда, совет кешеләренең бер-бер-

сенә туганнарча ярдәме икеләтә кирәк булган чорларда аеруча көчле чагыла. Язучының геройлары кешене пассив кызганучылар гына булып калмыйлар, алар иң авыр моментларда кешегә ярдәм кулын суза белүләре белән сокландыралар. «Ялгыз йортта» повестенда Мортаза бабай зур тәвәккәллек белән кызыл комиссар Әминәне аклар тырнагыннан саклап кала, аңа үзенең җылы өендә урын бирә, комиссарга көрәшче иптәшләре белән очрашу өчен кирәкле шартлар тудыра. Әминәнең сабый баласына сөт кирәк булгач, кечкенә Таҗи бер байның кәҗәсен урлап кайтудан да куркып тормый. Шулай итеп, Мортаза бабай белән кечкенә Таҗи, үзләре дә сизмәстән, халык бәхете өчен көрәшүчеләр булып китәләр. «Маратның язмышы» повесте, беренче битләреннән алып соңгы битләренә кадәр, Ватан сугышының авыр елларында совет кешеләренең бер-берсенә эчкерсез ярдәм күрсәтүләренә багышланган.

Сугышның кызган көннәре. Ленинград камалыш хәлендә. Әнисез калган сабый Маратны Гөлсем апа камалыштан алып чыга, Казанга алып кайта. Әлбәттә, сабыйны ул Казандагы берәр балалар йортына тапшыра алган булыр иде, ләкин алай эшләми. Үзенең ике баласы булуга карамастан, малайны үзенә уллыкка ала. Гөлсем апаны моңа беркем дә мәҗбүр итми, бу изге эшне ул йөрәк кушуы буенча эшли. Менә шунда совет кешеләренә хас киң күңеллелек, бер-берсе өчен кайгыртучанлык сыйфатлары ачылып китә. Безнең илдә үги ана, ятим бала кебек төшенчәләрнең бетә баруын күреп күңел куана, үзеңнең дә кешеләргә нинди дә булса берәр яхшылык эшлисең килә башлый.

«Әсәрләре балалар өчен дә, зурлар өчен дә бердәй кызыклы тоелган автор гына чын мәгънәсендә балалар язучысы була ала», дигән иде В. Г. Белинский. Бу сүзләр Г. Гобәй әсәрләренә дә туры килә. Мисал өчен шул ук «Маратның язмышы» повестен алыйк. Повесть беренче мәртәбә «Пионер» журналында басылды. Журналның һәр номерын олылар да көтеп алалар иде.

Г. Гобәй повестьлары, кирәк олыларда, кирәк яшь буында булсын, дөньяга коммунистик караш тәрбияләүдә зур роль уйныйлар. Һәм татар балалар әдәбиятының үсеш тарихын Г. Гобәй иҗатыннан башка күз алдына китерү авыр. Әдипнең баштагы әсәрләре татар балалар әдәбиятының үсеш кыенлыкларын чагылдырсалар, соңгылары исә ул ирешкән уңышлар турында сөйлиләр.

«Тормышта бала гаять каршылыклы, аңарда ата-ана, тирә-күрше аша кергән эгоистик, мещанлык һ. б. күп төрле зарарлы сыйфатлар очрый. Андый сыйфатларны сылап-сыйпап үтү, яшерү юлы белән түгел, хәтта аңлы рәвештә үткенләндереп күрсәтү юлы белән аларга каршы көрәшергә кирәк», — дигән иде язучы үзенең бер мәкаләсендә. Шунысын да искәртик, мәкалә әдәбиятта «конфликтсызлык» теориясе киң таралган елларда, 50 еллар башында язылган. Язучы мәкаләләрендә генә түгел, әдәби әсәрләре белән дә тормыш каршылыкларын җиңеләйтеп сурәтләүгә, конфликтсызлык теориясенә каршы көрәште. «Ләйсән яңгыр» повесте, барыннан да бигрәк, әнә шул ягы белән игътибарга лаек.

Әсәр безнең тормышыбызның ямен, тәмен боза, һавабызны агулый торган ямьсез күренешләргә каршы юнәлдерелгән. Г. Гобәй яшь геройлары Гүзәл белән Җиһангирны «теплица» шартларында гына сакламый, балаларга тормыштагы фаҗигале хәлләрнең шаһите булырга, күп кыенлыклар күрергә туры килә. Әсәргә шәхес культы елларында хаксызга рәнҗетелгән Дәүләтъяров язмышы да, Хәррәмов кебек аферист-спекулянт типлары да килеп керә.

Г. Гобәй бу повестенда үз геройларының эчке көрәшләрен, рухи конфликтларын ачуга аеруча зур игътибар бирә, характер формалашуның авыр һәм катлаулы процесс икәнен раслый. Мисалга Гүзәл образын алыйк. Гүзәл үзенең хәле белән бервакытта да килешеп яшәми. Ул һәр минутта эшләгән «гонаһлары» өчен курку һәм борчылу, үкенү һәм тынычсызлану, икеләнү һәм тетрәнү хәлендә яши. Ул, бер яктан, бик намуслы, икенче яктан, карак һәм кеше алдаучы. Шушы ике капма-каршы хиснең үзара тартышы повестьның буеннан буена сузылып килә.

Шул ук вакытта Г. Гобәй тормышыбызның караңгы якларын куерту белән дә артык мавыгып китми, әсәрдә якты күренешләргә, уңайны раслауга күп урын бирелгән. Вакыйгалар шундый итеп корылган: китапның II кисәгендә кызга азгынлыкта йөрү өчен бернинди мөмкинлек калдырылмый. Көзге салкында туңа-туңа караклар шайкасын күпме эзләп йөрмәсен, Гүзәл аларны барыбер таба алмый, кайтып мәктәпкә керергә

мәҗбүр була. Әле кайчан гына әшәкелектә йөргән урам кызының үги әтисен фаш итәрлек кеше булып үсүен повесть совет мәктәбенең тәрбияви көче белән бәйли. Әсәрдә һөнәр мәктәбе Гүзәл белән Җиһангир кебек яшьләрке мораль савыктыргыч «ләйсән яңгыр» итеп карала. Язучы геройларны мәктәптәге җәмгыятькә файдалы эшләргә тарта, аларда укуга дәрт, кызыксыну уята.

«Ләйсән яңгыр» повесте, мораль-этик проблемаларны күтәреп, безнең көннәр тормышын тасвирлауга багышланса, «Без үскәндә» (1963) повестенда Г. Гобәй үткәннәргә мөрәҗәгать итә. Бу әсәр Г. Гобәй иҗатында 30 елларда ук киң чагылыш тапкан тарихи-революцион теманы дәвам иттерә.

«Тәрәзә тиентен җиргә сеңгән, кыйшык-мыйшык кечкенә генә куыш. Тору да, эш тә шунда. Тыгыз, бау тузаны. Көнозын балта, ышкы, тукмак тавышлары. Бөтен гаиләбез белән көне-төне эшләсәк тә, ачлы-туклы, мохтаҗлыкта яшәргә туры килде», — ди Г. Гобәй, сабыйлык елларын хәтерләп. Әдип «Без үскәндә» повестенда шушы үзенә якыннан таныш тормышны — капиталистик җәмгыятьтәге эшче семьяларының ачы язмышын сурәтли, гаделсезлек нигезләренә корылган бу тормышның үзгәрергә тиешлеген тарихи закончалык итеп күрсәтә.

Повестьның баш герое — ярлы малае кечкенә Гарәфетдин. Язучы аны семья рамкалары эченә генә бикләми, геройның үсеш эволюциясе, «Язгы җилләр», «Онытылмас еллар» әсәрләрендәгечә, чорның иҗтимагый каршылыклары белән тыгыз бәйләп яктыртыла. Татар әдәбиятындагы әлеге уңай традиция, «Без үскәндә» повесте аша, балалар әдәбиятына үтеп керә. Гадәттән тыш эшләр йөкләп, язучы үз героеның ышандыру көчен дә киметми. Гарәфетдинне Арсений дәдә, Рәхимҗан хәлфә кебек халык бәхете өчен көрәшүче олы туганнарына булышчы итеп кенә куя. Ләкин автор Гарәфетдин башкарган эшләрне маҗаралы бер уенга гына да әверелдерми. Өлкәннәр политик листовкалар баскан чакта, коеп яуган яңгыр астында сакта тору, полицейский сизеп алгач, караңгы төндә Клим белән бергә басу машинасын каберлеккә илтеп яшерү кебек эшләр Гарәфетдиннән зур тәвәккәллек сорый. Зурларның һәрбер йомышы малайны бераз олыгайтып җибәрә.

Заманында А. Алиш: «Г. Гобәйдә әдәби тел эшләнеп җитмәгән, бу — аның иҗатындагы җитди кимчелекләрнең берсе», — дип язган иде. Әйе, әдипнең баштагы әсәрләрендә тел кытыршылыгы, катлаулы авыр җөмләләр еш очрый.

Г. Гобәй үзенә карата әйтелгән тәнкыйть фикерен дөрес аңлый. «Без үскәндә» повесте язучының хикәяләү теле камилләшә, осталыгы үскәннән-үсә баруы турында сөйли. Автор, повестьның башыннан алып соңгы битләренә кадәр, шома, йөгерек телдә яза, үзенең фикерләрен укучыга җиткерүдә халык теленең бай хәзинәсен эшкә куша.

РСФСР язучыларының икенче съездында сөйләгән речендә Л. Соболев «Без үскәндә» повестена югары бәя бирде. Г. Гобәй исемен дагстанлы Р. Гамзатов, башкорт шагыйре М. Кәрим, мордва язучысы Н. Эркайлар белән бер рәткә куйды. Бу — бик хаклы бәя.

Атеистик тәрбия мәсьәләләре белән Г. Гобәй «Маякчы кызы» повестеннан ук кызыксынып килә. «Без үскәндә» повестенда ул мәсьәләләргә тагын да киңрәк урын бирә. Ниһаять, дингә багышланган махсус китап — «Коръән серләре» дөньяга чыкты. Укучыларның күпчелеге аны хуплап, яратып каршылады. Бу шулай ук бик аңлашыла. Чөнки өстен сыйныфларның дине хезмәт ияләрен куркыту, рухи яктан гариплендерү чарасы итеп файдалануларын Г. Гобәй үзе яшьтән үк күреп, әрнеп үсә. Дин сөреме бүгенге яшьләрне агуламасын — язучының яңа әсәрдә уздырган төп максаты әнә шул.

Бу елның 26 августында Г. Гобәйгә 60 яшь тула. Гел яшьлек турында уйланганга, күрәсең, әдип әле яшь-яшь. Ә үткән гомер шактый, эшләнгән эш күз алдында. Әсәрләре милли рамкалар эчендә генә калмыйча, Бөтенсоюз әдәбиятының гомуми хәзинәсенә әверелделәр. «Маякчы кызы», «Ләйсән яңгыр», «Без үскәндә», «Замана балалары» русчага, «Замана балалары», «Маратның язмышы» повестьлары уйгурчага һәм казакъчага тәрҗемә ителделәр. Әмма ирешелгәннәр чик түгел, Г. Гобәй бүген дә яшьләрчә канатланып, яңадан-яңа иҗат планнары белән янып яши.

Ф. ИБРАҺИМОВА.

# *Безне Октябрь үстерде*

*Юрий Бейлькин*

## СКРИПКА МОҢНАРЫ



**Т**алант дигән серле нәрсә кеше күңелендә кайчан уяна икән?

Бәлки, беренче тапкыр тәпи йөреп киткән көннәрдәндер? Әллә сабый бала, нәни кулларын алга сузып, «әннә» дип дәшкән минуттанмы? Кем белә, бәлки, күп соңрак — кеше дөньяга аек күзләр белән карарга өйрәнгәч, үз-үзен аңлый башлагач — уянадыр. Тик менә сабый чагында музыкаль сәләтен әз генә дә сиздермәгән бер кызның соңыннан, үсеп җиткәч, бөтен дөньяны әсир итәрлек музыкант булып китүен ничек аңлатырга?..

Зоря үскән бүлмәдә Дамир абыйсының пианиносы тора иде. Шулай бервакыт өйдә аулак калгач, кызчык стена буендагы пианино дип аталган, абыйсы буш араларда гына ачып яба торган әлеге ялтыравыклы ящикка үрелде, аның авыр капкачларын күтәрде һәм, үзенең артык батыраеп китүеннән бераз шөлләбрәк, нәни бармакларын клавишаларга батырды... Гаҗәп аһәңле музыкаль авазлар яңгырап китте. Ләкин ул арада ишектә җитди чырайлы әни күренде. Кызының, куркынып, гаепле төс алган кыяфәтен күргәч, анә елмайгандай булды:

— Пианинога тотынма, балам, бармакларың кысылыр...

Зоря шуннан соң пианино янына якын да бармады. Иптәшләре белән качышлы уйнады, курчаклары, уенчыклары белән мәж килде, рәсемнәр буяды. Шулай да, йортның ачык тәрәзәләреннән агылган мелодияләр аны гел хисләндереп, ирнәләп тордылар. Бәхеткә каршы, музыкаль йортта, музыкаль җанлы кешеләр арасында үсте ул. Дамир абыйсы белән күрше кызый пианинода уйныйлар, ян тәрәзәдән скрипка моңнары агыла. Бигрәк матур уйныйлар инде! Вакыты-вакыты белән колакларын репродукторның кара тәлинкәсенә куя, аннан ишетелгән таныш моңнарга кушылып, үзе дә «көйләгән»дәй итенә. Ләкин моны беркем дә искәрми, кызыйның нияләр белән мавыгуы беркемне дә кызыксындырмый. Һәркем үз эшендә. Менә көне җитәр әле, төшенерләр әле...

Көне җиткәч тә артык исләре китмәде. Бервакыт кызы:

— Әни, минем скрипкада уйныйсым килә, — дигәч, Зариат апа бөтенләй аптырап калды. Ул аның укытучы, врач, инженер, кыскасы, теләсә кайсы һөнәргә өйрәнеп китә алачагына ышана иде, тик скрипач булып танылачагын күз алдына да китермәде. Шулай да, укытучы кеше буларак, баланың хәтерен калдырырга теләмәде.

— Әйдә, күңеле булсын, — дип уйлады ул, — теләгәнен эшләп карасын, көче җитмәсен күргәч, үзе үк төшенер, ташлар...

Озак та үтмәде, кызын ул Мәскәү консерваториясе каршындагы үзәк музыка мәктәбенә алып китте. Скрипка укытучысы Владимир Вульфман сүзне кыска тотты:

— Баланың сәләте бар кебек, ләкин үстерергә, чыныктырырга кирәк. Нәрсә буласын алдан әйтү кыен, шулай да, укып карасын әле.

Шулай алты яшьлек Зоря Шахморзаева музыка дөньясына беренче адымын атлый. Тәмле йокыларын калдырып шәһәр читендә яшәүче укытучы янына йөри башлагач, Зоря бер хакыйкатькә төшенә: музыкант булып китү өчен коры теләк, шул эшкә әзме-күпме сәләтең булу гына җитми икән. Моның өчен тырышлык, күп көч һәм энергия түгү, ару-талуны белми эшләү сорала. Аның каравы, Владимир Миронович белән һәр очрашу, аннан алган һәр сабак тавышлар дөньясының гаҗәп гүзәл серләрен ачты, анда чиксез дәрт, көчле омтылыш уятты. Бер серенә төшенеп алгач, музыка сиңа күпме ләззәт, бәхет һәм шатлык ките-

рәчәк, тормыш кыенлыкларын җиңәрлек күпме көч бирәчәк икән!

Зоря скрипкада уйнарга өйрәнде һәм шуннан соң аны беркайчан да кулыннан ычкындырмады. Уенчыкларын, рәсем ясауларын ташлады, ашавын онытты, түземлеген җуеп, «гамма»лар турында уйланды, бармакларын күнектерде. Алты яшьлек сабыйның музыкага әнә шулай үҗәтләнеп ябышуы күпләрнең исен китерде. Әллә бу — кызчыкның, үзенә күрә, скрипканы яратуын өлкәннәргә ышандырырга тырышуымы? Яки... яки моңа кадәр үзен сиздертми йокымсырап яткан талантның уянып китүеме? Кыскасы, һәр икесе дә бар иде бугай монда. Зариат апа, әле кайчан гына бәбкәенең якты теләкләрен күләгәләргә, скрипка дип сөйләшүеннән айнытырга йөрүенә үкенеп алды: «Кара инде, нинди зур хата ясый язганмын бит».

1940 ел. Скрипач Вульфман үзе Зоряны Үзәк музыка мәктәбенең хәзерләүләр курсына имтиханга алып килде. Иң сәләтле балалар гына кабул ителә торган бу мәктәпкә әлегү Зоря өчен кетелгән куанычларның беренчесе иде. Менә хәзер ул музыка дөньясына килеп керде һәм аның бормалы, текә баскычларыннан, берәмләп-берәмләп, атлый да башлады кебек. Шахморзаева фамилияле кыз бала класста иң тәртипле, иң тырыш укучыларның берсе булып китте. Бер генә дәрес тә әрәм булмады, бер генә көн дә югалмады. Ул укыды, тыңлады, өйрәнде: ритмиканың серенә төшенде һәм, нәни беләкләре талганчы, уйнады да уйнады... Кыз беренче класска бары тик отлично билгеләре белән генә күчте. Тик җәен сугыш башланды, музыка мәктәбе көнчыгышкарак күчеп китте һәм, нәкъ ике елдан соң, 1943 елда гына яңадан башкалага әйләнеп кайтты.

Зоря бу юлы күренекле педагог һәм музыкант Каюм Байбуров классына чабул ителде. Яраткан эше, якты максатлары белән чын күңеленнән мавыккан кеше өчен вакыт судан да йөгерек. Зоря әнә шул кадерле минутларның кадерен белеп үсте. Ул китапханәдә утырырга да, театр карарга да, концерт тыңларга да өлгерде. Өстәвенә ничәләп түгәрәккә язылды, барысына да йөрде һәм һәрберсеннән үзенә тиешле белем, күнекмә, гыйбрәт алды, рух җыйды. Әмма арада иң кадерлесе, иң якыны скрипкасы булды һәм ул беркайчан да аның кулыннан төшмәде, тәнәнмәс шатлыгына, сөекле хезмәтенә әйләнде, анын моңнары, кызыйга гүя туачак таңнарның матурлыгын, аһәңлеген сөйли иделәр. Зоря дөнья композиторлары, атаклы музыкантлар белән танышты. Вивальди, Холендро, Берио, Виотти иҗатын өйрәнде. Алардан соң Моцарт, Сен-Санс, Бетховен, Мендельсон, Паганинига күчте. Скрипка техникасына төшенә барган саен, мелодияләрне тәэсирләнеброк тыңларга, бөек композиторлар иҗат иткән әсәрләрнең кабатланмас гүзәллеген тирәнрәк аңларга өйрәнә барды.

Менә шул тыңгысыз, җанлы, дәртле, омтылышлы уку елларына имтихан тотар чак җитте. Ул, бөтен дөньясын онытып, тәэсирләнеп, Паганини концертын башкарды. Ә үзе гел уйланды: тиешенчә уйный алдыммы икән? Укытучым ни генә әйтер икән?..

Каюм Байбуров, каушап калган кызны коридорда туктатты һәм, аның дулкынланудан кызарган йөзенә, оялган күзләренә карап, шундый үз итеп елмайды:

— Молодец,— диде педагог укучысына,— болай булгач, консерватория ишекләре ачык сиңа.

Студент еллары... Совет скрипка мәктәбен тудыручыларның берсе, сәнгать йолдызлары Леонид Коган, Игорь Безродный, Эдуард Грач, Юлиан Ситковецкий, Марк Лубоцкийларны тәрбияләгән атаклы профессор Абрам Ямпольскийның шәкерте булу үзе ни тора! Баштарак кыз моңа ышанмады да. Ул тартынды, кыюсызланды.

Бәхеткә каршы, Абрам Ильич искиткеч гади табигатьле, киң күңелле һәм назакәтле кеше булып чыкты. Зоря үзенең педагогына шул кадәр тиз ияләнде, ул аны шул кадәр ихтирам итте, аның барлык сыйфатларын отарга, аныңча эшләргә, аныңча яшәргә тырышты.

Музыкантлар Ямпольский скрипканың ниндидер яшерен серләрен белә дип сөйлиләр иде. Зоряның әнә шул серләрне чишәсе, шуларга ия буласы килде. Ләкин, озак та үтмәде, ул төшенде, яшерен сере дә, күренмәс могҗизасы да юк икән бу остазның. Абрам Ильич үз шәкертләрен бары тик осталыкка, музыка телен аңларга өйрәтә. Аның иң зур сәләте тагын шунда: ул яшь музыкантны, ниндидер сихри көч белән, рухландыра, һәркемне үз юлын, үз моңын эзләргә ышандыра, ялкынланып иҗат итәргә ашкындыра белә.

Зоря атнага бер тапкыр Горький урамына чыга, атаклы музыкантның квартирасы шул якта. Ул өметле шәкертләрен өенә чакыра иде. Яшь музыкант өчен Абрам Ильич белән һәр очрашу үзе бер тантана, онытылмас истәлек була барды. Ә бер шомлы иртә йөрәк тетрәткеч хәсрәт хәбәре китерде: Абрам Ямпольский юк инде...

Йокысыз төннәр, тынгысыз көннәр сизелмиләр. Зоря тик отлично билгеләренә генә институтны тәмамлады.

Һәр талпынышның үз биеклеге, һәм һәр биеклекнең үз омтылышы була. Беренче талпыныш ясалды, беренче биеклек алынды, ә алда... Авыр һәм мактаулы бурычлар. Ул хәзер совет сәнгатен пропагандалаучы, музыкаль культура байлыгын халыкка илтүче, аның рухи халәтен баетучы. Менә кем булды хәзер Зоря Шахморзаева!

Нинди истәлекле, нинди бәхетле җәй булды әле бу шомырт чәчле, уйчан кара күзле Мәскәү кызы өчен! Башкалага дөньяның әллә никадәр илләреннән төрле телләрдә сөйләшүче күп милләт вәкилләре җыйналдылар. Яшьләрнең һәм студентларның алтынчы Бөтендөнья фестивале Зоряны лауреат итте. Скрипкачылар конкурсында алтын медаль алды ул.

Союзлар йортының Октябрь залы ак, кара, сары тәнле яшьләр белән тулы иде ул көнне. Дуслык миссиясе белән килгән яшьләр арасында танылган музыкантлар да күп. Зоряга иң зур бәяне әнә шулар бирде.

аның башкару осталыгын, талантын әнә шулар таныды. Йомгаклау концертына скрипач үзенең иң яраткан композиторларыннан берсе — Прокофьев мелодияләрен сайлады. Һәр фразада, һәр эпизодта, һәр бүлекчәдә ул зур композитор әсәрләрендәге гүзәллекне, нәфисләкне тыңлаучыларга җиткерергә тырышты һәм теләгенә иреште.

Ләкин яшь артистка өчен иҗади ярышның иң авыры, иң катлаулысы һәм иң мактаулысы әле алда иде. П. И. Чайковский исемендәге беренче халыкара конкурс үз тирәсенә дөньяның атаклы музыкантларын җыйды. Алар фикеренчә, бу конкурс көчләләр ярышы гына түгел, башкаручыларның сәнгатьчә осталыгын дөнья күләмендә улчәү дә иде. Башка скрипачлар белән бергә, Зоря биредә зур һәм җаваплы имтихан тотарга, совет скрипка мәктәбенең данын акларга тиеш иде. Бу беренчедән. Ә икенчедән, бу конкурста катнашуның Зоря өчен тагын бер кадерле ягы бар. Чайковский музыкасы кызны мәктәп эскәмиясеннән алып шушы көнгә кадәр тәрбия иткән сихри моң, канатландыргыч көчле аһәң булды. Ә менә хәзер, бөек рус композиторының үз исемендәге конкурста катнашу бәхетенә ирешү һәм аның әсәрләре белән чыгу артистка өчен гаҗәп зур бәйрәмгә әйләнде. Конкурста Шахморзаева сигезенче урынны яулады, лауреат исеме алды. Шул жюрида катнашкан америкалы Ефим Цимбалист, берничә елдан яңадан Мәскәүгә килеп чыккач, совет скрипачына карата күңелендә йөрткән матур тойгыларын теләп әйтеп китте: «Зоря Шахморзаеваны мин бик ихтирам итәм, — диде ул, — кыз бик талантлы һәм аны киләчәктә зур артистлык карьерасы көтәчәгенә һич шигем юк».

Маэстр Цимбалист хаклы булды. Конкурстан соң Зоряның исеме дөнья матбугатын шаулатты, эфирны тибрәтте. Аны илебез шәһәрләре генә түгел, чит илләргә чакырдылар. Ул Балтыйкны буйлады. Закавказьеда уйнады, Уралга килде, Белоруссияне иңләде, Урта Азиягә барып кайтты.

Ә туган каласы Казанга ул гастрольгә дип түгел, үз итеп, кунак булып килә. Һәм шуны да әйтергә кирәк: Зоря, гомере буе Мәскәүдә яшәсә дә, казанлылар аны үз кызлары итәләр, сагынып каршылыйлар, чакырып озаталар. Зоря татар композиторлары әсәрләрен бик яратып башкара. Ул аларның моңын, милли колоритын, бөтен матурлыгын саклап, тәэсирләнеп уйный. Монасыйпов, Мозаффаров, Яруллин әсәрләре артистның иҗатына аерым нур өстиләр, баеталар, тулыландыралар.

Зоря Шахморзаеваның исеме илебез чикләреннән тышта да яхшы таныш, аңа кул чапмаган ил юк, дияргә була. Аны Норвегия һәм Дания, Австрия һәм Италия, Польша һәм Болгария, Чехословакия һәм ГДР, Румыния һәм Югославия алкышлады. Маргарита Лонг һәм Жака Тибо исемендәге Париж конкурсында лауреат булды, Брюссельдә үткән Королева Елизавета исемендәге конкурста дүртенче урынны алды ул. Чит ил журналлары, газеталары ул елларны Зоряның рәсемнәре һәм аңа багышланган репортажлар белән тулы иде.

Талантлы Шахморзаева иҗаты турында күренекле сәнгать белгечләре күп мактау сүзләре әйттеләр: «Олы художникларча елгергәнлек», «Тумыштан килгән талант», «Тирәнлек, нәфис лиризм, сиземлек балкып торган тормышчанлык хас» диләр аның уенына.

Шулай да скрипач иҗатындагы төп үзенчәлек, аны сәхнәгә менгергән, зур сәнгать дөньясына чыгарган көч нәрсәдә соң? Моңа җавапны «Известия» газетасы бирде:

«...Ул шаккатырырга тырышып, көчәнеп уйнамый. Аның уены тамашачыны үзенең гадилеге, самимилеге, лиризмы белән, ялган артистизм элементларыннан азат булуы белән җәлеп итә...»

Дөнья шаулаткан уңышлардан, матбугат битләрендә мактаулардан соң, бераү максатыма ирештем, тиешле дәрәҗәмне алдым, дип тынычланыр, ял итәр, үз уңышларыннан үзе хозурланып яши белер иде. Ә Зоря андый түгел, ул үзенең иҗатына башкача карый, аның һәрчак янарып, тулыланып, яшәреп, баеп торуын тели. Аның элек укыган институтына яңадан әйләнеп кайтуын да шуның өчен дип уйларга кирәк. Профессор Дмитрий Михайлович Цыганов җитәкчелегендә аспирантурада узган дүрт ел Зоряны тагын да үстерде, баетты. Ул хәзер сәхнә йолдызы гына түгел, илебез ВУЗларының иң күренеклесе — үзен кеше иткән Мәскәү дәүләт консерваториясенең укытучысы да. Шулай да скрипач өчен иң әһәмитле, иң кадерле һәм иң мөһиме концерт — тамашачылар белән очрашу. Аның теләге, максаты — кешеләргә музыканың бөеклеген, гүзәллеген аңлату, ышандыру, аларны шатландыру.

Мин моңа, бигрәк тә, күптән түгел скрипачның консерваториянең кече залында биргән концертыннан соң инандым. Ул Шостаковичның Ун прелюдиясен уйнады. Никадәр тасвир байлыгы... Никадәр музыкага тирән үтемлек... Никадәр образлар төрлелеге... Шостакович әсәрләре белән шундый зур аудиториядә аның беренче мәртәбә чыгуы түгел иде, әлбәттә. Ләкин ул бу юлы композиторның бетмәс-төкәнмәс музыкаль байлыгын яңадан ачты шикелле... Мин яшь скрипачны тын алмый тыңлыйм һәм үземдә туа барган шатлык тойгыларын сизәм. Чу... Бәлки мин генә шулай тәэсирләнмимдер, мин генә шулай тыңлыймдыр... сакланып кына, кешеләрне концерттан алган сөенечле хисләреннән айнытмыйм дип кенә, як-ягыма карыйм. Барысында да үз кичерешемне сизәм, үз шатлыгымны тоям. Барысын да Шостакович музыкасы сихерләгән... Ә бит менә шушы матурлык, гүзәллек атмосферасы кешеләрне никадәр сөйнемләндерә, шәфкатьләндерә, ягымлыландыра... Атаклы скрипач Зариус Шахморзаева талантының бөтен гүзәллеге, көче менә шунда да инде.

Ә ул уйный да уйный... Кулындагы инструментка үзенең рухын, бай хисләрен кушкач, нинди тылсымлы көчкә әверелүен үзе сизә микән ул...

— — □ — —

# *Әдәбият теориясе мәсьәләләре*

*Гали Халит*

## РОМАНТИЗМНЫ ҺӘМ РЕАЛИЗМНЫ ЯКЛАП

*(Иҗат методларының үзара мөнәсәбәтенә карата)*

Соңгы елларда совет әдәбияты фәнендә төрле иҗат методларын һәм аларга нисбәтән әдәби стильләрне бәяләү ноктасыннан бик әһәмиятле эзләнүләр алып барыла һәм бәхәсләр үткәрелә. Ул бәхәс һәм эзләнүләр фәкать тар теоретик максатларны гына күздә тотмыйлар. Прогрессив һәм реакцион көчләрнең дөнья күләмендә барган көрәше яктылыгына куеп караганда, аларның реаль мәгънәсе, эчтәлеге хәзерге чорда аерата ачык төс ала: заман сәнгате ничек булырга һәм нинди юлдан барырга тиешлеге мәсьәләсе турыдан-туры кеше рухы өчен көрәшкә бәйләнгән. Шуңа күрә реакцион көчләр, гомумән реализмны һәм аңа якын торган, теләктәш булган сәнгать методларын, агым һәм юнәлешләрен кире кагып, түбәнсетеп, кешене чынбарлыктан, көрәштән аера, ераклаштыра торган модернизмны, декадентлыкны, формализмны, абстракционизмны яклыйлар, азындыралар. Тормышның турыдан-туры күзенә карап хөкем итүче реализмнан да, кешенең азатлыкка, матурлыкка омтылуына һәм киләчәк өчен көрәшенә дан җырлаучы романтизмнан да алар куркалар. Чөнки сәнгатьнең мондый формалары явызлык белән килешә алмыйлар. Реакцион көчләр, икенче яктан, мәсәлән, романтизмны үзләренә хезмәт иттерергә һәм реализмга каршы куярга да телиләр. Ә алдынгы көчләр исә романтизмда гуманизм һәм азатлык өчен көрәш коралы күрәләр, аны реализмның аерылмас юлдашы дип саныйлар. Шул рәвешчә, иҗат методы мәсьәләсе ниндидер абстракт бер төшенчә генә түгел, ә бик конкрет, тормышчан максатларга бәйле күренеш икән.

Иҗат методы берничә сүз белән генә билгеләнә торган формула түгел. Гомумәнрәк алганда, аның төп мәгънәсе — тормышны сәнгатьчә танып белү һәм сурәтләрдә чагылдыру принципларының системасына, бөтенлегенә кайтып кала. Әмма ул принципларның тарихи җирлектә барлыкка килүләрен һәм һәр чорда, һәр язучының иҗат практикасында үзгәреп, баеп торуларын искә алырга кирәк. Шуңа күрә барлык иҗат методларының да төп билгеләрен үзендә туплаган бөтен бер төшенчә, билгеләмә бирү кыен. Моңа кадәр бу юнәлештә ясалган тәҗрибәләр бик үк уңышлы булып чыкмадылар.

Иҗат методлары, әдәби юнәлешләр, агымнар һәм стильләр мәгълүм тарихи чорларда барлыкка киләләр һәм бер-берсен эзлекле рәвештә алмаштыралар яки инкарь итәләр. Бер иҗат методының яки әдәби юнәлеш һәм стильнең икенчесен алмаштыруы, җитлегүе үзара тирән бәйләнеш җирлегендә генә мәйданга килә ала. Бу бәйләнеш күп төрле һәм аның тарихи чикләре бик киң булырга мөмкин. Ул иң элек тарихи барышның сәнгатькә ясаган тәэсире никадәр тиз яки акрын, никадәр көчле, интенсив булуы белән билгеләнә. Ә икенче яктан, сәнгать традицияләренең әле, үз эчке законнары белән, бик борынгыдан ук, чордан чорга күчеп килүләре дә бар. Шунсыз сәнгатьнең өзлексез үсү, бер баскычтан икенчесенә күтәрелү тарихы да булмас иде.

Бигрәк тә безгә якын чорларда формалашкан романтизм, критик реализм һәм социалистик реализм кебек иҗат методларының тарихи җирлеген, үзенчәлеген һәм

үзара бәйләнешләрен бәяләү тирәсендә кызып киткән бәхәсләр әдәбият фәненең, әдәбият тарихының һәм бүгенге әдәби хәрәкәтнең күп төрле әһәмиятле, актуаль мәсьәләләрен көн тәртибенә куялар. Реализм һәм романтизм кайчаннан башлап мөстәкыйльлек алганнар, аларны бер-берсеннән аерган яки уртак иткән сыйфатлар нидән гыйбарәт? — кебек сораулар күпләрне борчый.

Романтизм — социалистик реализмның бер стиль күренеше генәме, әллә ул аның белән бергә үк яшәүче мөстәкыйль методмы яки әдәби агыммы? Бу сорауга җаваплар төрлечәрәк әле. Кайберәүләр совет әдәбиятындагы романтизмның ролен инкарь итүгә һәм кечерәйтеп күрсәтүгә каршы чыгалар. Алар фикеренчә, совет әдәбиятында романтизм хәтта аерым метод итеп тә саналырга хаклы. Шулай ук социалистик реализм белән романтизм арасында үтеп чыга алмаслык киртәләр дә юк. Алар бербересенә бәйләнгәннәр. Безнең әдәбиятта, кырыс реализм белән бергә үк, күтәренке романтизм да яши, һәм алар арасында бик күп уртаклык бар, диләр.

Бу мәкаләдә без әлеге темага бәйле мәсьәләләрнең әһәмиятле якларын тулысынча күзәтүне һич тә максат итмәдек. Фәкать шуларның кайберләренә генә игътибар итү белән чикләнеп, боларның татар совет әдәбияты тарихына, аерым алганда егерменче еллар әдәбиятына бәйләнештә кайбер фикерләр кузгатырга телибез.

## I

Мәгълүм ки, безнең күп кенә милли әдәбиятларыбыз социалистик революцияне төрле дәрәҗәдәге әдәби байлык, традицияләр белән каршыладылар. Болар арасында, социалистик реализм юлына чыга башлаганнары булган шикелле (руста М. Горький иҗаты), хәтта халык әдәбиятыннан узмаганнары да бар иде. Бездә социалистик әдәбиятның кайбер яралгылары барлыкка килсә дә (Г. Коләхметов иҗаты, революцион поэзия үрнәкләре), алар әле бөтен бер әдәби юнәлеш булып җитлегә алмадылар. Әмма моны берьяклы аңламаска кирәк. Безнең гасыр башындагы гомуми демократик хәрәкәтләрне пролетариатның революцион көрәшеннән аерып аңлау мөмкин булмаган шикелле, критик реализм әдәбиятын да үсеп барган пролетариат идеологиясенә һәм әдәбиятына бәйләнешсез итеп карарга ярамый.

Һичшиксез, социалистик революция булу белән яңа тип әдәбият формалаша, өстенлек ала барды. Аның беренче төп сыйфаты — чынбарлыкның, тарихның зур революцион борылышын һәм киң халык массаларының аңында, настроениеләрендә барлыкка килгән тирән үзгәрешне гәүдәләндерү булды.

Революция халык белән сәнгать арасында торган киртәләрне алып ташлау белән үк, демократик әдәбиятның халыкка бәйләнгән тамырлары тагын да ныграк тибә башлады. Халык азатлыгы аларга яңа тереклек бирде. Халык һәм тарих каршында үзен тулысы белән бурычлы санаган язучыкөрәшче дә кинәттән генә килеп чыкмады. Әгәр дә 13—14 яшендә үк инде Муса Җәлил:

**Яшим халкым өчен, көчләр табам мин,**
**Халык өчен һаман алга барам мин,**
**Минем гомерем төгәлләнер шуның чөн,**
**Күмелсәм дә бу юлда, бер дә янмыйм!**
**Халык хакыны хаклап, җыр язам мин!**
**Бизеп, күңелемне алмыйм дөньядан**
**мин! —**

дигән икән, бу уй-тойгыларның Тукай һәм Бабичлар поэзиясе белән турыдан-туры һәм тирән бәйләнеше барлыгын тою һич кыен түгел. Киресенчә, аларның традицияләре тагын да кабынып, үсеп һәм киң колач алып китәләр: шигъри шәхеснең, шагыйрьнең халык көрәше һәм азатлыгы белән тәмам кушылуыннан туган оптимизм, шатлык һәм батырлык идеясе тулы тавыш белән яңгырый. Яңа чор биргән беренче яңалык та менә шунда иде.

Безнең әдәбият фәне революция башындагы поэзиядә яңа идеяләрне иске, традицион формада җырлау турында күп язды һәм яза тора. Бу, әлбәттә, дөрес фикер. Әмма бу күренешнең әдәбият үсеше өчен яңалыгы нидән гыйбарәт? «Милли әдәбиятларда,— ди К. Зелинский,— политик теманы иҗади, художестволы үзләштерү — социалистик реализмның аякка басуында беренче баскыч булды дип әйтергә мөмкин». («Дружба народов» журналы, 1965, 4 сан, 244 бит.) «Политиканың әдәбиятка турыдан-туры бәреп керүе» — аңа яңа идеяләрнең, зур иҗтимагый ташкыннарның бәреп керүе иде. Бу чорда күтәрелеп киткән агитацион поэзия дә шул процесс ихтыяҗы белән мәйданга килде. Шуңа күрә бу хәл искенең яңа эчтәлек алуы гына түгел, ә яңа эстетик башлангыч та. Шул башлангычның бер көчле сый-

фаты буларак, агитацион-риторик стиль чәчәк атты һәм шул чорның романтик пафосын, революцион ашкынуларын гәүдәләндереп калдырды.

Моның белән бергә үк традицион-романтик стиль дә дәвам итте һәм хәтта нык кына үзгәрде дә. Революцион чынбарлык аның яңаруына этәргеч бирде. Бигрәк тә эпик поэзия жанрында кайбер кызыклы гына үзгәрешләр сизелде: бу традицион-романтик жанрга тарихи сюжет рухы килеп керде. Хәзер инде сүз гомумән геройларның көрәше һәм язмышы турында гына түгел, ә билгеле бер чордагы — совет иленең азатлыгы өчен барган революцион сугыш чорындагы геройлар, аларның көрәше һәм язмышы турында бара иде. Ф. Бурнаш поэмалары — шуның тулы һәм конкрет мисаллары.

Совет әдәбиятының башлангыч чорында иҗат ителгән әсәрләргә революцияне эмоциональ кичереш җирлегендә аңлау бик характерлы иде, дигән караш урнашкан. Татар әдәбиятында да ул тулысынча күренде. Нәкъ шул эмоциональ кичерештә яңа романтик башлангыч ята иде. Аның чыганагы — революцион батырлык идеалы. һәм традицион, һәм яңа романтик катламнарны шул идеал сугарды. Шулай итеп, татар совет әдәбиятына тирән булып революцион романтизм рухы үтеп керде.

Элекке әдәбиятта критик реализм да, прогрессив романтизм да, явызлыкны фаш итеп, аңа үзләренең уңай идеалларын каршы куйдылар. Мәсьәләнең тамыры аларның ул явызлыкны нинди сыйнфый-идеологик позициядән фаш итүләрендә һәм уңай идеалларның ничек булуларында гына түгел, ә алар арасындагы сәнгатьчә аермаларда, ягъни чынбарлыкка эстетик мөнәсәбәтләрнең, эстетик позицияләрнең башка-башка булуында. Әлбәттә, боларның берсе дә билгеле чорның тарихи һәм сыйнфый-идеологик шартларыннан тыш тегәл һәм дөрес бәяләнә алмый. Гомумәнрәк алганда, романтикның реалисттан аермасын түбәндәге моментта ачыграк күрергә мөмкин: «Романтиклар үз вакытындагы иҗтимагый мөнәсәбәтләрне кабул итмиләр, үзләрен әйләндереп алган чынбарлык тышында ятучы идеалга омтылалар» (Н. Гуляев. Романтизм теориясендәге бәхәсле нәрсәләр турында. «Русская литература» журналы, 1966, 1 сан, 75 бит).

Ә совет әдәбиятында революцион романтизм мондый төстә була алмый иде инде, чөнки эстетик идеал белән чынбарлык мөнәсәбәтендә әһәмиятле үзгәрешләр барлыкка килде: революция алдынгы иҗтимагый һәм шәхси омтылышларның гармониясенә, уртаклыгына юл ачты. Ул омтылышлар һичвакыт булмаганча тыгыз бәйләнешкә керделәр. Әмма моңардан һич тә сәнгать белән чынбарлык арасындагы каршылык та бетте, дигән нәтиҗә чыгарылырга тиеш түгел. Эстетик идеал белән чынбарлык арасындагы каршылыктан башка, гомумән, сәнгатьне күз алдына китерү кыен. Мәсьәләнең төп мәгънәсе — тарихи барышка нисбәтән ул каршылыкның табигате үзгәрүдә, сәнгать законнарының һәм эстетик идеалның тормышка мөнәсәбәте ничек булуда. Әмма шунысын да истән чыгармаска кирәк: һәр очракта да эстетик идеал тормышның алдыннан баруны, аңа билгеле бер йогынты ясауны, хәтта аны үзгәртүне һәм кешене үз теләгенчә тәрбияләүне максат итеп куя. Шуңа күрә, безнең сәнгатьтә хыял белән чынбарлык арасындагы аерма бетә, дигән карашны яклап булмый. Идеалларның чынлыкка әйләнә баруы әле аларның бетүе хакында сөйләми. Тарих яңа идеалларны тудыра, алар алга, ирешелгән максатлардан тагын да югарырак күтәрелергә чакыралар. Менә шундый хәл безнең сәнгатьтәге эстетик идеалның да бер романтик табигатен билгели. Шулай булгач, алга ашкынган һәрбер революцион һәм прогрессив сәнгатьтә әнә шул рухтагы романтик башлангычларның булуы бик табигый.

Октябрьга кадәр үк инде А. М. Горький кеше табигатендәге матур яралгы һәм сыйфатларны кабарынкырак, калкурак итеп күрсәтергә чакырган иде. Монда, һичшиксез, романтик идеализацияне яңача, башка максатлардан чыгып аңлау ятты. Бу чорда алдынгы сәнгатьнең бурычы — кешене уяту, аның үз көченә ышанычын арттыру максаты белән тыгыз бәйле булганлыктан, Горький күтәргән герой концепциясе дә, беренче нәүбәттә, әнә шуны күз алдында тотты. Кешене гадәттәгедән матуррак, көчлерәк һәм акыллырак итеп күрсәтү буржуаз җәмгыятьнең кешене изүенә, кимсетүенә һәм декадентларның аны фәкать ике аяклы «кәҗә тәкәсе» итеп карауларына каршы куелды. Әмма революция булганнан соң инде бу концепция искереп, үз бурычын үтәп, төшеп калырга тиеш идеме?

1919 елда А. М. Горький үзенең «Кыен мәсьәлә» дигән бер мәкаләсендә болай дигән иде: «Чама белән менә шундый җавап дөрес булыр дип җөрьәт итәм: безнең

заманда героик театр, үзенең максаты итеп шәхесне идеаллаштырган һәм романтизмны яңадан тудырган, кешене шигъри итеп бизәгән театр кирәк» («Горький сәнгать турында». М.-Л., 1940, 176 бит). Бу фикерләрне бәхәс кылучылар да бар. Горькийның романтик концепциясе бу чорда берьяклырак күренде, диләр алар. Әмма, безнең фикеребезчә, бөек язучы бу урында бик әһәмиятле бер максатны күз алдында тотты: революция уяткан һәм азат иткән, ләкин үз тарихи батырлыгының матурлыгын, үз иҗади миссиясен, бурычын аңлап җитмәгән кешегә хәзер сәнгатьнең тәрбияви йогынтысы тагын да активрак, кыюрак булырга тиеш, дигән таләпне куйды ул. Шуңа күрә дә, Горький уенча, кешене югарырак күтәреп, идеаллаштырып, күпләргә үрнәк булырлык итеп күрсәткән героик романтизм революция чоры сәнгатенә бик тә кирәкле һәм тапкыр.

Романтик геройның гадәттән тыш һәм югары сыйфатлар белән сурәтләнүе бер очракта аның сайланма шәхес, нииндидер идеалларга ия булуын һәм яшәмәктәге чынбарлыкка каршы торуын, ә икенче очракта үз сыйныфының әһәмиятле, типик сыйфатларын көчле һәм калку итеп чагылдырган вәкилен күрсәтергә мөмкин. Соңгысы — зур революцион ихтыярга ия булган һәм эре сызыклар белән күрсәтелгән герой. Шикләнмичә әйтергә мөмкин: социалистик революциянең башында ук татар поэзиясендә һәм драматургиясендә нәкъ шундый романтик герой мактаулы урынны алды. Шул ук вакытта ул туры мәгънәсендәге политик герой да иде. Шушы момент үзе генә дә татар совет әдәбиятындагы революцион яңаруның никадәр тирәннән башлануын һәм социалистик реализмның иң әһәмиятле яралгылары шытып чыгуын күрсәтә алыр дип уйлыйбыз. Егерменче еллар дәвамында татар язучыларының игътибарын җәлеп иткән герой проблемасы моны тулысынча раслады һәм яңа иҗат методының формалашуы, барыннан да элек, заман героеннан, яңача аңланган кеше концепциясеннән башка мөмкин түгеллеген күрсәтте[1].

Революциянең беренче елларындагы поэзияне бәяләгәндә, аның абстракт һәм риторик булуына басым ясау гадәткә кереп киткән. Әмма бездә моның ни өчен шулай булуын аңлатудан бигрәк, кимсетү мәгънәсендәрәк сөйләү ешрак очрый. Дөньяны сәнгатьчә сиземләүнең абстрактлыгы язучыларның шәхси, субъектив теләк һәм омтылышларыннан түгел, ә объектив иҗтимагый сәбәпләрдән килеп чыкты. Революцион яңарыш һәм үзгәрешләрнең зурлыгы, колачы, уй-тойгыларны әсир итеп, җирдәге башка вак нәрсәләрне читкә этәреп, игътибарны үзенә тартты. Тарихның һәм кешенең коллыктан азат ителү шатлыгы тудырган гомуми пафос дөньяны шигъри сиземләүдә дә өстенлек алды.

Соңгы елларда рус совет әдәбиятының беренче дәверендә зур гына роль уйнаган Пролеткульт романтизмын бәяләүдә дә элекке берьяклы карашлардан арынырга омтылыш ачык күренде. Пролеткульт әдәбияты сәнгатьтә революция темасын үзләштерү, революция пафосын чагылдыру юлындагы әдәби агымнарның киң таралганы һәм күренеклесе иде. Ул үз заманының революцион настроение һәм ашкынуларын кискен, кабарынкы итеп, гиперболик сурәтләрдә гәүдәләндереп калдырды. Бу мәгънәдә ул — үтәдән-үтә романтик күренеш.

Әмма Пролеткульт поэзиясен Октябрьдан соңгы әдәбиятның законлы бер баласы дип санау белән бергә, кайбер әдәбиятчылар икенче читкә дә киттеләр: Пролеткультның тарихи акланып бетми торган һәм тормыш белән бәйләнмәгән якларын күрми башлыйлар. Ә бит Пролеткульт романтизмының үзәгендә торган космизм аның төп эстетик доктринасы булды. Ахыр чиктә космизм тормыштан ерак торуны күрсәтте. Яңа чынбарлыкның матурлыгы әллә кайда, космослар дөньясында түгел, ә җирдәге көрәш эчендә иде. Барлык нәрсәгә космик югарылыктан караган Пролеткульт сәнгате, әлбәттә, чынбарлыкның алдыннан барып, кешене алга чакырган реаль сәләткә ия булып җитә алмады.

Безнең әдәбиятта туры һәм тулы мәгънәсендә пролеткультчылык хәрәкәте булмады. Әмма егерменче еллар башында аның йогынтысы көчле генә сизелеп калды. Аеруча гыйсъянчылык романтизмында ул йогынтының эзләрен күрергә мөмкин. Гыйсъянчылык, барыннан да элек, татар әдәбиятының билгеле бер традицияләренә, аның милли җирлегенә нык тоташкан. Ул безнең классик әдәбиятның демократик идеяләрен һәм романтик традицияләрен революция шартларында үстереп алып кит-

---

[1] Бу мәсьәләгә карата аерым беренчә мәкалә бастырган идек. Кызыксынган укучылар шуларга мөрәҗәгать итәргә мөмкин: «Тормышчан батырлык һәм сәнгатьчә матурлык сере» («Совет әдәбияты», 1963, 8 сан). «Яңа герой ничек туды» («Казан утлары», 1965, 7 сан) — Г. Х.

те. Ә бу процесс революция белән калкып чыккан әдәби хәрәкәтләр җирлегендә һәм йогынтысында тагын да катлауланды. Әйткәнебезчә, монда пролеткультчылыкның һәм аңа бәйләнгән «Кузница» поэзиясенең дә роле бар иде. Хәзер инде гыйсъянчылыкны элекке кебек гел кире мәгънәсендә бәяләүдән алгарак киттек шикелле. Аны егерменче еллар әдәбиятына хас революцион романтизм күренеше итеп аңларга теләү сизелә. Һәм шушы юнәлештә өйрәнү нәтиҗәле булыр дигән ышаныч та көчлерәк кебек.

Егерменче еллар тәнкыйте, элекке мирас белән совет әдәбияты арасындагы сыйнфый-идеологик аерманы кытай стенасына әйләндереп, ике чор әдәбиятын нигезеннән бер-берсенә каршы куйды. Иҗат методын билгеләү мәсьәләсендә дә элек «буржуаз реализм» һәм «идеалистик романтизм», ә совет әдәбиятында «пролетар реализм» гына өстенлек итә, дигән карашлар урын алды. Шуңа күрә революциягә кадәр иҗат итә башлаган һәм аннан соң совет әдәбиятының нигезен салышкан Г. Ибраһимов, М. Гафури, Ш. Камал, Г. Камал, К. Тинчурин, Ф. Бурнаш һәм Һ. Такташлар пролетар әдәбият, пролетар реализм лагерена кертелмәделәр, ә формализм белән мавыккан яки революциядән соң каләм алган яшьләр генә яңа революцион әдәбиятның нигезен салучылар рәвешендә тәкъдим ителделәр. Чынбарлык исә моның киресен күрсәтә: иң беренче нәүбәттә әнә шул олы буын язучылар, элекке әдәбиятның халыкчан реалистик һәм романтик традицияләрен дәвам иттереп, тагын да үстереп, яңа әдәбиятны тудыручылар булып чыктылар. Г. Ибраһимов белән М. Гафуриның егерменче еллар дәвамындагы әдәби эшчәнлекләре үзләре генә дә моны тулысы белән раслый ала. Хәзер инде бу хакта бәхәс алып бару көлке бер нәрсә генә булыр иде. Шулай ук новаторлыкны үз кулына алырга, пролетар әдәбиятка гегемон булырга маташкан формализмның да заман чире, тарих чүбе булып калуы шиксез.

Егерменче еллардагы татар әдәбияты безгә шул хакта сөйли: яңа методның формалашуы вульгар социологизм тәкъдим иткән рецептлар һәм сукмаклар буенча бармады. Чынбарлыкның каршылыклары һәм яшь совет әдәбияты кабул иткән идея-эстетик традицияләрнең катлаулылыгы эченнән яңа метод үзенә юл сала башлады. Яңа, социалистик җәмгыять ихтыяҗларына җавап бирә торган сәнгать методының язмышы көрәштә сыналды. Әмма җиңүне, өстенлекне тәэмин итү өчен, аңа әле беттәргә, төшеп калырга тиешле традицияләрдән бик нык арынырга һәм башка әдәби агымнарның, юнәлешләрнең уңышларыннан да тиешле өлешне, тәҗрибәне алырга кирәк иде. Әнә шул процесста бигрәк тә романтизм әһәмиятле урын тотты. Ул үзен реализмнан һичбер вакыт аерылырга теләмәгән ышанычлы юлдаш итеп танытты.

Әйткәнебезчә, егерменче еллар татар совет әдәбиятындагы романтизм революциягә кадәр һәм аннан соң барлыкка килгән берничә катламнан гыйбарәт иде. Революцион чынбарлык, элекке романтик традицияләрнең уңай һәм кире якларын ничек итеп бер-берсеннән аера барып, аларның кирәклеләрен үз чорына лаеклы сәнгать хәзинәсе алды? Яңа романтик катламнар ничек барлыкка килде? Ниһаять, социалистик реализм җирлегендә революцион романтизм нинди үзгәрешләр кичерде һәм кичерә, ул нинди формаларда чагыла? Болар һәммәсе — нечкәләп өйрәнүне көтеп кала торган мөһим мәсьәләләр.

## 2

Реализм белән романтизм арасындагы мөнәсәбәтне, үткән чорларга карата гына түгел, совет әдәбиятына карата да «романтизмнан — реализмга» формуласы белән хәл итү мөмкин түгеллеге әдәбият белгечләрен бик тә борчый. Соңгы вакытларда бу формулага догматик нәрсә итеп карау бер дә гаҗәп түгел. Совет әдәбиятларында романтизмнан реализмга күчеш барды, дигән берьяклырак караш киң таралган иде. Янәсе, романтизм совет әдәбиятларының балачагына хас булса, реализм исә аның җитлегүен, тагын да югарырак дәрәҗәгә күтәрелүен күрсәтә. Тыштан караганда, моның дөрес булуын инкарь итү кыен. Әмма безнең әдәбиятларның үсеш тарихы бу формулага сыя алмаганлыгы шулай ук яшерен түгел. Әйтик, украин совет әдәбиятының буеннан-буена романтизм кызыл җеп булып сузылып килүен дәгъва кылуларны һич тә нигезсез дип булмый. Моңа мисал итеп Ю. Яновский һәм А. Довженко кебек романтикларны гына искә алу да җитә. Яки әзербайҗан әдәбиятыннан С. Вургун поэзиясен, ә бездән Һ. Такташ, М. Җәлил һәм Ф. Кәрим поэзияләрен генә алып карагыз. Аларны романтизмнан аерып алу һәм «саф реалистлар» дип кенә карау мөмкинме икән? Мондый фактлар совет

әдәбиятларында романтизмның бик актив төстә яшәве турында сөйләмиләрме икән? Әллә болар — фәкать индивидуаль стиль күренешләре генәме?

Башка әдәби агым, юнәлеш һәм методлар шикелле үк, романтизм да — һаман хәрәкәттә һәм үзгәрештә булган эстетик күренеш. Дөрес, билгеле бер чорларга гына хас иҗат методлары һәм әдәби юнәлешләр белән чагыштырганда, романтизмның барлыкка килү һәм үсү тарихын чикләп кую шактый читен. Дөнья әдәбиятында реализм өстенлек итә башлаганнан бирле күп төрле әдәби агымнар булып үттеләр һәм булып торалар. Ә романтизм исә киресенчә — кешелекнең һаман да алга ашкынуларын һәм тарихның туктаусыз яңаруын хәбәр итүче ролендә булырга тели. Аның хыял канатлары һич тә талмый, кешене һаман да алга һәм югарыга чакыручы тавышы сүрелми. Чөнки тынгысыз кеше романтик булмыйча яши, иҗат итә алмый. Димәк, бу ноктадан караганда, реализм шикелле үк, романтизм да сәнгать чикләрендә генә бикләнеп калмый. Ул сәнгатьнең үзен дә киң тормыш мәйданына әйдәүче рухи көчкә әйләнә. Шуңа күрә, романтизмның шушы сыйфатын үзенә тиң итмәсә, шуның белән коралланмаса, реализм натурализм дәрәҗәсендә калачагын барлык бөек художниклар ачык сизенгәннәр.

Әгәр дә яңа чорга хас тормышчан сыйфатларга баемаса, искергән әдәби кысалардан чыкмаса, романтизм, әлбәттә, яңа әдәби хәрәкәткә тоткарлык та ясый башлый. Безнең егерменче еллар әдәбиятында да романтизмның искергән традицияләре беришә язучыларның һәм аерым әдәби жанрларның үсешендә билгеле авырлыклар, кыенлыклар тудыруын шулай ук истә тотарга кирәк. Алай гына да түгел, алар моннан соң да теге яки бу төстә үзләрен сиздереп тордылар һәм торулары мөмкин. Мәсәлән, Ф. Бурнаш — шундый романтик традицияләр авырлыгын кичереп үскән шагыйрь һәм драматурглардан берсе. Ул вакыттагы тәнкыйть, гадәттәгечә, боларның һәммәсенә «идея ягыннан артта калу» дигән мөһерне сукты һәм шагыйрьне яңа чынбарлыкны күрмәүдә гаепләде. Әмма чынлыкта Ф. Бурнаш совет әдәбияты алдына куелган яңа бурычларны аңлаудан артта калган яки читтә торган язучы булмады. Эш нәрсәдә иде соң? Гомумән алганда, үсеш каршылыкларында, бу үсешнең гел туры юлдан гына бармавында. Конкрет әйтсәк: иҗат методындагы һәм хәтта аерым жанрдагы традицияләрнең кай ягы искергәнлеген, ә кай ягы яңа белән бәйләнгәнлеген сәнгатьчә хәл итүдә язучының художниклык аңы, тойгысы өлгереп һәм бигрәк тә шагыйрьлек талантының яңа мөмкинлекләре, сыйфатлары тулысынча ачылып җитмәгән иде әле. Менә шушы яктан тәнкыйть Бурнашка реаль ярдәм күрсәтә алмады. Башкаларга карата да бу ярдәм бик саран һәм зәгыйфь булды. Без моның белән һич тә ул чордагы совет әдәбиятында идея югарылыгы өчен барган көрәшнең әһәмиятен читкә этәрергә теләмибез. Сүз монда киң мәгънәсендә яңа иҗат методы өчен көрәш кыенлыклары турында бара.

Романтизм, критик реализм һәм социалистик реализм арасындагы мөнәсәбәт һәм бәйләнешләрнең эчке мәгънәсен эстетик ноктадан конкрет итеп күз алдына китерүгә табан беренче адымнарны без әле яңа гына атлый башладык. Шуңа күрә, беренче адымнарга хас кыюсызлык та, абынусөртенүләр дә, хата-кимчелекләр дә аз булмаячак. Бәлки, боларның беришесе нәтиҗәле бәхәсләргә дә, хакыйкатьне ачуга да сәбәп булыр, ә беришесенең тиешле теоретик дәрәҗәдә тормавы да ачылыр. Соңгы елларда, мәсәлән, Г. Ибраһимов мирасы тирәсендә алып барылган тикшеренүләр безне күп очракта төрле иҗат методларының үзара мөнәсәбәте турындагы мәсьәлә алдына китереп куялар. Чөнки бигрәк тә бу язучы иҗатында романтизм һәм критик реализм традицияләре белән социалистик реализм арасындагы бәйләнешнең гаҗәп катлаулы һәм тирән эзләре калды. Шул сәбәпле аның иҗат методына караган фикерләрнең хәзерге этапта капма-каршы булуы да гаҗәп түгел. Шушы уңайдан «Казан утлары» журналының быелгы 3 нче санында М. Хәсәнов һәм О. Кадыйровлар бастырган мәкаләләрне искә алып китәсе килә. М. Хәсәнов үзенең «Галимҗан Ибраһимов» дигән китабында (1964), бу язучы иҗаты романтизм аша критик реализм юлына чыгып, революциядән соң социалистик реализмга үсте, дигән карашны үткәргән иде. Бу мәкаләсендә инде ул, романтизм мәсьәләсен бөтенләй читтә калдырып, «язучының критик реализмнан социалистик реализмга таба ныклы борылыш ясавы» турында фикер йөртә. Димәк, Ибраһимовка карата моңа кадәр кайберәүләр кулланган «романтизмнан — реализмга» формуласы алып ташла-

намы? М. Хәсәнов мәкаләсе тулысы белән беренче формуланы раслауга багышланган. Алай гына да түгел, хәтта бик катгый рәвештә Г. Ибраһимовның Октябрь алдыннан инде чын мәгънәсендәге критик реалистлыктан пролетариат әдәбиятына күчә башлавы хакында да сүз алып барыла: «Ул инде революция алды елларында ук критик реализмның күренекле вәкиле булып җитлеккән, татар прозасын идея-тематик яктан баетуга, аның әдәби-эстетик куәтен арттыруга зур өлеш керткән әдип иде. Ә 1914—16 еллардагы әдәби-тәнкыйть эшчәнлеге белән Г. Ибраһимов татар тәнкыйтен һәм эстетикасын революциягә кадәрге иң югары дәрәҗәсенә — революцион-демократик этабына күтәрде. Әйтергә кирәк, Г. Ибраһимов 1917 елга инде үзенең әдәби иҗат үсеше белән пролетариат әдәбияты алдына килеп җиткән, аның идея-эстетик эволюциясе киләчәктә бары тик социалистик реализмга таба гына мөмкин иде. Кыскасы, Г. Ибраһимовны революциягә иҗтимагый-политик карашлары үсеше генә түгел, әдәби иҗат практикасы да китереп җиткерде» («Казан утлары», 1967, 3 сан, 7 бит). М. Хәсәнов мәкаләсенең бу өлешендә Г. Ибраһимов иҗат методына караган концепциясе бик төгәл бирелгәндер дип уйлыйм. Монда аеруча кискенлек һәм кыюлык белән яңа положение тәкъдим ителә. Әлбәттә, моны бәхәссез хакыйкать дип кабул итү хәзергә бик кыен.

Монда фәкать шуны әйтү белән генә чикләнәбез: гомумән, Ибраһимов иҗатын романтизмнан аерып карау мөмкин түгел. Башкача аның иҗат методына һәм әдәби осталыгына бәйле күп кенә үзенчәлекле сыйфатларны аңлату, ачу кыен булачак. Безнең прозада романтизм белән реализмның синтезы, берләшүе нәкъ Ибраһимов иҗатында үзенең тулы бер гәүдәләнешен тапты да инде. Бу бигрәк тә совет чорында аеруча тирәнәйде һәм ныгыды.

О. Кадыйров мәкаләсе, бик претенциоз рәвештә, «Романтизмнан — реализмга» дип аталса да, анда Ибраһимовның Октябрьга кадәрге реализмы турында да, аннан соңгысы турында да бернәрсә сөйләнми. Әш, әлбәттә, исемдә түгел, ә җисемдә, эчтәлектә. Мәкаләнең эчтәлеге исә «дидактизмнан — романтизмга» дигән фикерне яклаудан гыйбарәт. Чөнки автор «романтизмның ул чордагы татар әдәбиятында киң таралган һәм бик туйдырган үгет-нәсихәтчелеккә, дидактизмга каршы реакция рәвешендә тууын», шушы ноктадан Ибраһимовның башлангыч иҗатындагы романтизм зур әһәмияткә ия булуын күрсәтергә тели.

Югарыда искә алынган мәкаләләр, һичшиксез, Ибраһимов иҗат методын тикшерүдә кызыклы гына күзәтүләр ясыйлар. Аларда бәхәс кузгатырлык фикерләр дә аз түгел. Без монда аларны бәрәмләп бәяләү максатын куя алмыйбыз. Хәтта аерым бер язучының иҗат методына кагылганда гына да, ничаклы зур һәм катлаулы мәсьәләләр калкып, аларга җавап бирү үзенең бөтен авырлыгы белән безнең каршыда торганлыгын күрсәтергә телибез.

Турысын гына әйткәндә, «романтизмнан — реализмга» яки «критик реализмнан — социалистик реализмга» кебек формулаларның хәзерге вакытта берьяклы, хәтта тотрыксыз булуы шул кадәр күзгә бәрелеп тора, без, күрәсең, аны фәкать сукыр килеш кенә кабатлыйбыз булса кирәк. Шуңлыктан әдәбият тарихындагы һәм әдәби хезмәттәге күп кенә әһәмиятле, катлаулы күренешләрне читләтеп яки атлап үтәбез. Чөнки алар алынган схемага сыймыйлар һәм башкача хөкем итүне сорыйлар. Мисал өчен Такташ иҗатына мөнәсәбәтне генә алып карыйк. Аның турындагы хезмәтләрдә, шагыйрь, нигездер символизмнан һәм романтизмнан арына барып, революцион романтизм аша социалистик реализм юлына чыкты, дигән тезис нык саклана. Гомумән алганда, монда дөреслеккә хыянәт юк шикелле. Әмма бу тезисның конкрет эчтәлегенә керсәң, берьяклылык, яссылык, схематизм сизелә башлый. Әйтик, Такташның революцион романтизмы нидән гыйбарәт соң? Гыйсъянчылыкмы, әллә башкамы? Ә гыйсъянчылыкка гадәттә вак буржуаз анархизм, бунтарьлык мөһере сугыла да аның сәнгать күренеше булуы, яңа иҗат методын һәм заман героен эзләү юлындагы роле ачылмый кала. Гыйсъянчылыкны революцион романтизмның демократик әдәбият традицияләре белән бәйләнгән катлаулы һәм үзенчәлекле бер күренеше дип атарга куркабыз гына түгел, Такташны һәм аның кайбер замандашларын гыйсъянчылык «богауларыннан» тизрәк азат итеп, аларга социалистик реализм кылычын тоттырырга ашыгабыз. Ә текәлеп карасаң, алар кулында әле шул ук гыйсъянчылык арсеналыннан алынган романтизм кылычы ялтырый икән.

Такташның «Гасырлар һәм минутлар» поэмасы, билгеле, бик шәп әсәр. Ул — шагыйрьнең иҗат үсешендәге якты маяклар-

ның берсе. Шулай булгач, ди безнең тәнкыйть, бу әсәр язучының реализмга үсүен күрсәтергә тиеш. «Гасырлар һәм минутлар»да Такташ — чын мәгънәсендә реалист шагыйрь»,— дип раслаган иде Х. Хәйри 1949 елда («Һади Такташ», 67 бит). Без дә Такташ турындагы хезмәтләребездә шул ук фикерләрне уртаклашкан идек («Татар совет әдәбияты тарихы», очерклар, 1960 ел, 125 бит). Х. Госман да бу барьерны атлап үтә алмады: «Ленин аның әсәрендә реалистик образ, ләкин ул тарих титаны итеп гәүдәләндерелгән» («Егерменче елларда татар поэзиясе», 1964 ел, 164 бит).

Шул рәвешчә, Такташ сурәтләгән Ленин образының титаник, ягъни романтик булуын күрсә дә, Х. Госман, үзенә-үзе каршы килеп, аны реалистик дип атарга ашыга. Ни өчен? Чөнки без һаман да романтик образны күбрәк иске мәгънәсендә берьяклы, кимчелекле итеп кенә аңлыйбыз. Ә Ленин шулай ук романтик образ була алмыйммы икәнни? — дигән сорауны күз алдына китерергә дә уйламыйбыз. Алай булса калса, Ленин образы, янәсе, дөрес күрсәтелмәс иде. Менә шулай вульгар социологизм безнең баш очында һаман бармак янап тора сыман. Ә чынлыкта бит «Гасырлар һәм минутлар» — революцион романтизмның гаҗәп көчле һәм матур бер үрнәге. Яхшы һәм тулы мәгънәсендәге риторик поэма дип атар идем мин аны. Чөнки анда бөтен сурәтләү чаралары һәм Ленин образы нәкъ безнең егерменче еллар поэзиясенә хас романтизмның риторик поэтикасына, аның контрастларына корылган. Шуңа күрә безгә, Ленинның титаник геройлар пьедесталына бастырылган мәһабәт романтик образын тудыруы белән Такташ бер иҗади батырлык эшләде, дип горур рәвештә мактанудан ни өчен куркырга?

Тагын да, Такташның егерменче еллар азагында язылган «Күмелгән кораллар», «Югалган матурлык» һәм «Камил» кебек драмалары бар. Бактың исә, шагыйрьнең бу әсәрләре һич тә очраклы гына килеп чыкмаганнар, ә аның иҗат методы формалашуда һәм яңа геройны эзләү, гәүдәләндерү юлында кызыклы гына тәҗрибәләр икән. Үз вакытында каты тәнкыйтькә дучар булган «Югалган матурлык»та (1928) Такташ, туры мәгънәсендәге романтик принциплар нигезендә, безнең чор кешеләренең каршылыклы психологиясен, идеалын ачуны максат итә. Шуның белән бергә үк «Мәхәббәт тәүбәсе» һәм «Алсу» кебек шигъри әсәрләрен тудыра. Безнең фикерезчә, бу әсәрләр өчесе дә, яңа геройның эчке дөньясын күрсәтү ноктасыннан килгәндә, бер-берсеннән һич тә аерылгысыз. Ә иҗат методы ноктасыннан ничек? Әнә шуны нечкәләп өйрәнүнең авырлыгыннанмы, әллә башка нәрсәдән уңайсызланыпмы, «Югалган матурлык»ны «просто» ташлап калдырабыз. Чөнки ул Такташ иҗатында социалистик реализмның өстенлек алуын раслау өчен дәлил була алмый шикелле. Дәреслектә исә, без моның белән фәкать ул еллардагы беркатлы, тупас тәнкыйть фикерен генә эндәшмичә яклыйбыз. Ә менә үзенең бөтен концепциясе белән вульгар социологизм тәэсирендә язылган «Камил»да социалистик реализмның уңышлы чагылышын табарга телибез. Чөнки монда шахтерлар, кулаклар һәм сыйнфый көрәш бар. Ә әсәрнең һәм геройларның җаны бармы? Камил заман герое булырга хаклымы? Мондый сорауларны куя башласаң, Такташның бу әсәрен аклау бик кыен булачак. Әлбәттә, монда язучыны гаепләүдән элек, ул чорда яңа иҗат методын һәм заман героен аңлауның бик катлаулы, каршылыклы хәлдә булуын күздә тотарга кирәк. Такташ әнә шундый хәлне бик кыен кичерә. Димәк, «Мокамай» һәм «Киләчәккә хатлар» кебек гүзәл әсәрләре шагыйрьнең нинди кыен иҗади эзләнүләре аша гына барлыкка килә алганнар икән! Ул кыенлыкларга күз йоммаска, киресенчә, чын художник иҗаты да гел тантанадан гына тормаганлыгын, ә кыенлыкларны кичереп, үзенә зур юл ярып баруын ачарга иде.

Җыеп кына әйткәндә, яңа метод өчен көрәш һәм аны иҗат итү җиңел булмады. Шуңа күрә иҗат методын «үзләштерү» яки «үзләштерә алмау» турында сөйләүләрнең асылында хата бер тәшенчә ята. Иҗат методы язучының фәкать дөньяны, чынбарлыкны сәнгатьчә аңлавы аша гына туа, аны ниндидер бер тәгълимат яки кагыйдәләр җыелмасы төсендә үзләштереп булмый. Сәнгать методы тик иҗат games итүләр гә генә мөмкин. Ясалма «иҗат методлары»ның гомере кыска була. Алар чын сәнгать әсәрләрен тудыра алмыйлар.

### 3

Рус совет әдәбияты белән чагыштырганда, татар әдәбиятында реализм акрынрак һәм соңгарак калып өлгерде. Югарыда күрсәтелеп, исә алынып үтелгән романтик традиция һәм катламнарның тотрыклылы-

гы һәм өстенлеге озаграк сакланды. Әмма шуның белән бергә, егерменче елларның беренче яртысында татар совет әдәбиятында революцион романтизм тәмам формалашты. Аның белән тыгыз бәйләнештә үк реалистик сыйфатлар да үсә бардылар. Инде егерменче елларның уртасыннан башлап реализмның көчәюе бәхәссез иде. Ләкин моны һич тә механик аңларга, «романтизмнан — реализмга» схемасына гына салып карарга ярамый. Монда яңа методның тарихи үсешендә аңа хас сыйфатларның кайсы чорда нинди яклары ачыла, өлгерә һәм үзара керешә баруын истә тотарга кирәк. Бу процесс, барыннан да элек, прозада һәм аннан соң поэзиядә көчлерәк күренде. Драматургиядә исә искергән, мелодраматик, сентименталь традицияләр ныграк сакландылар. Жанрлардагы тигезсезлекнең үз сәбәпләре бар, билгеле. Аларның эчке, сәнгатьчә закончалыкларын күз алдында тотканда гына, ул сәбәпләрнең мәгънәсен, характерын ачарга мөмкин. Бәлки, монда милли традицияләрнең дә роле кечкенә түгелдер.

Гомумән совет әдәбиятында, һәм шул исәптән безнең әдәбиятта да, яңа иҗат методының реалистик принципларын күрсәткән хасиятләр нидән гыйбарәт иде? Проза жанрына бәйләнештә, без шуның кайбер якларына игътибар итәргә телибез.

Революция әдәби формаларның яңаруын таләп итми калмады, әлбәттә. Декадентларның «акыл ташкыны» хаосын чагылдырырга тиешле әдәби формаларына каршы, халыкның аңлы хәрәкәтен төрле яклап күрсәтүне һәм аның эчендә формалашкан бөтен шәхес образларын ачуны максат иткән хикәяләү (повествование), киңрәк алганда — революцион чынбарлык колачына тапкыр килгән эпос өчен кәрәш көннәнкөн киңәя барды.

Күпләгән татар язучыларының тарихи-политик аңы һәм дөньяны реалистик сиземләве үсү алар иҗатында тормышның үткәнен һәм бүгенгесен киң итеп тасвирлау, иҗтимагый вакыйга һәм күренешләрне геройларның шәхси язмышлары һәм үзара мөнәсәбәтләре белән тыгыз бәйләнештә сурәтләү омтылышын көчәйтте.

Реалистик юнәлештәге эпиклык сыйфатлары аеруча өлкән буын язучыларның иҗатында ачыла барды. Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар», «Татар хатыны нилəр күрми», Ш. Камалның «Таң атканда», М. Гафуриның «Кара йөзләр» һәм «Шагыйрьнең алтын приискасында» кебек повесть, романнары моның күренекле үрнәкләре була алалар. Бу әсәрләрдә үткәннең һәм бүгенгенең тарихи-иҗтимагый сәбәпләре белән нык бәйле геройлар язмышы алгы планга куела. Алардагы эпиклыкның төп табигате дә әнә шунда. Әлбәттә, ул вакыттагы рус прозасы колачы белән чагыштырганда, татар әдәбиятындагы эпиклык кечкенә булып күренер. Әмма татар әдәбияты үсешендә ул зур яңалык һәм сизелерлек уңыш иде. Классик әдәбиятның бер көчле реалистик традициясе буларак, гади кеше язмышы егерменче еллар дәвамында татар совет әдәбиятының үзәгенә куелды. Бигрәк тә прозада гомумән халык, масса түгел, ә гади кешенең конкрет образы төп герой булып урын алды. Шул рәвешчә, халыкның эпик герое, гади кешенең эпик образы күпләгән әдипләрнең дикъкатен яулый барды. Җыеп кына әйткәндә, халык образына яңача караш гади кешенең тарихны, тормышны үзгәртеп корудагы батырлыгын, оптимизмын күрсәтүдән гыйбарәт иде. Менә шул рухта гади кешенең һәм аның аша халыкның сәнгатьчә тарихи-революцион биографиясен, иҗтимагый тормыш юлын гәүдәләндерүнең беренче зур тәҗрибәсе ясалды. Бу, һичшиксез, совет әдәбиятын билгеләп алган тарихи-эпик карашның чынбарлык белән нык бәйләнгән бер зур сыйфаты булып, ул барлык әдәби жанрларда үзенең чагылышын тапты.

Безнең әдәбият фәнендә һаман да сәер бер караш яшәп килә: егерменче елларда язучыларның үткәндәге тормыш темасына мөрәҗәгать итүләре критик реализмның дәвамы булса, ә яңа чынбарлыкны сурәтләү социалистик реализмга борылыш турында сөйли, имеш. Мондый фикерләрне тулысы белән кабул итү кыен. Чөнки иҗат методының асылын тематика түгел, ә язучының тормышка эстетик мөнәсәбәте билгели. Эстетик мөнәсәбәт инде әдипнең дөньяга карашыннан, тормышны ничек аңлавыннан, идея позициясеннән башка була алмый. Дөрес, татар язучыларының бер өлеше үткән чор темаларына күбрәк игътибар бирсә, икенче бер өлеше яңа чынбарлыкны күрсәтергә теләде. Моны, иң элек, язучыларның тормыш практикасы һәм әдәби материалы ничек һәм нинди темаларга якын торуы мәгънәсендә аңларга кирәк. Болай булмаса, Г. Ибраһимов 1928 елгы «Тирән тамырлар»ы белән социалистик реалист, ә шул ук елларда бөтенләй яңадан эшләнгән «Татар хатыны нилəр күрми»дә критик реалист позиция-

сен яклаучы[1], яки М. Гафури үзенең поэзиясендә башлыча социалистик реализм юлыннан бара, ә прозасында критик реализмга әйләнеп кайта яки шуны дәвам иттерә, ягъни бер үк вакытта бу язучылар ике иҗат методы белән эш итәләр, дигәндәй бер мәгънәсезлек килеп чыгарга да мөмкин. Ә чынлыкта исә мондый фактлар язучыларның иҗатында тема төрлелеген генә күрсәтәләр. Әмма, икенче яктан, үткәнгә игътибар итү — егерменче еллар әдәбиятындагы бер зур идея-эстетик концепциядән дә аерылгысыз: халыкның үткәнен, тарихын тирән итеп аңламый һәм ачмый торып, аның бүгенгесен дә сәнгатьчә үзләштереп булмый, дигән бик әһәмиятле караш игътибар үзәгендә торды. Безнең әдәбият алдына үткән белән бүгенгенең тарихи бәйләнешен күрсәткән закончалыкны сәнгатьчә ачу максаты килеп басты. Ә ул закончалыкны беренче нәүбәттә реалистик нигездә, эпик җирлектә генә тулы, тирән һәм киң итеп чагылдырырга мөмкин иде. Үткән белән бүгенгенең тарихи бәйләнешен күрсәтү безнең бу чор әдәбиятында контраст, антитеза[2] алымын үстереп җибәрде. Аның нигезендә ике чынбарлыкны каракаршы куеп сурәтләү ята. Ул да, һәм реалистик һәм романтик алым буларак, демократик әдәбияттан килә. Әмма совет чорында инде аның идея-эстетик чикләре бик тә киңәйде, мәгънәсе тирәнәйде. Элекке әдәбияттагыча, кешелеклелек белән кешелексезлекне каршы куюы шикелле гуманистик антитеза читкә этәрелмәде, әчтәлеге сыйнфый-революцион көрәш идеясе белән баетылды. Антитеза үз нәүбәтендә әдәби типларның иҗтимагый һәм психологик характерларын ачуда әчке, композицион элементларның һәм башка сурәтләү чараларының контрастлык поэтикасын да нык көчәйтте. Әлбәттә, моны һәр очракта да уңышлы үтәлде дип булмый. Социологик схематизм бу чор әдәбиятының тормышчан һәм сәнгатьчә сыйфатларын билгеле күләмдә тупасландырган иде. Моны һич тә яшерергә кирәкми. (Бу зур кимчелек аннан соң да тиз генә бетмәде әле.)

Романтизм шикелле үк, критик реализмның да аеруча егерменче еллар әдәбиятында да башка иҗат методлары белән янәшә яки аралашып яшәвен дәгъва итү нигезлеме?

Үткән ел азагында СССР Фәннәр академиясенең А. М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты институтында «Социалистик реализмның актуаль проблемалары»-на багышлап үткәрелгән дискуссиядә әнә шул иске алынган мәсьәләләргә аеруча игътибар ителде[1].

Егерменче еллардагы совет әдәбиятларында урын алган критицизм рухын критик реализм традицияләренең турыдан-туры дәвам итүе, аңа хас сыйфатларның саклануы дип карау һич дөрес түгел, диләр кайберәүләр. Үткән җәмгыятьнең тарихи-сыйнфый мөнәсәбәтләре җирлегендә барлыкка килгән һәм аларны инкарь иткән критик реализм методы бөтенләй яңа иҗтимагый шартлардагы әдәбиятка турыдан-туры, тирән үзгәрешсез генә күчә алмый. Хәтта социалистик революциядән соң үзенең иҗатында зур үзгәреш кичермәгән язучыны да, яңаны аңлап бетермәде һәм чагылдыра алмады дип, критик реализм ягында калдыру тарихи дөреслеккә туры килми. Мәсьәләнең сере, бәлки, тема белән, сурәтләү объекты белән тормышны сәнгатьчә танып белүне икесен бер итеп, бутап карау гынадыр? «Совет әдәбиятында критик реализмның булуын инкарь итү һич тә социалистик сәнгать белән критик реализм сәнгате арасында өзеклек барлыгын күрсәтми. Ә реализмның күчеш формалары, аралыктагы буыннары, алар арасында хәрәкәтчел чикләр булмыймыни?» — ди Г. И. Ломидзе (Критик һәм социалистик реализмның үзара мөнәсәбәте турында, 17 бит) һәм совет әдәбиятларының башлангычы нәкъ әнә шундый катлаулы бер күчеш дәвере булуын дәгъва кыла. Л. Якименко да совет әдәбиятында төрле иҗат методларының булуын дәгъва кылу дөрес түгел дип саный. Аның фикеренчә, социалистик реализм, бер бөтен иҗат методы буларак, туктаусыз хәрәкәт итә һәм үсә. Без күп вакыт аны әзер булган нормаларга салып үлчәп килдек. Ә социалистик реализм, һичбер иҗат методында булмаганча, үзенең әчке мөмкинлекләрен ача бара. (Л. Якименко. Тарих һәм иҗат методы.

---

[1] Бу хакта М. Хәсәновның «Г. Ибраһимов һәм татар әдәбиятында социалистик реализм формалашуының кайбер мәсьәләләре» дигән мәкаләсендә, безнеңчә, дөрес хөкем ителә («Казан утлары», 1967, 3 сан, 10 бит) — *Г. Х.*

[2] Бу хакта Х. Госманның «Егерменче елларда татар поэзиясе» (1964) дигән монографиясендә күп кенә әһәмиятле фикерләр әйтелә — *Г. Х.*

[1] Бу дискуссиягә чыгарылган докладлар аерым брошюра итеп басылганнар. Монда шулар, чыганак буларак, күз алдында тотыла — *Г. Х.*

«Литературная газета», 1967 ел, 12 апрель, 3 бит.)

Башкаларның фикеренчә, егерменче елларда ук инде реализм совет әдәбиятларында өстенлек итүче метод иде. Моны социалистик реализм белән критик реализмның янәшә яшәве яки аралашуы дип аңларга кирәк, әлбәттә. Совет әдәбиятларында критик реализмның дәвам итүе «чынбарлыкны художестволы үзләштерүнең бер бай формасы булган реалистик сәнгать традицияләре көчле икәнлеген, әмма шуның белән бергә үк әле социалистик әдәбиятны тудыручыларның эстетик аңында яңаның чагыштырмача йомшак» булганлыгын да күрсәтә,— ди, мәсәлән, М. Н. Пархоменко (СССР халыклары әдәбиятында социалистик реализм һәм критик реализм, 32 бит).

Безнең фикеребезчә, яңа иҗтимагый шартларда критик реализмның мөстәкыйль метод буларак яшәве мөмкин түгел иде. Г. Ломидзеның бу турыдагы карашы хаклырак кебек. Ләкин бу әле яңа иҗат методын формалаштыруда критик реализмның ролен һич тә киметми.

Социалистик реализм белән критик реализм арасында нинди генә әһәмиятле аерымлыклар булмасын, «...социалистик реализм ул барыннан да элек реализм, художестволы метод буларак, ул реализмның гомуми принциплары нигезендә тәрәккый итә»,— ди С. М. Петров («Реализм». М., 1964 ел, 482 бит). Димәк, бу ике тип реализмның чынбарлыкка сәнгатьчә мөнәсәбәтләре ноктасыннан килгәндә, аларны уртак итә торган сыйфатлар да бик күп булачак. Бу инде үз чиратында поэтика, ягъни сурәтләү чараларының уртаклыгында да әһәмиятле моментларны китереп чыгара дигән сүз. Критик реализм традицияләре — социалистик реализмдагы критицизм, иске җәмгыятьне һәм безнең чынбарлыктагы искелек калдыкларын тәнкыйтьләү, фаш итү ноктасыннан гына түгел, гомумән чынбарлыкны дөрес чагылдырудагы типиклаштыру принциплары ноктасыннан зур әһәмияткә ия булдылар һәм һаман да шулай булып калалар.

Әмма бездә, кызганычка каршы, критик реализмны аңлауда да берьяклы караш яшәп килә әле. Аны үткән җәмгыятьнең тамырын какшатуга хезмәт иткән һәм шундый максатны күздә тоткан иҗат методы, дибез дә (ә прогрессив романтизмда критицизм булмаганмы? Ул шулай ук иске җәмгыятьне инкарь итүгә һәм какшатуга хезмәт итмәгәнме?), критик реализмның сәнгать буларак башка бик күп төрле кыйммәтле сыйфатларын читтә калдырабыз яки аның эстетик принципларын бик тар аңлыйбыз. Бигрәк тә тормыш тирәнлегендәге һәм кешеләр мөнәсәбәтендәге драматик, трагик хәлләрне, коллизияләрне критик реализмның ничек ачуын, моның диалектикасын, сәнгатьчә тулы һәм матурлыгын тиешенчә бәяләмибез. Критик реализмдагы драматизм ул, барыннан да элек, чынбарлыктагы каршылыкларга курыкмыйча карый белү һәм аларны сәнгатьчә дөреслеккә күтәреп сурәтли алу дигән сүз. Классик әдәбияттагы критицизм рухын берьяклы аңлау яки аны социалистик идеалга каршы куеп бәяләү шулкадәр канга сеңгән, хәтта без үзебезнең тормышыбызга турыдан-туры зыян китерә торган зарарлы күренешләрне социалистик реализм чагылдырырга тиешлеме яки ничек чагылдыра ала? — кебек сорау алдында һаман да аптырап калабыз. Бәлки, монда шәхес культы шаукымының да билгеле бер тәэсире дәвам итәдер. Чөнки социалистик җәмгыятьне һәм аның кешеләрен авырлык, каршылык һәм кимчелекләрдән тәмам азат итеп, бизәп, ялтыратып күрсәтү җиңелрәк иде. Әмма без социалистик реализмның критик реализмга караганда да яңаны көчлерәк итеп раслаучы һәм явызлыкка рәхимсез хөкем чыгаручы какшамас хакыйкать, дөреслек белән коралланган әдәби метод икәнлегенә шикләнмибез. Шулай булгач, аның төп бурычларыннан берсе — тормышның, заманның, кешеләр язмышының тирән, эчке каршылыкларын, драма һәм фаҗигаләрен ачып бирү булырга тиешлеген дә таләп итмичә кала алмыйбыз. Менә безнең сәнгатьнең шушы сыйфатын үстерүгә критик реализм һәм классик романтизм традицияләре һәрвакыт юлдаш, таяныч булып калачаклар.

Егерменче еллар дәвамында совет әдәбиятының иҗат методын һәм юнәлешен билгеләү тирәсендә каты көрәш барды. А. М. Горький безнең әдәбиятның төп методы реализм белән романтизм синтезыннан торган өченче яңалык булырга тиеш дип карады. Бу караш, һичшиксез, совет әдәбияты кешелекнең художество тарихында алга яңа бер адым булуын тирән итеп аңлауны күрсәтә иде.

Әлбәттә, социалистик реализм ул нинадидер реализм һәм романтизмның гади кушылмасыннан торган бер метод түгел. Ул, барыннан да элек, яңа, социалистик идеаллар белән рухланып, социалистик эпоха эчтәлегеннән үсеп чыккан, шул заманга хас

сәнгатьчә ихтыяҗларны чагылдырган һәм, кешелекнең иң алдынгы әдәби казанышларын үзләштереп, туктаусыз үсә, камилләшә барган иҗат методы. А. М. Горькийның «өченче бер метод» турындагы фикерләрен иң элек әнә шул мәгънәдә аңларга кирәк. Бөек художник карашынча, социалистик реализм ул дөньяны киң мәгънәсендә реалистик танып белүнең, сәнгатьчә үзләштерүнең органик яңа бер формасыннан гыйбарәт. Югыйсә, бездә социалистик реализмны ниндидер «кисәкләрдән торган» бер корама метод рәвешендәрәк күз алдына китерү дә бар. Болай аңлау, ахыр чиктә, совет әдәбиятының үсешен һәм аерым язучыларның иҗат йөзен бик схематик итеп күрсәтүгә кайтарып калдырачак.

Шик юк ки, егерменче еллардагы совет әдәбияты методында төрле һәм каршылыклы сыйфатларның барлыгын һич тә инкарь итеп булмый. Чөнки бу чорда әле яңа метод, һәртөрле традицияләрнең калын катламнары астыннан калкып чыгып, үзенә лаеклы юлга аяк басу өчен көрәш авырлыгын кичерде. Шулай ук егерменче еллардагы татар әдәбиятында да традицияләр белән новаторлык мөнәсәбәтендә, яңа методның формалашуында нинди генә чуарлык һәм каршылыклар булмасын,— яңа метод елдан-ел үзенең табигатен тулырак ача барды.

Күпләгән тәҗрибәле язучылар яңа методка исем эзләгәндә, аны икеләнмичә реализм дип атадылар һәм элекке, критик реализмнан аермасын күрсәткән төрле сыйфатлар, эпитетлар тәкъдим иттеләр. «Социаль», «монументаль», «тенденциоз», «пролетар», «героик», «романтик», «психологик», «диалектик» һ. б. шуның шикелле аергычлар, өстәмә төшенчәләр белән бу яңа реализмның тулырак мәгънәсен билгеләү турында да сүз күп булды. Һәм берәздән соң кабул ителгән «социалистик реализм» төшенчәсе яңа әдәби методның төгәл билгеләмәсе, атамасы булып китте.

Шул рәвешчә, егерменче еллар дәвамында безнең күпләгән милли әдәбиятларда социалистик реализмның нигезе салынды. Бу әдәби методның барлыкка килүендә һәм формалашуында яңа революцион чынбарлык хәлиткеч фактор булды. Әмма, яңа сәнгать күренеше буларак, совет әдәбияты һәм аның иҗат методы, критик реализмның һәм прогрессив романтизмның иң алдынгы традицияләрен үзләштерә барып, мәйданга чыкты. Шул ук процесста аңарда романтизмның да, критицизмның да социалистик чынбарлык белән бәйле яңа сыйфатлары ачыла барды. Совет әдәбиятындагы реалистик һәм романтик башлангыч яки юнәлешләрне бер ноктага җыя, тарта торган көч бар: ул — тарихи-иҗтимагый шартларның һәм сыйнфый-идеологик факторларның бердәмлеге. Менә шуның җирлегендә безнең уңай идеал — сыйнфый каршылык һәм изүләрдән азат, гуманистик җәмгыять һәм кеше идеалы чәчәк ата. Бу идеал бөтен сәнгать дөньясының кыйбласына әверелә. Шундый шартлар һәм идеал яктылыгында критик реализмның да, прогрессив романтизмның да алдынгы мирасы социалистик сәнгать хәзинәсенә кабул ителә. Алардагы якын һәм уртак сыйфатларның органик берләшүендә, үсешендә яңа дәвер ачыла. Социалистик реализм шуннан башка була алмый.

Социалистик реализм безнең бөтен әдәбиятларда тамыр җәя, үсә һәм өстенлек ала барды дигәч тә, моннан әле һич тә башка әдәби метод һәм юнәлешләр белән ул үзенең бәйләнешен йомшатып яки алардан бөтенләйгә аерылып, үз эченә бикләнгән һәм тәмам «чистартылган» (стерильный) метод булып кына калды, дигән нәтиҗә ясалмаска тиеш. Менә шул процесс төрле тарихи дәверләрдә татар совет әдәбиятының төрле жанрларында һәм аерым язучылар иҗатында ничек чагылды һәм бүген дә ничек дәвам итә? — шундый сорауларга конкрет җавап кирәк. Бу мәкаләнең бер төп максаты шул юнәлештә тикшеренү һәм фикер алышуларны тагын да киңәйтә һәм көчәйтә барырга чакырудан гыйбарәт.

——□——

*Суфиян Сафуанов*

# Бакчачы турында хикәя

Бер җәйдә миңа Ибраһим Газиның Аккош күлендәге дачасында булырга туры килде. Бәләкәй генә йорт тирәли үскән бакчага килеп кергәч, һәр ботакны сырып алган чикләвек-чикләвек карлыганнарга, яфракларын каплап киткән крыжовникларга, кара кучкыллы чияләргә, агачларын сыгып төшергән аксыл алмаларга гаҗәпләнеп, хуҗадан сорап куйдым:

— Нигә бу җимешләрне җыеп алмыйсыз инде?

Ибраһим агай, күзлегеп сул кулы белән күтәреп, саран гына елмайгандай итте:

— Мин — үстерүче. Теләгән кеше үзенә кирәген җыяр әле. Әнә, күңелең тарткан куактан рәхим ит...

Күренекле язучының иҗаты турында уйлаганда, күз алдына һәрвакыт әнә шул эпизод килә. Алтмыш ел гомер иткән һәм татар совет әдәбиятының зур бакчасында кырык ел буе тырышып эшләгән бу бакчачы нинди генә асыл җимешләр үстермәде дә, ул җимешләрне кемнәр генә авыз итмәде һәм яратмады!

* * *

Мәһабәт талгынлык белән аккан киң Иделгә гүзәллек өстәп, аның уң ягыннан күксел таулар сузылып бара. Шушы таулар куенына сыенган татар авыллары элек-электән үзләренең алма бакчалары белән дан тотканнар. Кама Иделгә килеп кушылган тәңгәлдә, бакчаларга күмелгән Олы Карамалы авылында, 1907 елның 4 февралендә Ибраһим Гази дөньяга килгән. Әтисе Зарифулла агай, «уч төбедәй» җир кисәге генә туендырып бара алмагач, күмер шахталарына китеп эшләргә, таш чыгарырга, Иделдә сал агызырга мәҗбүр була. Шулай, бәхет кошын тотарга омтылып йөри торгач, авырый башлый һәм, семьясын бөлгенлектә калдырып, вафат була.

Тәтеш балалар йорты, анда урта мәктәптә белем алу, комсомол сафына аяк басу, Казанда совет-партия мәктәбе, аннары Кукмарада комсомолда эшләү, ВЛКСМның Татарстан өлкә комитетының агитпроп мөдире — И. Газины зур тормыш юлына чыгарган сукмаклар менә шулар.

1929 еллардан башлап, газета-журнал битләрендә И. Газиның зуррак күләмле очерклары һәм әдәби парчалары күренә башлый. Аларда яшь автор шул заманның актуаль мәсьәләләрен күтәрә, үзенең каләмен үлемгә йөз тоткан иске тормышка каршы юнәлдерә, иске белән яңаны контраст куеп, яңаның җиңүчән көче турында рухланып сөйли.

Язучының менә бу әдәби әсәр, дип авыз тутырып сөйләрлек беренче хикәясе дә шул ук 1929 елда дөньяга чыга. Сүз «Авыл яшьләре» журналының 9 санында басыл-

ган «Чабаталар ләштер-лөштер» исемле хикәя турында бара. Автор үзенең бу әсәрендә, илнең социализмга таба үсүе белән бергә, кешеләрнең дә үзгәрүе, аларда яңа характер сыйфатлары формалашуы турында сөйли. Мәһинур, Рәхим образларында ул совет авылында барган зур үзгәрешләрнең кеше аңына ничек тәэсир итүен, аңарда яңалыкка омтылышның ничек туа һәм үсә баруын ачарга тели. Композицион төзелеше ягыннан хикәя аерым геройларны характерлаучы кечкенә-кечкенә картиналар тезмәсеннән гыйбарәт. Авылда барган зур социаль үзгәрешләрне күрсәтү максаты белән, автор әсәргә төп сюжетка турыдан-туры бәйләнмәгән төрле вакыйгалар һәм детальләр дә китереп кертә.

Вакытлы матбугат битләрендә чыгып килгән күп санлы фельетон һәм әдәби парчалары, бәләкәй-бәләкәй очерклары И. Газиның, язучы буларак, һаман үсә, остара баруын раслыйлар. Әсәрдән әсәргә аның каләме шомара, иҗат почеркы ачыклана барды.

1930 ел башында язган бер мәкаләсендә, яшь язучылар алдында торган бурычларга тукталып, И. Гази болай дигән иде: «...Тормышның эченә кереп кайнаган булу, бүгенге көрәш моментларын үткен, дөрес чагылдыра белү һәм тормыштагы бөек үзгәрешләрне укучыларны сокландырырлык, аларга революцион пафос кертерлек итеп шигырь рамкасына салу кирәк».

Бу — язучыларны заман, халык тормышы белән бер адымнан атларга чакыру иде. Әнә шул елларда ул үзе дә производство яшьләре тормышын чагылдырган әсәрләр язарга керешә. 1929 елда аның «Ташкын йөрәкләр» (соңыннан «Кич алтыда» дигән исем белән чыга), 1930 елда «Бармак», 1931 елда «Көмеш сулы Нурминка» хикәяләре басыла. Автор әсәрләре өчен материалны Кукмара киез итек фабрикасы эшчеләре тормышыннан ала. Хикәяләрнең геройлары хезмәт процессы белән бәйләп сурәтләнәләр, яшьләрнең мораль сыйфатлары коллективка карашларында ачыла, һәр герой иҗтимагый хезмәткә мөнәсәбәтендә сынала. Буржуаз мещанлык калдыкларына каршы көрәш белән бәйләнешле кискен моментларны сурәтләү бу хикәяләрдәге геройларның хисләрен, рухи дөньяларын тирәнрәк ачарга мөмкинлек бирә. Геройларының газаплы уйларын, борчылуларын, күңел борылышларын укучы тоеп-сизеп торырлык итеп язарга өйрәнә. Моның өчен ул шул профессия кешеләренә генә хас тел чаралары куллана, уртак сөйләм дип аталган стилистик алымнан файдалана. Беренче әсәрләрендә үк очраган бу алым язучының соңга таба язылган әсәрләрендә бик нык үстерелде.

И. Гази иҗат иткән образларның тормышчанлык дәрәҗәсенә, ул кулланган сурәтләү чараларының уңышлы булуына үз вакытында тәнкыйть тә игътибар итте. «Яңалиф» журналының 1931 елгы бер санында М. Әмир, мәсәлән, болай дип язды: «Бу образлар әдәбиятны киң катлау масса эченә алып керә торган образлар. Болар авторның һәр нәрсәне нык күзәтүче булуын, бөтен вакыйгаларга-детальләргә әһәмият бирүен күрсәтәләр».

1932 елда басылган «Бригадир кыз» повестенда инде яңа кеше проблемасы киңрәк масштабта, чынбарлыкны күпьяклы итеп чагылдырган материалда хәл ителде.

Әсәрнең үзәгенә куелган Галия образы татар әдәбиятында моңарчы сурәтләнгән хатын-кызлардан тормышка актив мөнәсәбәте, иҗат кешесе булуы белән аерылып тора. Комсомолка Галияне, аның бригадасындагы яшьләрне, газета редакторы Назыров кебек геройларны автор, беренче чиратта, хезмәттә, производствоны алга җибәрү өчен барган көрәш процессында күрсәтә. Шуның белән бергә, яшьләрнең көнкүрешен сурәтләүгә, кызыксыну даирәләрен, эчке дөньяларын ачуга да зур гына урын бирә.

Характер буларак, геройлар, бер яктан, хезмәт фронтында, яшьләр тормышындагы аерым җитешсезлекләр белән көрәштә формалашсалар, икенче яктан, үз мәнфәгатен генә күзәтүче слесарь Адаев, бюрократ Касыйм кебек тискәре персонажлар белән бәрелештә ачылалар.

«Бригадир кыз» повестенда социалистик чынбарлык хәкыйкате яңаның җиңә баруы, иске, кара көчләрнең җиңелеп калуы төсендә гәүдәләнә. Галия производстводагы, яшьләр тормышындагы кимчелекләр белән көрәштә үскәннән-үсә барса, яхшы оештыручы һәм алдынгы эшче булып җитешсә, Адаев үзенең эгоистлык хәрәкәтләре белән

һәр адымда хурлыкка очрап тора. Касыймга да озаклап иркенәеп яшәү насыйп булмый. Әсәрнең композициясе дә шушы үсешне ачыграк күрсәтердәй итеп төзелгән. Повестьта башта Адаев алгы планда тора, аның эше, тормышы сурәтләнә. Акрынлап аңа каршы көрәшүчеләр беренче планга чыга, ә ахырга таба инде тантана итүче лагерь вәкилләре — Галияләр, Назыровлар төп урынны били.

Бу повестьта И. Газиның образлар иҗат итү, тормыш вакыйгаларын җанлы картиналарда тасвирлау осталыгы да шактый камилләшкән, үскән. Ул, халык тормышының мөһим моментларына мөрәҗәгать итеп, аны, социалистик реализм методы нигезендә, дөрес чагылдыра, җанлы образлар ярдәмендә, социализм идеяләренең җиңүчән көчен раслый.

Әнә шулай, әдәби осталык юлында төрле эзләнүләр кичереп, И. Гази әсәрдән әсәргә үсә барды һәм утызынчы еллар азагына танылган прозаик булып җитеште. Татар әдәбиятының зур бакчасында аның үз җимешләре күзгә күренеп, аерылып торалар иде инде. Татар әдәбиятының бай тәҗрибәсен үзләштерү, бөек рус әдәбиятын, бигрәк тә А. П. Чехов, М. Горький иҗатларын ныклап өйрәнү И. Газига үзенчәлекле язучы булып формалашуда зур ярдәм итте. Бу елларда ул Чехов, Салтыков-Щедрин, Горький әсәрләрен татарчага тәрҗемә итү өстендә актив эшләде, бөек пролетар язучының иҗаты турында мәкаләләр белән дә чыгыш ясады.

* * *

Илебезгә фашистлар явы ябырылгач, И. Гази да, үз каләмен штыкка тиңләп, иҗатын илбасарларга каршы көрәшкә юнәлдерде. Башка күп язучыларның иҗатындагы кебек, аның бу чор әсәрләрендә дә фашизмга нәфрәт, азатлык өчен көрәш һәм совет кешесенең батырлыгы темалары үзәк урынны тотты. Сугышның беренче елларында И. Гази «Совет әдәбияты» журналының редакторы булып эшли, шунда аның «Кышкы кичтә», «Ана», «Авылдаш» кебек хикәяләре басылып чыга. Бу әсәрләрдә вакытлыча фашистлар кулында калган районнарда яшәүче совет кешеләренең батырлыгы күрсәтелә, гитлерчыларның кабахәтлеге фаш ителә. Фашист-илбасарларга карата нәфрәт уяту максаты белән язылган бу хикәяләрдә әдәби сурәтләү алымнары да шактый үзенчәлекле. Немец солдатлары, гадәттә, карикатура алымнары белән, сатирик планда сурәтләнәләр. Һәр деталь, һәр факт аша гитлерчыларның талаучылар, ерткычлар булуы ачыла. Хикәяләрнең тонында ук ниндидер шомлылык, караңгы буяулар, авыр кичерешләр өстенлек итә.

1942 елның көзендә Ибраһим Гази фронтка китә. Дүртенче Украина һәм Өченче Белоруссия фронтларында татар телендә чыккан газеталарда эшли. Фронт газеталарында аның «Командир Локманов», «Тормышын аямыйча», «Гайнетдин улы Хисаметдин», «Хәйләкәрлек, кыюлык һәм йөрәклелек» кебек очерклары, зарисовкалары басыла. Газета күләме таләп иткәнчә, алар үтә җыйнаклар. Характерны ачардай бер үткен эпизод, бер-ике җанлы деталь аша автор татар солдатының сугыш кырындагы фидакарьлеген ача. «Капитан Сәлим Мәгъсумов», «Тупчы егет» кебек очеркларда сугышчылардагы геройлыкның чыганаклары да шактый тулы күрсәтелә. Фронт батырлары белән иңгә-иң яшәү авторга совет кешеләренең гүзәл образларын гәүдәләндерерлек хикәяләр иҗат итәргә мөмкинлек бирде. «Әхмәт бабай» һәм «Йолдызлы малай» әсәрләрендә «Кышкы кичтә», «Ана» кебек хикәяләрдә алынган мотивлар тагын да үстерелде һәм көчәйтелде. Әгәр сугышның беренче елларында язган хикәяләрендә илебез халыкларының батырлыгы тиешенчә күрсәтелмәгән булса, соңгыларында инде совет кешесенең горурлыгы, буйсынмаучан табигате тулы һәм оста ачыла. Әхмәт бабай образы да, «Йолдызлы малай»дагы Илгизәр образы да конкрет сыйфатлары, тирән эчке кичерешләре, югары рухи байлыклары белән биреләләр.

А. П. Чеховның күп кенә хикәяләрендә төп урынны настроение, интонация, узган эш турында сөйләү алып тора. И. Газиның сугыш елларында язылган хикәяләре дә шундыйрак. Алар үтә җыйнаклар. Аларда геройны характерлаучы иң мөһим моментлар һәм вакыйгалар гына алына.

Авторның 1944 елда басылган «Алар өчәү иде» исемле хикәясендә совет кешесенең Ватан азатлыгы өчен көрәше киңрәк планда сурәтләнә. Биредә сугышчыларның көрәшен сурәтләүдә дә, үткәннәрне искә төшергән чигенешләрдә дә, киләчәкне күз алдына китергән уй-кичерешләрдә дә бер максат күздә тотыла: бу — совет кешесенең тыныч хезмәт кешесе булуын, бөеклеген, җиңелмәслеген раслау. Сөләйманов — тыныч хезмәт кешесе, сугышка кадәр укытучы булган, иң тыныч, иң күркәм эш башкарган. Ул әле дә кемне дә булса басып алу, буйсындыру өчен түгел, бәлки тыныч көннәр килсен өчен сугыша, шул хакта уйлый. Геройның кичерешләре, үткән тыныч көннәрне сагынып искә төшерүләре әнә шуны раслый. Туган якка мәхәббәт, семьяга тугрылык, Ватанга бирелгәнлек идеясе Коненко һәм Неплюйко образларында да шактый тулы һәм матур ачыла.

И. Газиның батырлык, героизм темасын хәл итүдәге тагын бер үзенчәлеге шуннан гыйбарәт. Аның хикәяләрендә сурәтләнгән персонажлар үзләренең искиткеч кыюлык күрсәтүләрен гадәти эш итеп, гади адым итеп карыйлар. «Якташ» хикәясенең герое шундый иде, Сөләйманов белән Неплюйко да иң гади кешеләр булып күз алдына киләләр. Шуңа күрә тәнкыйть аларны «җир кешеләре» дип атады.

Совет сугышчылары образларын иҗат итүне И. Гази соңга таба да дәвам итте. 1947 елда аның «Без әле очрашырбыз» повесте, алтмышынчы елларда «Югалган Мәрзия», «Абрикос төше ашаганда» хикәяләре чыкты. «Без әле очрашырбыз» повестенда сугыш героикасы романтик планда хәл ителә. Совет кешесенең рухи бөеклеге мавыктыргыч ситуацияләрдә ачыла, геройларның эчке матурлыгы, ихтыяр көче һәм ул көченең чыганаклары киң яктыртыла. Разведчик Закир Дәүләтшин образында югарыда телгә алынган хикәяләрдәге персонажларның төп характер сыйфатлары тагын да үстерелеп бирелә.

Драматик ситуацияләр, трагик коллизияләр белән тулы фронт тормышы язучыга гаять бай материал бирде. Шуңа күрә И. Газиның бу чор иҗатында документаль фактларга нигезләнгән очерк белән художество фантазиясенә корылган хикәя һәм повесть арасында күп очракта чик тә җуела. Аның башта «очерк» дип куйган кайбер әсәрләрен укучы хикәя дип кабул итте. «Әхмәт бабай» әсәре белән, мәсәлән, шулай булды. Аның 1943 елда басылган «Лейтенант Сөләйманов» исемле очеркы соңыннан тулысы белән «Алар өчәү иде» хикәясенең нигезенә ятты, ә «Капитан Сәлим Мәгъсумов» очеркыннан аерым өлешләр «Без әле очрашырбыз» повестеның тукымасына кертелделәр. Болар барысы да язучының тормыш белән тыгыз бәйләнешен раслый, тагын бер кат аның иҗат үзенчәлеген күрсәтеп тора.

* * *

«Әдәбият — безнең бөек төзелеш планнарыбызны башкарып чыгуда, сугыш китергән яраларны төзәтеп, халык хуҗалыгын тагын да үстерүдә партиягә, хөкүмәткә, халыкка ярдәм итүче көч ул»[1]. Язучыларның сугыштан соңгы еллардагы миссиясен И. Гази әнә шулай аңлый. Һәм ул, фронттан кайту белән, совет солдатының тыныч тормыштагы эшен һәм көрәшен сурәтләргә керешә. «Алмагачлар чәчәк ата» (1950) повестеның үзәк герое Гаяз, фронт юлларын кичеп, орден-медальләр тагып, туган авылына кайта. Кайта да шәп-шәрә калган җимеш бакчаларын янадан яшәртү эшенә керешә. Әлбәттә, аның җиң сызганып бакча үстерү эшенә керешүен укучы Туган илне гөлбакчага әверелдерү өчен башланган көрәш итеп кабул итә. Бакчачы Гаяз — сугышта җиңеп чыккан һәм хәзер үз көченә ышанган, тарихта үз урынын яхшы аңлаган совет кешесе образы ул. Аның бөтен хәрәкәтләре, «инде өстән бомба явып тормый», «әкренләп өлгерербез» дип яшәгән колхоз председателе Гыймади белән бәрелешләре аша язучы шул төп идеяне уздыра. И. Гази бу образда сугыш чоры әсәрләрендә сурәтләнгән көрәшчеләрен алга таба үстерә, Сөләймановлар, Дәүләтшиннарны, әйтерсең, яңа шартларга куеп сурәтли.

[1] И. Гази. Яшь язучылар, аларның иҗатлары һәм бурычлары. «Совет әдәбияты» журналы. 1946 ел. 11—12 саннар. 132 бит.

Җиңеп кайткан сугышчы! Повестьның бөтен тел-стиль тукымасы шатлык хисен, җиңеллекне, җиңү настроениесен сиздереп тора. Якты, ачык тоннар белән эшләнгән рәсемдәге сыман, әсәрдән кояш нуры, яз исе аңкый. Бу күтәренке эмоция һәр вакыйганың диярлек күңелле юмор белән өретелүеннән дә, авторның герой уйлары белән органик рәвештә кушылып киткән лирик чигенешләреннән дә, сөйләмгә җылылык өстәп торган инверсияләрдән дә һәм, әйтергә кирәк, хәтта сурәтләү объектының — җимеш бакчасының — үзенең үк лирик настроение тудыра алу үзенчәлегеннән дә килеп чыга. Повестьта И. Газиның соңгы елларда актив кулланган үзенчәлекле алымы: геройларның уй-фикерләрен, эчке кичерешләрен, хәтта сөйләгән сүзләрен үк уртак сөйләм формасында бирүе бик нык күзгә ташлана. Бу алым әсәрне җыйнакландырырга, сыгылмалыландырырга, образлылыкны тирәнәйтергә мөмкинлек биргән. Укучы хәтта геройның хис-кичерешләрен күреп торган, аларны уртаклашкан төсле була.

Чорның иң әһәмиятле мәсьәләләрен күтәрү һәм замандашларыбызның җанлы образларын тудыру теләге И. Газины яңадан-яңа тормыш материалларына этәрде. Татарстанның көнчыгыш районнарында нефть промышленносте туып, татар халкыннан нефтьче кадрлар үсеп чыга башлау белән, электән дә эшчеләр образын яратып сурәтләгән язучының күңеле тыныч кала алмады, билгеле. Ул Бөгелмә, Әлмәт якларына юнәлә, эшчеләр белән бергә буровойларда йөри, нефтьчеләр башкарган хезмәтне үз куллары белән эшләп карый, аларның характерлары белән таныша, ни белән яшәүләрен күрә. Һәм 1955 ел башында аның «Гади кешеләр» исемле яңа романы дөньяга чыга.

Әсәрдә республикага нефть промышленносте белән кергән зур яңалыклар күп төрле картиналарда тулы чагылыш тапты. Анда, Баку һәм Башкортстанда кара алтын чыгару һөнәренә өйрәнеп, Татарстан хезмәт ияләренә ярдәмгә килгән тәҗрибәле эшчеләр дә, кичәге колхозчыдан яки әле генә парта арасыннан чыккан яшүсмердән нефтьче булып китүчеләр дә урын алалар. Әсәрнең һәрбер бите аларның тормыштагы төрле каршылыкларны җиңә барып, алдынгы эшче булып җитешүләрен, ил байлыгын арттыру хакына фидакарь хезмәт итүләрен җанлы картиналарда сурәтләүгә багышланган.

Бу хезмәт кешеләрен автор гади кешеләр дип атый. Моңарчы язган әсәрләрендәге кебек үк, И. Гази аларның башкалардан берни белән дә аерылып тормавына, иң гадәти кешеләр булуына басым ясый. Габитов, әйтик, бүтәннәрдән һични белән дә аерылып тормаган гадәти нефтьче, «урталар» вәкиле итеп күрсәтелә. Бригада членнары да үз җитәкчеләреннән узып әллә ни эшләмиләр. Романның төп кыйммәте шунда: автор шушы «гади» кешеләрнең зур инициативалы, киң карашлы геройлар булып үсә алуын күрсәтә.

Гади, «кечкенә» кешенең бөеклеген, тарихтагы әһәмиятен сурәтләү ягыннан И. Гази татар әдәбиятында Ш. Камал, Г. Газиз хикәяләре традициясен алга таба үстерде. Билгеле, бу традиция А. П. Чеховтан да килә. И. Газиның әлеге роман өстендә эшләгән елларда чыккан бер мәкаләсендә шундый юллар бар: «А. П. Чеховның барлык әдәби шедеврлары иске Россиядәге «кечкенә» кешегә, ягъни хезмәт ияләренә тирән мәхәббәт белән сугарылган... Шуңа күрә Чеховның иҗаты безнең күңелебезгә бик якын... Без — татар язучылары да Антон Павлович Чеховны әдәби остазларыбызның берсе дип саныйбыз»[1].

Моннан тыш, илленче еллар әдәбиятындагы күбрәк ялтыравыклы, зур шәхесләргә игътибар юнәлдерү кебек күренешләргә каршы эчке полемика да сизелә бу романда. Әсәрнең исемен үк «Гади кешеләр» дип алып, И. Гази аларның тарихны алга илтүчеләр булуына тагын бер кат басым ясый. Бу — әсәрдә күтәрелгән үзәк проблемаларның берсендә бигрәк тә ачык чагыла. Игътибар үзәгендә ун-унбиш алдынгы кеше торырга тиешме, әллә бөтен производствоның нигезен тәшкил итүче меңнәр, ун меңнәрме? Әсәр әнә шул проблема белән башланып китә: «Сүз һаман байракчылар тирәсендә әйләнә: ун-унбиш байракчы инде баядан бирле киңәшмәнең теленнән төшми, ә ун-ун-

[1] И. Гази. Кыска язарга, ягъни талантлы язарга өйрәник. «Совет әдәбияты» журналы. 1954 ел. 7 сан. 87 бит.

биш меңнәр хакында әле ун сүз дә әйтелгәне юк. Ә бит планның авыр башын шушы меңнәр күтәреп бара!»

Һәм автор әнә шул меңнәргә игътибар юнәлтү кирәклеген яклый. Шул тирәдә — әсәрнең төп конфликты, шул материал романның үзәк фабуласын тәшкил итә. Романда без иң гади геройларның эшләре белән дә, хезмәт процессында туган кичерешләре һәм омтылышлары белән дә танышабыз. Интим дөньяларын, гаилә тормышын һәм һәр геройның үзенә генә хас индивидуаль сыйфатларын ачучы картиналарны да очратабыз. Автор характерлар көрәше аша тормыш каршылыкларын ача бара; нефть районнарында кызу үсеш темпы арасында килеп чыккан кайбер кимчелекләрдән дә күз йоммый, тормышчан проблемаларны күп төрле характер сызыкларына ия булган образлар системасы аша хәл итә.

Габитов образы булсын, Алмаев, Стрельцов яки Камышев булсын, аларның һәркайсы үзенчәлекле, хәтта каршылыклы характер сыйфатларына ия. Еш кына аларда, уңай сыйфатлар белән бергә, бик үк әйбәт булмаган гадәт-холыклар да күренеп-күренеп китә. И. Гази хәзер инде, «Бригадир кыз» яки «Көмеш сулы Нурминка»дагы кебек, менә монысы уңай, монысы тискәре дип кап урталай аерып куярдай образлар белән эш итми.

Тормышчан проблемалар күтәрү һәм оригиналь характерлар тудыру ягыннан уңышка ирешсә, күп төрле сюжет җепләрен берләштерүдә, әсәрне композицион яктан бер бөтен итеп оештыруда автор зур гына авырлыкка да очрады. Сугыштан соңгы елларда бөтенсоюз әдәбиятында да, татар әдәбиятында да производство мәсьәләләрен беренче планга куеп сурәтләгән әсәрләр күп чыга иде. Андый әсәрләрнең геройлары, гадәттә, үзләре башкарган хезмәттән тыш темага сүз дә алып бармыйлар. «Производство романы» дип яманаты чыккан шундый әсәрләрдәге берьяклылыктан качарга омтылып, И. Гази геройларны производство даирәсендә генә чикләп калдырмый, мәхәббәтләрен, семья тормышларын да күрсәтә. Әмма бу моментлар үзәк проблеманың аерылмас өлеше булып өлгермиләр, «производство темасы» үз алдынарак, «шәхси» дөнья үзенә башкарак яши. Шуңа күрә үзәк конфликт белән бернинди бәйләнеше булмаган аерым эпизодлар, үтә мөстәкыйль үсеп киткән сюжет сызыклары да урын ала.

Аннан соң, илленче елларда, И. Гази әдәби әсәрләрнең кыйммәте кеше күңелен әсир итә торган характерларда, әдәби образларда... хәлиткеч нәрсә — образ, дигән бик дөрес фикерләр әйтү белән бергә, әдәбиятта сюжетның әһәмиятен кечерәйтеп карау кебек берьяклырак тенденциягә дә бирелде кебек. «Бик гади сюжетлар ярдәмендә дә классик язучылар менә дигән җанлы һәм оригиналь образлар тудырганнар, — дип язды ул. — ...Зәгыйфь сюжет эчендә үскән образ да зәгыйфь була, дип, сюжетны беренчел итеп кую дөрес түгел»[1]. Күрәсең, шушы караш язучыны, Мансур, Сибгатуллин, Алмаев, Стрельцов кебек үзенчәлекле образлар белән эш иткәндә, мавыктыргыч кызыклы һәм төрле коллизияләргә бай сюжет төзүгә җитәрлек игътибар бирмәүгә китергән. Бу — язучының соңгы елларда иҗат иткән кайбер хикәяләрендә дә үзен сиздерде. «Ай юлы»нда Миңлебаев белән Исмаеваның, «Өч Мәхмүт»тә өч тарихи чорда яшәгән Мәхмүтләрнең, «Матур кыз» хикәясе героеның үзләренә генә хас рухи сыйфатлары, холык-фигыльләре билгеләнсә дә, ул сыйфатлар гади сөйләшүдә, борылышсыз вакыйгаларда гына бирелә. Хикәяләрдә образның оригинальлеге һәм психологик моментлар сюжетның сүлпәнлеген йомып калдыра алса да, роман кебек киң эпик полотнода язучы үзе әйткән «тыныч конфликт» сюжетны бераз таркатып җибәрә. Замандашлар образын биргән «Яңа мастер» һәм бигрәк тә «Күңел ярасы» хикәяләрендә язучы бу берьяклылыктан котыла, аларда характерлар кешеләр арасындагы кискен мораль-этик бәрелешләрдә тулы ачыла инде.

* * *

Тәҗрибәле бакчачының җимеш агачлары арасында аеруча яратып, кадерләп үстергән төпләре була. Бер үк оста тарафыннан үстерелгәнгә, алар башка алмагачларга охшый да, шул ук вакытта күп еллык тәҗрибәне салып, үзенә кадәрге бакчачыларның

[1] И. Гази. Хикәяләр турында. «Совет Татарстаны» газетасы 1958 ел. 26 апрел

казанышларын кулланып армый-талмый тәрбияләү аркасында, бүтәннәрдән аерылып, үткән-сүткәннәрнең күз явын алып та тора. И. Газиның иҗат бакчасында да күз явын алырдай шундый җимеш агачы бар. Ул — «Онытылмас еллар» повесте.

Әле 1933 елда ук, «Пионер каләме» журналы җибәргән анкета сорауларына язган җавабында ул: «Мин үзем бу ел балалар өчен берничә кечкенә хикәяләр эшләргә сүз бирәм. Шуның өстенә ятим балалар тормышыннан зуррак бер хикәя язар өчен дә материал әзерләдем. Вакыт җитсә, анысын да эшләргә тотыначакмын» [1], — дип язган иде.

Һәм язучы, бу ниятен тормышка ашырып, «Совет әдәбияты» журналының 1934 елгы 5 һәм 7 саннарында «Балконлы йортта» исемле повестен бастыра. Анда, гражданнар сугышы чорында Идел буеның бер өяз шәһәрендә барган вакыйгалар сурәтләнеп, үзәккә балалар йортында тәрбияләнүче Хәлим образы куелган иде. Ул әсәр И. Газиның алга таба яктыртылачак зур материалга беренче кул салып каравы булып калды. Язучы вакыйганы Хәлимнең балалар йортындагы тормышы белән чикләмичә, гомумән Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы дәверендә яшь буынның язмышы турындагы әсәр итеп үстерергә ниятли, кечкенә героеның элеккерәк тормышына да күз ташлый. Нәтиҗәдә, «Хәлимнең яшьлеге» дигән киңрәк планлы әсәр барлыкка килә. 1940 елда «Совет әдәбияты»нда аның байтак кына өлеше басылып та чыга.

Әмма еллар үткән, язучының тормыш һәм иҗат тәҗрибәсе арткан саен, аның иҗади планнары да киңәя барды. Ул, үзенең нәни героен илебез тарихындагы иң кискен, иң катлаулы бер чорда биргәнгә, шул заманның сулышын да әсәргә кертмичә кала алмады, билгеле. Дәверне сурәтләү бурычы исә, үзеннән-үзе, тарихның әйдәүче көчен тәшкил иткән типларны бирүгә китерде. Шулай итеп, «ятим балалар тормышыннан зуррак бер хикәя» булып кына калмый, бәлки яңа тормыш төзү өчен барган көрәш эпохасын күпьяклы чагылдырган киң полотно булып үсә. Хәзер ул хәтта бер китап рамкасында гына чикләнми. 1949 елда басылган беренче китапка әсәргә этәргеч биргән момент — балалар йорты тормышы — бөтенләй сыймый кала. Һәм И. Гази, яңадан байтак еллар эшләгәннән соң, шул чор материалларын эченә алган икенче китапны 1962 елда укучыларга тәкъдим итте, ә 1966 елда әсәрнең өченче — соңгы өлеше дөнья күрде.

Капитализм чорындагы аерым кешеләрнең язмышларын күрсәтү белән башланып, кискен сыйнфый көрәш елларында бөтен Таулар авылы крестьяннары тормышын сурәтләүгә таба үсә барган хикәят икенче китапта инде үзенең рамкасын тагын да киңәйтә, бөтен бер өяз тормышын сурәтләүгә күчеп, урыннарда Совет властен ныгыту өчен киеренке көрәшнең күп төрле эпизодларын бирә, шул тарихи хәрәкәттә төрле катлау кешеләрен күрсәтә.

Әсәрнең драматик нигезен капитализм дөньясы белән революцион чынбарлык арасындагы гаять зур, кискен конфликт билгели. Бу конфликт шул чор тормышының күп төрле сферасын биләп алган: башта авылларда ярлы крестьян массасының алпавытка каршы җир өчен көрәше, кулаклар кабаласына каршы чыгыш төсендә гәүдәләнә ул, аннары гомумән азатлык өчен, Совет власте өчен көрәш булып үсеп китә. Әсәрнең икенче кисәгенә таба исә калалардагы политик тормышта да, экономик үсештә дә чагыла бу конфликт. Бер очракта ул турыдан-туры ярылып яткан каршылык төсендә гәүдәләнсә, һәм карашлар бәрелеше яки кораллы көрәш аша хәл ителсә, икенче очракта яшерен, астыртын хәрәкәт төсен ала, өченче очракта исә бу конфликт шушы катлаулы елларда аерым кешеләрнең үз күңелләрендә туган икеләнүләр, каршылыклар рәвешендә дә яши. И. Гази «Онытылмас еллар»да, әнә шул күп төрле каршылыкларның бөтенесен бер фокуска туплап, капитализм һәм социализм дөньялары арасындагы килешмәүчән кискен бер конфликт итеп гәүдәләндерә.

Повестьта күтәрелгән проблемалар бай образлар системасы аша хәл ителә. Анда күп төрле индивидуаль характер сыйфатына ия булган, төрле карашлы геройлар урын ала. Аларның һәркайсының шәхси дөньялары тегеләйме-болаймы гомуми иҗтимагый проблемаларга килеп тоташалар һәм шуны чишәргә булышалар. Автор үзенең персо-

---

[1] «Пионер каләме» журналы. 1933 ел. 4 сан 10 бит.

нажларын мөһим тарихи вакыйгалар эченә куеп, шул вакыйгаларга мөнәсәбәтләре аша аларга, әйтерсең лә, кискен сынау үткәрә, шулай итеп, тарихта бу геройның урыны ачыла.

Повестьта һәр геройның көрәш елларында гына була торган кискен үсеше күрсәтелә. Революция алар өчен политик чыныгу мәктәбе була. Беренче китапта Якуп Сатгаровның, әйтик, авылдан шәһәргә эш эзләп китеп, пролетар мөхиткә эләгүе, Ленин идеяләре белән сугарылуы һәм крестьяннарга политик аң таратучы булып җитешүе сурәтләнсә, икенче китапта инде аның, ревком председателе буларак, бөтен өяз күләмендә Совет властен ныгыту, контрреволюцион элементларга каршы көрәшне оештыру буенча эшчәнлегенә зур урын бирелә. Гади авыл егете Шәрифҗанның кыска гына вакыт эчендә революционер көрәшче булып формалашуы эпизодтан эпизодка ачыла бара. Революция елларында Миңнулла кебек крестьян массасы вәкилләре дә көрәш мәктәбен үтәләр. Үз кайгысын күз яше аша көлү белән каплап, мәзәк белән күнелен тынычландырып яшәгән ярлы Миңнулла җир өчен, авылда Совет властен ныгыту өчен көрәш мәлендә хәтта крестьяннарның җитәкчесе булып китә.

Әсәрдә сурәтләнгән вакыйгалар дәвамында иң зур үсеш алган герой — Хәлим. Башта язучы аны күп кенә тарихи вакыйгаларның шаһите итеп, социаль тормыш күренешләренең бала зиһенenә ничек урнаша баруын, аның кая таба үстерүен, характеры формалашуда нинди йогынты ясавын ачык буяулар белән сурәтләп бирә. Әсәрнең башыннан ук тарих дулкыннары аны үз эченә чайкалдырып алып кереп китә, һәм ул шул дулкыннарда чыныга бара, аның канаты ныгый, карашы формалаша. Башта интуитив төстә, соңга таба аңлы рәвештә теге яки бу күренешкә симпатия һәм антипатияләрен белдереп килгән Хәлим әсәрнең өченче китабында инде социализм өчен көрәшнең актив катнашчысы итеп күрсәтелә.

Геройның үсеш этапларына бәйле рәвештә, аны гәүдәләндерү ысуллары да үзгәрә бара. Беренче китапта, әйтик, Хәлим образын гәүдәләндерүдә көнкүреш планы шактый урын алган булса, икенче һәм өченче китапларда ул тулысы белән социаль планга күчереп сурәтләнә. Икенче китапта аның язмышы Якуплар алып барган ярсулы көрәшкә тыгызрак бәйләп чагылдырыла. Шәрифҗаннар отрядында йөрүе, каланы төзекләндерү өмәләре, саранчага каршы көрәш, фронт файдасына кием җыю, ашлык складларында сакта тору кебек гомуми-иҗтимагый вакыйгаларда сурәтләнеп, хәзер инде Хәлим тулысы белән социаль вакыйгаларның актив катнашчысы итеп гәүдәләндерелә. «Канатланыр чак» исемле соңгы өлеш исә тулысы белән диярлек Хәлим эшчәнлегенә багышланган.

Хәлимнең эчке кичерешләренең, күңел дөньясының нык ачылуында күп кенә картиналарның аның күзе аша үткәреп сурәтләнүенең әһәмияте зур. Ул, бер яктан, Хәлимнең күрү үзенчәлекләрен, дөньяга караш рәвешен, фикер йөртү куәтен ачса, икенчедән, бөтен повестька лирик агым алып керә.

Аерым геройларның эш хәрәкәтен һәм язмышын сурәтләү белән бергә, бу әсәрдә язучы халыкның җыелма образын бирүгә дә бик нык игътибар итә. Әсәрнең нигезенә зур социаль-политик конфликтны алу халык массасын иң актив көч итеп, күтәрелгән проблемаларны хәл итүче итеп сурәтләүгә китергән. Халык иң кискен моментларда алга чыгарыла. Мәсәлән, крестьяннарның җир өчен көрәшләрен биргәндә автор аерым персонажлар хәрәкәтен генә түгел, бөтен авыл халкын берьюлы күрсәтә. Шәһәрдә революцион көрәш картиналары, интервентлар белән бәрелеш эпизодларында халык массасы үзәктә тора, аның һәрбер хәрәкәтеннән җанлы тарих сизелеп тора. И. Газиның халык образын гәүдәләндерүдәге осталыгы бигрәк тә массачыл күренешләрне сурәтләүдә, массаның социаль портретын бирүдә ачык күренә. Я ул бөтен массага берьюлы яктылык бөрки, я шул масса эченнән «ябык йөзле, кискен хәрәкәтле», «бер кара бүрек», «кызыл йөзле, юан муенлы» дип характерланган аерым-аерым кешеләрне күрсәтеп-күрсәтеп ала.

И. Гази революция елларында массаларның күп төрле, хәтта каршылыклы төркемнәрдән торуына да басым ясый.

Язучы хәтта Казанда Татарстан автономияле республикасы төзелү унае белән уздырылган митинг кебек тантаналы вакыйганы сурәтләгәндә дә ике дөнья капмакаршылыгын күрсәтә алган. Бер якта — бөтен урамны тутырып, ташкындай барган эшчеләр массасы, партия җитәкчелегендә үзенең тарихи җиңүгә ирешүен чын күңелдән бәйрәм итүче халык, икенче якта — һаман да тарих арбасында үзенә урын алырга маташкан милләтчеләр, буржуа калдыклары, дин әһелләре өере. Менә шул ике группаны параллель күрсәтеп, И. Гази халыкның тарихтагы зур көчен чагылдыра, икенче төркемнең тарих тәгәрмәчен барыбер үз якларына бора алмауларын раслый.

Халык образын массовый күренешләрдә сурәтләгәндә, язучы массаларның төрле настроениеләрен берьюлы чагылдыручы полилог рәвешендәге сөйләмнәрне бик ачык куллана. Менә, әйтик, авыл җыены картинасында Гафиятнең яхшы җирләрне алпавыт алуы турында сөйләп, «шулай булгач, безгә ни кала?» — дигән соравына каршы төрле яктан тавыш күтәрелә:

— Безгә тау башы — малайларга чана шуарга!

— Ясмык булып, ясмык үсми бит безнең җирләрдә...

— Шайтан таягы үсә ич, ярамаган тагын сиңа!..

Һәрбер репликаны бик нык индивидуальләштерү аркасында, әңгәмәдәшләрне сыйфатлап тормаса да, И. Гази һәрбер сөйләмнең артында нинди характерлы һәм кайсы социаль төркемгә керүче кеше торганлыгын төсмерләтә. Югарыдагы репликаларның беренчесе, әйтик, үзенең начар тормышын усн-көлкс, шаянлык белән капларга тырышучы тарафыннан әйтелә; икенчесеннән чын күңелдән зарланучы, тормышыннан тәмам гаҗиз булган ярлыны ишетәбез, ә өченчесе исә — ярлы тәкәббер сүзләре...

Берниндн ремаркасыз бирелгән мондый репликалар бәрелеше әсәрдә драматик киеренкелекне тагын да арттыра. Әйтерсең лә, автор вакыйгалар дилбегәсен үз кулыннан бөтенләй җибәрә дә, бөтен вакыйганы халык массасы үзе алып бара. Бу күренеш халык массасының көчен, сурәтләнгән күренешләрдәге ролен тагын да ачыграк итеп гәүдәләндерә. Массовый күренешләрне әсәрдә актив куллану — хикәяләүдә типизациягә ирешүдә мөһим художество чарасы. Бөтен халыкның уй-фикерләрен, омтылышларын һәм бердәм хәрәкәтләрен бирми торып, шул чор вакыйгаларының мөһимлеген тулысынча ачып булмас иде.

Сурәтләнгән вакыйгалар дәвамында халык массасының идея ягыннан бик нык үсүен дә И. Гази күп төрле ситуацияләрдә күрсәтә. Башта әле Ленин турында ишетүләре белән генә горурланган крестьян агайлар соңга таба үзләренең фикерләрен аның сүзләре белән раслыйлар, чыгышларында юлбашчыны телгә алалар һәм политик тормышта аның карашларына таянып эш итәргә омтылалар, авыр моментта Ленинга сыеналар.

Катлаулы эпоханы киң итеп чагылдыру һәм онытылмас еллардагы халык язмышын күрсәтү максаты әсәрнең стилена да нык йогынты ясаган. Автор хронологик яктан үсә барган киң эпик хикәяләү формасын сайлаган. Бу иркен эпик хикәят халыкның күп төрле тормыш картиналарын да сыйдыра, аны бөтен тарих белән бәйләп күрсәтергә дә мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта, М. Горький, М. Шолохов әсәрләрендәге кебек, киң тормыш картиналарын тудыру кешеләрнең эчке дөньясын да тирән итеп бирү белән берләшә. Тик, әйтергә кирәк, өченче китапта бу эпик киңлек вакыйгаларны тәфсыйллап-детальләп сурәтләү белән ныгытылмый калган иде. Анда образларны характерлауда әһәмиятле роль уйнардай күп кенә мөһим моментлар өстән-өстән хикәя ителеп үтәләр, шуңа күрә бирелә эскизлылык төсе ике китап белән чагыштырганда, диспропорция күзгә ташлана. Бу хәл, ничектер, көзге кыраулар якынлаша башлагач, бакчачының кайбер куакларны ашык-пошыграк кышка әзерләвен хәтерләтә. Әмма, безнеңчә, әле бит бакчачыга күз ерак, һәрбер җимеш куагын җентекләп эшкәртергә аның көче дә, вакыты да җитәрлек...

Күләменең зур булуына һәм күпчелек әдәбиятчыларның «роман» дип атавына карамастан, И. Гази үзенең бу киң эпопеясын повесть дип билгеләгән. Ләкин аны без гадәттә күреп өйрәнгән повестьлар белән тиңләштереп булмый. Күтәргән һәм хәл иткән проблемаларның мөһимлеге ягыннан да, образларның күплеге һәм эшләнеш тирәнлеге

ягыннан да, тормышны сурәтләүдәге күп планлылыгы җәһәтеннән дә ул хаклы рәвештә роман дип аталырлык. И. Газида исә бу атама тарихи хикәят (повествование) мәгънәсендә алына һәм әсәрнең киң тормыш агышын тарихи хроника рәвешендә чагылдыруына ишарә ясап тора.

* * *

И. Газиның тормыш һәм иҗат юлы белән танышканда, ни өчендер һәрвакыт күз алдына мәһабәт Идел килеп баса. Идел буенда туып үскәнгәме, әллә бөтен геройлары да, үзе кебек, Идел егетләре булгангамы — тиз генә әйтүе дә кыен. И. Газины да, нәкъ Хәлимне утыртып киткән шикелле, Иделнең ак пароходы яр өстендәге балконлы детдомнан чакырып чыгарып, Казанга, зур тормыш юлына алып китә. Шуннан бирле ул үз геройлары белән утызынчы еллар төзелешләрендә дә була, Сөләймановлар белән бергә фронт сукмакларын да таптый, Габитовлар янында кара алтын елгасы чыккан җирдә дә яши. Ә Идел һаман аның күңелендә, ул аның әсәрләренә, улы өенә кунакка килгән ана кебек, кыю килеп керә һәм түргә, мактаулы урынга урнаша һәм нәтиҗәдә Туган ил образы булып күтәрелә.

Идел ага да ага. Аның тирәсен гөлбакчага әверелдерү өчен көрәшкән халыкның эшенә язучының да өлеше килеп кушыла. Җир күкрәгеннән алган ундырышлы суы белән шул туган туфракның үзен сугарган Иделдәй, И. Газиның халык тормышыннан илһам алып үскән иҗаты да туган халкының үзенә хезмәт итә. Идел ару-талу белми ага. Ә Казанның иң биек урыннарындагы бер йортта И. Газиның Иделгә таба караган тәрәзәсендә кичләрен ут сүнми.

——□——

*Фуат Вәлиев*

# ЧУПТАРЛЫ ҺӘМ АСАЛЫ ТУКЫМАЛАР ХАЛЫК СӘНГАТЕ ӘСӘРЛӘРЕ

Элек татар хатын-кызларына тормыш кирәк-яраклары өчен дистәләрчә аршын тукыма тукырга, озак вакытлар киндер сугу станы төбендә утырырга туры килгән. Моның сәбәбе ачык: авыл бары натураль хуҗалык белән көн күргән, крестьян үз хуҗалыгында эшләп чыгарылган продуктлар белән ихтыяҗларын канәгатьләндереп торган. Ул вакытта әле фабрик эшләп чыгарган тукымалар авыл җирендә бик аз күренә торган булган.

Чигү, каю кебек кул эшләренә бик һәвәс булган һәм менә дигән сәнгать әсәрләре иҗат иткән татар хатын-кызы туку һөнәрендә дә үзенең бөтен осталыгын, иҗади сәләтен күрсәтә алган. Гаҗәеп бизәкләре, күңелне рәхәтләндергеч төрлетөрле төсләре белән әсир итәрлек нинди генә әйберләр үтмәгән алар кулыннан: кызыл башлы сөлге, ашъяулык, тастымал, чаршау, чыбылдык, паласлар... Бу әйберләр өй эчен ямьләү, өйгә «кот кертү» өчен кулланылган. Яшь киленнең киявенә һәм киявенең кардәш-ыруларына дип алып килгән туй бүләге — бирнәсе дә, киленнең уңганлыгын, осталыгын күрсәтә торган күркәм әйберләр буларак исәпләнеп, бу әйберләр ил йоласына да кергәннәр. Кызыл башлы сөлгеләр ил күзендә бигрәк тә абруйлы булган. Сабан туйлары алдыннан яшь киленнәрдән янсә җиткән кызлардан сабан туй сөлгесе алу йоласы яшәгән. Сабан туйларында, мәйданга ямь биреп, көрәшүче, узышучыларны җиңүгә дәртләндереп җилфердәгән бу сөлгеләр азактан мәйдан тоткан батырларга, бәйгеләрдә алдын чыгучыларга ил бүләге итеп бирелгән.

Журналның үткән елгы сәхифәләрендә укучыларны без халык сәнгатенең башка төрләре белән таныштырган идек. Бу юлы шуның тагын бер төре — туку сәнгате хакында сүз йөртәчәкбез, бу һөнәрнең техник ысуллары, кораллары, материаллары, тукыма әйберләрнең сәнгатьчә эшләнеше, композициясе, колориты, бизәкләре хакында кыскача мәгълүмат биреп китмәкче булабыз.

Туку өчен гадәттә киндер һәм киҗе-мамык җеп кулланыла. Йон җеп сирәгрәк, аерым төр бизәкләрне сукканда гына кертелә. Җепләрне ману өчен башлыча табигый буяулар — төрле үлән сулары кулланыла. Унтугызынчы гасыр азакларыннан башлап ярминкә, базарларда ясалма — химик (анилин) буяулар да күренә һәм туку эше осталары тарафыннан файдаланыла башлый.

Киндер сугу станының безнең халык арасында өч төрле тибы очрый. Боларның өчесенең дә төзелеше, детальләре һәм борынгы гади формалардан соңгы дәвернең катлаулы формаларына хәтле ни рәвешле үзгәреп, камилләшеп килүе этнографик әдәбиятта инде шактый тикшерелгән. Профессор К. И. Воробьев, Р. Г. Кузеев, М. Г. Бикбулатов һәм башка галимнәрнең хезмәтләрендә Идел-Урал буе халыкларында (татар, башкорт, чуваш, рус, удмурт, мари, мордва) очрый торган туку станы төрләре Себер, Казагыстан һәм Урта Азия халыкларыныкы белән чагыштырылып, кызыклы тарихи күзәтүләр ясалган. Безгә бер нәрсә ачык: Казан татарлары һәм аларның бабалары туку һөнәренә бик борынгы заманнарда ук ия булганнар.



Алача тастымал.

Археологик тикшеренүләр безгә болгарларда туку эшенең алга киткән булуы турында сөйли. Туку эшенең техникасы һәм коралларына караган атамаларның — терминологиянең бик җентекләп эшләнгән булуы да моның тамыры бик ерактан килүе һәм мөстәкыйль рәвештә үсүе, үзяшәешлелеген раслый.

Татар көнкүрешендә иң күп кулланылган һәм иң күп сугылган тукыма төрләреннән алача тукымаларны күрсәтергә кирәк. Ашъяулыклар, тастымаллар, чаршаулар гадәттә алачадан була. Алача киемсалымга да тотыла: күлмәк-ыштан, алъяпкычлар алачадан тегелгән.

Алачаларның буенда да, аркавында да төрле төстәге җепләр, билгеле бер тәртип белән буй-буй булып чиратлашып килеп, төрле-төрле, чуар (юкка гына «алача», ягъни ала, төсле-төсле димәгәннәр) шакмак рәвешендәге бизәкләр ясала. Боларда кызыл, көрән, акбүз, яшел, күк, зәңгәр, кара төсләрнең һәрберсе бер-берсе белән янәшә килергә, бик килешле, матур булып керешеп, ярашып китәргә тиеш була.

Шакмакны вак итеп тә, эрерәк итеп тә сугарга була. Казан арты районнарында алачаны күбрәк вак шакмаклы итеп, көньяк-көнчыгыш районнардагы, Урал якларындагы татарларда эре шакмаклы итеп суга торган булганнар.

Алача сугу әллә ни катлаулы булмаса, бизәкләп тукуның башка төрләре — чуптарлап сугу, асалап сугу кебекләре катлаулырак. Чуптарлы һәм асалы әйберләр көнкүрештә киң кулланылган. Кызыл башлы сөлгеләр, ашъяулык, палас, чаршау, тастымал кебек әйберләр шушы техник алымнар белән сугылган. Аса, чуптар дип йөртелә торган тукыма бизәкләр, туку техникасына буйсындырылганлыктан, киртләч-киртләч геометрик фигура рәвешен алганнар. Алар арасында ромбалар да, X, Z рәвешендәгеләр дә, хач яисә йолдыз сыман фигураларны да еш күрергә була. Аларның бер бөтен композициягә тезелү, теркәлү формалары да күп төрле: я бер-берсе белән кисешәләр, яисә йомык хәлдә бер үзәк эченә камалып, катлы-катлы булып киләләр.

Геометрик бизәкләрнең реаль чынбарлыктагы нинди күренешләрне чагылдыруын бүгенге көндә инде белеп булмый. Бәлки, кайчандыр бер заман алар реаль мәгънәгә дә ия булганнардыр; гасырлар буе килә-



Асалап сугылган сөлге башы.


килә ул мәгънәләре онытылган, б́ары бизәк кенә булып кабул ителгәннәрдер.

Асалап сугылган тукымалар бигрәк тә үзенчәлекле. Аса төрле-төрле төстәге аркау көреләре белән сугыла, һәр бизәк өчен үз төсендәге көре сайлап барыла. Аса ясый торган аркау көреләр буй көреләргә кыстырылып, аны каплап бетергәнлектән, бизәк тукыманың уң һәм тискәре ягыннан да ачык беленеп тора торган булып чыга.

Асалы тукымаларның иң күркәме — кызыл башлы сөлгеләр — җете төсләргә бай гаммасы, бизәкләре, геометрик мотивларның һәм аларның тезелү-урнаштырылу рәвешләренең гаҗәеп төрлелеге белән күңелне әсир итә. Җирлек җете кызыл төстә, асасы исә яшел, сары, зәңгәр һәм башка шундый төсләрдә була. Татар халык сәнгатенә хас төрле төсләр яратучанлык, буяуларга байлык асалы тукымаларда бөтен тулылыгы белән чагыла. Композициясе бик килешле төзелә, гадәттә берничә (үзәктә яки як-якта) орнаменталь буйдан тора. Һәр буйда ике-өч геометрик бизәк булып, алар билгеле бер тәртип белән чиратлашып киләләр, кабатланалар. Бу буйлар тар да, киңрәк тә булырга мөмкин. Буйлар исә шулай ук бер-берсе белән яраша: гадәттә алар я бер-берсенә каршы куелалар, яисә аерым бизәкләр билгеле бер ритм белән кабатланырга мөмкин.

Казан татарларының көнкүреш сәнгатендә чүпләмләп — чуптарлап сугу техникасы белән тукылган әйберләр дә зур урын алып торган. Чүпләмле сөлгеләр ике төрле төстәге — кызыл һәм акбүз җепләрдән тукыла. Кызыл — аркау көре, акбүзе — буй көре була. Бу төр тукыманың уңы-тискәресе булмый, кайсы якның уң яки тискәре булуы бар тик төс ягыннан гына аерыла. Уң якта акбүз җирлек өстендә кызыл чүпләмнәр хасыйл була, тискәре якта исә, җирлек кызыл булып, чүпләмнәр (чуптарлар) ак булып чыга.

Төрле-төрле төстәге чуптарлы тукымалар сугуның техникасы тагын да катлаулырак булган, зур осталык, игътибар һәм күп вакыт таләп иткән, шуңа күрә аны тәҗрибәле хатын-кызлар гына башкара алган. Монда яшел, ал, сары, зәңгәр төстәге буй көреләрне нәкъ шул төстәге чуптар килер-



Чуптарлап сугылган сөлге башы.

гә тиешле урынында гына чүпләп, сайлап сугарга кирәк булган. Өч, дүрт, алты, сигез һәм аннан да артыграк көре белән сугылган ашъяулык, чаршау, тастымал башлары да очрый. Бизәкләп туку техникасының бу төре дә бик катлаулы, четерекле һәм шуңа күрә чагыштырмача сирәк кулланыла. Мондый тукымаларда бизәк, чигүләрдәге шикелле, күпертмәле, рельефлы булып килеп чыга.

Чуптарлы тукымаларның бөтен төрләрендә дә без геометрик бизәкләрнең төрле формаларын очратабыз, халыкның фантазиягә байлыгын күрәбез. Гаҗәеп күп төсле булулары белән алар татар өенә ямь кертәләр, күңелгә көрлек тойгысы бирәләр.

XIX гасырның икенче яртысыннан башлап, татар авылының товар-акча мөнәсәбәтләренә тартылуы нәтиҗәсендә, өйдә сугылган тукымаларны куллану кысылганнан-кысыла барган һәм кулдан туку һөнәре үзенең элекке әһәмиятен югалткан. Кустарь кәсепчелек рәвешендә яшәү омтылышлары да булмаган түгел, мәсәлән, элекке Норлат һәм Әтнә волостьларында кул хезмәтенә нигезләнгән мануфактуралар булып, комач һәм төрле-төрле бизәкле тукымалар эшләп чыгарып торганнар.

XX гасырның 10—20 елларыннан бирле инде өйдә туку һөнәре бөтенләй диярлек бетүгә йөз тота. Казан артында һәм Татарстанның көнчыгыш районнарында асалы палас һәм башка шуның ише кайбер нәрсәләрнең сугылуын исәпкә алмаганда, бүгенге көндә инде туку сәнгате яшәүдән, үсүдән туктаган. Безгә, хәзерге буын кешеләренә, бары тик моннан 60—70 ел элек сугылган әйберләрне генә күреп канәгатьләнергә туры килә. Сандык төпләреннән шундый әйберләрне чыгарып, бәйрәм көннәрендә өйләрен бизи торган олы буын кешеләр авыл җирләрендә әле бүгенге көндә дә бөтенләй юк түгел. Әйе, чын сәнгать беркайчан да онытылмый да, туздырылмый да, гамәлгә яраксыз бер нәрсәгә әверелеп югалып та калмый. Борынгы әсәрләр һаман да безне тәэсирләндерәләр, сокландыралар. Бу иске әйберләрдәге бизәкләү сәнгате алымнарының гомерен тагын да озынайтырга, хәзерге көнкүреш өчен файдаланырга мөмкин булыр иде; әйтик, фабрикалар күпләп эшләп чыгара торган диван мендәрләре, декоратив сөлгеләр, гардина тукымаларының (тәрәзә пәрдәләре) эскизларын эшләгәндә рәссамнарыбыз халкыбыз сәнгате хәзинәсенең классик өлгеләреннән күп нәрсәгә өйрәнә алырлар иде. Гасырлар буе халыкның эстетик зәвыгын канәгатьләндереп килгән, күп санлы гүзәл әсәрләр калдырган туку сәнгатебез моңа, һичшиксез, лаек булган зур мирас ул.

Роберт Батуллин

# Бүген концерт була

*Юл язмалары*

Күз ачкысыз буран.

Артистларны озатырга дип клуб янына җыелган колхозчыларның күбесе безне чын күңелдән кызгана:

— Мескеннәр, ничек кенә барып җитәрсез икән! — диләр.

Икенчеләре артист бакчасына таш ыргыта: тормышмыни бу, янәсе, чегәннәр кебек күчеп йөриләр...

Бу очракларда без дәшмибез. Артистларны бары бер нәрсә борчый: юл! Ун-унбиш чакрым араны адашмыйча үтеп, ничек булса да кичке концертка өлгерү!

— Атлар яхшы, күз ачып йомганчы илтеп җиткерерләр! — ди арадан бер колхозчы.

Боегып кына чанада утыручы артистларга шушы сүз өмет өсти.

Кузгалабыз.

— Хәерле юл сезгә! — дип калалар Чынлы колхозчылары.

Якты утлары, җылы мичләре, кайнар ашлары белән йортлар кар эчендә тиз югалалар. Мин колхоз председателе биргән толып чабуы белән аякларымны каплап, олаучыга сыенып утырган килеш, үземне сүгә-сүгә барам. Филармония артистлары белән гастрольгә чыгуыма үкенеп бетә алмыйм. Казандагы җылы фатирымда гына ятсам ни булган иде соң?!

Юл газабы — гүр газабы, ди.

Аңламыйм! Концертыбызда катнашучы сигез артистның сигезен дә аңламыйм мин! Ничәмә еллар тәгәрмәч-чана өстендә йөреп туймадылар микәнни?! Калада җылы урын табып, рәхәтләнеп шәһәрнең бар ләззәтен татып кына яшәрдәй кешеләр! Шушы тормышны сайлаганнар бит!

— Туңасың бит, төшеп йөгер!

Моны минем белән бер чанада утырып баручы артист, оригиналь жанр остасы Габделхәй абый әйтә. Ул тәҗрибәле кеше. Казаннан ук калын киенеп чыккан. Рәхәтләнеп авыз эченнән генә моңланып бара. Ә мин аягымны япсам, баш ачыла. Бәркәнсәм, аякларым туңа. Еларга җитешеп, артист профессиясен әрлим. Кая ди ул

төшеп йөгерү, кыймылдарга да куркып утырам. Берничә мәртәбә кабатлаганнан соң, Хәй абый мине төртеп төшерде. Мин өлкән артист адресына бер-ике әче сүз әйттем. Тик буран ул сүзләрне Хәй абыйга ишеттермәде бугай. Толып чабуына урала-урала, мин ераклаша баручы чана артыннан йөгерергә мәҗбүр булдым.

— Тәртәгә ябыш! — ди тәҗрибәле артист.— Тәртәгә ябышсаң, армассың!

Тәртәгә барып тотынам. Ат белән янәшә чабам.

— Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап... На, бахбай!

Монысын алгы чанада баручы баянчы кычкыра. Чанадагылар шырык-шырык көләргә тотыналар. Янәсе, юмор! Бала-чага кебек үчекләшеп баралар.

Атның сулышы миңа бәрелә. Ул әледән-әле башын борып карый. Аның күзләрендә үземә карата кызгану сизәм. Хайван хәлем мөшкел икәнен тоя кебек. Кинәт ат белән бергә икәүләшеп көрткә чумабыз. Кардан чыгып, мин чанага килеп авам. Кучер юл катысын капшый. Туңа төшкән артистлар чана тирәли сикергәлиләр. Безне арттагы атлар куып җитә.

— Тайпылдык, ахры!

— Уңга китәргә кирәк иде... Бу кар тотучы трактор эзе бугай.

Бәхәсләшә торгач, олаучылар бер фикергә килеп, атларны уңга бордылар. Бераз баргач, тагын юлны югалттык. Концерт башланырга бер сәгать калып бара. Кайчан барып җитәрбез, анысын алла белә. Җил ачынып-ачынып кар ургыта. Атлар җилгә яннарын куеп торалар. Җил ат ялларында, койрык кылларында ямьсез көйләр уйный. Шаярулар бетте. Артистлар дәшми. Буран эченнән трактор герелдесе ишетелгән сыман... Күршем кулындагы кесә фонарен бер яндырып, бер сүндереп сигнал бирә. Эзли чыгучылар өчен! Концертка ярты сәгать калды... Без юлсыз җирдән барабыз да барабыз. Әллә кая барабыз!

Ике фара яктысы күңелләргә җылы сирпи...

Без турыдан-туры клубка! Халык җыелган. Көтә. Чыгышлары алдарак булган артистлар сәхнә киемнәрен киләр. Калганнары кайнар мичне сырып алалар. Ярый әле бу авылда клуб җылы. Кайбер авылларда ягылмаган сәхнәдә күлмәкчән уйнарга туры килгәли.

Менә пәрдә ачыла, кара буранда адашып кала язган сәнгать клуб сәхнәсеннән тамашачы күңеленә барып ирешә.

## Сәхнә артында уйланулар

Яшерен-батырын түгел, мин үземдә элек бу артистларга карата әллә ни хөрмәт хисе сизми идем. Тик, очраклы рәвештә, шушы артистлар белән юл йөргән вакытлардан соң гына мин үземнең ялгыш фикердә булуымны аңладым. Дөрес, бу группада кайчандыр дан тотып, шөһрәт югарылыгында булып та, хәзер кризис кичерә торганнары да бар. Бу тормыш һәм сәнгатьнең рәхимсез законы инде. Мине төшенерләр дип уйлыйм. Шулай да мин аларны яратып өлгердем.

Сәхнәдә баянчы. Клуб һавасы шулкадәр дымлы, баян басмалары бүртәннәр, бармаклар тиеп киткәнгә дә баталар. Баянчы бер октавада гына уйнап чыгарга тырыша.

Нух пәйгамбәр заманыннан калган мәчет искергән, кыйшайган. Бүрәнә ярыклары сыкы кунган. Бүгенге көн кадагына суга торган плакатлар да, кыек-мыек язылган өндәү җөмләләре дә, хәтта космоска очучы ракета сурәтләнгән үтә замани картина да бу борынгы бинага заман рухы кертә алмаган. Клуб мескен хәлдә. Ә колхоз егәрле. Үзешчән коллективлар һәм килгән артистлар өчен элементар уңайлыклары булган клуб салырлык акча колхоз казнасында бардыр, дип уйлыйм. Тик... Сәхнә артында киемнәр эләргә кадак таба алмыйча теңкә корый.

— Фатир мәсьәләсе иң мөһим мәсьәлә, дип уйлыйм мин. Килеп төшкәннән соң, сәгать-сәгать ярым фатир эзләп үтә. Тапканы сиңа ошамый. Яки киресенчә. Кайбер колхозларның гостиницалары бар...

Баянчыдан соң бию. Биючебез чемоданнан яңа гына алган, бөтәрләнеп беткән костюм-чалбарын җилфердәтә-җилфердәтә сәхнәгә узды.

Сәхнәгә халтурачылар кирәкми дибез!

Бүгенге хәлдә биючебезнең һичбер гонаһы юк!

Авыл сәхнәсенең примитив шартлары ирексездән халтурага илтә торгандыр! Костюмның утүкләнмәгән булуы, клубларда яктырткыч приборларның бөтенләй булмавы, чишенү-киенү бүлмәсенең тарлыгы, муенга тач-точ тамып торучы тамчы концертның нәфисләгән кыйммәтә.

Иҗади хезерлек өчен кыен шартларга, юлда күргән бимазаларга карамастан, артистлар зарланмыйлар. Алар һаман җор сүзләләр, бер-беренә шаян-төртмә сүзләр ычкындыралар. Алар үзләре белән булган аяныч вакыйгаларны да көлке итеп сөйләп, эчне катыралар:

— Нәкъ шушы клубта, моннан 8—10 еллар чамасы бардыр, спектакль уйныйбыз. Җәй көне иде. Клуб шыгрым тулы. Сәхнә мунча ләүкәсе кебек. Дулкынланабыз. Спектакльнең сыйфатын тикшерергә режиссер килгән икән дигәч, дулкынлануыбыз каушауга күчте. Режиссер бик усал нәмәрсә иде, каһәрең. Чыгышыңа соңга калсаң — бетте баш! Бәхетсезгә җил каршы дигән сыман, мин нак раз шул көнне фатир хуҗасының кайнамаган сөтен эчеп, эч шәрифләрен бозган идем. Башладык спектакльне. Эч, мин сиңа әйтим, бора гына бит. Кая керер тишек тапмыйм. Зал аркылы чыгу турында уйларга да ярамый. Халык. Артта артистлар өчен ишек юк. Нишләргә? Актык чиктә тәрәзәне алып, бакчага сикерергә мәҗбүр булдым. Туп-туры патша җаяү йөри торган урынга! Тәрәзәгә генә килеп җитәм, малай, кире борылырга туры килә. Щукэр карт шикелле, байтак таптадым ике араны. Режиссер ярдәмчесе кычкыра, соңга каласың, соңга каласың! Мине көтеп тамашаны туктатырга мәҗбүр булдылар. Ну эләкте дә соң режиссердан үземә. Ул мине орыша, мин эчтән генә клуб салучыларны сүгәм. Артистларны фәрештә дип белделәрмикәнни соң! Нинди мөһим нәрсә турында онытканнар. Чын-чын!

## Директор, балалар һәм без

Көн аяз, юл яхшы. Колхоз машина бирде. Тәялдек. Кузгалабыз гына дип торганда, пальто өстеннән плащ кигән ир кеше машина каршысына килеп басты.

— Туктап тор әле! — диде ул шоферга. Һәм безгә борылып,— администраторыгыз кем була? — дип сорады.

Группа җитәкчесе кабинадан башын тыгып:

— Мин булам, ни йомыш? — дип үзен таныштырды.

— Иптәш администратор! — Ир кеше машина басмасына сикереп менде.— Мин шушы авыл мәктәбенең директоры булам... Балаларга концерт куеп китә алмассызмы?

Артистлар бер-берләренә карап алдылар. Мин бу сүзсез сөйләшүнең мәгънәсен яхшы төшендем.

— Баш катырма әле! — дигән сүз иде ул.

Җитәкчебез көлеп үк җибәрде.

— Сез, иптәш директор, бала-чага кебек... күрмисезмени, без китеп барабыз... Кичтән сөйләшергә кирәк иде...

— Кичтән РОНОда идем, кайтып кына килүем... Зинһар, иптәш администратор, балалар сорыйлар!

Без ул төртеп күрсәткән якка борылып карадык. Мәктәп капкасы янында укытучылар, укучылар җыелып басканнар.

— Что сез, безнең юлга чыгасыбыз бар, кичен концерт! Аннан соң балаларга расчитанный программабыз да юк!

Директор соңгы елларда балаларга концертларның сирәк булуы турында сөйләп маташты. Ул администраторга ялынып та, ялварып та, хәтта газетага язуы белән куркытып та карады. Тик администраторны күндерү мөмкин түгел иде. Чөнки балалар концерты ярты нормага туры килә, аннан җыйган акча да финанс әһелләрен канәгатьләндерми. Аннан соң, гомумән, көнгә ике концерт куюы артистлар өчен дә бик авыр. Берничек тә барып чыкмагач, директор әмәтен өзеп, мәктәп ягына китеп барды. Аның йөзе ачулы, иреннәре кысылган, иңнәре ихтыярсыз салперәгәннәр иде.

Мин аны шулкадәр кызгандым. Директордан битәр балаларны кызгандым. Үзе көндерә алмагач, балаларга әйтте бугай, уннарча укучылар машинаны сырып алдылар.

Машина кузгалды. Ләкин балалар без борылмада югалганчы таралмадылар. Әллә эчтән генә кире беткән артистларны сүгәләр инде?! Бәлки машина кире борылыр әле дип өметләнгәннәрдер?

Аларның берсе генә дә безгә кул болгамады.

Кече Шәйморза авылы артта калды.

## Нәгыйм һәм стакан

Зур Шәйморзага кергәч ук — безнең бәлдерү. Бәлдерү башында ук «Балалар кертелмиләр!» дигән язу.

— Абый, дересме ул, кич белән безне кертмиләр икән? — дип сорый Нәгыйм. Нәгыйм минем фатир хуҗасының малае.— Мине алып бар инде син, абый, ямә!

Ни әйтергә дә белмим. Алып бармасаң, читен — хуҗа улы. Алып барсаң, ярамый — педагогика! Мин авыз эчемнән генә укучыларга барырга ярамаганлыгы турында мыгырданып, ял итеп алу өчен, урынга яттым. Озак та үтми, кемдер мине уята.

— Абый, тор инде!

Бу Нәгыйм иде.

— Чәй әзер! Соңга калабыз!

Мин Нәгыймнең очкыннар атып торучы күзләренә, шат йөзенә карыйм.

— Тор! — дип кабатлый малай.— Мин сиңа бүләк алып кайттым!

Өстәл артына кереп утыргач кына бүләкнең ни икәнен күрәм. Нәгыйм миңа стакан суза.

— Мә! Үндүрт кырлы стакан. Әле генә кибеттән алып кайттым.— Җиде тиен.

Нәгыйм ат бүләк иткәндәй миңа карый. Мин елмаям. Һәм бүләкне шатланып кабул итәм. Кунак ашы кара каршы, ди! Мин дә Нәгыймгә китап бүләк иттем. Шулай итеп, минем Шәйморзада яңа дустым артты. Тик кич белән, концертка җыена башлагач, безнең арадан кара мәче йөгереп узды. Нәгыйм белән Алсу да киенергә тотындылар.

— Чишенегез, абыегыз барырга ярамый, диде бит!

— Әти, без качып кына карарбыз, укытучыларга күренмәбез!

Мин Нәгыймнең күңеле тулганын сизәм. Ул күзләренә килгән мөлдерәмә яшьләрен кире йота. Ирен кырыйлары ирексездән калтырыйлар. Алсу өлкәнрәк. Ул бу кайгыны ирләрчә кичерә. Һәм дәшмичә генә чишенә башлый.

Аларны юатырга тырышып мин:

— Сезгә барырга ярамый кичке концертка! — дидем.

Нәгыйм кинәт кенә итекләрен мич арасына томырды да алгы өйгә кереп, тиз генә кире чыкты.

— Мә! — Нәгыйм көндез бүләк иткән китапны миңа ыргытты. Ул күз яшьләрен җыйган. Хәзер ул кыерсытылган малай түгел, ачуы чыккан ир кешегә охшаган иде.

— Ал бүләгеңне. Безнең китапханәдә дә андый китаплар дачурта!

Мәсьәлә кабыргасы белән куелган иде. Мин каушап калдым. Шушы кечкенә малай каршында мин үземне гаепле кеше сыман хис иттем. Баланы нәрсәдәндер мәхрүм иттем шикелле. Әйтерсең лә, бу миннән генә тора!

Мин бу вакыйганы онытырга тырыштым. Ләкин малай күңелемне нык дулкынландырган иде. Бу турыда артистларга сөйләдем. Сөенечемә каршы, җитәкчебез дә, группа да балаларга иртәнге концерт бирергә риза булдылар. Бу бәлдерүне ата-аналар да, укытучылар да кул чабып каршы алдылар. Шундук артистларыбыз иске репертуарларын кузгатып, балалар өчен җырлар, хикәяләр эзләп табып, кабатлый башладылар.

Без кайтканда, Нәгыйм белән Алсу чишенмәгән килеш йоклыйлар иде. Ятар алдыннан, гадәттәгечә, хуҗалар белән чәй эчтек. Тик мин үндүрт кырлы стаканны күпме генә эзләсәм дә таба алмадым.

Икенче көнне иртән клуб балалар белән шыгрым тулы иде. Концерт башланды. Такта ярыгыннан тамаша залын күзәтергә тотындым. Алсу белән Нәгыйм иң беренче рәттә утыралар...

Күзләр, күзләр...

Комсыз, кызыксынучан, тирән күзләр!

Бу күзләрнең берсе генә дә буш түгелләр!

Баш ияргә сәхнәгә бөтенебез дә чыктык.

Саубуллашу билгесе итеп, җырчыбыз җырлап җибәрде. Бөтен зал җырны күтәреп алды. Без укучыларга җырлыйбызмы, укучылар безгәме?!

Һәрвакыт булсын кояш!
Һәрвакыт булсын әни!

Һәм кайсыдыр үткен сүзлесе залдан бөтенебезне уздырып:

— Һәрвакыт булсын концерт! — дип кычкырды.

Концерттан соң туп-туры икенче авылга китәбез. Атлар әзер. Безнең якка таба кул болгый-болгый чабып килүче малайны күрдем: бу Нәгыйм иде.

— Абый, мә стаканыңны! — диде ул чанага килеп җиткәч. Мин кире кайтарылган бүләкне кабул иттем. Артистлар бу вакыйганы беләләр иде инде. Көлеп җибәрделәр. Ләкин Нәгыйм аларга игътибар итмәде.

— Син абый, китабыңны бир инде! — диде ул.— Мин мәктәпкә соңга калам! Китапны үзләре өендә калдырганымны әйттем. Нәгыйм тиз генә варигасын (бу якта бияләйне шулай диләр) салды да ялт итеп кулын миңа сузды.

— Тот бишне, абый, рәхмәт!

Малай иптәшләренә кушылды. Без кузгалдык.

— Тагын килегез, ямегез!

Капка төбенә җыелган нәни тамашачылар безгә кул болгап калдылар.

## Коллегалар

Безнең концерт буласы клубта курчак театры белдерүен күреп, гаҗәпкә калдык. Бер көнне бер клубта ике тамаша!

Курчак театры артистлары буранда адашып, юлда калганнар икән. Алар көч-хәл белән генә гостиницага кереп ял итәргә егылдылар.

— Ике көн инде,— ди клуб мөдире,— ике көн курчак театры була дип, балаларны клубка җыябыз. Җыелалар да таралалар. Әле бүген дә клубта көтәләр.

Артистлар мөдирнең ризасызлыгын аңлыйлар. Тик нишләмәк кирәк — буран бит! Бераз җылынып алганнан соң, алар клубка китәләр. Без дә, курчак тамашасы карарга дип, аларга иярәбез.

Мин тамашачылар арасына кереп урнаштым. Янәшә утырган малайларның бәхәсләшкәннәренә колак салам.

— Монысы ничек икән? Ну, узган елгы «Шомбай курае» шәп булган иде...

— «Шомбай курае» узган ел түгел, өченче ел килде, белдеңме?

— Узган ел инде...

— Узган сиңа... Без аны караганда дүртенчедә укый идек!

— Тсс, башлана!

Кечкенә фонарьларның ширмага ут сирпүе булды, зал шып тынып калды.

Яшел, кызыл, зәңгәр утлар...

Әкияти музыка астында талгын гына пәрдә ачыла.

Кечкенә курчак сәхнәсенең матур төсләргә бай булуыннан, мавыктыргыч, тылсымлы вакыйгалар вәгъдә итә торган декорацияләрне күреп, зал бердән аһылдап куя. Балалар гына түгел, мин дә күңел кытыклануы белән тамашаны көтәм. Балалар белән мин дә хыялымы әркылы әкияти, матур, маҗаралар дөньясына китәм.

Тәнәфес вакытында мин сәхнә артына кердем. Артистлар арасында миңа таныш булмаган туташ нидер сөйли иде:

— Балаларга караганда укытучылар үзләре кызыксынып карыйлар! — диде әлеге туташ. Укытучы яки пионер вожатыедыр инде, дип уйлыйм.— Тик сирәк киләсез бит. Зарыктырасыз. Бала мәктәпне тәмамлаганчы, күп булса, ике-өч спектакль карап кала... Диңгездән бер тамчы.

Артистларның мондый зарларны укытучылардан кырыкмаса кырык ишеткәннәре бар инде. Дәшмиләр.

— Соң, уйлап карагыз,— дип дәвам итә туташ. Чая кыз. Сөйләгәндә ачынып-ачынып, нәрсәдер исбат итәргә теләгән кебек, янып сөйли.— Әхлаки-әдәп тәрбиясе! Эстетика, дип кычкырабыз. Мескен мәктәп бер үзе генә бу мәсьәләләрне күтәрә алмый бит! Сәнгать мәктәпкә ярдәмгә килергә, безнең коллегабыз булырга тиеш бит!

Чукынып китим, бу кыз миңа ошый! Яшь педагог бүген генә туган фикерен сөйләми. Кайчандыр, кем беләндер бу турыда күп мәртәбәләр сөйләшеп, бәхәсләшеп, нык формалашкан проблема турында сәнгать кешеләренең үзләренә чәчми-түкми сөйләргә дип кергән бу кыз.

— Ике елга бер спектакль күрсәтеп кенә бала күңелендә сәнгатькә карата мәхәббәт уятып булмый бит! Курчак театрыгыз сагындырып кына килә. Яшьләр театрының бу якка бөтенләй килгәне юк...

Бирерә әңгәмәгә курчак театры артисты катнашып китә.

— Туташ! — ди артист.— Менә мин сезгә гади арифметика мисалы чишеп күрсәтәм. Татарстанда курчак театры килеп уйнарлык авылларның саны ярты мең чамасы. Без сезонга 200—250 ләп спектакль бирә алабыз. Ягъни елларны, юл өзеклекләрен исәпкә алсаң, гастрольләрдә йөреп, бер спектакльне күрсәтеп бетерү өчен, без өч ел йөрергә тиешбез...

— Ә нигә ике группа белән йөрмисез?

— Группа бер генә булганга!

— Шундый күп тамашачыга бер генә группа? Нигә алай соң ул?

Кыз җавап алып өлгермәде, спектакльгә чакырып кыңгырау шалтырады. Кыз үз урынына кереп утырды. Миңа аның тәкәббер, ләкин таләпчән профиле генә күренә. Табар ул биргән соравына җавап, табар, дип уйлыйм. Тапканчы эзләр. Күрәсең, ул чын педагог!

Кич белән коллегалар безнең концертка килделәр.

Без булдыра алганча, җае чыккан саен, көндезге концертлар бирә башладык. Билгеле, моңа кадәр дә көндезге концертлар тәҗрибәдә булган хәл. Тик алар сирәк, очраклы күренешләр кебек тоела миңа. Филармония, концерт бригадалары күп булуга карамастан, елга 200 ләп кенә концерт бирә. Меңгә якын мәктәп өчен бу чүп кенә!

Көндезге концертлар башланыр алдыннан мин һәрвакыт пальто өстеннән плащ кигән мәктәп директорын искә төшерәм. Русча әйтсәк, неужели инде ул, директор, һәр килгән труппага ялварып, ялынып йөрергә тиеш икән?!

Шулай булса, бик мөшкел бит синең эшләрең, директор абый!..

## Ана сөте һәм тана сөте

...Авылга кечкенә оркестры булган балалар концерты килә. Сәхнәгә мөлаем генә апа чыга. Һәм балаларны музыка кораллары белән таныштыра башлый.

— Балалар, менә бу кларнет дип атала...

Шул чак музыкант кларнетта соло уйнап күрсәтә.

— Кларнетның тавышы курай тавышын хәтерләтә, ишетәсезме. Кларнет кош авазларына охшаш тавышлар да чыгара ала. Менә монысы саксофон...

Мөлаем апа инструментлар белән таныштырганнан соң, музыка тыңларга тәкъдим ясый. Оркестр уйнаган вакытта апа балаларга музыканың нәрсә сөйләгәнен аңлатырга тырыша, нәниләрнең фантазиясен кузгатырга омтыла.

Икенче килгәндә апа музыка жанрлары турында сөйли.

Бала кечкенәдән үк музыка сәнгатенең ни икәнен белеп үсә. Мондый тере лекцияләрне тыңлаган бала, үсмер булгач, «опера» сүзеннән коты очып качмас иде.

...Мәктәпкә яшь тамашачылар театры килә. Аның репертуарында бүген мәктәптә үтелә торган классик язучыларның әсәрләре бар. Спектакльдән соң тере Чичиков, тере Катерина, тере Тукай белән әңгәмә башлана. Актерлар театр сәнгате, рольләр-образларның ничек тууы, актер хезмәте, режиссура һ. б. лар турында сөйлиләр.

Елга ике-өч мәртәбә генә шушы очрашуларны, шушы тамашаны күргән кеше драма театрының югары художестволы спектакльләрен караганнан соң, аларга примитив бәя бирмәс иде.

«Бәйрәм кичендә», «Җиргә тапшырылган серләр» кебек фәлсәфи әсәрләргә, күңелне дулкынландыргыч спектакльләргә халык активрак йөрер иде.

Башлангыч белемсез урта мәктәп тәмамлап булмый!

Урта белеме булмаган кеше институтта укый алмый!

Сәнгать серләре яшь чактан ук даими рәвештә аңлатылмаса, сакаллы булгач кына кеше симфоник музыканы, опера сәнгатен һәм катлаулы драматик әсәрләрне аңлый алмастыр!

Ана сөте белән кермәгәнне тана сөте белән кермәс! ди халык! Шул тәрбияне алмаган кеше сәнгатьнең шедеврларын, фәлсәфәсен аңлый алмый һәм аңларга да теләми. Андый кешегә гади сюжетлы, идеясе артык өстә яткан җиңел комедияләр, күздән яшь чыгара торган арзан мелодрамалар һәм халтурага якын торган әсәрләр ошыйлар.

Ул кеше берьяклы, тар карашлы булып кала.

*«Мәктәп тормышында эстетик тәрбия иң мөһим урын тотарга тиеш. Балаларга физик тәрбия бирү, аларда акыл һәм ихтыяр көче тәрбияләү белән генә тулы канлы, җитлеккән кеше тәрбияләп үстерү мөмкин түгел. Эмоциональ тойгылар, матур хисләре булмаса, кешенең хезмәткә сәләтлелеге һәм ихтыяр көче нык булуы гына аны чын кеше итә алмый. Кеше сәнгать белән нык аралашса гына дөньяны бар катлаулылыгы белән тоя ала.*

*Эстетика һәм сәнгать мәктәптәге тәрбия хезмәтендә иң әһәмиятле өлкә булырга тиеш».*

*РСФСР НАРКОМПРОСның 1918 нче ел тезисларыннан.*

*«Балалар өчен махсус театр оештыру иң мөһим мәсьәләләрнең берсе. Профессиональ художник-артистлар балаларга, бигрәк тә нәниләргә, матур-нәфис пьесалар уйнасыннар иде».*

*А. В. Луначарский. 1918 нче ел.*

Яшь буынга эстетик тәрбия бирү турында хөкүмәтебез яши башлавының беренче көненнән үк кайгыртты. Югарыда китерелгән документлар әнә шуны раслыйлар.

Әхлаки-әдәп, коммунистик тәрбия бирүдә музыка, эстрада, театр сәнгате миссиясенең никадәр олылыгын кәгазьгә язсаң, язып, сөйләсәң, сөйләп бетергесез!

Балалар әдәбияты бар!

Балалар газета-журналы бар!

Ни өчен яшь тамашачылар театры юк?!.

——□——

*Гомәр Саттаров*

# КАЗАН УРАМНАРЫНЫҢ ИСЕМНӘРЕ

Урам, тыкрык, проспект һәм мәйдан исемнәре — күп гасырлы, шаулы шәһәребез тормышының үзенчәлекле һәйкәлләре, аның революцион көрәше, сәнгате, социалистик промышленносте һәм төзелеше турында күп нәрсә сөйли торган тарих хәбәрчеләре.

600 елга якын тарихы булган Казан шәһәре[1] урамнары микротопонимикасын формалаштыруда байтак кына табигый һәм ясалма географик объектларның, аерым шәхес һәм тарихи вакыйгаларның исем-атамалары катнашкан. Менә шуңа күрә, килеп чыгышлары һәм кулланылышлары ягыннан, шәһәребез урамнарының исемнәре күптөрле һәм катлаулы. Ләкин Казан урамнарының исемнәре фәнни нигездә бөтенләй тикшерелмәгән әле. Тормыш һәм практика исә топонимика фәне алдына тарихи һәм революцион традицияләргә бай, зур промышленность һәм культура үзәге булган Казан шәһәре урамнарының элекке һәм хәзерге исемнәрен махсус өйрәнү бурычын куя һәм, һичшиксез, моңа багышланган аерым хезмәт сорый.

Бу мәкаләдә Казан шәһәре урамнарының элекке һәм хәзерге исемнәрен[2] лексик-семантик яктан төркемләү күздә тотыла. Бу исә урамнарга исем бирү һәм исем алмаштыруның үзенчәлекләрен билгеләргә ярдәм итә.

Исем бирү чыганагы буенча, Казан шәһәре урамнарының элекке исемнәрен 12 группага аерырга мөмкин:

1. **Урам исемнәре итеп аерым кешеләрнең исем-фамилияләре бирелгән.** Октябрь революциясенә кадәр, нигездә, завод-фабрика, предприятие хуҗалары булган зур байларның, сәүдәгәрләрнең, түрәләрнең исем-фамилиясе белән аталу Казан топонимикасына да хас була. **Юсупов мәйданы** (XVIII—XIX йөзләр) — татар байлары Юсуповларның йортлары шунда булган. **Кочетов тыкрыгы** (XVIII—XX йөзләр) — бай купец А. Я. Кочетов фамилиясе белән аталган. Казанның Совет районындагы бу тыкрык хәзер дә шул исемне йөртә.

2. **Һөнәр, профессия, сословие терминнары белән аталган урамнар.** XIX гасырда Казанда **Мещанская** һәм **Солдатская** дигән урамнар булган. Боларның исемнәре сословие атамалары белән мөнәсәбәтле булуы яхшы аңлашыла.

---

[1] XIV нче гасыр азагында (1394 елларда) Казан шәһәре хәзерге урынында корыла башлый. Тарих фәннәре докторы, профессор М. Г. Сәфәргалиев тә «Алтын Урданың таркалуы» (Саранск, 1960, 249 бит) дигән хезмәтендә хәзерге Казанның салына башлавын 1394—1402 еллар белән билгели. Рус елъязмаларында 1395—96 елларда хәзерге Казан беренче мәртәбә телгә алына. Димәк, 1994 елда хәзерге Казанның салынуына 600 ел тула, ә беренче урында төзелүенә (Иске Казан) 700 елдан артык вакыт уза. Бу датаны бөтен ил һәм республикабыз күләмендә билгеләп үтәргә тиеш булабыз.

[2] Казан урамнарының элекке исемнәре дип, Бөек Октябрь революциясенә кадәрге чорда, ягъни XV—XIX йөзләрдә һәм XX гасыр башында бирелгән исемнәргә әйтәбез. Хәзерге исемнәр дип исә Бөек Октябрь революциясеннән соң кулланылышта калган күп кенә элекке исемнәрне һәм Совет власте елларында бирелгән яңа исемнәрне атыйбыз.

3. **Этнонимнар [халык исемнәре] белән аталган урамнар.** Казанда урта гасырларда ук байтак кына милләт вәкилләре яшәгән. Күпчелекне алар тәшкил иткән урамнарга, урыннарга шул халык исеме бирелгән: **Әрмән урамы** (XV—XIX йөзләр. Хәзерге Спартак урамы), **Таҗик чокыры** (XV—XVII йөзләр).

4. **Торак пунктлар исеме белән аталган урамнар: Псков урамы, Вологда урамы, Ярославль урамы** (XVI—XVIII йөзләр), **Мәскәү урамы** (XIX йөз).

5. **Ясалма микротопонимик объектлар** (корылмалар, сәүдә биналары, базарлар һ. б.) **исеме белән аталган урамнар: Бассейн урамы** (XIX—XX йөзләр), **Печән базары** (XIX—йөз һәм XX йөз башы).

6. **Физик-географик объектлар исеме бирелгән урамнар.** Башлыча, елга, күл, тау һ. б. физик-географик объектлар тирәсенә урнашкан урамнарга шул объектларның исемнәре кушылган: **Акком асты урамы** (XIX—XX йөзләр), **Черек күл урамы** (XIX йөз), **Казанка урамы** (XX йөз).

7. **Урнашу урынына карап исемләнгән урамнар: Аркылы урам** (XIX йөз), **Кырый урам** (XIX—XX йөз), **Арткы урам** (XIX йөз).

8. **Тышкы йөзе һәм аннан алынган тәэсираттан чыгып исемләнгән урамнар. Яңа урам** (XIX йөз), **Зур урам** (XIX йөз), **Тар урам** (XIX йөз), **Кыек тыкрык** (XX йөз).

9. **Чиркәү һәм монастырь исеме белән аталган урамнар.** Октябрьгә кадәр Казанда бу группага караган урам исемнәре күп була. Казанның 1565—68 һәм 1646 елгы писцовая кенәгәсендә байтак кына чиркәү һәм монастырьлар, алар исеме белән аталган бистәләр, тыкрык, урамнар теркәлгән: **Спас урамы һ. б.**

10. **Кулланыш максатыннан чыгып исемләнгән урамнар.** Бу группага караган урам исемнәре күп түгел: **Эт тыкрыгы, Прогонная урамы, Җәяүлеләр урамы** һ. б.

11. **Символик исемнәр бирелгән урамнар.** Казанда бу төргә кергән урам исемнәре Октябрьгә кадәр бик аз була: **Триумфальная урамы** (XIX йөз).

12. **Күрше урам исемнәре кабатланып аталган урамнар.** Бу группа тыкрык, тупик, урам исемнәрен үз эченә ала. Мондый атамалар кабатлана торган исем алдыннан аерым эпитетлар (күбесенчә, иске-яңа, югары-түбән, зур-кечкенә, озын-кыска, алгыарткы, аскы-өске, аркылы-беренче, икенче... һ. б. кебек аергычлар) килү юлы белән ясалганнар: **Иске бистә, Яңа бистә, Аркылы Грузин урамы, Арткы Бөгелмә урамы һ. б.**

Бөек Октябрь социалистик революциясе тормышның һәр өлкәсенә яңалык алып килде. Торак пунктлар (шәһәр, авыл, поселок һ. б.) топонимикасына да аның дулкыны тәэсир ясамый калмады. Искелекне, капитализмны хәтерләткән урам исемнәре яңа тормыш эчтәлегенә туры килә торган исемнәр белән алмаштырылды. Тарихитрадицион әһәмияткә ия булган элекке урам исемнәре үзгәртелмәделәр, Октябрьдан соң да кулланылышта калдылар. Бу исә урам исемнәренең ныклы стабильлелеген һәм дәвамчанлыгын, тематик төрләре ягыннан элекке һәм хәзерге урам исемнәре арасындагы тыгыз бәйләнешне тәэмин итте.

Лексик-семантик яктан Казан шәһәре урамнарының хәзерге исемнәрен 11 группага аерырга мөмкин [1]. Нигездә, алар без элек санаган группалар белән тәңгәл киләләр. Билгеле, мәгънәви яктан күпчелеге яңа эчтәлек, яңа төшенчә белдерәләр.

1. **Күренекле кешеләр исем-фамилиясе белән аталган урамнар.** Бу группага караган урам исемнәре, илебезнең башка шәһәрләрендәге кебек үк, Казанда зур күпчелекне тәшкил итәләр. Мондый исемнәрнең үзләрен берничә төркемгә аерырга мөмкин. Пролетариатның бөек юлбашчыларының исем-фамилияләре белән аталган урамнар: **Ф. Энгельс урамы** (Ленин районында). 1887 елда В. И. Ульянов-Ленин укыган мәһабәт университет бинаялары белән башланып, ак башнялы чал кремльгә барып тоташкан тез урамга даһи юлбашчыбыз **Ленин исеме** бирелгән. Казанның җитен комбинаты, мех комбинаты, университет, врачлар белемен күтәрү институты, музей, республика үзәк китапханәсе, яңа район, Үзәк культура һәм спорт стадионы, Казанка елгасы аша төзелгән күпер, Лобачевский һәм Куйбышев урамнары арасындагы бакча В. И. Ленин исемен йөртәләр. Казанда В. И. Ульяновлар семьясы яшәгән урам **Ульяновлар урамы** дип исемләнгән.

---

[1] Чиркәү-монастырь исемнәре белән мөнәсәбәтле группа Казанның хәзерге урам исемнәрендә урын алмый.

Казанның байтак кына урамнары крестьян восстаниесе җитәкчеләре (**Степан Разин урамы, Салават Юлаев урамы** һ. б.), декабристлар (**П. И. Пестель урамы, К. Ф. Рылеев урамы**), революционер-народниклар (**С. Халтурин урамы, В. Н. Фигнер урамы** һ. б.), рус революцион-демократларының (**В. Г. Белинский урамы, Н. Г. Чернышевский урамы** һ. б.) исем-фамилиясе белән аталган.

Атаклы полководецлар (**М. И. Кутузов урамы, А. В. Суворов урамы, М. В. Фрунзе урамы**), 1812 елгы Ватан сугышы геройлары (**Денис Давыдов урамы, Надежда Дурова урамы**), гражданнар сугышы геройлары (**Маркин урамы, Чапаев урамы, Әхтәмов урамы** һ. б) һәм Бөек Ватан сугышы геройларының (**Олег Кошевой урамы, Газинур Гафиятуллин урамы, В. Дубинин урамы** һ. б.) **исемнәре** бирелгән урамнар зур бер төркем тәшкил итәләр.

Казанның күп кенә урамнары **хезмәт иясе** массасын капитализм коллыгыннан азат итү өчен үз-үзләрен аямыйча көрәшкән революционерларның, күренекле партия һәм дәүләт эшлеклеләренең якты истәлекләрен гәүдәләндерәләр: **Н. Э. Бауман урамы, С. М. Киров урамы, Я. М. Свердлов урамы, Ф. Э Дзержинский урамы** һ. б.

Казанда һәм Казан губернасында революцион эш алып барган һәм Совет властен урнаштыру өчен көрәшкән партия һәм дәүләт эшлеклеләренең исем-фамилияләре белән аталган урамнар: **Н. Е. Федосеев урамы, В. А. Тихомирнов урамы, Хөсәен Ямашев урамы, Мулланур Вахитов урамы, Я. С. Шейкман урамы, Н. Ершов урамы, Камил Якуб урамы** һ. б.

**Башка** илләрнең коммунистлар партиясе җитәкчеләре, күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклеләре исеме мәңгеләштерелгән урамнар: **Э. Тельман урамы, Клара Цеткин урамы, Карл Либкнехт урамы, Патрис Лумумба урамы** һ. б.

Казан урамнарының байтагы рус, татар һәм башка тугандаш халыкларның танылган язучылары (**М. Горький урамы, Гафур Коләхметов урамы, Кәрим Тинчурин урамы, Һади Такташ урамы, Галимҗан Ибраһимов проспекты, Алишер Навои урамы, Я. Гашек урамы, Җамбул урамы, Ш. Руставели урамы, Садретдин Айни урамы** һ. б.), сәнгать кешеләре (**Салих Сәйдәшев урамы, Чайковский урамы, Шишкин урамы, Шаляпин урамы, Зәйни Солтанов урамы, Хәлил Әбҗәлилов урамы** һ. б.), фән һәм техника эшлеклеләренең (**Бутлеров урамы, Ломоносов урамы, Каюм Насыйри урамы, Ползунов урамы** һ. б.) исем-фамилияләрен йөртәләр.

Алдынгы эшчеләр, инженер-техниклар исем-фамилиясе кушылган урамнар бар. Мәсәлән, Совет районындагы мәһабәт телеграф һәм сөйләшү пункты бинасыннан башланып киткән, яңа төзелешләре күп булган урам, Казанны төзекләндерүдә зур эшчәнлек күрсәткән тәзүче инженер **Бари Галеев** исемен йөртә. Сөйләшү пункты бинасына кадакланган мемориаль такта бу кеше турында бик тыйнак һәм ачык сөйли.

Югарыда күреп үткәнебезчә, күренекле кешеләр хөрмәтенә исемләнгән урамнар Казанда бик күп һәм алар берничә тематик төркемгә һәм төркемчәгә бүленәләр. Боларда кешене, аның җәмгыятькә, халыкка багышланган титаник хезмәтен олылау, тирән хөрмәт итү, якты образын мәңгеләштерү кебек бөек гуманистик идеяләр чагылыш табалар.

2. **Һөнәр, профессия, кешеләр группасы исемнәре белән аталган урамнар: Журналистлар урамы, Студентлар урамы, Укытучы урамы** һ. б.

3. **Этнонимнарга нигезләнгән урам исемнәре.** Казан урамнарының беркадәресенә союздаш һәм автономияле республикаларның исемнәре бирелгән. Аларның нигезендә исә теге яки бу халыкның исеме, ягъни этноним ята: **Татарстан урамы, Украина урамы, Казагыстан урамы, Болгар урамы, Татар бистәсе** һ. б.

**4. Торак пунктлар исемнәре белән аталган урамнар:**

а) Казанның байтак кына урамнары илебезнең башка шәһәрләренең исемнәрен йөртәләр: **Ашхабад урамы, Баку урамы, Волгоград урамы, Ленинград урамы, Уфа урамы, Чиләбе урамы.** Мондый күренеш башка шәһәрләргә дә хас.

б) Татарстан АССР районнары исеме белән аталган урамнар. Татарстанның элекке һәм хәзерге административ-территориаль бүленеше буенча булган районнарның исемнәре Казан урамнарының атамасы буларак кулланылалар: **Арча урамы, Биләр урамы, Буа урамы, Норлат урамы.**

в) Берничә урамга Татарстандагы поселок һәм авыл исеме бирелгән: **Аракчино урамы, Колай урамы, Кокушкино урамы, Коркачык урамы** һ. б.

5. **Ясалма микротопонимик объектлар исеме бирелгән урамнар: Аэропорт урамы, Ипподром урамы, Вокзал урамы, Карьер урамы** һ. б.

6. **Физик-географик объектлар исеме кушылган урамнар.** Бу группага караган урам исемнәрен ике төркемчәгә аерып карарга мөмкин:

а) Казан территориясендәге физик-географик объектларның исемнәрен йөртүче урамнар: **Кабан урамы, Күл урамы, Чокыр урамы.**

б) Башка җирләрдәге физик-географик объектлар (күбесенчә, елга, күл, диңгез, тау, утрау) исемнәре белән аталган урамнар: **Иртыш урамы, Кавказ урамы, Байкал урамы, Каспий урамы, Сахалин урамы** һ. б.

7. **Урнашу урынына карап исемләнгән урамнар. Тышкы урам, Кыектау урамы, Үзәк урам, Тау асты урам** һ. б.

8. **Тышкы йөзе һәм аннан алынган тәэсираттан чыгып исемләнгән урамнар: Күтәренке урам, Кәкре урам, Текә тыкрык, Яңа урам, Киң урам** һ. б.

9. **Кулланылыш максатыннан чыгып исемләнгән урамнар: Чабыш урамы, Физкультура урамы** һ. б.

10. **Символик исемнәр бирелгән урамнар.** Октябрьдан соң, башка шәһәрләрдәге кебек үк, Казанның да күп кенә урамнарына социалистик революция, совет чынбарлыгы тудырган символик исемнәр бирелде: **Хезмәт урамы, Урак һәм Чүкеч урамы, Ирек мәйданы, Таң урамы, Восстание урамы, Кызыл Армия урамы, Революция урамы** һ. б.

11. **Күрше урам исемнәре кабатланып аталган урамнар: Арткы Дәүләки урамы, Яңа Кремль урамы, Аркылы Кабан урамы, Иске Әмәт урамы** һ. б.

Югарыдагы мисалларда Казан урамнарының хәзерге исемнәренең, һәр группа эчендә диярлек, баюын, тулылануын һәм яңаруын ачык күрәбез. Тематик группаларның үз эчләрендә тармакларга, төркемчәләргә бүленүе менә шуны раслый.

Урам исемнәрен алмаштыру — нык уйлап эш итүне сорый торган җаваплы һәм мөһим мәсьәлә. Октябрьга кадәрге чорда Казан урамнарының исемнәрен алмаштыру стихияле төстә барган. Кайбер урам исемнәренең аһәңсезлегенә, яңгырашсызлыгына һәм чуарлыгына игътибар ителсә дә, бу кимчелекләрне бетерү өчен патша учреждениеләре тарафыннан чаралар күрелмәгән. Бары тик 1899 елда гына шәһәр думасы утырышында шәһәр башлыгы С. В. Дьяченко урам исемнәрен алмаштыру белән шөгыльләнергә кирәк дигән мәсьәләне күтәрә [1]. Моның проектын төзү Казан тарихчысы Н. Я. Агафоновка тапшырыла. Ул шул ук елда үзенең проектын тәкъдим итә [2]. Ләкин Н. Я. Агафонов, югары катлау вәкиле буларак, Казан урамнарының исемнәрен алмаштыру мәсьәләсендә үз сыйныфы интересларыннан чыгып эш итә. Ул, беренче чиратта, патшалар, эре түрәләр, дворяннар һәм бай сәүдәгәрләр исем-фамилияләрен Казан урамнарына бирүне күздә тота.

Шул ук вакытта Н. Я. Агафонов проектының заманы өчен уңай, прогрессив яклары да бар. Автор күп кенә урамнарга атаклы язучылар, галимнәр, мәгариф һәм культура эшлеклеләренең исемнәрен бирергә кирәк дип карый. Л. Н. Толстой, А. С. Пушкин, С. Т. Аксаков, Г. Р. Державин, К. Фукс, А. М. Бутлеров, татар галимнәре Хәлфиннәр хөрмәтенә Казанның аерым урамнарының атамаларын алар исеме белән алмаштырырга тәкъдим итә. Казанда хәзер А. М. Бутлеров, Л. Н. Толстой, А. С. Пушкин урамнары да, К. Фукс бакчасы да бар. Ә менә күренекле рус язучылары С. Т. Аксаков, Г. Р. Державин, татар мәгърифәтчеләре Хәлфиннәр исемен йөртүче урамнар юк әле. Бу исемнәрне Казан урамнарына бирү бик урынлы булыр иде. Әлегә кадәр Хәлфиннәр семьясының өч буыны (Сәгыйт, Исхак, Ибраһим) мәгълүм иде. Н. Я. Агафонов үзенең проектында аларның дүртенче буыны — Ибраһим улы Асланбик Хәлфин турында да сүз алып бара. Асланбик Хәлфин, ата-бабалары кебек, татар теле һәм әдәбияты белән кызыксынган. Татар әдәбияты белемен караган хезмәтләр язган. Әмма аларның табылганы юк әле. Н. Я. Агафонов Асланбикнең бик ярлы яшәве һәм 27 яшендә хәерчелектән аерылып үлүен хәбәр итә.

---

[1] Бэн. Вопросы о переименовании улиц г. Казани. «Волжский вестник» газетасы. 1899 ел. 164—165 саннар; В. К. Магницкий. Нечто о переименованиях. «Волжский вестник» газетасы. 1899 ел. 210 сан.

[2] Н. Я. Агафонов. Историческая объяснительная записка наименования Казанских улиц (Материалы к вопросу переименовании улиц г. Казани). Казан. 1899 ел.

Зур галим Ш. Мәрҗани, татар драматургиясенә нигез салучы Ф. Халиди һәм Г. Ильяси исемнәрен дә Казан урамнарына бирергә мөмкин булыр иде.

Революциядән соң урамнарга исем бирү һәм аларның исемнәрен алмаштыру бик җаваплы һәм планлы эшкә әверелде. Казан шәһәр советы урамнарның исемнәрен алмаштыру буенча зур чаралар үткәреп килә. Соңгы берничә ел эчендә (1960—67) генә дә урам исемнәрен алмаштыруда әһәмиятле эшләр башкарылды. Совет халкы фән һәм техника өлкәсендә көннән-көн зур җиңүләр яулый. Совет кешеләре дөньяда иң беренче булып Галәмгә юл салдылар, космосны үзләштерүдә гаять зур уңышларга ирештеләр. Хезмәт иярәренең үтенече буенча, шәһәр советы Казанның Унберенче Союз урамына летчик-космонавт **Ю. А. Гагарин** исемен бирде. Шәһәребез топонимикасында, космик киңлекләрне яулау белән бәйле рәвештә, **Космонавтлар, Восток, Ракета,** (урамнар), **Спутник** (кинотеатр) кебек исемнәр барлыкка килделәр.

Фашистик Германияне тар-мар итүгә 20 ел тулу уңае белән, Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган каладашларыбыз — Советлар Союзы Геройларының исемнәре урамнарга бирелеп мәңгеләштерелде. Алар арасында Советлар Союзы Геройлары **В. П. Николаев, Ш. С. Рәхмәтуллин, Ф. М. Фәтхуллин** исемнәре бар.

Казан урамнарының хәзерге исемнәре арасында алмаштырылырга тиешлеләре дә бар әле. Без аларга түбәндәге төр урам исемнәрен кертәбез:

а) Халыкның эстетик зәвыгы үсешенә туры килми торган, ямьсез яңгырашлы урам атамаларын: Саңгырау урам, Кыек тыкрык, Саз урам, Бойня урамы, Ямская урамы, Барак урамы, Кыска урам, Склад урамы һ. б.

б) Номерлы урам исемнәрен. Мондый урам исемнәре соңгы елларда еш күренә башлады. Номерлар шул ук исемдәге берничә урам барлыкка килгәндә биреләләр һәм кайбер бер төсле атамалы урамнарның номерлы саны дистәдән артып китә (мәсәлән, Казанда Дәүләки урамы — 13, Клевер урамы — 6, Завод урамы — 5, Муром урамы — 8). Бу хәл кешеләргә аралашу өчен һәм почта-телеграф эшчеләренә зур кыенлык тудыра, буталчыклыклар китереп чыгара.

в) Эпитетлар (иске-яңа, кечкенә-зур, югары-түбән) өстәлеп кабатланучы урам исемнәре: Аркылы Үзәк урам, Зур Крылов урамы, Кечкенә Крылов урамы, Параллель Чехов урамы һ. б.

г) Шәһәрнең төрле районнарындагы урамнарга бер үк исем бирүне: Азин урамы (Ленин районы), Беренче Азин урамы (Совет районы), Мәктәп урамы (Идел буе районы), Мәктәп тыкрыгы (Совет районы) һ. б.

Дөрес, урам атамалары итеп, номерлар һәм эпитетлар өстәлгән башка урам исемнәрен куллану ярдәмче чара гына. Ләкин боларның чиге булырга тиеш. Мондый урам исемнәрен кичекмәстән тәртипкә китерергә, яңа исемнәр белән алмаштырырга кирәк. Аларны атаклы кешеләрнең исем-фамилияләренә, символик атамаларга, чәчәк, гөл исемнәренә һәм югарыда күрсәтелгән башка группаларга нигезләнгән урам исемнәре белән алмаштырырга бик мөмкин.

Урам исемнәре арасында күренекле революционер һәм дәүләт эшлеклесе, Казандагы беренче социал-демократик түгәрәкләрне оештыруда актив катнашучы **А. М. Стопани** (1871—1932), казанлы революционер-большевик, Хөсәен Ямашевның якын дусты **Галимҗан Сәйфетдинов,** гражданнар сугышы каһарманы, Кызыл Армиянең милли частьларын оештыруда актив катнашучы кызыл командир **Х. Г. Мәүлетов,** беренче татар театры группасы «Сәйяр»не оештыручы, татар театрына нигез салучы **Габдулла Кариев,** композитор **Фәрит Яруллин,** Казанда туып-үсеп, татар совет музыка сәнгатен үстерүдә зур эшчәнлек күрсәткән композитор **Мансур Мозаффаров,** күренекле язучы **Фатих Әмирхан,** атаклы драматург **Мирхәйдәр Фәйзи,** танылган шагыйрь һәм драматург **Ф. Бурнаш,** бай иҗат мирасы калдырган татар совет шагыйре **Әхмәт Фәйзи,** күренекле балалар язучысы **Абдулла Алиш,** әдәбият белгече һәм күренекле тәнкыйтьче **Галимҗан Нигъмәти,** рус һәм татар телен фәнни өйрәнү өлкәсендә зур эшчәнлек күрсәткән телчеләр **В. А. Богородицкий, Гыйбад Алпаров, Галимҗан Шәрәф, М. Корбангалиев, Л. Җәләй,** Казанда яшәгән һәм эшләгән танылган сәяхәтче, астроном һәм географ **И. М. Симонов,** көнчыгышны өйрәнү белгече **О. М. Ковалевский,** күренекле терапевт-профессор **Н. А. Виноградов,** Казан гимназиясен тәмамлаган, бурят халкының атаклы мәгърифәтчесе **Дарджи Банзаров,** татар мәгърифәтчесе **Гали Мәхмүдов** һәм башкаларның исемнәрен очратмыйбыз әле. Аларның халык өчен башкарган зур

прогрессив эшчәнлекләре моңа, һичшиксез, лаек. Казан шәһәр советы, Бөек Октябрьның илле еллык юбилее уңае белән, Казан урамнарына бу исемнәрне бирел мәңгеләштерсен иде, дигән олы теләк белдерәсе килә.

Кайбер шәһәрләрдә урам бәйрәмнәрен үткәрү матур традиция буларак кереп бара. Мәсәлән, Днепропетровск шәһәрендә Ленин урамына 42 яшь тулу көне бәйрәм ителде. Львов шәһәрендә Валентина Николаева-Терешкова исеме кушылган яңа гына төзелгән урамның бәйрәме үткәрелде. Күптән түгел район үзәге Апасның Кызылармеецлар урамының бәйрәме зурлап һәм тантаналы итеп уздырылды. Киләчәктә мондый урам бәйрәмнәрен Казанда да оештырасы иде.

Мәскәү, Дрезден шәһәрләре үрнәгендә, Казан урамнарының чатларына бу урамның ни өчен шулай аталуын аңлаткан табличкалар куелса, шәһәр халкы урам исемнәре белән яхшырак таныша һәм аларны хәтерләрендә ныграк калдыра алырлар иде. Танып белүдән тыш, моның зур тәрбияви әһәмияткә ия булуын да истән чыгармаска тиешбез.

Табличкаларга урам исемнәрен русча да, татарча да дөрес язу, русча исемнәрне татарча, ә татарча исемнәрне русча фәнни транскрипция белән бирү бик зарури (Казан урамнарында я русча, я татарча исемнәре грамотасыз язылган табличкалар да күзгә чагыла әле. **«Күл урам»**—русча **«Коль урам»** дип транскрипцияләү хата, дөресе—**«Куль урам»**. Язу традициябездә урнашканча, татарча **«Гадел Кутуй ур.»** дип язарга кирәк иде, ләкин татарчасы да **«Адель Кутуй ур.»** язылган h. 6.).

Урамнарга исем кушу һәм исем алмаштыру мәсьәләләрен хәл итү өчен, Казан шәһәр советы каршында махсус комиссия оештырырга кирәк дип саныйбыз. «Киңәшле эш таркалмас», ди халык мәкале. Шәһәр урамнарына яңа исемнәр биргәндә, яки элеккеләрен алмаштырганда, комиссия нык киңәшеп, мәсьәләне һәрьяклап тирән уйлап, фәнни һәм тормышчан нигездә хәл итә алыр иде.

—□—

# КЕМ УЛ ӘНИС БАДИГИН?

Журналның быелгы 1—3 нче саннарында Әхсән Баяновның «Яшьлегемне эзлим» исемле повесте басылып чыкты. Дөресен әйтик, бу повесте белән шагыйрь Әхсән Баянов үзен сәләтле генә прозаик итеп күрсәтте. Бигрәк тә әсәрнең беренче бүлеге матур, бай тел белән язылган. Анда Агыйдел буеның гүзәл табигате, колхозчы хезмәтенең романтикасы, яшь йөрәкләрнең талпынуы оста тасвирлана.

Автор дәһшәтле сугыш вакытында һәм аннан соңгы авыр елларда яшь буынның ничек үсүен күрсәтергә тели. Кереш сүзендә ул: «Яшьлек юлдашларыма: ...Сезнең хакта да нәкъ чынлыктагыча язарга тырыштым мин» [1], — ди. Повесть Әнис Бадигин дигән егетнең истәлекләреннән гыйбарәт.

Кем ул Әнис Бадигин! Әнискә унҗиде яшь, ул баянда оста уйный, җиде класс белеме бар. Бер җәй эчендә ике кызга — тыйнак Фәһимәгә һәм чая Ленага — берьюлы гашыйк була. Кешене күз алдында китерү өчен бу гына аз әле. Ни өчен яши ул дөньяда, нәрсәгә омтыла, нинди хисләр белән яна! Хыялларын тормышка ашыру өчен нинди эшләр башкара! Менә шунысы әһәмиятле.

Әнис Бадигин музыкаль белем алырга тели. Ләкин теләгенә ирешә алмый һәм үзенең яшьлеге күңелсез узуда әз дә түгел, күп тә түгел, бөтен кешелекне гаепли: «Миңа әерым исемнәр кирәкми, Кешелек, мин синнән сорыйм! Менә мин дөньяга килдем, синнән сорыйм: миңа үсү, кеше булу өчен мөмкинлек бир!.. Син миңа бөтенесен соңыннан, тынычлыкта кайтарып бирермен дисеңме! Ә елларны, югалган елларны, яшьлегемне минем кайтарып бирә алырсыңмы! Кайтара алсаң, мин сине гафу итәрмен...» [2]

---

[1] «Казан утлары» журналы, 1967 ел, 1 сан, 47 бит.

[2] «Казан утлары» журналы, 2 сан, 71 бит.

Әнис Бадигин нинди «кешелек»кә мөрәҗәгать итә соң! Кешелек ут сызыгы белән икегә бүленгән бит. Үзеңне үтерергә, юк итәргә кизәнгән дошманга: «Яшьлегемне җимердегез, гафу итмәм», дию мәгънәсезлек булыр иде.

Әнис Бадигин туган илгә, дәһшәтле сугышларда кан койган әти-абыйларга, тормыш авырлыгын үз җилкәләренә күтәргән әни-апаларга үпкәлидер, ахры.

Шулай ук Әнис Бадигинга үсү, кеше булу өчен берниндн мөмкинлек тә калмаганмыни! Аңа бердәнбер теләгән тормышка ашыру — музыкаль белем алу юллары бикле булганмыни! Юк, алай ук түгел икән. Автор үзе үк әйтеп тора: сугыш, ачлык, хәсрәт дөньясында яшь буынны онытмаганнар. Әзме-күпме сәләте, теләге булган яшьләрне җыялар, укыталар. Уку йортларына берниндн конкурс юк. Техникумнарның, институтларның ишекләре ачык. Хәттә консерватория дә эшли! Сәләтең бар икән, кер, теләсә кайсы факультетында укы, сиңа Мәскәү профессорлары белем бирер.

Консерваториягә Әнис Бадигин да кабул ителә. Әмма Әнис консерваториягә барып җитә алмый, ярты юлда, Уфада туктап кала. Булачак авырлыклардан куркып, зур хата эшли, җиңел акыллылык күрсәтә, үз бәхетен үзе җимерә.

Хәер, Әнис үзен бәхетсез иткән сәбәпне күрсәтә. Ул да булса — Лена. Французлар әйтмешли, һәр бәхетсезлекнең сәбәбен хатын-кыздан эзлә. Әнис тә эзли һәм таба. Шул каһәр суккан Лена Әниснең Уфадан китүенә каршы, Әниснең китәр юлына кертә сала ул: «Ташлап китмә мине!.. Ташлап китмә мәхәббәтеңне!»

Ике кеше дус булганда, кемнең ихтыяры ныграк, рухы көчлерәк — шул өстенлек ала, көчле кеше йомшак дусны үзенә буйсындыра. Мәхәббәттә дә шулай. Лена Әнисне үзенә буйсындыра. Укырга да егетне ул ияртеп алып бара. Консерваториягә җибәрми, техникумга урнашырга

өиди. Ихтыярсыз, җебегән Әнис аңа буйсына. Хәтта Лена күрәләтә начар эшкә баргында да аңа каршы тора алмый: аның белән бергәләп милиционер ярдәмендә бер гаиләне квартирыннан куып чыгара, гаилә башлыгына кул күтәрүдән дә чиркәнмый.

Автор Ленаны начар кеше итеп күрсәтергә тырыша. Ләкин, шуңа карамастан, бу кыз укучы күз алдына тирән хисле, сөя белә торган, сөйгәне хакына теләсә нинди корбаннарга әзер кеше булып килеп баса. Ә менә Әниснең Ленада кайгысы юк, ул бары үз шәхесе белән генә мәшгуль.

Ленага авыр вакытлар кичерергә туры килә: ул, үзенең авырлы икәнен белгәч, кайгысыннан Әниснең аягына килеп егыла. Ләкин Әнис кебекләрдән мәрхәмәт, шәфкать, кеше күңелен аңлау көтеп буламы соң! Ленаның рухы сынган чак, зур газаплар кичергән көннәре. Аңа таяныч кирәк, ярдәм кирәк. Хәзер инде Әнис катгый карарга килергә тиеш. Ләкин ул үз өстенә нинди дә булса җаваплылык алырга теләми, тизрәк таю ягын карый.

Әнис үзенең юньсезлеген фәлсәфи нигезгә куеп акларга маташа һәм барысында да әлеге шул бичара Ленаны гаепли: «Лена, монда синең тормышың, мин монда бүтәнчә кала алмыйм, ышанасыңмы! Бу дөнья минем өчен түзү мөмкинлеге калмаган дәрәҗәдә тынычсыз, һавасы агулы диясем килми, телем бармый, тик мин сулый торган түгел. Монысы—хакыйкать»[1]. Әнә ничек үз вакытында аңлап ала егет бу хакыйкатьне! Шулай да Әнис нинди булса эшкә тәвәккәллек итә торган кеше түгел бит әле. Ул бу мәсьәләдә абыйсы Сафуан янына киңәшкә бара. Сафуан белән түбәндәгечә сөйләшү була:

«— Паспортыңны пычраттыңмы!

— Юк, намусны гына...

Ул миңа, бу нинди кулга тотып булмый торган әйберләр турында сөйлисең дигәндәй, сәерсенеп карады.

— Намусны гына булгач, ничево, — диде ул, шаяртып, — намустан чалбар тегеп булмый».

Димәк, «намусны гына» пычрату әллә ни куркыныч эш түгел икән, дип уйлый Әнис, паспорты чиста бит, Ленадан котылу ансат... Ул Ленаны һәм авиация техникумын ташлап, авылга, саф күңелле, тыйнак һәм беркатлы Фәһимә янына кайтып китә. Һәм әле генә үзе тәмам юкка чыгарган, хурлаган «намус»ка ишарә ясый:

«Аның [Фәһимәнең — М. М.] күзләренә туры карар өчен, тормышны яңача корырга, «намус» дигән, күренми торган сызыкның бу ягында, сафлык, гаделлек ягында торырга кирәк. Менә мин хәзер шул якка чыктым»[1]

«Намусның бу ягына чыгу»ны нидән башлый соң Әнис! Тота да башыннан үткәннәренең бөтенесен, бар түбәнлеге, пычраклыгы белән кыз алдына чыгарып сала. Аның эше ашыгыч, аңа хәзер тизрәк Фәһимә кирәк, кыз аны кичерсен. Ләкин Фәһимә бернәрсә дә әйтми, ул сынган гөл кебек ихтыярсыз. Берничә көннән соң ул Әниснең мылтыгы белән атылып үлә. Язучы аның нилектән һәлак булганын ачык әйтми: «Ничек үлде! Мондый хәл булырга мөмкинме! Мылтыкка ул кагылдымы! Ялгышмы! Әллә үзе аңлы рәвештәме!»

Чыннан да, нилектән һәлак була соң Фәһимә! Тормышта мондый хәлнең булуы мөмкин һәм аны түбәндәгечә аңлатып була. Әйткәнебезчә, Фәһимә — эчкерсез, тирән хисле, горур һәм тыйнак кыз. Авыр елларда, тирә-ягында ачлык, бәхетсезлек тулып торганда, Фәһимәнең олы таянычы, гүзәл дөньясы — саф мәхәббәте булган һәм бу бөек хис аңа яшәргә дәрт, киләчәккә өмет биргән. Әнис үзенең чын йөзен беркайчан тартынусыз ачып күрсәткәч, кызның тормышын яктырткан кояш сүнә. Ләкин ул моны тиз генә аңлап җиткерә алмый. Катастрофага эләккән кешеләр дә кайчак, нык гарипләнгән, яраланган булуларына карамастан, авырту сизмиләр. Медицинада бу шок хәле дип атала. Кеше терелсен өчен, аны шок хәленнән чыгару — авыртуны сизү дәрәҗәсенә китерү шарт, юкса аның үлеп китүе мөмкин. Күрәсең, Фәһимәнең күңеле бу җәрәхәтне күтәрә алмый, аның рухы шок хәлендә. Һәм ул, шул хәлдән чыга алмый, атылып үлә.

Юристлар Фәһимәнең үлемендә Әниснe гаепләрлек дәлилләр тапмыйлар, әмма әхлакый кануннардан чыгып карaганда, Фәһимәне үтерүче кеше — Әнис. Ленаның фаҗигасендә дә, Фәһимәнең һәлакәтендә дә Әнис гаепле. Ләкин автор бу вакыйганы тиешенчә ачып бирми, шунлыктан укучы өчен Фәһимәнең һәлакәте очраклы, аңлаешсыз фаҗига булып калуы мөмкин.

Бадигинга унсигез яшь. Халыкча әйтсәк, балигъ булган егет. Юридик яктан карaганда, кылган эшләре өчен җавап бирер

[1] «Казан утлары» журналы, 2 сан. 93 бит.

[1] «Казан утлары» журналы, 3 сан. 20 бит.

яше җиткән гражданин. Законлаштырмаса да, өйләнеп, хатын белән торган, ата бу-ла язган ир. Аның яшендәгеләр фронтта башларын салалар, тылда тормышның те-рәге саналалар.

«Син туган илеңә, кешеләргә нинди файда китерәсең!» — дигән сорауга Әнис Бадигин ни дип җавап бирер иде икән... Бер җәйне печән чапкан идем, икенче җәйне ашлык ташыдым, дипме! Әзрәк тү-гелме икән! Әниснең әнисе, үзеннән кече туганнары бар бит әле. Егетнең алар ту-рында кайгыртканы, аларга нинди дә бул-са ярдәм иткәне күренми.

Әниснең, авылга кайткач, Сафуан ал-дында хатыннарны яклавы, дусты Хәмитне караклыкта тотуы да — бер кыланчыклык кына, кешеләргә һәм үзенә: «Менә мин нинди әйбәт кеше», — дип исбат итәргә тырышуы гына. Асылда исә ул кеше өчен, җәмгыять өчен нинди дә булса эшкә сә-ләтсез адәм. Председатель Сафуан трак-тор тәгәрмәче астына ятканда да ул бер тамашачы сыйфатында читтән генә карап тора. Соңгы елларда комсомол секретаре булып эшләве дә Әнисне мактауга лаек кеше итми, чөнки бу эш аның олы макса-тына әверелми.

Гомумән, бармы соң Әниснең олы, изге максаты! Юк. Ул бернәрсәгә дә омтылмый, бернинди теләк белән дә янмый. Аның бердәнбер томанлы хыялы — музыка. Лә-кин ул бу өлкәдә нишләргә теләгәнен ачык белми. Әсәрнең ахырында ул изге хыял символын — баянын ташлап чыгып китә. Утызга якынлашып килгәндә дә, институтның өченче курсына күчкәч тә, ул әле кем буласын белми.

Дөрес, әсәрнең ахырында Әнис: «Мин-дә Бетховен үлде, үземнән башка беркем-не дә гаепли алмыйм һәм теләмим», — ди. Әмма, шуңа да карамастан, Әнис үзен бәхетле саный: «Лена бәхетсез, аныңча яшәп калган булсам, мин дә аның төсле булыр идем».

Әнис Бадигин дөньяда үзе өчен генә яши, ул — эгоист. Әсәрнең эчтәлегеннән, вакыйгалар үсешеннән объектив рәвештә түбәндәге нәтиҗә килеп чыгарга тиеш иде: эгоизм — бик куркыныч нәрсә, эгоист үзе бәхетсез, җәмгыять өчен файдасыз кеше булу өстенә, башкаларга да фаҗига, хәтта һәлакәт китерә.

Әдәби әсәрдә мондый образ булуы мөмкин, әлбәттә, һәм ул тиешенчә ачыл-са, үз бурычын үтәр иде. Вакыйгалар үсешеннән күренгәнчә, әсәрнең ахырында Әнис рухи фаҗига кичерергә һәм тормыш-ка, кешеләргә яңача карарга, яки ялгыз-лыкка, бәхетсезлеккә дучар кеше булып калырга тиеш иде. Кызганычка каршы, язучы моны эшләми, аның бөтен симпа-тиясе Әнис ягында. Әсәргә кереш сүзен-дә автор: «Монда минем... фикерләрем, уйларым, уйлануларым... язмышым да шу-шында, бәлки минеке генә түгел... мин монда үземнең дә гадәттә автобиография-гә керми кала торган, моңарчы беркем-гә дә әйтелмәгән серләремне ачам, алар-ның вакыты җитте», — дип яза. Алдан болай дип әйтеп куйгач, Әнис авызыннан сөйләгәннәр авторның үз сүзләре, үз фикерләре дип кабул ителә.

Үткәннәренә борылып карагач, Әнис: «Минем гомеремнең яртысы... кешелек дәрәҗәмне югалта язганда саклап калу, теләсә нинди кыен шартларда да төшер-мәү, үземнең «мин»емне һәртөрле ялган-нан, түбәнлектән азат тоту, горур шәхе-семне раслау өчен көрәшеп узды... Үз алларында бил бөгүемне... көткән кызга-ныч бәндәләр ялгыштылар — мин, кай-бер яшь ялагайлардан аермалы буларак, үземнең бүгенге көнемә һичнинди яракла-шусыз килдем. Бу яктан мин максатыма ирештем, бу — җиңү, намуслы җиңү. На-мус һәм бәхет сүзләре барлык телләрдә ничектер бертөрле, охшаш яңгырыйлар төсле. Дөньяда иң зур фаҗига — үзеңне ихтирам итү өчен хакың булмау», — ди. Димәк, автор фикеренчә, Әнис — тирән хисле, намуслы, яхшы күңелле егет, ихти-рамга лаек кеше. Шулай итеп, автор тели-ме-теләмиме эгоизмны, кешеләргә, бигрәк тә хатын-кызларга, карата шәфкатьсез мө-нәсәбәтне яклый булып чыга. Укучыда Әнис кебек «горур шәхесне раслау өчен көрәшеп» яшәү — мактауга лаек тормыш икән, дигән фикер туарга мөмкин.

Әсәрдән чыгарга тиеш булган объектив нәтиҗә белән язучының субъектив фике-ре — капма-каршы. Бу зур буталчыклык тудыра, әсәрдә идея эзлеклелеге югала, укучыда авыр тәэсир калдыра. Язучы бу әсәре белән ни әйтергә теләгәнен ныграк ачыклаган булса, үз алдына куйган бурыч-ны — сугыш чорында яшүсмерләрнең кеше булып үсеп җитүен күрсәтү бурычын — уңышлырак үтәп чыккан булыр иде.

Мәдинә МАЛИКОВА.

## ЧИТ ИЛ ЯЗУЧЫЛАРЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТУРЫНДА

*Шукран Вуап-Мокану*

Әдәбият белгече, Румыния халык республикасы

# ҖӘЛИЛ РУМЫНИЯДӘ

Муса Җәлилнең Моабит шигырьләре дөньяның төрле почмакларында, төрле телләрдә яңгырый; аның тормышы, көрәш юлы һәм иҗаты белән кызыксыну көннән-көн арта бара. Луи Арагон, Жованни Жерманетто, Леон Небенцаль, Эрих Мюллер, Ярослав Кабичек һәм Роже Бодер кебек сүз осталары Муса Җәлилне олылап искә алалар һәм аның җырларына югары бәя бирәләр.

Бик күп милләт укучылары кебек үк, румын халкы да патриот шагыйрьнең ялкынлы җырларын үз телендә укый. Румын укучысы Муса Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлы белән беренче мәртәбә 1958 елда «Рус китабы» нәшриятында чыккан «Героик җыр»[1] исемле шигырьләр җыентыгы аркылы танышты. Җыентыкка кергән шигырьләрнең тәрҗемәчесе — шагыйрь Теодор Поскэ. Күренекле татар тәнкыйтьчесе Гази Кашшаф язган сүз башында героик шагыйрьнең тормышы һәм иҗат юлы турында киң мәгълүмат бирелгән.

Җыентыктагы илле сигез шигырьдән[2] уналтысы шагыйрьнең әсирлеккә кадәр иҗатыннан алынган, калган кырык икесе «Моабит дәфтәрләре»ннән сайланган. Җыентык ике бүлектән тора. Беренче өлеше «Дуска истәлек» дип аталган, ә икенчесе «Моабит дәфтәрләреннән» дип исемләнгән. «Иртән», «Комсомолларга», «Юл сызмалары», «Безнең сөю», «Тирга», «Сәрби әби», «Ул үскәндә», «Хуш, акыллым» шигырьләре, рус теле аша тәрҗемә ителүләренә карамастан, шагыйрьнең осталыгы, зур талантка ия булуы турында сөйлиләр. Моабит циклыннан оригиналга бик якын һәм уңышлы тәрҗемә ителүләре белән, түбәндәге шигырьләр аерылып тора: «Ирек», «Аерылу», «Кол», «Соңгы җыр», «Мәхкүм», «Кандала», «Ана бәйрәме», «Күлмәк», «Вәхшәт», «Дуска», «Катыйльгә», «Ышанма», «Батырлык турында», «Аяксыз», «Иман» һәм «Җырларым».

Татарча җыентыклардагы кебек, румын телендәге җыентык та «Җырларым» исемле шигырь белән ачыла. Шагыйрьнең «Томаулы гыйшык», «Тозлы балык», «Күршеләр», «Сәгать», «Хәдичә» кебек юмористик шигырьләре дә онытылмаган. Җыентык татар шагыйренең рухын һәм осталыгын, чын художник һәм чын кеше булуын укучының күз алдына китереп бастыра һәм тәэсирләндерә.

1961 елда Муса Җәлилнең «Ышанма» һәм «Дуска» шигырьләре, Лукрецка Попэску һәм Ион Потопин тарафыннан тәрҗемә ителеп, «XX нче гасыр»[3] әдәби журналында басылып чыкты. Шул уңайдан тәрҗемәчеләр укучыны Муса Җәлилнең кыскача биографиясе белән таныштыралар, румын укучыларына аны шагыйрь дә, көрәшче буларак та тәкъдим итәләр.

Тора-бара Муса Җәлил иҗаты белән кызыксыну тагын да үсә төште. 1965 елда «Чит илләр әдәбияты турында очерклар»[4] дигән гыйльми журнал битләрендә Шукран Вуапның «Моабит дәфтәрләре» мәкаләсе басылып чыкты. Мәкаләдә Муса Җәлилнең татар әдәбиятында тоткан урынына, аның әдәби эшчәнлегенә, әсирлектә һәм Моабит төрмәсендә иҗат иткән шигырьләренә шактый тулы характеристика бирелгән.

Муса Җәлил, бөек «бер карт иман» төсле, тамырларын татар җирлегенә тирән җәелдереп көч алган һәм шуның аркасында яшәрә, матурлана барган үлемсез шагыйрь. Сугышта күрсәткән батырлыгы һәм үлеме белән генә түгел, үзенең гүзәл әсәрләре белән дә ул исемен мәңгеләштерде. Үзе үлсә дә, «мең яшәрлек иман булып», яшьлегенә «һәйкәл булып», эше калды, эзе калды.

---

[1] Муса Җәлил. Героик җыр. «Рус китабы» нәшрияты. Бухарест. Румын телендә.

[2] Шигырьләр хронологик тәртиптә бирелгәннәр.

[3] XX нче гасыр. Чит ил әдәбияты журналы. 1961 ел. 10 сан. 80—81 битләр.

[4] Чит илләр әдәбияты турында очерклар. Бухарест. Румын телендә. 1965 ел. VII том. 255—277 битләр.



сатира
һәм
юмор

*Шәүкәт Галиев*

## Юаттылар...

Улы армиягә киткәч,
Керәп күрше апалар,
«Кайтыр, кайтыр, кайгырма!» дип,
Әнисен юаталар.
Кызы кияүгә киткәч тә,
Керә шул ук апалар,
«Кайтыр, кайтыр, кайгырма!» дип,
Әнисен юаталар...

## Бари

— Ник эшләмисең, Бари!
Тик ятып тормыш бармый!
Елмаеп карый Бари:
— Эшләмәгәч тә ярый —
Алдым, менә, лотерей,
Шул лотерей отар, — ди.

## Шигырьчегә

Ничә карасаң да китабыңда
Хуплар өчен урын әз әзен,
Мактамыйча булмый әмма тышын
Һәм шытырдап торган кәгазен!

## Дөнья — куласа...

„Картлар алай, картлар болай» диеп
Йөри торгач,
Яшь гомерләр үткән.
Инде менә
«Яшьләр алай, яшьләр болай» диеп
Сукраныр чак җиткән...

## Чамала

Яратсаң Волейболны,
Белмәссең Валидолны!

## Чират күпере

Әби карчык, юкка шүрлисең син,
Искә алып сират күперен,
Көнгә чыккач ничә үтәсең бит
Кибетләрдә чират күперен!

# Халык артисты



Касыйм агага 75 яшь тулды. Ләкин бабай дип булмый әле үзен. Тукай әйтмешли: «яңак, маңгай җыерылмаган, тешләр дә сау, яшьләрчә саф, ачык чыга аның сүзе».

Касыйм Шамил 1892 елның 30 августында Әлмәт авылында туа. Авыл мәдрәсәсен тәмамлагач, Казанның «Мәрҗани» мәдрәсәсендә укый башлый. Ләкин озак та үтми, шәкертләр хәрәкәтенә катнашкан өчен, мәдрәсәдән куыла. Шуннан инде булачак артистның тормыш мәктәбе башлана. Устьеда җиләк-җимеш белән сәүдә итүчедә эшләү дисеңме, йомышчы малай булып йөрү дисеңме — Шамилнең башыннан барысы да уза.

Әле мәдрәсәдә укыган елларда ук Касыйм театр белән кызыксына башлый. Приказчиклар клубында куелган спектакльләргә йөри. Озакламый ул үзе дә һәвәскәр артист булып китә.

Шулай да аны зур сәнгать дөньясына «Сәйяр» труппасы, татарның атаклы артисты Габдулла Кариев алып чыга. Театр сәнгатенә чын күңелдән бирелгән яшь егетне Кариев труппага чакыра. К. Шамил «Сәяр»да суфлерлык итә, билет сата, афишалар ябыштыра. Болардан тыш, ул тавыш-эффект һәм грим остасы да була.

Касыйм ага Шамилнең «Сәйяр»да башкарган барлык рольләренә дә тукталу мөмкин түгел. Алар күп. Шуның белән бергә, һәрбер артистның иҗат характерын, аның сәхнә тарихында тоткан урынын ачыклаган һәм билгеләгән төп рольләре була. Касыйм аганың шундый рольләреннән берсе — Кулигин образы («Яшенле яңгыр»).

Бөек Октябрьдан соң К. Шамил җиң сызганып, татар совет театрын төзү эшенә керешә. 1918 елда Казанның Елга аръягында (Пороховой бистәдә) беренче эшче театрын оештыра. Иҗат юлларын шушы театрда башлаган Җ. Саинов, Г. Борнаев, Х. Алмазова кебек артистлар хәзер дә Киров районы халык театрының актив һәвәскәрләре булып саналалар.

Казанда беренче Татар дәүләт совет театрын төзүдә дә К. Шамил зур булышлык күрсәтә, берникадәр вакытлар труппаның режиссеры булып эшли. Шул ук 1920 елның апрель ахырында Хәрби коллегиянең сәяси бүлеге, театр эшләрен юлга салу өчен, Касыйм Шамилне Мамадышка җибәрә. Чит шәһәрләрдә яшәгән артистларны чакырып һәм Мамадышта эшләп килгән драмтүгәрәк кешеләрен җыеп, Касыйм Шамил район театры төзи. Театрга «Сабанчы» исеме бирелә.

К. Шамил татар балалар театрын булдыруда күп көч һәм энергия түккән тынгысыз йөрәкле артистларыбызның берсе. 1918—1919 елларда Касыйм ага Шамил «Алафузов театрында» (хәзерге Җитен комбинаты клубында) балалар труппасы төзи. Аның җитәкчелегендәге труппа балаларга «Корымчы бабай», «Шүрәле» кебек әсәрләр күрсәтә. 1923 елда шәһәрнең Елга аръягы районында фабзавуч мәктәбендә Касыйм Шамил тагын бер балалар труппасы төзүдә катнаша. Ә 1925 елдан Татар дәүләт театры каршында да балалар труппасы эшли башлый. Труппаның репертуарында: «Тычканга үлем, мәчегә көлке», «Бездә һәм аларда», «Октябрь чәчәкләре» кебек зур тәрбияви кыйммәткә ия булган пьесалар куела. Кызганычка каршы, тиешле ярдәм булмаганлыктан, бу труппа да тарала...

Габдулла Кариев җитәкчелегендәге труппада башлангыч тәрбия алган артист совет чорында үзенең сәхнә осталыгын тагы да тирәнәйтте һәм киңәйтте. Касыйм аганың сәхнә осталыгы бигрәк тә авыл кешеләрен сурәтләгән әсәрләрдә тулы ачылды. Ул совет колхозчыларының күркәм табигатен, теләк-омтылышларын әйбәт бирә. Шуңа күрә дә ул тудырган образлар тормышчан, ышандырырлык булалар.

Касыйм Шамил тарафыннан иҗат ителгән икенче бер теркем — руханилар тибы. Юныс хаҗи булсынмы, «Зәңгәр шәл»дән Ишан яки Әблиевнең «Шәмсекамәр»ендәге Суфи булсынмы, аларның һәрберсе үзенчәлекле, артист һәрберсенә кабатланмас штрихлар салган.

К. Шамил аеруча уңышлы иҗат иткән өченче теркем образлар — сәүдәгәрләр. Болар инде үзләренә аерым бер галлерея:



К. Тинчуринның «Беренче чәчәкләр» спектакленнән күренеш. Сулдан беренче, Суфи ролендә К. Шамил.

Сиражи («Банкрот»), Кәрим бай («Башмагым») һәм бик күп башка сәүдәгәр типлары.

Дөрес, киң диапазонлы артист буларак, ул болар белән генә чикләнми. Ул башкарган образлар күп төрле, аларның һәркайсы тулы канлы, тамашачы күңелендә озак саклanырлык булып иҗат ителгән.

**Х. ГОБӘЙДУЛЛИН,**
сәнгать фәннәре кандидаты.

# *Сәнгатькә багышланган гомер*

Артист-режиссер, педагог һәм оста оештыручы буларак, Сәет Садри улы Булатов татар совет театрын үстерүдә, сәхнә өчен профессиональ кадрлар тәрбияләүдә зур хезмәт күрсәткән кешеләрнең берсе.

1912 елда Сембер (хәзерге Ульяновск) шәһәренең алдынгы яшьләре «Ак-белем» түгәрәгә оештыралар. Бу түгәрәккә йөрүчеләр рус язучыларының цензура тарафыннан тыелган әсәрләре белән танышалар, күп вакытларын йорт спектакльләре куюга багышлыйлар. Түгәрәкнең оештыру эшләрендә яшьтән үк тыңгысыз йөрәкле Сәет тә актив катнаша.

Күптәннән Сембер шәһәрендә татар театры оештыру турында хыялланып йөргән Барый Тарханов 1916 елда, ниһаять, «Таң» исемле труппа төзи. Кыска гына вакыт эчендә коллектив Г. Камалның «Безнең шәһәрнең серләре» комедиясен әзерли һәм 1916 елның 16 январенда беренче мәртәбә Сембер шәһәре тамашачыларына түләүсез, ачык спектакль күрсәтә. С. Булатов бу спектакльдә ике роль — Фатыйх һәм декламатор-конферансье рольләрен — башкара. 1917 елның җәендә «Таң» Мәләкәс, Бәгелмә шәһәрләрендә гастрольдә була. Бу вакытларда инде аның репертуары шактый киңәя. Артистлар Г. Камалның «Беренче театр», М. Фәйзинең «Галиябану», Г. Гейненың «Әльмансур»ын һәм башка күп кенә спектакльләр әзерлиләр. 1918 елның июнендә, Сембер шәһәрен чехлар басып алгач, «Таң» труппасы яшәүдән туктый.

Шәһәр тыныч тормышка кайту белән, Сембер партия комитетының милли бүлеге Б. Тарханов белән С. Булатовка татар театры труппасын яңадан оештыру эшен тапшыра. Ахырдан бу яңа труппа татар-башкорт полкларына культура хезмәте күрсәтүдә зур роль уйный. 1919 елның июлендә Үзәк хәрби мөселман коллегиясе тарафыннан С. Булатов Стәрлетамак шәһәренә — Башвоенкомның сәяси бүлек идарәсе карамагына режиссер итеп җибәрелә. Биредә ул оештырган татар театры «Мираж» кинотеатры бинасында үзенең спектакльләрен күрсәтә башлый һәм тиз арада шәһәр тамашачыларының ихтирамын казана. 1920 елның көзендә Юденич бандасы Петроград шәһәренә куркыныч сала. Стәрлетамак театрының күп кенә артистлары (М. Сульва, Р. Урманцева, Ә. Сәмитова, Ә. Хисамов һ. б.) Петроград фронтына җибәреләләр. С. Булатов исә, партия кушуы буенча, Урта Азиягә китә. Биредә алар Камал I белән Үзбәк дәүләт драма театрын (хәзерге Хәмзә театры) оештыруда катнашалар. Тиз ара эчендә театр өчен җәйге

бина төзелә, милли кадрлар туплана һәм Урта Азиядә яшәүче үзбәк, татар халыкларына культура хезмәте күрсәтү буенча шактый зур эш башкарыла. Берничә ел дәвамында С. Булатов бу театрның директоры, ә Камал I художество җитәкчесе булып эшлиләр.

1923 елда С. Булатовны Уфага җибәрәләр. Анда ул, Минһаҗов, Бухарский һәм башка артистлар белән берләктә, Башкорт дәүләт театрын төзешә. Тагын бер елдан соң яңадан үзенең туган шәһәре Сембергә кайта һәм, Ф. Латыйпов, К. Шамилләрнең якын булышлыгы белән, Беренче күчмә музыкаль комедия труппасы оештыра. Төзелүенә күп тә үтми, музыкаль труппа Саратов, Астрахань, Куйбышев, Волгоград һәм башка шәһәрләрнең тамашачыларын «Аршин мал алан»н, «Мәштибат», «Башмагым», «Оҗмахтан тәмугка», «Галиябану» кебек спектакльләр белән таныштыра.

1925 елда С. Булатов Казанга чакырыла. Мәгариф комиссариаты кушуы буенча, С. Булатов, Х. Уразиков, З. Богданова, С. Сакаевалар авыл һәм район тамашачыларына культура хезмәте күрсәтү эшен оештыралар. Алар, Минзәлә шәһәре һәвәскәрләре белән кушылып, Минзәлә театрын төзиләр. 1927 елда исә, татар театрында профессиональ белемле режиссерларның җитешмәвен күздә тотып, С. Булатов Мәскәү ГИТИСына укырга җибәрелә.

1930 елда ул ГИТИСны тәмамлый. Озакламый без инде аның фамилиясен Фрунзе исемендәге Эшче театрының афишаларында укыйбыз. Бирелә ул Савельев, Любезнов, Богатыренко, Майоров, Емельянов кебек сәхнә мастерлары белән бергә уйный. Мәскәүдә үткән елларда Булатов алдынгы рус культурасы, сәхнә мастерларының эшләре һәм рус театр дөньясындагы иң яхшы спектакльләр белән таныша. Станиславский, Немирович-Данченко, Вахтангов кебек гениаль режиссерларның эш методларын өйрәнә.

1931 елның көзендә С. Булатов Казанга кайта һәм Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында режиссер булып эшли башлый.

Сәет Булатовның Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куйган беренче спектакле драматург Т. Гыйззәтнең «Бөек борылыш» әсәре булды. Бу спектакль театр коллективының, иҗатта төрле «изм»нардан котылып, социалистик реализмга таба борылыш ясавын раслады.

С. Булатов эрудицияле, эмоциягә һәм фантазиягә бай режиссер булды. Аңа зур вакыйгаларны эченә алган, көчле характерларның бәрелешен чагылдырган романтик әсәрләр якын иде. Спектакль өчен кирәкмәгән трюклардан качарга тырышты. Шул ук вакытта сәхнәдә төссезлекне, тигезлекне, бертөрлелекне яратмады, үзенең режиссерлык эшендә контрастлардан оста файдаланды. Аның мизансценалары төгәл һәм кыю. Ул куйган спектакльләрдә фикер ачык, максат билгеле һәм конкрет. Булатов спектакльләре тамашачыларны беркайчан да тыныч калдырмыйлар, уйландыралар.

Бу елларда С. Булатовның актерлык сәләте дә шактый камилләшә. Ул Сәләхи («Шәмсекамәр»), Дикой («Яшенле яңгыр»), Казый («Хуҗа Насретдин»), Беркутов («Бүреләр һәм сарыклар»), Президент («Мәкер һәм мәхәббәт»), Мигуэль («Салют Испаниягә!») кебек капма-каршы характердагы образлар галлереясы тудыра.

«Бронепоезд 14—69» спектаклендә С. Булатовка Себер партизаннары җитәкчесе Вершинин образы тапшырыла. Дәрәслек эзләүче бу тынгысыз кешене тормыш үзе революция ягына этәрә. Авыл крестьяны Вершинин-Булатов интервентларның һәм контрреволюционерларның явыз ниятләрен сизә, ләкин ялгызы гына дөрес юл сайлый алмый. Бу юлны аңа революцион комитетның председателе Пеклеванов күрсәтә. Һәм Вершинин-Булатов туган халкын коллыктан азат итү өчен көрәш сафына баса.

«Шәмсекамәр» спектаклендә С. Булатов Сәләхи ролен уйный. Капиталистик тормышның социаль нигезләрен фаш иткән бу образ аның башкаруында хәйләкәр, үз максатына ирешү өчен теләсә нинди әшәкелекне эшләргә әзер торучы кеше булып хәтердә калган. Үзе иҗат иткән уңай образларын никадәр көчле яратса, аларга үзенең йөрәк җылысын салса, алар аша халыкка, туган илгә мәхәббәт уятса, ул вак җанлы эгоистларга, кешелек дөньясының явыз дошманнарына, хыянәтчеләргә, паразитларча көн күрүчеләргә шулкадәр үк көчле нәфрәтен белдерде. Аның түбән регистрдагы, эмоциягә бай тавышы, зур, таза гәүдәсе сәхнә өчен үзе бер бизәк булды.

С. Булатов сәхнә өчен кадрлар тәрбияләү эшенә дә зур игътибар бирде. Аның педагоглык эшчәнлеге 1935 елдан ук башлана. Озак вакытлар Казан театр техникумында укыта. Аннан укып чыккан 150 ләп артист хәзер Минзәлә, Әлмәт колхоз-совхоз театрында, Татар дәүләт академия театрында һәм башка шәһәрләрдә уңышлы эшләп киләләр. Алар арасында тамашачыларның мәхәббәтләрен казанган, театр сәхнәсендә онытылмаслык образлар иҗат иткән Н. Гайнуллин, С. Өметбаев, Р. Җиһаншина, З. Басыйрова, У. Альмеев, И. Гафуров кебек сәхнә осталары бар.

С. Булатов байтак еллар буе Әлмәт театрының баш режиссеры булып та эшләде. Авыл һәм район тамашачыларының көннән-көн үсә барган сорауларына җавап бирерлек спектакльләр иҗат итте. Үз тирәсенә яшь драматургларны туплап, театрның репертуарын яңа әсәрләр белән баету турында да кайгыртты.

Бөек Октябрь революциясе алдыннан театр сәхнәсенә аяк баскан талантлы художник һаман да тынгысыз тормыш белән яши. Сәет ага хәзер лаеклы ялда. Ләкин, олы яшьтә булуына карамастан, ял итү турында уйламый. Элеккечә үк кайнар йөрәк, зур дәрт белән үзешчән сәнгать коллективларының иҗат эшендә катнаша, аларга сәхнә кануннарын үзләштерүдә ярдәм итә.

Ф. ШӘРӘФИЕВ.

## Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары

### ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫ

Шушы елның 9 июнендә Татарстан язучыларының ачык партия җыелышы булды. СССР язучылар союзының IV съезды йомгаклары уңае белән үткәрелгән бу җыелышта Татарстан язучылар союзы председателе, съезд делегаты Мирсәй Әмир доклад ясады.

— СССР язучылар союзының IV съезды, — диде ул, — җитди һәм эшлекле шартларда узды. Анда совет язучыларының илле ел эчендә башкарган эшләренә йомгак ясалды, ирешкән уңышлары билгеләнеп үтелде. Язучылар иҗаты үзган илле ел эчендә илебез тарихы белән тыгыз бәйләнештә үскәнлеге һәм зур уңышларга ирешкәнлеге күрсәтелде. СССР язучылары союзының хөкүмәтебез тарафыннан Ленин ордены белән бүләкләнүе — әнә шул зур уңышларның нәтиҗәсе ул. Узган илле ел эчендә, аеруча соңгы елларда, безнең татар әдәбияты да бик нык үсте. Татар язучылары иҗат иткән байтак әсәрләр Бөтенсоюз аренасына чыкты һәм хәтта чит телләргә дә тәрҗемә ителде. Бу — куанычлы хәл. Әмма без, ирешелгән уңышларыбыз белән беррәттән, житешсез якларыбызны да күрә белергә тиешбез. Съездда бу мәсьәләгә дә игътибар ителде. Җентекләбрәк карасак, безнең әдәбиятта да кимчелекле яклар бар әле. Соңгы елларда, мәсәлән, кайбер язучыларның әсәрләрендә, зур эшләр башкаручы бүгенге көн геройларын, тормыштагы уңай күренешләрне сурәтләү урынына, тискәре күренешләрне, кимчелекле якларны чагылдыру очраклары сизелә башлады. «Казан утлары» журналы редакциясе дә кайчакта шундый әсәрләргә урын биргәләп куя... Безнең төп максатыбыз — коммунизм төзүче бүгенге көн кешеләре образын тудыру. Моны без һәрвакыт истә тотарга тиешбез. Мине дөрес аңлагыз, гел уңай күренешләрне генә сурәтләргә, тискәре якларга игътибар итмәскә димим мин. Андыйларны да чагылдырырга мөмкин һәм кирәк. Әмма безнең әдәбиятның төп юнәлеше социалистик реализмның төп юлыннан тайпылышсыз барырга тиеш, игътибарны күбрәк уңай һәм үрнәк булырлык образлар тудыруга юнәлтергә кирәк безгә.

Докладчы шулай ук язучыларның ил алдындагы һәм, гомумән, бөтен дөнья халыклары алдындагы гражданлык бурычына, аларның җәмәгатьчелек алдындагы җаваплылыгына, тормышны тирәнрәк, тулырак өйрәнү мәсьәләләренә тукталды һәм IV съезд куйган бурычларны тормышка ашыруда республикабыз язучылары тагын да ныграк илһамланып эшли башларлар дигән ышаныч белдерде.

М. Әмирдән соң съезд делегаты профессор Хатип Госман сүз алды. Ул съездда туган тәэсирләре белән уртаклашты һәм язучыларның кешелек дөньясы язмышы өчен җаваплылыгы, социалистик реализмның нигезен тәшкил иткән тарихи хакыйкать, һәр әдипнең ил алдындагы, бөтен дөнья алдындагы бурычлары турында сөйләде.

Съезд делегаты Гомәр Бәширов та съезд көннәрендә алган тәэсирләре белән уртаклашты һәм яңа уставтагы үзгәрешләрне җентекләбрәк аңлатып бирде.

Язучыларның IV съезды йомгаклары буенча фикер алышуларда шулай ук Сибгат Хәким, Нәби Дәүли, Җәвад Тәрҗеманов, Әминә Бикчәнтәева да катнаштылар һәм күп кенә файдалы тәкъдимнәр керттеләр. Соңыннан җыелыш Язучылар союзының эшен тагын да яхшырту буенча резолюция кабул итте һәм ул резолюциянең күчермәсен СССР язучылар союзына тапшырырга дигән карар чыгарды.

### ЖУРНАЛ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Татарстан язучылар союзы идарәсенең 22 июньдә үткәрелгән киңәйтелгән утырышында «Казан утлары» журналының бу елгы 1—6 саннарында басылган материаллар турында фикер алышу булды.

Утырышта журналның 1—3 саннарына Әхмәт Юныс, 4—6 саннарына Хәсән Хәйри күзәтү ясадылар. Аннары әлеге саннар турында язучылар үз фикерләрен сөйләделәр. Түбәндә, бераз кыскартып, шул утырышта катнашкан иптәшләрнең чыгышларын урнаштырабыз.

— Мин сүзне проза әсәрләреннән башламакчы булам, — диде **Ә. Юныс**. — Ни өчен дигәндә, журналның йөзен, аның сыйфатын беренче чиратта проза әсәрләре билгели. Мин сүз алып барачак беренче һәм өченче саннарда И. Газиның «Малайлыкта кунакта», Ә. Баяновның «Яшьлегемне эзлим» исемле повестьлары һәм Л. Ихсанованың «Мин әле бу», Р. Фәизовның «Гафур» исемле хикәяләре бирелгән. Күрәсез, проза әсәрләре сан ягыннан күп түгел. Әмма хикмәт санда түгел, бәлки ул әсәрләрнең сыйфатында. Ибраһим Газиның «Малай-

лыкта кунакта»сы жыйнак кына әсәр ул. Әмма бик житди, бик кызыклы һәм оста язылган әсәр. Анда бернинди шаккатарлык хәлләр дә юк, ләкин повесть беренче юлларыннан ук күңелне жәлеп итеп ала да ахырынача ияртеп бара. Минемчә, язучының уңышы шунда, ул күп сүз сөйләми, вакыйгаларның иң кирәклеләрен генә сурәтләп бара һәм, шулай итеп, зур тормышны, төрле хәлләрне укучының күз алдына китереп бастыра. Әсәрнең теле шома, образлы. Шунлыктан ул бик ансат укыла һәм истә кала. Тагын шунсын да әйтеп үтәргә кирәк, автор бу әсәрендә берьюлы ике роль башкарган: бер үк вакытта авыл малае булып та, зур жәмәгать эшлеклесе, бүгенге көн таләпләреннән чыгып фикер йөртүче булып та сурәтләгән ул вакыйгаларны.

Әхсән Баяновның «Яшьлегемне эзлим» исемле повестеның герое Әнис туган авылына кайта һәм яшьлек елларын искә төшерә. Анда да матур гына образлар сурәтләнгән. Минем күңелемә, мәсәлән, Килмит образы хуш килде. Аны автор үзенә генә хас буяулар белән күрсәтеп бирә алган. Ленасы да шулай ук үзенчәлекле образ. Кыскасы, бу әсәрендә авторның үзенчәлекле таланты күренеп тора. Әмма ул шул талантын тиешенчә файдалана алмаган. Әнис образы житди образ түгел. Аның эчке дөньясына тормыш җиле кагылмый диярлек. Әсәрне укыганда автор бөтен эшне әлеге тискәре, тар фикерле Әнискә тапшыра да үзе шуның арбасына утырып кына бара кебек тәэсир туа.

Журналның үзе күзәткән саннарында басылган хикәяләргә тукталып, Ә. Юныс, Р. Төхфәтуллинның «Пыяла батыгы һәм асылташ», «Ике көймә», «Яшьлек сере» исемле парчаларын һәм Л. Ихсанованың «Мин әле бу» исемле хикәясен уңай яктан билгеләп үтте, ә Р. Фәизовның «Гафур» исемле хикәясеннән канәгать булмавын әйтте.

— Бу хикәядә, — диде ул, — Р. Фәизов акылга тулы булмаган кешене образ итеп алып әйбәт итмәгән, әһәмиятлерәк, зуррак вакыйганы сурәтлисе урында, вак темага әсәр язган.

Аннары Ә. Юныс Г. Ибраһимов юбилее уңае белән басылган материалларга, истәлекләргә һәм Ф. Хөснинең «Урыннарындамы сүзләр-солдатлар?» исемле мәкаләсенә тукталды һәм аларның тирән эчтәлекле, кызыклы һәм файдалы икәнлекләрен әйтте.

— Ә миңа бу өч сандагы очеркларга һәм тәнкыйть мәкаләләренә карата алай әйтеп булмый, — диде ул, сүзен дәвам итеп. — Өч санның берсендә дә телгә алып әйтерлек житди тәнкыйть мәкаләсе тапмадым мин. Очеркларга килгәндә дә мактанырлык эш юк. Мәхмүт Хәсәновны язучы буларак хөрмәт итә идем мин. Әмма журналда басылган «Таныш булыгыз, Сәет Сәлимгәрәев» исемле очеркын укыгач, аптырабрак калдым. Язучы кулы белән язылганга охшамаган ул. Язучыга хас әдәби осталык, вакыйгаларны жанлы, ачык итеп сурәтләү житеп бетми. Бик ашыгып өстән-өстән генә язылган кебек тәэсир калдыра ул.

— Соңгы елларда, — дип сүзен башлады **Хәсән Хәйри**, — журналның гомуми торышы, һичшиксез, яхшырды: яшьләр ижатына шактый киң урын бирелә башлады, яңа бүлекләр ачылды. Мин күзәткән 4—6 саннарда аеруча игътибарга лаеклы ике әсәр бар. Гомәр Бәшировның «Туган ягым— яшел бишек», Фатих Хөснинең «Язмыш шуклыгы» исемле повестьлары алар. Бәшировның повесте турында ныклап сөйләргә иртәрәк, чөнки ул әле басылып бетмәгән. Шулай да, басылган кадәресеннән чыгып фикер йөрткәндә, ул повесть әйбәт, өметле булырга охшый.

Ф. Хөснинең «Язмыш шуклыгы», минемчә, элегрәк язылган булырга тиеш. Әмма соңгарак калып басылган ул. Журнал аны соңгарыбрак күтәреп чыккан. Минемчә, бу повесть әдәби эшләнеше ягыннан йомшак әсәр. Көчәнеброк язылганга охшый ул, Фатих талантына хас әйбер түгел. Образлары да ахырына кадәр эшләнеп житмәгән шикелле. Эш хәтта анда гына да түгел. Эш шунда, автор бу әсәрендә образлы сурәтләү урынына публицистика белән артыграк мавыгып киткән.

Үзе күзәткән саннардагы поэзия әсәрләренә тукталып, Х. Хәйри Ә. Давыдов һәм Р. Гатауллин шигырьләренең әйбәт икәнлеген әйтте. Тәнкыйть бүлегенә караган материаллар арасында, әдәби ел йомгаклары материалларын исәпләмәгәндә, житди мәкалә булмавын һәм яңа чыккан китапларга рецензияләр аз бирелүен искәртеп үтте. Аннары ул әдәбият тарихына караган документларның соңгы вакытта журналда шактый еш күренә башлавын әйтте һәм шул ук вакытта андый әйберләр белән редакция кирәгеннән артыграк мавыкмасын иде дигән теләк белдерде. Соңгы вакытларда журналда очерклар, публицистик мәкаләләр азайды, дип, бүгенге көн кешеләре башкарган зур эшләр турында очерклар һәм публицистик мәкаләләрне журналда күбрәк урнаштырырга тәкъдим итте.

Шуннан соң фикер алышулар башланды.

**Хатип Госман:**

— Мин әдәбият, культура тарихына караган материаллар хакында берничә сүз әйтмәкче булам. Х. Хәйри журналда тарихи материаллар артыграк күбәеп китүен әйтте. Минемчә, артык түгел алар. Культурабыз, әдәбиятыбыз тарихына караган материалларны киләчәктә дә журналда бастырып барырга кирәк. Мин, мәсәлән, Галимжан Ибраһимовның үз кулы белән язылган автобиографиясен журналда бастырып, редакция бик яхшы эшләде дип саныйм. Ул документны әзерләп биргән өлкән язучыбыз Афзал Шамовка да рәхмәт әйтәсе килә.

Яшьләр үз ата-бабаларының тормышын, гореф-гадәтләрен белеп үсәргә тиешләр. Ә моның өчен аларны культура һәм әдәбиятыбыз тарихы белән мөмкин кадәр киңрәк таныштырып барырга кирәк. Менә шул жәһәттән чыгып караганда журналның тарихи материалларга урын биреп баруын

кимчелек димәс идем. Әмма тарихи материалларны басканда аларның текстологиясенә бик нык игътибар итәргә кирәк. Анда бернинди дә төгәлсезлекләр китмәскә тиеш... Соңгы елларда басылган тарихи материалларда шул нәрсә сизелә: хәзер безнең галимнәр буш сүз сөйләмиләр, алар үз фикерләрен фактлар белән дәлилләп бирә башладылар. Бу — куанычлы күренеш.

Аннары Х. Госман Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» исемле повестена да тукталды һәм ул әсәрнең теле гаҗәеп дәрәҗәдә бай, халыкчан булуын, аның әдәби телебезне баетырга ярдәм итәчәген әйтте.

**Фатих Хөсни:**

— Узган тикшерүләрдә дә әйтелүгә карамастан, журналда бүгенге әдәбиятыбызга ныклап анализ ясаган җитди тәнкыйть мәкаләләре һаман да күренми әле. Күрәсең, редакция бу эшне тиешенчә оештырмый булса кирәк. Әмма, шул ук вакытта, гаепне редакция өстенә генә аударып калу да дөрес ук булмас. Алар безгә, язучыларга, телдән дә, хатлар язып та әледәнәле журналда катнашырга мөрәҗәгать итәләр. Без үзебез акрынрак кыймылдыйбыз, ахрысы.

Журналның алтынчы санында Ф. Ибраһимовның «Без түбәннән күтәрелдек» исемле мәкаләсе басылган. Анда сүз музыкабыз турында бара. Музыка турында бары тик музыка белгечләре генә язарга тиеш дип әйтмим мин. Теләсә кемнең язарга хакы бар. Әмма мондый җитди, җаваплы мәсьәләләр турында кемнән яздыртуны ныклабрак уйларга кирәк. Ф. Ибраһимов мәкаләсендә кайбер фикерләр дә, терминнар да сәеррәк килеп чыккан... И. Газиның «Малайлыкта кунакта», Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» исемле повестьларында халкыбызның үткән тормышы сурәтләнә. Җиргә, туган якка зур мәхәббәт сизелә. Рәхәтләнеп укыла торган әсәрләр болар. Ә менә яшь язучыларыбыз әсәрләрендә ул нәрсә җитенкерәми. Әхсән Баянов повестена карата Ә. Юныс байтак тәнкыйть сүзләре әйтте. Мин аның белән килешәм. Әхсәннең Әнисе гел үзе турында гына уйлый, үзе белән генә кокетничать итә. Әмма мәсьәлә анда гына түгел. Мәсьәлә безнең кызларыбызны йөгәнсез итеп бирүдә. Алар шулай, повестьта бирелгәнчә, теләсә кемне кочак җәеп кабул итәргә тормыйлар лабаса. Безнең хатын-кызларга хас сыйфат түгел бит бу, егетләр! Әхсәннең геройлары бик йомшак буынлы итеп бирелгән. Дөрес, тормышта бозык хатынкызлар да була, әмма андыйларны сәхнә түренә менгереп утырту кирәкме икән? Мине рәнҗеткән өченче нәрсә шул: әсәрдә геройның үз халкына югарыданрак каравы сизелә. Бу бик хәвефле нәрсә, болай булса, ерак китә алмабыз без. Әсәрнең теле дә шактый кытыршы. Тел белән бик сак эш итәргә, аны хөрмәтләргә кирәк...

Хәсән, синең белән дә бик бәхәсләшәсем килә. Минем повестьта, син уйлаганча, сүз культ мәсьәләсе турында гына бармый бит. Мин анда борыннарын каян җил иссә шул якка куеп, тыштан бик гадел булып, галим булып күренергә тырышсалар да, бары тик үз интересларын гына кайгыртып йөрүче ике аяклы бүреләр бакчасына таш атмакчы идем. Һәм ул таш тиешле урынына төште шикелле...

**Сибгат Хәким:**

— Бу ел басылган поэзия әсәрләре арасында Илдар Юзиевнең «Тынлык белән сөйләшү» исемле поэмасы аеруча игътибарга лаек. Илдар иҗатын мин башыннан ук күзәтеп килөм. Үзенчәлекле, бары тик аңа гына хас буяулар белән иҗат итә торган шагыйрь ул. Һәм, минемчә, автор шул матур сыйфатларын бу әсәрендә тагын да үстерә төшкән. Илдар иҗатында мин Һади Такташ иҗаты белән охшашлык күрәм. Такташ зур вакыйгаларны бик оста тотып алып, кабарынкы, тәэсирле итеп сурәтләп бирә белә иде. Илдарда да шуңа охшашлык бар. Ләкин аның моңа кадәрге иҗатын мин менә болайрак күз алдына китерәм: әйтик, ул тауга менеп барышлый, ашыкмыйча гына, башта тау итәгендә моңланып, уйланып йөри. Бары шуннан соң гына тау башына күтәрелә. Ә менә бу әсәрендә ул, тау буенда озак йөрми, турыдан-туры күтәрелә, ягъни вакыйгаларны җыйнап тотып, иң кирәклеләрен сурәтли башлый. Бу — Илдарның иҗади уңышы, бер адым алга китеше дияр идем мин.

Инде Әхсән Баяновның «Яшьлегемне эзлим» повесте турында берничә сүз. Бу җыелышта әсәрнең эченә кереп, аны төрле яклап тикшерергә тиешләр иде. Әмма гомуми сүзләр генә сөйләнелә. Әсәрнең эчтәлеген сөйлибез, идеясен тикшерәбез, аның җанына үтеп кереп, асылын аңларга тырышмыйбыз. Дөрес, Әхсән әсәренең кимчелекләре дә бар, мин алар турында үз вакытында авторга да әйттем. Ләкин ул әсәрне юкка чыгарырга да ярамый бит. Мәсәлән, мин үзем анда Әхсәннең үзенә генә хас стилен, үзенчә язарга, вакыйгаларны үзенчә сурәтләргә тырышуын күрәм. Бик оста итеп, шагыйрьләрчә сурәтләнгән картиналар бар анда... Әсәр турында сөйләргә тотынганбыз икән, аның кимчелекле якларын гына түгел, матур, уңышлы якларын да билгеләп китәргә кирәк безгә...

**Атилла Расих:**

— Бу җыелыш миңа бик ошый. Җыелыш шушылай фикерне туры әйтешле, бәхәсле булырга тиеш. Бүген сүз күбрәк Әхсән повесте турында бара. Мин ул әсәрне укый башлау белән Экзюперигә ияргән икән бу дип уйладым. Белепме, белмичәме аңа ияреп язган ул. Әхсән әле үз стилен тапмаган, әмма мин анда талант юк дип әйтмәс идем. Тик Әхсән ул талантын үстерергә тиеш...

Фатихның «Язмыш шуклыгы» повесте да алай ук үтереп ташларлык әсәр түгел. Бу әсәрендә дә Фатих Фатих булып калган. Әмма аның да кимчелекләре бар. Күрәсең, төрле кешеләрнең киңәше буенча күп урыннарын үзгәрткәнгәдер, әсәрдә ямау салынган кебегрәк тәэсир калдыра торган моментлар очраштыргалый...

**Зәки Нури:**

— Мин бу саннарда эх, юкка баскан моны журнал, дип әйтерлек әсәрләр күрмәдем. Шул ук вакытта журнал редакциясе авторлар белән эшләүне тагын да көчәйтергә тиеш. Аларга әсәрләрен каткат эшләтергә, таләпчәнлекне арттырырга тиеш. Гел авторлардан килгән әсәрләрне генә көтеп ятарга ярамый, язучылар белән сөйләшеп, кайбер материалларны аларга заданиеләр биреп тә яздырырга кирәк. Бездә йөздән артык язучы бар. Ә журналда күбесенчә гел бер авторлар гына катнаша. Киләчәктә журнал күбрәк язучыларны тарту турында да кайгыртырга тиеш. Шулай ук әдәби портретларны да системалы рәвештә һәр сан саен урнаштырып барырга кирәк...

**Баян Гыйззәт:**

— Журнал яңа басылган әсәрләргә карата укучылар фикерен, ягъни укучылар хатларын шактый еш урнаштырып килә. Бу әйбәт, билгеле. Әмма, шул ук вакытта, язучыларның теге яки бу әсәргә карата әйткән фикерләре бик аз басыла. Минемчә, язучылар фикерен дә журналда системалы рәвештә биреп барырга кирәк...

Журналның җаваплы редакторы **Рафаэль Мостафин** сүз ала:

— Журналның бу елгы алты саны турында иптәшләр байтак кына файдалы фикерләр әйттеләр. Әмма мин Ә. Юнысның Р. Фәизов хикәясе — «Гафур»га биргән бәясе белән килешә алмыйм. Ул хикәядә хикмәт акылга тулы булмаган кеше образын бирүдә түгел бит. Автор ул хикәясендә, кешене кызгану бер яклы гына булганда, аны бозып та җибәрергә мөмкин, дигән фикер уткәрә иң. Бер-беребезгә мөгамәлә иткәндә саграк, акыллырак булырга ишарә ясый ул.

Очерклар журналда азрак бирелә, бирелгәннәре дә әллә ни мактарлык түгел дип бик дөрес әйттеләр. Безнең үзебезне дә борчый бу мәсьәлә. Без язучыларга заказлар да бирәбез, аларны командировкаларга да җибәрәбез. Әмма күп вакыт ул заказлар үтәлми, хәтта командировкага барган язучыларның да байтагы очерк язмыйча кала. Очерк жанрын җанландырып җибәрү өчен, язучылар үзләре активрак эшләсеннәр иде...

Ә. Баяновның «Яшьлегемне эзлим» повестена карата Ә. Юныс һәм Ф. Хөсни әйткән фикерләр белән дә килешеп бетмим мин. Алар әсәрнең тәрбияви роле юк дигәнрәк фикер әйттеләр. Дөрес, ул әсәрнең йомшак яклары, кимчелекләре дә бар. Әмма анда тормыш дөреслеге дә бар бит. Димәк, повестьның тәрбияви роле дә бар.

Шулай ук Хәсән Хәйри фикерләренә дә тулысынча кушыла алмыйм. Ул журналда бер үк әсәргә карата төрле фикерләр әйтелүен, әмма ул фикерләрнең кайсы дөрес икәнлеге редакция тарафыннан күрсәтелмәвен кимчелек итеп билгеләп үтте һәм, шулай итеп, журналның идея юнәлеше түбәнәя бара дигәнрәк нәтиҗә ясады. Минемчә, асылда эш алай түгел. Бер үк әйберләр турында төрле фикер булуы табигый, һәм ул фикерләрне урнаштырудан журналның тоткан юлы һич тә үзгәрми. Әйе, без журналда теге яки бу әсәргә карата төрле фикерләр урнаштырырга тырышабыз. Хәзерге укучылар әдәбиятны яхшы беләләр, алар үзләре нәтиҗә чыгара алалар. Кыскасы, дөреслеккә бер кеше фикере белән генә ирешеп булмый. Дөреслеккә үзара фикер алышу, бәхәсләшү аркылы гына ирешеп була. Редакция менә шуны күздә тотып эш итә.

Аннары Р. Мостафин тыңлаучыларны журналның перспектив планы белән таныштырды, редакция хезмәткәрләренең тормыш-көнкүрешен яхшырту мәсьәләләренә тукталды.

**Мирсәй Әмир:**

— Журналга күзәтү ясаган иптәшләр бу эшкә яхшылап әзерләнгәннәр. Ә. Юныс та, Х. Хәйри дә шактый гына файдалы фикерләр әйттеләр. Әмма кайбер иптәшләргә аларның тәнкыйте ошап җитмәде булса кирәк... Монда без сүзне чын сәнгать югарылыгыннан торып алып барырга тиешбез. Язучылар теге яки бу әсәргә карата мактавын да, тәнкыйтен дә турыдан-туры әйтергә тиешләр.

С. Хәким чыгышы миңа бик үк ошап җитмәде. Минемчә, бүген чыгыш ясаучылар телгә алынган әсәрләрнең кимчелекләрен генә түгел, яхшы якларын да әйтеп киттеләр... Мин Әхсәннең иҗаты белән танышып барам. Таланты бар аның. Әмма ул әле, минемчә, язучы буларак үзен табып җиткермәгән. Шунлыктан аның әсәрләрендә кайбер чатаклыклар була. Аның Әнисе безнең заманның судьясы булып йөри. Ә ул моңа лаеклы кеше түгел. Үзе җәмгыятькә эш күрсәтмәгән килеш, Әнисенең хөкем чыгарып йөрергә хакы юк. Шунлыктан ул, образ буларак, миндә мәхәббәт уятмый. Әхсәндә бер ялгыш тенденция бар: безнең шартларда туры юл белән генә максатка ирешеп булмый, димәкче була ул. Бу тенденцияне пьесасында да үткәрергә тырышкан иде. Дөрес, тормышта андый хәлләр дә була, аларны да күрсәтергә кирәк. Әмма аны ышандырырлык итеп, дәлилле итеп сурәтләргә кирәк.

Соңгы елларда безнең язучылар арасында автобиографик әсәрләр язу гадәткә кереп китте. Фатих Хөснинең «Минем тәрәзәләрем»ен укыдык, Ибраһим Газиның «Малайлыкта кунакта»сын укыдык, инде хәзер Гомәр Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек»ен укыйбыз. Мондый әсәрләр дә кирәк, әлбәттә. Әмма ул әсәрләрдә чор рухы тиешенчә чагылып бетми. Бу яктан Ибраһим повестен уңышлы эшләнгән дияр идем мин. Анда элекке заман рухы да, бүгенге көн рухы да яхшы сизелә...

## «КАҺАРМАН ШАГЫЙРЬ» УКРАИН ТЕЛЕНДӘ

1914 елда украин халык шагыйре Тарас Шевченконың тууына 100 ел тулу уңае белән Галимҗан Ибраһимов «Каһарман шагыйрь» исемле зур бер мәкалә язган һәм аны «Йолдыз» газетасында бастырып чыгарган иде. Бу мәкалә шушы елның 10 мартында «Литературная Украина»

газетасының 20(2506) санында украин телендә басылып чыкты. Мәкалә алдыннан, М. Хәсәнов мәкаләсеннән алып, әдип турында биографик белешмә бирелгән һәм Г. Ибраһимовның фотосы урнаштырылган.

## БАШКОРТ ӘДӘБИЯТЫ АТНАЛЫГЫ

Татар һәм башкорт халыклары арасындагы дуслык — бик борыннан килә торган күркәм сыйфат. Бу дуслык елдан-ел ныгый бара һәм аңа ике тугандаш халыкның әдәбияты һәм сәнгате аеруча зур ярдәм итә. Башкорт һәм татар халкы бер-берсенең әдипләре һәм композиторлары язган әсәрләрен яратып укыйлар һәм тыңлыйлар.

Соңгы елларда татар һәм башкорт әдәбияты атналыклары үткәрелүен дә шул дуслыкның матур бер нәтиҗәсе итеп карарга кирәк. Узган ел татар язучылары Башкортстанда үткәрелгән татар әдәбияты атналыгында катнашып, китап укучылар белән очрашулар, әдәби кичәләр үткәреп кайткан булсалар, бу елның июнь аенда башкорт язучылары республикабызның нефть районнарында үткәрелгән башкорт әдәбияты атналыгына килделәр. Атналыкта катнашкан башкорт язучылары Фәрит Исәнгулов, Кәтибә Киньябулатова, Әнгам Атнабаев, Марат Кәримов, Рафаэль Сафин Азнакай районының «Авангард» колхозы колхозчылары, Җәлил шәһәре нефтьчеләре һәм Әлмәт шәһәре пионер лагерьларында ял итүче пионерлар белән очраштылар. Аннары Әлмәт шәһәренең Техника йортында үткәрелгән зур әдәби кичәдә катнаштылар. Соңыннан кунаклар Казанга килделәр һәм Петров исемендәге паркта шәһәр хезмәт ияләре алдында чыгыш ясадылар. Аларны халык һәркайда якын итеп, үз итеп каршы алды һәм иҗатларында зур уңышлар теләп озатып калды.

## ЯШЬ ШАГЫЙРЬЛӘР ТУРНИРЫ

17 майда телестудиядә республикабыз яшь шагыйрьләренең турниры үткәрелде. Аны Татарстан язучылар союзы, ВЛКСМ өлкә комитеты, радио һәм телевидение комитеты уздырды. Ярыш өч турда үткәрелеп, анда девиз белән 16 яшь шагыйрь катнашты. И. Юзеев (председатель), Нури Арсланов, Шәүкәт Галиев, Марс Шабаев, Әминә Сафиуллина (секретарь), Индус Сирматов составындагы жюри артистлар тарафыннан укылган һәр шигырьгә балл куя бардылар. Очколар суммасы нәтиҗәсендә беренче урынны — радио һәм телевидение комитеты призын — Фәнис Яруллин, икенче урынны — ТАССР язучылар союзы призын — Гәрәй Рәхим, өченче урынны — ВЛКСМ өлкә комитеты призын — Борис Хәлимов яулап алдылар. Мөдәррис Әгъләмов һәм Тәүфыйк Камалиевларга кызыксындыру премияләре бирелде.

## УЛЬЯНОВСКИДА ТАТАР КУЛЬТУРАСЫ КӨННӘРЕ

Ульяновск шәһәрендә һәм өлкәсендә, Октябрьның 50 еллыгына һәм В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга багышлап, татар культурасы көннәре үткәрелде. Ульяновск өлкәсендә ун көн буе татар халкының җырлары, биюләре, музыкасы яңгырады, Казан студиясенең фильмнары күрсәтелде, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренең хезмәт ияләре белән дусларча очрашулары уздырылды.

Татарстан сәнгать осталары биргән 53 концертта 15 меңнән артык тамашачы булды, Совет Татарстаныннан килгән әдәбият һәм сәнгать осталары белән предприятиеләрдә, совхозларда һәм колхозларда үткәрелгән иҗади очрашуларда ун меңнән артык кеше катнашты. Казан кинематографчылары төшергән фильмнарны уннарча мең тамашачы карады. Радио буенча 9 һәм телевидение буенча 8 тапшыруда өлкәнең йөз меңләгән хезмәт ияләре Татарстанның культура казанышлары белән таныштылар.

Татар дәүләт академия театры, Татар дәүләт опера һәм балет театры, җыр һәм бию ансамбле һәм СССР халык артисты, дәүләт премиясе лауреаты, профессор Н. Рахлин җитәкчелегендәге дәүләт симфоник оркестры чыгышлары зур уңыш белән үтте.

Танылган композиторлар Әнвәр Бакиров, Хөснул Вәлиуллин, Заһит Хәбибуллин, Рөстәм Яхин, язучылардан Әмирхан Еники, Гариф Ахунов, Рөстәм Кутуй һ. б. хезмәт ияләре белән күңелле очрашулар үткәрделәр.

Республиканың халык һәм атказанган артистлары Әлфия Афзалова, Галия Гафиятуллина, Гали Җәмлиханов, Идеал Ишбүләков, Владимир Степанов, Илһам Шакиров, Венера Шәрипова, Сөләйман Юсупов, Әзәл Яһудин һәм башкаларның чыгышлары да шәһәр һәм авыл хезмәт ияләрендә бик җылы тәэсир калдырды.

Татарстан графикларының, художникларының һәм скульпторларының Художество музее залларында оештырылган күргәзмәсен меңнәрчә кеше карады. РСФСРның халык художнигы, дәүләт премиясе лауреаты Х. Якупов, Татарстанның күренекле художнигы Л. Фәттахов, РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Н. Кузнецов, ТАССРның халык художнигы, Тукай премиясе лауреаты Б. Урманче, Г. Рахманкулова һәм башкаларның иҗатлары тамашачыларда зур шатлык һәм дулкынлану уятты.

Ульяновск шәһәрендә һәм өлкәсендә Татарстан культурасы көннәрен үткәрү формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик культураның һәрьяклап үсүен һәм чәчәк атуын күрсәткән яңа дәлил булды.

## РАЙОННАРДА ӘДӘБИЯТ АТНАЛЫКЛАРЫ

Фатих Хөсни, Атилла Расих, Әмирхан Еники, Хәсән Туфан, Ләбибә Ихсанова, Илдар Юзеев, Марс Шабаев, Рәисә Ишморатова, Абдулла Сәләхетдинов һәм Касыйм Фәсәхов республикабызның Мөслим районында әдәбият атналыгы үткәреп кайттылар. Алар атналык көннәрендә Уразмәт, Күбәк, Мелләтамак, Әмикәй, Сал Мухан, Багаков, Түбән Табын, Мөслим мәктәпләрендә укучылар белән очраштылар, «Карл

Маркс», «Правда», «М. Горький», «Фрунзе», «Урал», «Кызыл Октябрь», «Вахитов», «Киров» исемендәге колхозлар клубларында колхозчылар алдында чыгышлар ясадылар. «Авыл утлары» исемле район газетасы каршындагы әдәбият түгәрәге членнары, район китапханәләре хезмәткәрләре белән очраштылар. Мөслим культура йортында үткәрелгән әдәби кичәдә катнаштылар.

* * *

Әдәби атналык республикабызның Кукмара районында да үткәрелде. Ул атналыкка барган язучылардан Мирсәй Әмир, Габдрахман Минский, Самат Шакир, Госман Бакиров, Галимжан Латыйп, Әминә Бикчәнтәева, Гөлшат Зәйнашева, Р. Батуллин, Газиз Нәбиуллин һәм Заһирә Гомәрова Кукмара культура йортында үткәрелгән әдәби кичәдә катнаштылар. Ядегәр, Олыяз, Зур Сәрдек, Әсәнбаш, Пычак авылларындагы һәм «Нырты» совхозындагы мәктәпләрдә укучылар белән очраштылар. «Алга», «Әсәнбаш», «Коммунизмга» һәм «Урал», «Восток» исемле колхоз клубларында әдәби кичәләр үткәрделәр.

## ХӘРБИ-ПАТРИОТИК ТЕМАГА ЯЗУЧЫЛАР КУРСЫ

Быел Мәскәүдә А. М. Горький исемендәге әдәбият институтында хәрби-патриотик темага язучыларның курсы оештырылган иде. Бу курска илебезнең барлык республикаларыннан кырыклап язучы чакырылды. Анда Татарстаннан язучы Самат Шакир барды. Курста укучылар өлкән язучылардан Борис Полевой, Алексей Сурков, Сергей Смирнов, Константин Симонов, драматург А. Штейн, адмирал-академик А. Берг, очучы-космонавт В. Терешкова-Николаева, Советлар Союзы Маршалы, ике тапкыр Советлар Союзы Герое И. С. Конев, Советлар Союзы Маршалы, ике тапкыр Советлар Союзы Герое В. И. Чуйков һәм башкалар белән очраштылар, аларның лекцияләрен тыңладылар.

Соңыннан курста укучылар герой шәһәр Ленинградка бардылар һәм музейларда, тарихи урыннарда булдылар. Кронштадтта булган вакытта Самат Шакир флотта хезмәт итүче якташларыбыз белән очрашты һәм аларга үзенең шигырьләрен укыды.

* * *

Балтач районы культура йортында шагыйрь Самат Шакир Балтач урта мәктәбе укучылары һәм укытучылары белән очрашу үткәрде. Ул анда Мәскәүдә А. М. Горький исемендәге әдәбият институтында кыска сроклы курста алган тәэсирләре турында сөйләде, яңа язылган шигырьләрен укыды.

* * *

Татарстан язучылар союзының җаваплы секретаре шагыйрь Зәки Нури Псков өлкәсенең Михайловское авылында үткәрелгән Бөтенсоюз Пушкин поэзиясе бәйрәмендә катнашты. Ул Опочка шәһәрендә үткәрелгән әдәби кичәдә һәм Михайловское авылында үткәрелгән поэтик митингта чыгышлар ясады.

— — □ — —

# *Журналга язылыгыз!*

**ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫБЫЗ!**

1 нче сентябрьдә 1968 ел өчен «Казан утлары» журналына язылу башлана. Шул уңай белән редакциягә укучылардан күп санлы хатлар килә. Алдагы саннарда һәм киләсе елны журнал битләрендә нинди яңа әсәрләр басылачак? «Казан утлары» журналына ничек язылырга була? Ничек итеп журналның җәмәгать тәртибендә таратучысы булырга мөмкин? Мондый сораулар, күрәсең, безгә хат язучыларны гына түгел, башка укучыларны да кызыксындыра. Шуңа күрә без ул сорауларга журнал аша җавап бирүне кирәк дип таптык.

## 1. АЛДАГЫ САННАРДА һӘМ 1968 ЕЛНЫ «КАЗАН УТЛАРЫ» БИТЛӘРЕНДӘ НИНДИ ЯҢА ӘСӘРЛӘР БАСЫЛАЧАК!

9 нчы, 10 нчы, 11 нче саннарда журнал битләрендә атаклы прозаигыбыз Атилла Расихның татар халкының данлыклы улы, беренче татар большевигы Хөсәен Ямашев турындагы яңа романы басылачак. Автор үз әсәрен Бөек Октябрь революциясенең 50 еллыгына багышлый. «Ямашев»[1] исемле бу романны укучылар зур кызыксыну белән кабул итәрләр дип ышанабыз.

Шул ук саннарда редакция яшь, әмма иseме шактый билгеле булган язучы Нурихан Фәттахның «Мөдир Саҗидә» исемле яңа повестен урнаштырырга уйлый. Повестьта сүз бүгенге авыл яшьләре турында бара, аларның хезмәте, дуслыгы, мәхәббәте, эчке кичерешләре тасвирлана.

Журналыбызның 12 санында Аяз Гыйләҗевның «Җиргә тапшырылган серләр» исемле пьесасы (бу пьеса Татар академия театры сәхнәсендә барды) һәм Әмирхан Еникинең «Җиз кыңгырау» исемле күләмле хикәясе басылачак.

1968 елны редакция Рафаил Төхфәтуллинның «Агымсу» исемле повестен (әсәрдә сүз бүгенге нефтьчеләр тормышы турында бара), Эдуард Касыймовның «Бир кулыңны, дустым» исемле яңа повестен (бу әсәр җитди әхлак проблемаларын күтәрә), Гариф Ахуновның «Хуҗалар» исемле романын («Хәзинә»нең дәвамы), Әхәт Фазылҗановның «Үз сукмагым», Нәби Дәүлинең «Мин — XX гасыр кешесе», Мәхмүт Хәсәновның «Беренче карлыгач» исемле повестьларын, Фатих Хөсни, Мирсәй Әмир, Габдрахман Минский, Гариф Галиев, Хәсән Сарьян, Альберт Хәсәнов, Роберт Батуллин һәм башка өлкән һәм яшь прозаикларыбызның хикәяләрен бастырырга планлаштыра.

Киләсе ел поэзия өлкәсендә дә шактый бай һәм кызыклы булыр дип ышанабыз. Зур шагыйребез Хәсән Туфан журналга яңа цикл шигырьләр вәгъдә итте. Талантлы шагыйрә Саҗидә Сөләйманова туган ил һәм аның кешеләре турында «Җир—су» исемле лирик поэмасын редакциягә тапшырды. Шагыйрь Әнвәр Давыдов Ленин партиясенә багышланган патетик поэмасын тәмамлый. Редакция портфелендә шулай ук Сибгат Хәким, Илдар Юзиев, Шәүкәт Галиев, Хисам Камалов, Равил Фәйзуллин һ. б. шагыйрьләрнең яңа матур шигырьләре бар.

Алдагы саннарда журнал битләрендә карт артист Локман Аитовның язмаларын (аларның бер өлеше журналыбыз битләрендә басылган иде инде, хәзер укучылар соравы буенча автор аларны дәвам итә), шагыйрь-революционер К. Акчурин турында, Түбән Кама комбинатын төзүчеләр, укытучылар һәм нефтьчеләр турында очерклар, яшь язучы Халәф Гардановның татар халкының яңа гореф-гадәтләре турындагы публицистик мәкаләсен һәм башка күп санлы материалларны укырсыз. Киләсе елда редакция халкыбызның батыр уллары, замандашларыбыз, атаклы галимнәр һәм сәнгать эшлеклеләре турындагы очерклар сериясен дәвам итәчәк.

Шулай ук журналда бүгенге әдәбият турында проблемалы мәкаләләр, яңа китапларга рецензияләр, язучыларыбызның иҗат портретлары, әдәбият тарихыннан материаллар, истәлекләр, укучылар хатлары һ. б. характердагы материаллар басылачак.

## 2. «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫНА НИЧЕК ЯЗЫЛЫРГА!

Кайбер укучылар, үзләрен журналга яздыруны сорап, редакциягә хат җибәрәләр, хәтта акча да салалар. Әмма редакция журналга яздыру белән шөгыльләнми. Сез редакция ярдәменнән башка да безнең журналга бик ансат кына языла аласыз. Аның өчен бары тик үзегез яши торган районнардагы элемтә бүлегенә кереп, «Союзпечать» дип язылган тәрәзәчек янына барырга да журналга язылырга теләвегезне әйтергә генә кирәк. «Казан утлары» журналы Бөтенсоюз газета һәм журналлар каталогына теркәлгән журнал ул һәм **аңа Советлар Союзының теләсә кайсы элемтә бүлегендә берниндн чикләүсез язылырга мөмкин.** Журналга шулай ук җәмәгать тәртибендә матбугат таратучылар аркылы да язылырга була.

Әгәр «Казан утлары»на язмау очраклары булса, тиешле чараларны күрү өчен, редакциягә хәбәр итүегезне үтенәбез.

Газета-журналларга яздыру бу ел өч айга якын, ягъни 1 сентябрьдән 20 ноябрьгә кадәр дәвам итәчәк. Әмма «Казан утлары»на язылуны әлеге срокның соңгы көннәренә калдырмаска киңәш итәбез. Югыйсә аңа вакытында языла алмавыгыз һәм, шуның нәтиҗәсендә, журналның соңга калып килүе мөмкин.

«Казан утлары»на бер елга язылу бәясе 4 сум 80 тиен, ярты елга — 2 сум 40 тиен. Журналга елның теләсә кайсы аеннан һәм теләсә нинди срокка язылырга мөмкин. Әмма аңа берьюлы бер елга язылу хәерлерәк. Шулай иткәндә журнал Сезгә ел буе даими рәвештә килеп торачак.

## 3. НИЧЕК ИТЕП «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫН ҖӘМӘГАТЬ ТӘРТИБЕНДӘ ТАРАТУЧЫ БУЛЫРГА МӨМКИН!

Редакциягә язган хатларында күп кенә укучылар «Казан утлары»н җәмәгать тәртибендә таратучы булырга теләүләрен әйтәләр һәм аның өчен нәрсәләр эшләргә кирәк дип сорыйлар. Җәмәгать тәртибендә матбугат таратучы булу бик җиңел ул: үз предприятиегездәге, колхозыгыздагы, совхозыгыздагы, уку йортыгыздагы партия оешмасына мөрәҗәгать итәргә һәм урындагы «Союзпечать» бүлеге белән элемтәгә керергә кирәк. Алар сезгә үз районыгызда, авылыгызда ничек эш итәргә кирәклеген аңлатырлар.

Башка газета-журналлар белән беррәттән, «Казан утлары» журналын таратуда да меңнәрчә җәмәгать тәртибендә матбугат таратучылар катнаша. Алар ярдәме белән соңгы 2—3 ел эчендә генә дә журналның тиражы 20 меңнән 60 меңданәгә якын артты. Узган ел, журналны таратуда актив катнашканнары өчен, редакция 200 ләп җәмәгать тәртибендә матбугат таратучыны бәяле һәм истәлекле бүләкләр (фотоаппаратлар, сәгатьләр, музыкаль инструментлар һ. б.) белән бүләкләде. Күп кенә җәмәгать тәртибендә журнал таратучыларга Татарстан язучылар союзы идарәсе тарафыннан рәхмәт белдерелде һәм яраткан язучыларының автографлары белән китаплар җибәрелде.

«Казан утлары» редакциясе бу ел да, узган елгы кебек үк, журналга яздыру компаниясе вакытында журналны укучылар актив катнашырлар дип ышана һәм шул эштә аларга уңышлар тели.

**«КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕ.**

Җаваплы редакторы **Рафаэль Мостафин.**

Редколлегия: **Һәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев.**

Производствога бирелде 15/VI-1967 ел. Басарга кул куелды 24/VII-1967 ел. ПФ 03197. Кәгазь форматы $70\times108\,{}^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 56246 экз. Заказ М-1039. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1967 ел.

Бәясе 40 тиен
Цена коп.

*Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал*

# КАЗАН УТЛАРЫ

(ОГНИ КАЗАНИ)

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

Индекс 73210